ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Р.Ф. Харрасова**

# ӘДӘБИ РЕДАКЦИЯЛӘҮ НИГЕЗЛӘРЕ

Казан
2018

**УДК 808.2**
**ББК 81**
**Х 20**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы **А.Г. Әхмәдуллин,**
филология фәннәре кандидатлары
**И.Г. Гомәрев, З.Г. Мөхәммәтшин**

**Харрасова Р.Ф.**
**Х 20** **Әдәби редакцияләү нигезләре:** студентлар һәм аспирантлар өчен уку әсбабы / Р.Ф. Харрасова. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 316 б.
ISBN 978-5-93091-273-9

Китап әдәби редакцияләү өлкәсендәге фәнни эзләнүләрне, нәшрият хезмәткәренең гамәли эш методологиясен һәм редакцияләүнең универсаль кануннарын чагылдыра, басмага хәзерләнүче текстны камилләштерү этаплары турында сөйли. Ул мөгаллимнәргә, журналистларга, мөхәррирләргә, филология юнәлешендә белем алучы студентларга һәм аспирантларга тәкъдим ителә.

**УДК 808.2**
**ББК 81**

**ISBN 978-5-93091-273-9**

© Харрасова Р.Ф., 2018;
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2018

## КЕРЕШ

Әдәби редакцияләү – текст камилләштерү теориясен һәм методикасын эшләүче мөстәкыйль филологик дисциплина. Һәм фәнни, һәм нәфис, һәм публицистик материалларның сәнгатьчә сыйфаты, аларны дөньяга чыгаручы хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгы көннән-көн зуррак әһәмияткә ия була барганда, аны укыту да үтә мөһимләшә. Әдәби редакцияләү предметы нәшриятларның, массакүләм мәгълүмат чараларының яшь хезмәткәрләренә каләм почеркын булдырырга, шомартырга һәм чыгачак материалны хәзерләү барышында теләгән нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Булачак галимнәрне исә әдәби редакцияләү гамәлияте фәнни хезмәтләр язу һәм китап хәзерләү культурасына күнектерәчәк.

Татар теленең функциональ сферасы тарайганда, аны кулланучылар саны кимегәндә, мәктәпләрдә ана телне уку-укыту ихтыяри дип куелганда һәм уку-укыту планнары аңа зыянга үзгәртелгәндә, халык сөйләмендәге җитешсезлекләр күзгә күренеп арта, хәтта вакытлы матбугат, радио-телевидение хезмәткәрләре дә үз чыгышларына игътибарсызга әйләнә, ә редакторлар, авторларга файда итәсе урынга, үзләре дә текстларга хаталар өсти башлый. Без бүген шул күренешләрнең шаһите булып яшибез. Шушы шартларда тирән белемле белгечләр хәзерләү, татар теленең язмышына битараф булмаган мөгаллимнәр һәм яшь галимнәр тәрбияләү өлкән буын филологларының изге бурычына әйләнә.

Бу китапта әдәби редакцияләү методларына, алымнарына телнең хәзерге үсеше һәм филологик фәннәрнең Яңа заман биеклекләреннән күз ташлана; автор текстының тәүге һәм эшкәртелү этапларындагы вариантларына бәйле проблемалар

карала. Әлбәттә, дәреслекне алга таба тагын да киңәйтергә – ул чагылдырган проблемаларны арттырырга, анда моңарчы ачылган темаларны тирәнәйтергә һәм бай кушымта өстәргә мөмкин. Бүген тәкъдим ителгән хезмәт моңа кадәр КФУда, ТӘһСИдә төзелгән уку-укыту программаларындагы темалар кысасыннан чыкмый һәм әлеге оешмаларның эш планнарында күрсәтелгән сәгатьләрне исәпкә ала. Аны язу барышында тел белеме проблемаларын күтәргән русча һәм татарча күпсанлы хезмәтләрдән, шулай ук редакцияләүгә, текст төзелешенә караган дәреслекләрдән файдаланылды. Алар уку әсбабының Әдәбият исемлегендә китерелә. Шулай да бу урында И.Б. Голубның «Конспект лекций по литературному редактированию», Н.С. Валгинаның «Теория текста», К.М. Накорякованың «Литературное редактирование. Общая методика работы над текстом», В.И. Максимов редакциясендә чыккан «Стилистика и литературное редактирование», С.Г. Антонова, В.И. Васильев, И.А. Жарков һ.б. хәзерләгән «Редакторская подготовка изданий», Ф.С. Сафиуллинаның «Татар телендә сүз тәртибе», И. Низамовның «Татарча әдәби редакцияләү» кулланмасын аерып күрсәтергә кирәк. Уку әсбабында әдәби мөхәррирлеккә хәзерләнүче студентлар белән берлектә башкарылган «Яшь редактор киңәшләре», «Татар матбугаты: бүген һәм иртәгә», «Остаз кадерен оста белер» һ.б. җыентыклардагы фикер-мисаллар да чагылыш тапты.

«Әдәби редакцияләү нигезләре» каләм иясе тәкъдим иткән текстны матбагага хәзерләүнең барлык баскычларын ача, урыны белән хәтта тибын, атрибуциясен күрсәтү кебек эшләрне дә үз эченә ала, чөнки хәзерге чорда редактор китап материалын урнаштыру осталыгына ия булырга, ярдәмче аппаратны формалаштыра һәм чыгыш мәгълүматларын күрсәтә белергә тиеш дип карала. Бигрәк тә кечкенә, азсанлы хезмәткәрләрдән оешкан шәхси нәшриятларда белгечләрдән универсаль күнекмәләр таләп ителә.

Яңа технологияләрнең барлыкка килүе редактор һөнәренә яңача якын килергә мәҗбүр итә. Шәхси компьютерлар, башка

төр өстәл һәм кесә техникасы, онлайн аралашуның интернет, кәрәзле бәйләнеш тудырган чаралары нәшрият эшчәнлегенең бөтен системасын үзгәртә, автор һәм редактор хезмәтен тизләтә.

«Кулъязма»ларның электрон вариантлары барлыкка килгән, әдәби хезмәткәрләрнең һөнәри сәләтен куллану өлкәләре арткан, әйтик, интернет-сайтларны коррекцияләү кебек гамәлләр барлыкка килгән чорда яшибез, һәм бу күренешләр шулай ук алдыбызга үз таләпләрен куя.

Бүген кулыгызга алган китап авторның Казан дәүләт (соңрак: федераль) университетында (КДУ, КФУ) унъеллык укыту тәҗрибәсенә, яңа гасырга аяк баскач башкарылган, апробация узган, басмага тәкъдим ителгән һәм төрле электрон версияләрдә яшәгән кулъязмаларына, аның тарафыннан студентларга һәм аспирантларга атап хәзерләнгән белем бирү программаларына нигезләнә.

## Беренче бүлек

## ӘДӘБИ РЕДАКЦИЯЛӘҮ ПРЕДМЕТЫ

**Фәнни дисциплина идеясе.** XX–XXI гасыр чигендә әдәби редакцияләүне филологик факультетларда белем бирү программаларына кертү заман үзгәрешләре, мәгарифтәге реформалар, массакүләм мәгълүмат чараларының үсеше, җәмгыятьнең универсаль күнекмәләргә, нык камилләшкән һөнәри сыйфатларга ия, тиз аралашучан, авторлар белән диалог алып барырга сәләтле һөнәр ияләренә ихтыяҗы белән аңлатыла. Үзгәртеп кору елларында хәтта галим һәм мөгаллимнәр өчен дә өр-яңа, алар тарафыннан моңарчы хәзерләнмәгән белгечлекләр ачылды, югары уку йортларында укыту эшен оештыруда үзгәрешләр барлыкка килде, белем бирүнең кайбер методлары алмашынды, һәм бу күренеш әле һаман да дәвам итә.

Әдәби редакцияләү концепциясе нигезенә текстка төзәтмәләр кертү теориясен һәм телне, аның берәмлекләрен гамәли дөрес файдалану кирәклеген аңлау идеясе салынган. Ул стилистиканың гомумкабул ителгән нормаларыннан, әдәби әсәр, публицистик, фәнни-популяр һәм башка төр материалларның формалашу кануннарыннан читләшмәүне күздә тота.

Дөрес һәм матур сөйләмгә ия булу каләм ияләренә – китаплар чыгарганда, вакытлы матбугатка материаллар хәзерләгәндә, офис хезмәткәрләренә – документлаштыру белән шөгыльләнгәндә, эшлекле язышу алып барганда, укытучыларга – мәктәп балаларына белем биргәндә бик кирәк. Ул иҗтимагый бәйләнешләр, туризм, мәдәни хезмәттәшлек сфераларында да, эчке сәясәттә дә, илара мөнәсәбәтләрне корганда да – кыскасы, һәркайда мөһим.

Мөхәррирлек күнекмәләре чит текстлар белән һөнәри дәрәҗәдә эш итүчеләрнең хезмәтен генә яхшыртып калмый, һәркемгә фикерләү культурасын үзләштерергә ярдәм итә, шәхси карашларны язма рәвештә дөрес һәм логик формалаштырырга өйрәтә. Боларның барысын да күздә тотып, узган гасырның туксанынчы еллары уртасыннан «Әдәби редакцияләү» курсын күп кенә югары уку йортларында филология факультетларының уку-укыту планнарына керттеләр; элек текст белән эшләү күнекмәләренә журналистлар гына өйрәтелсә, яңа гасырга аяк баскач, әлеге фән булачак педагогларга да, нәшрият хезмәткәрләренә дә укытыла башлады. Соңгы елларда ул ТӘһСИнең аспирантура бүлеге кабул иткән уку планнарында да чагылыш таба.

Билгеле, әдәби редакцияләү белән махсус белгечләр генә түгел, хәтта һәр кеше диярлек гомер буе шөгыльләнә. Безгә дус-ишләребезгә, туганнарыбызга ошарлык, отышлы һәм урынлы яңгыраган котлау сүзләре уйлап табарга, төрле урыннарда кешене җәлеп итәрлек чыгышлар ясарга туры килә. Мәктәп укучылары иншалар, докладлар, рефератлар хәзерли. Бу вакытта аларны кат-кат төзәтә, камилләштерә. Әти-әниләр исә сабыйларының өйдә башкарган хезмәтләренә редактор сыйфатында күзәтчелек итә. Хатларны, көндәлек дәфтәрләрне, контроль эшләрне без һәрвакыт, башкарып чыкканнан соң, тагын бер кат күздән кичерәбез.

Соңгы вакытта халыкның телдән аралашуы кими төште, ә менә язма рәвештәгесе көннән-көн тормышыбызда киңрәк урын ала. Интернет-сайтлардагы кимчелекле һәм тупас яңгыраган текстлар, телефон «смс»ларындагы хаталарның күплеге, авторларның, сүзләр язылышын белмәгәндә яисә язарга иренгәндә, аларны гомумкабул ителгән шартлы билгеләр, үзләре уйлап тапкан тамгалар белән алмаштыруы заман кешесенә аралашу культурасының да, белемнең дә җитмәвен күрсәтеп тора. Татарча сөйләшкәндә яисә иҗат иткәндә генә түгел, хәтта чит телләрдә хаталы язу да кешене бизәми, шуңа

да карамастан сөйләмгә хас җитешсезлекләр көннән-көн арта гына бара.

Әле бик борынгы заманнарда ук, кешегә хат юллыйсы булса да, бигрәк тә гариза, үтенеч кәгазьләре язганда да, авылларда иң «грамоталы абзый»га мөрәҗәгать иткәннәр. Андый рольне күпмедер русчасы да булган солдатлар, рухани-мөгаллимнәр башкарган. Совет чорында да югары белемле укытучыларга авылдашлары һәрвакыт хат яздырырга килә иде. Алар чит кешеләр хәзерләгән документларны, хаталарын төзәтеп, тиешле урыннарга юллау белән дә шөгыльләнде.

Хәтта танылган галим һәм әдип башкарган язмаларны камилләштерүгә дә белгечләрне тарту шуның белән аңлатыла: кеше үз текстларындагы хаталарны башкаларныкына караганда авырданрак тота, махсус тикшергәндә дә, игътибар белән укый алмый, хәтеренә нык сеңгән, күзе күнеккән җөмләләрне өстән-өстән генә карап уза. Икенче яктан, авторга, йөгерек укудан качу һәм яңа гына язган текстын яхшылап редакцияләү өчен, кырыйга куеп торырга, «онытырга», вакытлар узгач, кабат кулга алырга һәм чит күз белән карарга кирәк. Бүгенге тизләнешле заманда бу мөмкин хәл түгел. Еш кына китап чыгу ниндидер вакытлар кысасына куела. Өченчедән, нәшрият теге яки бу хезмәтне дөньяга, укучы хөкеменә чыгарырга алынган икән, ул, аның форматы һәм бизәлеше өчен генә түгел, һәм эчтәлеге, һәм формасы өчен дә җаваплы.

Милли тел камиллеге, матурлыгы турында онытмау – һәр кешенең бурычы. Ике-өч кеше арасында барган аралашудагы җитешсезлекләргә күз йомганда да, халыкта сөйләм культурасын формалаштырырга тиеш белгечләрнең гади кешегә караганда хаталырак сөйләшүенә битараф калырга ярамый. Беркемгә дә сер түгел: сәхнәләрдән, радио-телеэфирлардан инде кимчелексез чыгышларны ишетү мөмкин булмаган бер хәлгә әйләнде. Матур һәм бөтен, күңелгә ятышлы сөйләмне авылда яшәгән бик өлкән абый-апалар белән аралашканда гына тыңлыйсың.

Хәзерге вакытта күпләребезне шушы күренешләр аеруча борчый кебек:

• радио-телевидение хезмәткәрләре авызыннан яңгыраган җөмләләрнең синтаксик конструкциясенә хас җитешсезлекләр;

• төрле тип, хәтта әдәби тапшыру алып баручыларның да сөйләмнәре камил формалаштырылмау һәм аларда җөмләара бәйләнешләрнең юклыгы;

• эфир хезмәткәрләренең тиешле һәм кирәкле дәрәҗәдәге сүзлек байлыгына ия булмаулары, төшенчәләргә еш кына дөрес мәгънә салмаулары, чит, беренче чиратта, русча сүзләрдән кирәгеннән артык, хәтта татарчага алмаштыру мөмкин булганда да файдаланулары.

Алай гына да түгел, кайвакыт бигрәк тә телеэкраннардан чыгыш ясаган җырчы артистларыбыз, үзләренең авылда туып үскәннәрен «яшерергә теләгәндәй» яисә «истән чыгаргандай», гап-гади татар сүзләрен дә «оныта», хәтерләренә китереп утыргандай кылана я, һич кыенсынмыйча, сөйләмнәренә сүз арты сүз русча кыстыра.

Редакторларга, тамаша алып баручыларга килгәндә, аларның диалог өчен сайланган җөмләләре матур яңгырамый һәм еш кына теге яки бу темадан белемнәренең үтә чиклелеген күрсәтеп тора, ә сораулары җавап бирергә тиешле кешегә аңлаешсыз булып кала. Интервьюерларның бер үк сүзләрне даими кабатлавы, әңгәмәдән әңгәмәгә күчкән калып сораулары, нәтиҗәләре, мәгънәсез һәм кирәксез «чөй җөмлә»ләре, аралашу барышында отышлы төшенчә таба алмыйча утырулары, фикерсезлекләре турында әйтәсе дә юк. Текст сыйфатында алдан күзалланмаган «сөйләшү»ләрдә хәл тагын да катлаулырак. Ә бит журналистларның, дикторларның, редакторларның сөйләме башкаларга үрнәк булырга тиеш!

Газета-журналларыбызда да, чыккан китапларда да хаталар көннән-көн арта гына. Бу җитешсезлекләр махсус

хәзерләнгән белгечләрнең азлыгы, илдә гомумән белем дәрәҗәсенең төшүе, хезмәткәрләрнең үз эшләренә җавапсыз каравы белән дә аңлатыла. Әнә шул ямьсез күренешләрне бетерү, телгә хөрмәтле мөнәсәбәт тәрбияләү һәм, шуның белән бергә, милләтебезнең гомерен дә озынайту өчен, татар телендә иркен һәм хатасыз язучы филологларны, аларның хезмәтләрен тагын да ныграк камилләштерүче редакторларны хәзерләү бүген үтә актуаль дип уйларга кирәк.

Мөхәррир кульязманы интуитив, үзенчә аңларга сәләтле булырга; стереотип фикерләү чикләреннән чыгарга; яңалыкны кабул итә, тәртипкә китерә белергә; күпмедер дәрәҗәдә иҗади потенциалга ия булырга һәм телнең ныгыган традицияләрен, матбага эшенең электән килгән тәртипләрен дә онытмаска тиеш. Ул, текст камиллеге өчен җаваплылыкны үз өстенә бөтен тулылыгы белән алганда, хезмәтенең мөһимлеген аңлап эш йөрткәндә, аны камилләштерү юллары турында уйланганда, автор белән берлектә, нәшер итү технологиясенә, гомуммилли мәдәнияткә, аның әдәбиятына, теленә күпмедер өлеш кертмичә калмый.

Автор текстларындагы җитешсезлекләрнең төп гаебе, хәлбуки чит кеше язмасы белән генә эш итсә дә, редакторга төшә. Беренчедән, мөхәррир басма сүз өчен турыдан-туры җаваплы. Әгәр, артык зур үзгәрешләр кертмичә генә, текстны камилләштереп бетерү мөмкин түгел икән, ул аны авторга кире кайтарырга тиеш дип карала; ә инде хаталар беренче карашка ук күп булып күренсә, кульязма редакциягә кабул ителмәскә дә мөмкин. Икенчедән, алда билгеләп узганыбызча, теләсә кайсы язма авторына шәхси хатасын, бигрәк тә кат-кат укылган текстларындагы җитешсезлекләрне табып бетерү – шактый кыен эш, хәтта реаль түгел, шуның өчен мөхәррир һөнәре уйлап табылган да. Әйткәнебезчә, әсәр иясе редакцияләү максатыннан текстны кат-кат укыса, язганына күзе тагын да ныграк ияләшә – ул тексттагы бушлыкларны, әйтелеп бетмәгән сүзләрне еш кына «тутыра», төшеп калган

хәрефләрне күрми башлый, дөрес куелмаган тыныш билгеләрен тотмый, шунлыктан әйтергә теләгән фикерен бар кеше үзе теләгәнчә аңларлык калыплаштырдым дип белә. Әле бит редактор өстеннән дә күзәтчеләр кирәк. Белемле корректорлар кайвакыт хәреф хаталарын гына түгел, мөхәррир күрмичә калдырган мәгънә җитешсезлекләрен дә тотып ала һәм бу хакта аңа хәбәр итә.

Студентлар яисә аспирантлар, үзләре иҗат иткән тексттагы хаталарга төртеп күрсәткәндә, еш кына, мин анда шулай дип әйттем, аңлатыйммы, киңәйтеп сөйләп күрсәтимме, дип сорыйлар. Әңгәмә барышында фикереңне аңлату мөмкинлегең бар, ә менә басылып чыккан текстыңны ил буйлап таралган публикага шәрехләп йөри алмыйсың. Әлбәттә, бик акыллы кеше синең ничек һәм нәрсә җиткерергә теләгәнеңне фаразлый алыр, әмма, шуны да әйтеп бирә алмаган, дип уйлар. Күпчелек укучы исә бары текстта язылганны гына аңлаячак. Димәк, публика текстыңны тиешенчә кабул итми икән, сәбәбен аның хәзерлексезлегенә генә кайтарып калдырмаска, гаепне иң элек үзеңнән эзләргә кирәк.

Текст башыңда йөргәндә генә, караламада гына – синеке, акламага күчкәч, «ташка басылгач» – укучыныкы. Теләсәң дә, терсәгеңне тешләсәң дә, берни үзгәртә алмыйсың. Кәгазь битләрендә чагында һич кимчелексез тоелган язма, басылып чыкканнан соң, китабыңны ачуга ук, бөтен җитешсезлекләрен калкытып куя. Кулыгыздагы хезмәт авторының кылынган хаталары белән күңелне газаплаган узган гомер, онытылырга тиешле мәхәббәт темасына язылган әсәре бар. Аның тышкы, яшерелмәгән мәгънәсе кәгазьдәге хаталарның да җуелмавын, үзеңнең дә, кешенең дә күзенә ташлануын да сөйли:

*– Син мине яратмыйсың, – дип,*
*Туйдым битәрләвеңнән.*
*Һәм сине аттым сызып ук*
*Күңелем дәфтәреннән.*

*Сызылса да (ялгышыпмы?)*
*Язылган сүз дәфтәргә,*
*Шунда ук күзгә ташлана*
*Битен ачкан мәлләрдә.*

Әйе, хатаңны кешедән яшерү өчен, кырасың, бозасың, бетерәсең, шуңа күрә һәркемнең күзе бигрәк тә шул урынга – пычранган, тишелгән, буялган юлларга төшә. Димәк, тормышыңны, үзара мөнәсәбәтләреңне баштан ук матур корырга кирәк булган кебек, текстларның тәүге вариантын ук камил язарга омтылу зарур.

Күпләргә таныш хәл: китабың чыкканнан соң, кайбер битләрендә хаталарга юлыккач, аптырап каласың. Мин боларны гына белмәслекмени (?!), дисең. Күңелеңне, их, беразга гына нигә читкә куеп тормадым, эшемне игътибарлырак, белемлерәк редакторга тапшырсалар була иде бит, ни өчен үзем җентекләп укымадым инде... кебегрәк үкенеч хисләре биләп ала. Әнә шушы хәлгә калмас өчен, грамоталы, үз җаваплылыгын җитәрлек тоя торган редакторлар хәзерләү кирәк тә. Һәм шуны онытма, дустым: китапка гына түгел, халыкка ирешергә тиешле теләсә кайсы текстка чит кеше күз төшереп алса яхшы.

Бөтенләй корректорсыз һәм редакторсыз эшләгән нәшриятлар да бар бит әле. Үзебез дә, зур чыгымнардан качып, эшләребезне ничек язган булсак, шул килеш бастырабыз. Иң хаталы китаплар бигрәк тә «беркөнлек» шәхси матбагалардан чыга. Кайберләрендә, хәтта редакторлар булса да, аның эше өчен язма иясеннән акча алсалар да, җаваплылыктан качып, китапның чыгыш мәгълүматына: «Редактор һәм корректор – автор үзе», – дип язып куярга мөмкиннәр. Аталган күренешнең төп сәбәбе ачык: шәхси нәшриятларда күп очракта руслар яисә русча белем алган, кайвакыт филолог булмаган хезмәткәрләр утыра. Алар милли әдәбиятны чыгарырга бик ашкынып тормый, бассалар да, авторларга татарча укучы корректорлары юклык хакында искәртә һәм,

шуның белән, җаваплылыкны үз өсләреннән төшерә. Бу төр гамәлият ерак үткәндә калсын иде инде, дигән теләк бар. Дөрес, аерым шәхси нәшриятлар, бигрәк тә соңгы елларда кибетләргә күпсанлы продукция тәкъдим иткән «Ак бүре», «Мәгариф – Вакыт» нәкъ менә китапларның сыйфатына игътибарын арттыра гына бара.

Мөхәррирләр штаты тотмаган, бары тик тиражлау белән генә шөгыльләнгән нәшриятлар, хәтта типографияләр аша гына китап чыгаручылар да юк түгел. Бу очракта хезмәтнең сыйфаты хакында сөйләшеп тору да урынсыз. Кыскасы, филология факультетларына әдәби редакцияләү курсын кертү – гаять тә кирәкле һәм вакытлы бер гамәлдер.

**«Әдәби редакцияләү» фәненең дөньяга килүе һәм үсеше.** Әдәби редакцияләү, белем бирү курсы сыйфатында, безнең илебездә узган гасырларда ук барлыкка килә. Аны, беренчеләрдән булып, Мәскәү полиграфия институтында, ә аннан соң Мәскәү дәүләт университетында укыта башлыйлар. МПИның редакцияләү кафедрасы мөдире К.И. Былинский 1948 елда «Основы литературного редактирования и правки газетных материалов» дип исемләнгән ярдәмлек яза. 1957 елда, Д.Э. Розенталь белән берлектә, «Литературное редактирование» дәреслеген бастырып чыгара. Әлеге хезмәтләрдә курсның предметы һәм төп бүлекләре ачык билгеләнә.

Гуманитар дисциплина дип күзалланган редакцияләү илленче елларда гамәли характерда була, чөнки аның теориясен уйлап табуны заман алып килгән үзгәрешләр, беренче чиратта, Совет илендә нәшрият эшчәнлегенең киң җәелүе, ә моның өчен махсус хәзерләнгән белгечләрнең җитмәве таләп итә. Басма сүзне зур идеологик корал дип аңлаган җитәкчелек ил үсешендәге бу төр юнәлешне һич кенә дә күздән ычкындыра алмый. Редакцияләүдә формаль рәвештә өч аспектны аерып чыгару да идеологик максат-бурычларга барып тоташа. Болар: сәяси, фәнни һәм әдәби яссылыклар. Текстка сәяси ноктадан якын килү бу чорда һәрвакыт алгы

планга куела. Әдәби редакцияләү эше дә, заманына хас булганча, катгый канунияте ноктасыннан, эчтәлек һәм форма берлеген күздә тотып оештырыла. Кульязма эчтәлеген тиешле дәрәҗәгә китерү текстны сәяси һәм фәнни редакцияләү дип аталса, форма ноктасыннан камилләштерү әдәби редакцияләү дип карала.

Текстка өч аспекттан якын килү булачак мөхәррирләргә укытылырга тиешле башка фәннәрне ачыклауга да булыша. Редакторлар, журналистлар, сәяси һәм фәнни хәзерлек узу максатыннан – социаль-икътисади, ә текстны хатасыз итү өчен, филологик дисциплиналарны узарга тиеш дип санала.

Вакытлы матбугат һәм радио-телевидение челтәре киңәю, тапшырулар саны арту, төрлеләнү, халыкның әдәбиятка ихтыяҗы кискен үсү шартларында эрудицияле, язу һәм редакцияләү осталыгына ия белгечләр хәзерләү проблемасын чишәргә, фәннең үзен теоретик планда да тирән эшләргә кирәк була. Алтмышынчы-җитмешенче елларда әдәбият һәм тел өлкәләренең төрле юнәлешләрдә гыйльми үсеше «Әдәби редакцияләү» предметы положениеләрен тагын да ныграк камилләштерүгә булышлык итә. Әлеге дисциплинаны алга таба теоретик планда үстерүгә рус галимнәре А.В. Абрамович, Э.А. Лазаревич, А.Э. Мильчин, Н.М. Сикорский, К.М. Накорякова, Н.С. Валгина, И.Б. Голуб һәм башкалар зур өлеш кертә.

Узган гасырның икенче яртысында нәшрият эшчәнлегендә стилистикага зур әһәмият бирелгән. Шулай да әдәби редакцияләүне әле бер, әле икенче яссылыкта башкару алгарак чыккан. Әмма, текст төрләренә, аларны халыкка җиткерү юлларына бәйле рәвештә фикер йөрткәндә, галимнәрнең төп игътибарны күпчелек очракта вакытлы матбугатта басылган язмаларны эшләүгә юнәлтүен билгеләргә кирәк. Бу, мөгаен, әдәби редакцияләү хезмәтенә ул заманнарда журналистика факультетларында, полиграфия институтларында гына хәзерләү белән дә бәйледер.

Вакытлы матбугат материалларын камилләштерүне күздә тотып башкарылган хезмәтләргә мисал итеп, төрле еллардан К.И. Былинскийның «Литературное редактирование газеты» (1953); А.Э. Мильчинның «Методика редактирования текста» (1980); Я.С. Воскобойников һәм В.К. Юрьевның «Журналист и информация: Профессиональный опыт западной прессы» (1993); К.М. Накорякованың «Редактирование материалов массовой информации» (1994) китапларын китерергә булыр иде.

Сиксәненче еллар радио-телевидение материалларын эшкәртү проблемасына да игътибар арту белән аерылып тора. Бу юнәлештә бигрәк тә М.В. Зарва актив эшли. Аның «Некоторые особенности языка радио как вида массовой коммуникации // Язык и стиль средств массовой информации и пропаганды. Печать, радио, телевидение, документальное кино (1980); «Слово в эфире» (1971) хезмәтләре дөнья күрә.

Туксанынчы елларда – компьютерлардан файдалану, ә икемеңенче елларда электрон аралашу гомумкүренешкә әйләнә башлагач, медиаматериалларны хәзерләү тизләнгәч, аңа мөнәсәбәтле эш тәртипләре үзгәргәч, вакытлы матбугат һәм интернет-сайтлар өчен текстларны яңа заман шартларында редакцияләү проблемасын чишү көн кадагына куела (*Горбачевский М.В., Караулов Ю.Н., Шаклеин В.М.* Не говори шершавым языком. О нарушениях норм литературной речи в электронных и печатных СМИ, 2000; *Добросклонская Т.Г.* Вопросы изучения медиатекстов, 2000).

XX гасырның соңгы чирегендә әдәби эшкәртү юнәлешендәге киң планлы гыйльми эзләнүләр инде күпсанлы югары уку йортларында радио-телевидение, вакытлы матбугат өчен махсус белгечләр хәзерләнү, журналистика факультетларының мөстәкыйльләшүе, аларда белем бирүнең тирәнәюе, шул максаттан төрле махсус дисциплиналарның төп предмет буларак укытыла башлавы, редакцияләү гамәлен теоретик нигезгә салу кирәклеге һәм шул юнәлештә эзләнүче галимнәр саны арту белән дә аңлатыла.

Әдәби редакцияләү курсының ике гасыр чигендәге үсеше бигрәк тә теоретик һәм гамәли стилистиканы өйрәнү, үстерү белән турыдан-туры бәйләнгән. Кулыгыздагы дәреслек авторы – ике фәнне «Функциональ стилистика һәм әдәби редакцияләү» курсына берләштерү ягында. Русларда шушы юнәлештә эшләү XX гасыр ахырында көчәеп китте. Әйтик, Л.В. Рахманиновның «Стилистика и литературное редактирование» (1997), В.И. Максимов редакциясендә басылып чыккан «Стилистика һәм литературное редактирование» (2004) китаплары бу төр специфик эшчәнлек нәтиҗәсе булып тора.

Татар телендә текст стилистикасын һәм әдәби төзәтү өлкәсендәге барлык белемнәрне гомумиләштереп чагылдырган бер генә зур хезмәт тә әлегәчә басылмаган. Бу китапның тагын да күләмлерәк, үзгәрәк эчтәлектәге тәүге кульязмасы хәзерләнгән икемеңенче еллар уртасында «Әдәби редакцияләү» дәреслекләре гомумән юк иде. Милли филологиябездә төрле тип әсәрләрне камилләштерүнең гомумкабул ителгән һәм тирән эшләнгән методикалары булмаса да, бу юнәлештәге яисә текст стилистикасы проблемаларына кагылышлы, ана телебезне куллану үзенчәлекләрен яктырткан уңышлы хезмәтләр алай да бар. Мисал итеп, В.Х. Хаковның «Татар теле стилистикасына кереш» (1963), С.М. Ибраһимов һәм Ф.С. Сафиуллинаның «Практик стилистика» (1978), Ф.С. Сафиуллинаның «Текст төзелеше» (1993), И.М. Низамовның «Уем тел очында...» (1995), «Ярдәмең берлән синең» (2008), «Татарча әдәби редакцияләү» (2012) китапларын китерергә мөмкин.

Бүгенге көндә журналистларның иҗади эшчәнлеген, редакцияләрдәге хезмәтен оештыруны чагылдырган кече күләмле татарча китаплар, рисаләләр инде шактый. Белгәнебезчә, һәр журналист – һичьюгы үз хезмәтенең мөхәррире, һәм ул текст камилләштерү нигезләреннән яхшы хәбәрдар булырга тиеш. Редакторларның, журналистларның шәхси басмалар яисә басмаханәләр ачуын һәм төрле нәшриятларда алып

барган оештыру эшчәнлеген, китап басудагы проблемаларны чишүдә актив катнашуын күздә тотып, Казан дәүләт университетында милли нәшриятлар өчен универсаль күнекмәләргә ия хезмәткәрләр хәзерләү башланган иде. КДУ галимәсе Р.Ф. Харрасова тарафыннан белгечлек юнәлешендәге махсус фәннәрнең программалары («Иҗат лабораториясе», «Әдәби тәнкыйть теориясе», «Әдәби редакцияләү» һ.б.) төзелде һәм икемеңенче елларда бастырып та чыгарылды. Шушы ук чорда Казан дәүләт гуманитар-педагогика университеты доценты М.Х. Вәлиев тә «Нәшрият эше һәм редактор хезмәте» дигән белгечлеккә укучы студентлар өчен махсус курс программасы төзеде һәм алга таба, авторның укыту эшчәнлеге нәтиҗәсендә, 2006 елда «Милли нәшрият һәм китап редакторы: югары уку йортлары өчен уку әсбабы» дөнья күрде. Галим анда нәшрият эшчәнлеген оештыруның хокукый нигезләрен һәм башка аспектларын, билгеле бер күләмдә мөхәррирлекнең иҗади-фәнни нигезләрен дә яктыртты.

КДУның журналистика факультетында әдәби редакцияләү фәне күптәннән укытылса да, татар филологиясе студентлары аны үзләштерүгә 2007 елдан гына кереште. Әлеге дисциплинаның уку-укыту планына кертелүе яңа һөнәрләргә өйрәтә башлау белән бәйле иде – моны милли массакүләм матбугат челтәре өчен бик тә кирәкле әдәби редакторлар, тәрҗемәчеләр, әдәби тәнкыйть буенча белгечләр хәзерләү зарурлыгы таләп итте. Кызганыч ки, КДУ КФУга әверелгәч, татар филологиясе (хәзерге вакытта: татар филологиясе һәм мәдәнияте) бүлегендә сәләтле студентлар арасыннан «әдәби редактор һәм тәнкыйтьче» төркемнәрен туплау туктатылды. Аларга атап, тирәннән эшләнгән, әмма азкүләмле сәгатьләрдә башка группаларда да укытылган бик мөһим курслар белем бирү планнарыннан киселде. Дөрес, кайберләре, укытучылык янәшәсендә, журналист та булырга хәзерләнүчеләр өчен калдырылды.

**Русча текстларны әдәби редакцияләү тарихыннан**. Редакцияләү дигәндә, без аерым текстларны төрле

максатлардан камилләштерүне дә, ниндидер хезмәтләрне китап сыйфатында таратуга хәзерләүне дә күздә тотабыз. Димәк, кулъязма китап та, басмасы да, аерым форматта дөнья күргәнче, коррекцияләү чорын уза. Кулъязманы бастыруга хәзерләүнең ныгыган тәртибе, беренче чиратта, дини китаплар тиражлау традициясенә барып тоташа. Бүгенге көнгә килеп җиткән «Остромирово Евангелие» (1056–1057 еллар) русларда борынгы чорларда ук югары китап культурасы булганлыгын сөйли. Мәсәлән, дьякон Григорий әлеге Евангелиене новгородлы посадник Остромир өчен пергаментта төгәл, авыштырмыйча, геометрик хәрефләр белән ачык буяулар кулланып башкарган.

Кулдан башкарылган китаплар бигрәк тә язма әдәбиятның башлангыч чорында күп хәзерләнмәгән, аларга, нигездә, югары катлам кешеләре һәм руханилар гына ия булган. Теге яки бу урында гамәли кулланылыш өчен мәҗбүри хезмәтләр дә билгеле. Әйтик, төгәл язылуы һәм чиркәүләрдә кулланылуы мәҗбүри дини әдәбиятка «Евангелие», «Апостол», «Псалтырь», «Требник», «Общая минея», «Триодь постная» и «Триодь цветная», «Служебник» кергән. Кызганыч ки, төрле сәбәпләр аркасында, бик борынгы дөньяви китаплар аз сакланган, хәтта «Слова о полку Игореве»ның «списогы» да бүгенге көнгә килеп җитмәгән.

Византиялеләр язган хезмәтләрдән тәрҗемә ителгән тәүге дини китаплар тарала башлау белән, Россиядә әдәби редакцияләү проблемасы килеп туа. Бер яктан, рухани әдәбият славян-чиркәү телендә язылырга, икенче яктан, киң катлам халыкка да аңлашылырга тиеш була. Мондый әдәбиятны рус теленә күчергәндә, динчеләр тәрҗемәчеләргә каноник текстларның эчтәлегенә үзгәрешләр кертмәүне төп таләп итеп куя.

Чит телләрдән русчалаштырылган хезмәтләр арасында тарихка кагылышлылары да шактый. Аларның эчтәлегенә еш кына тәрҗемәчеләр тарафыннан үзгәрешләр кертелгән, хәтта тарихи вакыйга-күренешләрен чагылдыру да автор

инанган идеягә буйсындырылган. К.М. Накорякова, проблемага мөнәсәбәтле рәвештә, болай дип яза: «Анализ перевода «Истории Иудейской войны» Иосифа Флавия, одного из самых популярных памятников литературы Киевской Руси, и других переводных произведений позволил сделать вывод о том, что переводчик часто был не рабом, а скорее соперником автора, творчески подчинял его положения своей основной идее. Подобных фактов можно привести много. Так, далеко не всегда точно повторяли источник русские списки «Девгениева деяния» (перевод относится к XII в., но дошел до нас в более поздних списках). Это отчетливо прослеживается, например, при включении образных средств, которые соответствовали не оригиналу, а русской литературной и народно-поэтической традиции»[1].

Вариантларда очраган аермалар әдәби традицияләр, авторның текстологик мәсьәләләргә мөнәсәбәтле ныклы карашлары белән генә билгеләнми, әлбәттә. Борынгы кулъязмаларны тәрҗемә итү, аны заман графикасында чагылдыру һәм әдәби эшкәртү тәүге чорда шактый кыен була. Еш кына теге яки бу хезмәт тәрҗемәдән тәрҗемәгә камилләшә бара. Икенче яктан, бер башкарылган тәрҗемәләрне яңадан күчерү вакытында күп тапкырлар төзәтмәләр кертелә. Билгеле, алар һәрвакытта да текстны камилләштерми, кайчак тәрҗемә оригиналдан ераклаша да башлый. Әйтик, узганга кагылышлы чыганаклар белән эш иткәндә кертелгән дата үзгәрешләре, ниндидер өстәлмәләр тарихны дөрес күзалларга ярдәм итәргә дә, киресенчә, максатчан рәвештә яисә ялган инанулар аркасында, укучы күзаллауларын буташтырырга да мөмкин.

Әдәби редакцияләүгә һөнәри якын килүне Россиядә басмачылык тарихын башлап җибәргән Иван Фёдоров исеме белән бәйләп карыйлар. Ул, 1564 елда «Апостол» китабын

---

[1] *Накорякова К.М.* Очерки истории редактирования в России XVI–XIX вв. – М.: Издательство «ВК», 2004 // http://textfighter.org.

бастыру алдыннан, текст өстендә зур эш башкара: аңлашылмаган чит сүзләрдән арындыра, иске лексемаларны кулланыштагыларга алмаштыра, кирәкле грек төшенчәләрен өсти, хата грамматик формаларны төзәтә.

Россия китапчылыгының тарихы озынлыкка карамастан, басма хезмәтләр артык күп булмый. 1600 елга кадәр нибары 18 китап дөнья күрә. Китапчылык эше рус тәхетенә беренче Романовлар – Михаил Фёдорович (12.07.1596 – 13.07.1645) һәм Алексей Михайлович (14.07.1645 – 29.01.1676) утырганнан соң билгеле бер дәрәҗәдә кызуланыш алса да, 80 елга якын вакыт аралыгында нибары 187 китап, анда да бик кечкенә тираж белән басыла. Әдәби әсәрләргә килгәндә, бу чорда бигрәк тә көн кадагына җавап биргән, бирмәгәндә, текстларга күпмедер үзгәрешләр дә кертелгән төрле исемле хрестоматияләрне искә алырга мөмкин.

Әлбәттә, басмачылык туып кына килгән һәм бик әкрен үскән бер чорда редакторның, төзүченең автор текстына хөрмәтсезлеге, тиешсез мөнәсәбәте турында сүз алып бару дөрес булмас. Басма сүз тарихының башында авторлык хокуклары даими бозылган, моның өчен беркем җавап та бирмәгән, гомумән, теләсә кайсы язма хезмәт халык байлыгы кебегрәк каралган. Бу уңайдан, академик Д.С. Лихачёв сүзләрен искә төшереп китәргә мөмкин: «Литература Древней Руси не была литературой отдельных писателей: она, как и народное творчество, была искусством надиндивидуальным. Это было искусство, создававшееся путем накопления коллективного опыта и производящее огромное впечатление мудростью традиций и единством всей, в основном безымянной письменности»[1].

Дөрес, әдәби әсәрләргә булган ирекле мөнәсәбәт борынгы заманнарда да руханилар тарафыннан каноник текстларга карата катгый тыелган, тарихи хезмәтләрдә исә вакыйга һәм

[1] *Лихачёв Д.С.* Первые семьсот лет русской литературы // Изборник: Сборник произведений литературы Древней Руси. – М., 1969. – С. 7.

күренешләрне даталаштыру – төгәл, тасвирлау тормыштагыча булырга тиеш дип саналган. Төрле тип текстларга шушы рәвешчәрәк якын килү хәзерге көннәрдә дә күзәтелә дип әйтергә мөмкин.

Рус тарихының XVI гасыры – һөнәри әдәбиятчылар барлыкка килгән чор. Бу заманда китап тарату эше тагын да ныграк җанлана, әмма сан үзгәрешләре сыйфатның кире якка күчешенә китерә. Әсәрләр эчтәлегенә ил сәясәтеннән чыгып төзәтмәләр кертү гадәти бер хәлгә әверелә, бу хәтта дини китапларга да зур зыян сала. Галимнәр, мәсәлән, «Повести временных лет»ка таянып торгызылган яңа кулъязмаларда шактый аермалыклар булу хакында сөйли – димәк, текст беренче язылышындагыча сакланмаган. Ә бит әлеге китапта тәүге мәртәбә рус тарихы яктыртыла, һәм ул рус әдәбиятының да чишмә башы санала. «Повесть временных лет»ның төп ике редакторы билгеле. Елъязманы, бердән, Владимир Мономах кушуы буенча, Василий төзәтә, икенче вариантын новгородлы Добрыня Ядрейкович башкара. Галимнәр тарафыннан һәр икесенең эшендә өстәп язулар, төшереп калдырулар, төрле каршылыклар табылган.

Явыз Иван идарә иткән елларда борынгыдан килгән текстларга тупас тыкшынулар тагын да ешрак күзәтелә, шул ук вакытта дини китапларны төрлечә шәрехләүләр өчен җәзалаулар да башлана. Әйтик, «Апостол»ны үзенчә аңлаткан, шуның нәтиҗәсендә кара халыкка ирек биргән, иконаларга табынуны кире каккан Матвей Башкин хөкемгә тартыла.

Редакторлар, тәрҗемәчеләр бик кыен хәлгә куелган бер заманда патша галиҗәнаплары басмачылык эшеннән яхшы таныш, шома каләмле, европа белеменә ия данлыклы шәхестән – афонлы Максим Гректан грекча язылган «Учёная Псалтырь»ны русчалаштыруын сорый. Ул ярты гомерен чит хезмәтләрне рус теленә күчерүгә бирә. Грек «Триодь цветная», «Часослов», «Псалтырь», «Евангелие» һәм «Апостол» китапларына моңа кадәрге тәрҗемәләр вакытында кертелгән

үзгәрешләрне барлый, әмма бу эш күпләргә ошамый, һәм аны Тверьдагы Отрочь монастырена сөрәләр. Чынлыкта игътибарга да алынмаслык, бик кечкенә генә шәхси җитешсезлекләрен моңа сәбәп итеп күрсәтәләр.

Явыз Иван чорында борынгыдан килгән әдәбиятны барлауга ныклап керешәләр, һәм, шуның нәтиҗәсендә, XVI гасырның илленче елларында митрополит Макарий җитәкчелегендә «Четьи-Минеи» дип аталган – «Собрание всех книг, чтомых на Руси» төзелә. Ә инде Пётр Беренче идарә иткән чорда текстларны редакцияләүгә игътибар бермә-бер арта, ул фәнни нигезгә куела башлый. Кулъязмаларны басмага хәзерләү белән патша ныклап кызыксына, гамәли эшләргә дә актив катнаша. Бүгенге көнгә килеп җиткән кайбер хезмәтләрдә аның үз кулы белән керткән төзәтмәләрен күрергә мөмкин.

Пётр Беренче китапларның Россия тарихын милләт һәм ил файдасына яктыртуын кайгырта. Ул, басмачылыкның гомуми барышын күз уңыннан ычкындырмаса да, төп игътибарын фәнни хезмәтләрне, аерым алганда тарихи текстларны эшләүгә юнәлтә. Пётр Беренче китапларны басмага хәзерләүгә, аерым алганда редакцияләүгә, якыннарын яисә теге яки бу өлкәдә зур белгеч булып аерылып торган кешеләрне, бигрәк тә чит илләрдә югары белем алган яшь дворяннарны тарта. Мәсәлән, хәрби әдәбиятны полководец П.Я. Брюс укый һәм төзәтә.

Алда кыскача гына сөйләп узылган күренешләр дә редакцияләү хезмәтенең башында ук текстларга сәяси-фәнни якын килүнең төп аспект булганлыгын дәлилли. Икенчедән, К.М. Накорякова фикеренчә, без әле бүген дә редакцияләү теориясенең XVIII гасырда салынган логик һәм лингвистик кануннарына, шул чорлардан ук килгән аерым традицияләргә таянабыз[1].

---

[1] *Накорякова К.М.* Очерки истории редактирования в России XVI–XIX вв. – М.: Издательство «ВК», 2004 // http://textfighter.org.

XVIII гасырда редакцияләү эшенең камилләшә баруы әдәбият мәйданына талантлы язучылар килү белән бәйле. А.Д. Кантемир, В.К. Тредиаковский, М.В. Ломоносов, Н.И. Новиков, А.Н. Радищев, Н.М. Карамзин кебек универсаль белемнәргә ия һәм сәләтле шәхесләр басмачылык, журналистика, тел гыйлеме кебек өлкәләрне аеруча кайгырта. Бу чорда автор текстларын камилләштерү схемалары төзелә, шул эшнең матур үрнәкләре туплана. Русларда чын мәгънәсендә әдәби редакцияләү традицияләре нәкъ менә XVIII йөз язучылары тарафыннан салына, ә инде яңа гасырга атлагач, аларны М.Ю. Лермонтов, А.С. Пушкин кебек яңа талантлар дәвам итә, алга таба үстерә.

Россиядә вакытлы матбугат тарала башлау редакторлык хезмәтенә шулай ук үзгәрешләр кертә. Нәшрият мөхәррире белән вакытлы басма мөхәррире эшчәнлегендә, охшашлыклар янәшәсендә, аермалыклар да барлыкка килә, бу һөнәрләр торган саен ачыграк күзаллана башлый. Әйтик, китапның ничек язылуы, нинди эчтәлеккә иялеге, беренче чиратта, автордан тора, ә инде массакүләм мәгълүмат чараларының форматын аны чыгаручылар, абунәчеләр һәм иганәчеләр дә билгели. Әлбәттә, нашир үзе теләмәгән һәм табыш китермәгән хезмәтне басмаска, аннан баш тартырга мөмкин. Журналда яисә газетада эшләгән мөхәррир исә авторларга басманы гамәлгә куючыларның һәм чыгаручыларның шәхси таләпләрен еш кына алдан ук җиткерә.

Вакытлы матбугат ачылганда, аның эчтәлеге, мәсләге турында игъланнар бастыру гадәти күренешкә әйләнә. Мөхәррирләр авторлар китергән материаллардан газета-журнал башкарган максат-бурычларга җавап биргәннәрен генә сайлап ала. Редакторлар әдипләр арасыннан фикердәшләр барлый һәм аларны үзләренә хезмәттәшлеккә тарта. Бу чор газета-журналларында текстларга искәрмәләр, аңлатмалар, керешләр, реклама ише нәрсәләр язу редактор вазифасы дип карала.

XIX гасырда «Современник»ны чыгарган Н.А. Некрасов текстлар белән эшләүнең матур үрнәкләрен калдыра. Шул ук вакытта ул да, башка басмаларда эшләүче танылган каләм ияләре дә автор индивидуальлегенә, хокукларына һәм әдәби ирегенә юл куя, язучыларга зур хөрмәт белән карый.

XIX гасырның беренче яртысында әдәби әсәрләрне редакцияләү традицияләре бик ныгып китә, ә инде икенче яртысыннан гыйльми хезмәтләрне басмага хәзерләү эше ныклы нигезгә куела. Фәнни китапларның җентекле редакцияләнүе, күпләп басылуы рус фәненең үсеше белән бәйле. Бу чорда төрле гыйльми өлкәләргә Н.И. Лобачевский, Д.И. Менделеев, И.П. Павлов, И.М. Сеченов кебек атаклы шәхесләр аяк баса, һәм аларның нәкъ менә заманча камил телдә язылган китаплары исемнәрен бөтен дөньяга таныта да. В.И. Вернадский, Н.И. Вавилов кебек галимнәрнең хезмәтләре исә гыйльми редакцияләүнең камил үрнәкләре дип санала.

XIX–XX гасыр чигендә публицистикага игътибар сизелерлек көчәя. Вакытлы матбугатның кискен үсеш алуы, сәяси-иҗтимагый көрәштә үткен коралга әверелүе шартларында газета-журналларда басылачак материалларны ныклап эшкәртергә, һәр кеше аңларлык хәлгә китерергә, эчтәлегенең теге яки бу төркемнәрнең, фиркаләрнең, басманы гамәлгә куючыларның карашларын чагылдырырга тиешлеген дә исәпкә алырга кирәк була. Яңа заманда вакытлы матбугат күзгә күренеп төрләнә, басмалар рубрикаларга, авторларга торган саен ныграк байый.

Мөхәррирләр еш кына иҗади-сәяси, әдәби планда бәхәсләргә керәләр, үз матбагаларына абунәчеләрне күбрәк тарту һәм аларны шәхси, фирка карашларына инандыру өчен көрәшәләр. Димәк, журналист материалларының төгәл һәм тирән фикерлелеге, ачык аңлашылуы, заман сулышын чагылдыруы кирәк була; текстларның актуальлеге, халыкчан телдә язылуы мөһим роль уйный башлый. Зур көрәшләр эчендә кайнаган, шул ук вакытта фән белән шөгыльләнгән,

иҗат иткән, әдәби редакцияләүгә тартылган каләм ияләре XX гасыр башында сәяси эшлеклеләрнең басма сүзгә, газета-журналларга мөнәсәбәтле фикерләрен, хезмәтләрен өйрәнү гамәленә дә керешә.

Октябрь инкыйлабыннан соң СССРда яшәүчеләрнең вакытлы матбугаты, фәннәре бер үк кысаларда, бер үк юнәлешләрдә һәм бер үк күзәтчелек астында үсә яисә теге яки бу якка үзгәрә башлый. Иҗтимагый-сәяси тормыш, фән, мәдәният мәйданнарының һәр тарафында барган көрәшләр, реформалар, көчле тыюлар һәм кысынкы гына булса да чор алып килгән кайбер мөмкинлекләр редакцияләү гамәлиятендә дә чагылыш таба, анда да һәм уңай, һәм тискәре күренешләр күзәтелә. Шул ук вакытта гуманитар өлкәләрнең кискен үсеше, филологиянең нык тармаклануы, аннан аерымланган өлкәләрнең барысының да гыйльми нигезгә куелышы, алга китеше сөйләмнең бер формасы булган текст белән эшләүгә дә сизелерлек йогынты ясый.

**Татар текстларын әдәби редакцияләү тарихыннан.** Россиядә әдәби редакцияләүнең кулъязма хәлендәге дини эчтәлекле китаплар таралышына барып тоташуы хакында берникадәр язылды инде. Татарлар арасында әлеге күренеш тагын да киңрәк күзәтелә. Озак вакытлар дәвамында үз хезмәтләрен бастыру хокукыннан мәхрүм милләттәшләребез дини чыганакларны гына түгел, әдәби һәйкәлләрне дә кулдан күпләп күчерәләр, ә гыйлемле кешеләр, руханилар копияләрне оригинал белән чагыштыралар, аларга төзәтмәләр кертәләр, комментарийлар һәм искәрмәләр язалар. Шундый галимнәргә мисал итеп, Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләрен китерергә булыр иде.

Аеруча XIX гасыр ахырына татар мәдрәсәләрендә һәм бай тормышлы кешеләрнең шәхси китапханәләрендә кулъязмалар, башка телләрдә, бигрәк тә гарәпчә-фарсыча, төрекчә, русча язылган басма әдәбият байтак туплана. Аларга таянып, әлеге байлыктан иҗади файдаланып, чит хезмәтләргә

тәнкыйди якын килергә, кулъязмаларны заманга лаек формалаштырырга һәм язма текстлар белән эш итү методикасына өйрәнәләр. Рухи кыйммәтле, камил эшләнешле мәдәни ядкярләр сәнгатькә карата билгеле бер зәвык тәрбияли, аларны бәяләү критерийлары булдыра, әдәби әсәрләрне сайлап укуга, тиражлауга күнектерә.

Татар кешесе, кайсы илдә генә яшәсә дә, белем алса да, беренче чиратта, китапханә туплауны максат иткән. Әйтик, Галимҗан Барудиның, Урта Азиядә җиде ел укып, төрле төбәкләрен гизеп һәм атаклы шәхесләр белән танышып кайтканда, кырык пот йөге була, һәм ул, нигездә, фәнни әдәбияттан тора. Галимнең 1920 елда хөкүмәт карамагына тапшырган китапханәсендә генә дә 4288 китап исәпкә алынган. Шуларның 947сен – кулъязмалар, 2274ен гарәп телендәге әдәбият тәшкил итә[1]. XX гасыр башы тарихчысы Г. Алисов бу хакта түбәндәгеләрне әйтә: «Во время своих путешествий по мусульманским странам такие муллы собирают значительные библиотеки книг и рукописей на арабском, турецком и персидском языках»[2]. Галим гарәп телен хәтта мөселман дөньясының латин теле дип атый һәм ерак авылларда да гарәпчә иркен аралашучы кешеләр, бигрәк тә муллалар барлыгын яза.

Укымышлыларыбызның тел гыйлеменә әһәмият бирүләрен китапханәләрендәге кайбер китаплар да сөйли. Мәсәлән, Һади Максуди туплаган мирасханәдән бүгенгә кадәр килеп җиткәннәренең берсе – русча язылган «Теория словесности» хезмәте[3]. Галимнең дәреслекләр хәзерләвендә, ана телебезнең беренче аңлатмалы сүзлеген төзүендә, әлбәттә,

---

[1] *Юсупов М.Х.* Галимджан Баруди.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2003. – С. 45–46.

[2] *Алисов Г.* Мусульманский вопрос в Росии // Русская мысль. – 1909. – № 7.

[3] *Зәбиров Г.* Максуд баба һәм Максудилар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 22 б.

чит әдәбият белән танышлыгы зур роль уйнаган. Ул алардан үрнәкләр рәвешендә дә, белем алу максатыннан да файдаланган.

XIX гасырда язмача тупланган истәлекләрне әдәби эшкәртү даимиләшә. Аеруча фольклордагы охшаш әсәрләрне тәртипкә салалар, автор текстындагы үзгәрешләрне ачыкларга омтылалар. Цензура архивларында чыгаруга табу салынган татарча кулъязмалар күп. Цензорның аларны өйрәнүе, бәяләве, текстларга төрле тип төзәтмәләр кертүе күпмедер дәрәҗәдә хәзерге редакторларның әдәби эшкәртүен хәтерләтә, әмма шунысы хак: аталган гамәлләр китапның сыйфатын яхшырту өчен башкарылмаган.

Ни кызганыч: кайвакыт цензорларның әдәпсез рәвештә тыкшынуларыннан соң, эчтәлек шул дәрәҗәдә начарланган ки, кулъязмаларны бастыруның мәгънәсе үк калмаган. В.Смирнов, Н.И. Ильминскийлар тырышлыгы белән, бик күп китаплар басылудан алынган, югалтылган, кыскартылган, авторларына кире кайтарылган, кайвакыт аерым әсәрләрнең ияләре авторлыктан, иҗаттан баш тарту хәленә җиткән, чөнки чыгачак һәм чыккан китапларның халык өчен әһәмияте күзгә күренеп кимегәнлеген аңлау авыр булган.

Милли үзаң үсешкә атлаган шартларда бернинди киртәләр дә татар басма сүзе, шуңа бәйле рәвештә нәшрият эшчәнлеге үсешен тоткарлый алмаган. Китап уку, кеше әсәренә тәнкыйди карау, авторлар белән бәхәскә керү – татар кешесенең канында. Көнчыгышта әдәби иҗат белән шөгыльләнү формасы ук ярыш рухы белән сугарылган, шунлыктан каләм ияләре башкалар язган әдәби әсәрләрне яңадан эшләү, камилләштерү белән дә мәшгуль булган. Барлык Көнчыгыш халыкларындагы кебек, татарларда да стилизация алымы бик киң таралган, каләм ияләребез таныш сюжетларны, образларны, тулы текстларны иҗади файдаланган. Әйтик, шагыйрьләр мирасында назирә кебек формаларның күп очравы шул турыда сөйли.

Әдәби текст белән эшләү тарихының этаплары – динифәлсәфи һәм эстетик фикер үсешенең этаплары, әдәби барыш белән тыгыз бәйләнештә. Бигрәк тә башында Г. Утыз Имәни, Г. Курсави кебек галимнәр торган XVIII– XIX гасырлар чиге реформаторлыгы барышында һәм XIX гасырның икенче яртысында – мәгърифәтчелек идеологиясе чәчәк аткан елларда – бик күпләр үзләренә әдәби тел нормаларын, милләтебезнең сәнгать әсәрләренә зәвыгын формалаштыру җаваплылыгын ала һәм шуңа мөнәсәбәтле гамәлләрендә әдәбиятның иҗтимагый, тәрбияви, эстетик функцияләр башкаруын күз уңыннан чыгармый.

Г. Утыз Имәни, танылган әдип, галим булгач та, китап күчерү эшеннән туктамый. Газали, Гаттар, Хафиз, Руми һәм башкаларның киңбилгеле әсәрләрендәге башка күчерүчеләр тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм мәгънәви ялгышлыкларны төзәтә, текстларны булдыра алганча авторныкына якынайта. Г. Утыз Имәни Җ. Руми мәснәвиләреннән генә дә – 290, С. Аллаһияр хезмәтенең үзе файдаланган нөсхәсеннән 373 «ялгышлык һәм хата» тапкан икән[1]. Г. Утыз Имәнинең җитешсезлекләрне шул рәвешчә аерып куюы ук редакцияләүнең галим күзаллаган принциплары, төрләре барлыгын сөйли.

Билгеле авторларның хезмәтләрен күчергәндәге текстологик гамәлләр кайчандыр дөнья күргән китапларны бүген яңадан басарга хәзерләүнең архетибы булып тора. Шул ук Г. Утыз Имәнинең Кол Гали язган «Кыйссаи Йосыф»ның тәнкыйди нөсхәсен башкаруын әдәби текстка һәм фәнни, һәм әдәби якын килүнең үз чоры югарылыгындагы үрнәге дип карарга кирәк. Текстологик хезмәткә теләсә кайсы каләм иясе теге яки бу күләмдә тартыла. Икенче бер танылган каләм иябез Т. Ялчыгол, мәсәлән, мөселман хокукы китапларын

[1] Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 1 т. / редколлегия: Ш.Ш. Абилов, Н.Ш. Хисамов, Х.Ю. Миңнегулов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Б. 441.

шәрехләгән, шулай ук суфи Аллаһиярның шигъри әсәрләренә аңлатмалар язган. Гомумән алганда, чын мәгънәсендәге әдәби редакцияләү эшенең заман мөмкинлекләреннән чыгып башкарылган беренче үрнәкләре реформаторлыкның тәүге чорларында инде шактый тупланган. Бу урында шунысын да әйтик: ерак заманнарга караган абруйлы текстологик чыганакларга бүгенге көн галимнәре дә таяна. Элек кулъязма хәлендә йөргән китапларны басмага хәзерләгәндә, әлеге хезмәтләрне еш кына ышанычлы нигез итеп алалар.

Элекке заманнарда татар милли китабы берничә телдә басылган. Россиянең социаль-иҗтимагый шартларында һәм күп гасырлык мәдәни-дини традицияләргә, көчле халыкара бәйләнешләргә мөнәсәбәтле, бик күпләр өчен гарәп, фарсы, рус… телләре беренче, икенче, өченче … тел кебек йөргән. Татарлар чит телләрнең сүзлекләренә кадәр төзегәннәр. Мәсәлән, универсаль белемнәргә ия Г. Утыз Имәни шундый эшләр белән дә шөгыльләнгән[1].

Узган чорда югары белемле зыялыларыбыз башка телләрне хәтта ана тел дәрәҗәсендә яхшы белгән. Чит телләрдән аралашу чарасы буларак та, гыйльми-әдәби максатларда да файдаланганнар, фәнни хезмәтләрне бигрәк тә гарәпчә я булмаса фарсыча язганнар. Шулай итеп, әдәби редакцияләүнең үсеше төрле юнәлештә, төрле телләрдә барган.

«Татарская книга пореформенной России» хезмәтендә могтәбәр галимебез Ә. Кәримуллин, татар китабы турында сүз йөрткәндә, рухи мәдәният нәтиҗәсе саналган басма продукциянең кайсы халыкныкы икәнлеге авторның милли чыгышына бәйле дигән карашны алга сөрә, шул ук вакытта матди мирасханәгә дә караган бу төр хезмәтләрнең аны нәшер итүче халыкныкы саналырга тиешлекне дә әйтә. Китапның әлеге билгеләрен һәр очракта да бергә бәйләп

[1] Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 1 т. / редколлегия: Ш.Ш. Абилов, Н.Ш. Хисамов, Х.Ю. Миңнегулов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Б. 431.

булмау милли китап чикләрен билгеләүдә кыенлыклар барлыгын сөйли.

Ә. Кәримуллин бик хаклы рәвештә милли китап һәм милләт китабы төшенчәләренең тәңгәл түгеллеге, төрки рухи байлыкларны куллануның спецификлыгы, тугандаш халыкларның берсе тудырган әсәрне икенчесенең үзенеке сыйфатында кабул итүе, кайчак авторларның шуны алдан ук күздә тотып язуы, аерым чорларда гомумтөрки телле хезмәтләрнең популярлыгы турында фикер йөртә. Галим, тел берлеген, территориаль уртаклыкны һәм башка бик күп күренешләрне исәпкә алганда гына, татар милли китабы турында сүз йөртеп булганын, анда да инкыйлабка кадәр һәм бигрәк тә борынгы чорларда язылган һәр әсәргә үзенчәлекле якын килергә кирәклекне ассызыклый[1]. Милли китап тамгасын сукканда, тел якынлыгын беренче планга кую да һәрвакыт үзен акламый икән.

Стильләр киң кулланышка төрле елларда керә, тарихи этапларда активлашулары да төрлечә, һәм аларның басмаханәләр тарихы, китап продукциясенең нинди эчтәлектә булуы яисә вакытлы матбугат үсеше белән турыдан-туры бәйләнеше бәхәссез. Әдәби редакцияләү исә татар телендә беренче китап басылуга мөнәсәбәтле рәвештә чын мәгънәсендә һөнәр сыйфатында яши башлый.

Россиядә бигрәк тә Пётр Беренче идарә иткән вакытта нәшрият эшчәнлеге кызу темплар белән үсеп китә, дидек, әмма шуны онытмыйк: хәтта ул чакта да милли азчылык дип саналган халыклар цивилизациянең бу төр заман уңышларына якын җибәрелми. Дөрес, татарларның аерым бер катламнары фәнни яңалыклардан хәбәрдар була, һәм рус гыйльмиятендә дә алар калдырган эзләр бар. Русларга тәрҗемәче, елъязмачы, төрле дәрәҗәдәге чиновник

---

[1] *Каримуллин А.* Татарская книга пореформенной России. Исследование. – Казань: Татар. кн. из-во, 1983. – С. 37 – 99.

сыйфатында хезмәт итүчеләрнең рус стилистикасының үсешенә үзләреннән күпмедер дәрәҗәдә өлеш кертүләрен билгеләп узарга кирәк.

Пётр Беренче тәхеттә утырганда рус матбагасын нигезләүгә төрле халык вәкилләре тартыла, аларның иҗади потенциалыннан, хезмәтләреннән мул файдаланыла. Бу тупланган ядкярләргә мөнәсәбәттә дә чагылыш таба. Мәсәлән, XVIII гасырда, Пётр Беренче кушуы буенча, Россия акчасына бастырылган һәм үз мәдәниятләренә хезмәт иткән һолланд китаплары русларның да милли байлыклары булып саналган.

Әлбәттә, татарча матбагаларны тәртипкә салу эше Россиянең кайсыбер халыкларыныкы белән чагыштырганда озынрак тарихлы. Дөрес, әле XIX гасырда да Казанда татар телендәге китаплар бары тик шәхси нәшриятларда һәм Казан университеты типографиясендә генә басылган. Әлеге басмаханәләрдә татарлар хәреф җыючы, корректор һәм хәтта редактор вазифаларын башкарганнар, еш кына аларның хезмәтен мактау кәгазьләре, истәлекле бүләкләр белән билгеләп узганнар. Университет типографиясендә яхшы эшләгәне һәм үз укучыларын булдырганы өчен, Ситдикъ Әхмәтов хәтта алтын медаль белән бүләкләнгән[1].

Китап басуга хөкүмәт мөнәсәбәте үзгәргәләп торган, әмма аның дәүләткүләм мөһим күренеш икәнлеген бервакытта да онытмаганнар. Әледән-әле басмаханә эшләренә кагылышлы кануннар чыгарылган. Әйтик, 1865 елда «Временные правила о печати» исемле документ башкала типографияләрендә китап бастыру барышына бераз җиңеллек биргән, әмма чит шәһәрләрдәге басмаханәләр эше һаман да ныклы цензура күзәтүе астында калган.

1865 елда Россиядә халыкка 500 типография һәм литография хезмәт күрсәткән. XIX гасырның икенче яртысында

---

[1] *Каримуллин А.* Татарская книга пореформенной России. Исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983.– С. 63.

Казанда гына да 5 басмаханә ачуга рөхсәт бирелгән. Шулардан иң беренче басмаханәне 1800 елда Г. Бурашев ачкан. Ул 1829 елга кадәр мөстәкыйль рәвештә эшләгән, ә аннан соң Казан университеты типографиясенә кушылган.

Типографияләрнең үзәкләшүе, бәлки, күпмедер дәрәҗәдә басмаларның тышкы сыйфаты яхшыруга китергәндер, әмма кырыгынчы елларга кадәр милли китапларыбызның университет карамагында гына дөнья күрүе басмачылыгыбыз үсешен нык тоткарлаган. Алай да шунысын уңай күренеш буларак искә алырга мөмкин: кайчак университет үз хисабына татар китапларын да бастырган. Болар – нигездә, гыйльми хезмәтләр, дәреслекләр, сүзлекләр. Алар арасында ана телебезне гамәли куллану буенча китаплар да очрый[1]. Бу исә XIX гасырда татарча хезмәтләрне әдәби редакцияләү өчен фәнни таянычларның инде булганлыгы хакында сөйли.

Кырыгынчы еллардан соң күпләп шәхси нәшриятлар ачылу татарча басма продукциянең санын күзгә ташланырлык арттырган, әсәрләрне тематик киңәйткән, димәк, төрләрен күбәйткән. XIX гасырның сиксәненче еллары башында Казанда ел саен 300 тирәсе (игътибарга алынырлык саннар!) исемдә китап чыккан, шәһәребез полиграфчылары хәтта башка җирләрдә китап басу эшен җайга салуда катнашкан. Шул ук вакытта тарих дәвамында бер ачылган басмаханәләрнең ябылуын, китап чыгаруда югары хакимият кешеләре махсус тудырган каршылыкларны да әйтеп узарга кирәк. Татар китабын бастыру, тарату зур авырлык белән бара икән, басмачылык культурасы да авырлык белән үсә дигән сүз.

XIX гасырның икенче яртысында, ана телебездәге китапларны чыгару буенча, университет типографиясеннән тыш, Коковина-Чирковлар басмаханәсе дә игътибарга

---

[1] *Каримуллин А.* Татарская книга пореформенной России. Исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983.– С. 46.

лаек. Алар белән бер генә типография дә ярыша алмаган. Университет китапханәсендә хәзерге көнгәчә сакланган күпчелек продукциянең шушы басмаханәләргә каравы моны ачык күрсәтә. Белгечләр Чиркова типографиясендә татар китаплары басылуны бары тик аны сатудан файда алу белән бәйли һәм хуҗаның продукция сыйфатына игътибарсызлыгын билгели. Моңа үз заманында ук татар наширләре игътибар иткән була – димәк, басмаларның камиллеге проблемасы татар зыялыларын элек-электән борчыган. Мөхәррирләр Г.М. Вячеслав типографиясен, мәсәлән, китапларының кәгазе, хәрефләренең матурлыгы һәм ачыклыгы, бизәлеше өчен мактаган. Шулай итеп, басма сүз тарихының беренче көннәреннән үк китап чыгару эшен дөрес күзаллау, аңа һәм эчтәлек, һәм формалаштыру ноктасыннан якын килү күзәтелә, дип әйтә алабыз.

Милли китапларыбыз XIX гасырда ук башка шәһәрләрдә дә басылган. Гарәп шрифтларын 1722 елда Пётр Беренче кушуы буенча ясаган булалар, әмма алар белән күчмә басмаханәдә нибары ике генә китап чыгаралар. Әле соңрак, Россия Фәннәр Академиясе корылгач ясалган шрифтлар да киң кулланышта йөрми.

Гарәп хәрефләреннән Фәннәр академиясе һәм Мәскәү университеты типографияләрендә XVIII гасырның соңгы чирегендә ныклап файдалана башлыйлар. Татар милли китабы Петербургта, Мәскәүдә шактый басыла. Бигрәк тә Оренбургта «Кәримов, Хөсәенов һәм К°» типография ширкәте эшен киң җәелдереп җибәрә. Матбагаларны еш кына язучылар үзләре ачкан, аларда танылган шагыйрь һәм әдипләр, Яңа заман мәгърифәтчеләре хезмәт иткән.

Вакытлы матбугатның тууы, артуы публицистика, әдәби тәнкыйть кебек юнәлеш һәм тармакларның барлыкка килүенә, үсешенә китергән. Газета һәм журналлар милли телне куллану мәйданын киңәйткән, аның стильләрен эшләүгә булышкан, грамматик нормаларны тагын да ныграк

эшкәртүгә һәм гамәли куллануга хезмәт иткән, тормышыбызда әдәби тел позициясен көчәйткән.

Хәзерге вакытта редакцияләүдә бик актуаль юнәлеш күзгә ташлана, бу – автор текстын нәшер итүгә комплекслы якын килү. Тәкъдим ителгән дисциплинаны алып баручы мөгаллимнәр заман таләпләрен истән чыгармыйлар һәм әдәби редакцияләү фәненең теориясен тагын да үстерәләр.

Кызыклы факт: русча фәнни хезмәтләрне әдәби редакцияләү нигезләрен төгәл фәннәр галимнәре саналган Н.И. Лобачевский, И.М. Сеченов, Д.И. Менделеевлар эшләгән. Татарларда аның белән күбрәк руханилар шөгыльләнгән, ә менә публицистикага һәм аны редакцияләүгә Россиядә бик күп социаль төркемнәр тартылган – җәмгыять хадимнәре дә, язучылар да, телчеләр дә…. Кыскасы, халыкның киләчәге турында кайгырткан һәр кеше, үз каләме белән, иҗтимагый-фәлсәфи фикергә генә түгел, милли матбага үсешенә дә ярдәм иткән.

**Әдәби редакцияләү предметы, максаты һәм бурычлары.** Әдәби редакцияләү – яңа гуманитар фән, ул хәзер мөстәкыйль тармак сыйфатында кабул ителә, һәм аның тууы тормышыбызның гамәли шартлары белән аңлатыла. Редакторларның көндәлек хезмәте, хәзерге нәшрият үзәкләренең җайланган эшчәнлеге әдәби редакцияләү теориясен хәзерләүнең нигезе булып тора.

«Редакцияләү» терминының килеп чыгышы латин телендәге «redactus» сүзенә барып тоташа, ул исә «тәртипкә китерелгән»не аңлата. Журналист-студентлар өчен хәзерләнгән «Әдәби редакцияләү» программасында А.Е. Базанова бүгенге көндә аның өч төп мәгънәсе бар дип санауларын яза. Болар:

• теге яки бу басма белән идарә итү;

• текстны тикшерү һәм басмага яраклы булырлык төзәтү;

• теге яки бу төшенчәне, фикерне сүзләр ярдәмендә төгәл формалаштыру.

Галимә, төшенчәнең беренче мәгънәсе баш мөхәррир эшчәнлегенә карый, икенче һәм өченчеләре редакцияләүнең

төрле аспектларын үз эченә ала, ди.[1] Безнеңчә, бүгенге көндә, редакцияләү дигәндә, зур күпчелек, баш мөхәррирнең теге яки бу журнал-газетаны чыгару эшчәнлеген, ягъни аларны матбагага хәзерләүче коллектив белән идарә итүен күздә тотмый.

Әдәби редакцияләү предметы текстологик, филологик анализ методларына һәм башка дисциплиналарның – логика, психология, журналистика, философия, социология фәннәре ирешкәннәргә таяна. Әдәби мөхәррирлекне иҗат юнәлеше дип карыйбыз икән, аны иҗат психологиясе, иҗат лабораториясе кебек тармаклар да өйрәнергә тиеш дигән сүз. Әгәр язма сөйләм вакытлы матбугатта дөнья күрә һәм радиотелевидение челтәреннән яңгырый икән, ул журналистикага караган өлкә сыйфатында да яши булып чыга.

Галимнәрнең бер үк предметка төрле яссылыклардан якын килүләре тикшерү объектын тагын да тирәнрәк, киңрәк аңлауга китерә. Иҗтимагый- мәдәни күренеш саналган һәм кешенең аңлы, рухани омтылышлы җан иясе сыйфатындагы ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлтелгән китап басу гамәлиятен җәмгыятьчеләр дә, социологлар да, мәдәниятчеләр дә игътибарга ала. Һәрбер эш логик законнарга нигезләнә, ә китаби сүз чын мәгънәсендә логик фикер чагылышы булырга тиеш. Шулай икән, аны логика кануннарына да нигезләнеп анализларга кирәк. Басма продукция булган китапны нәшриятлар эшчәнлеген өйрәнүчеләр шулай ук күз уңыннан читтә калдыра алмый, чөнки ул полиграфчылыкны белү дәрәҗәсен чагылдыра, аларның редакция хезмәткәрләре белән берлектәге җайланган уртак хезмәтләренең нәтиҗәсе булып тора.

Текст теориясе, практик стилистика, текстка филологик анализ кебек тармакларның өйрәнү объекты әдәби редакцияләү дисциплинасыныкы белән якынча туры килә:

---

[1] *Базанова А.Е.* Литературное редактирование: учеб. пособие. – Ч. 1. – М.: Изд-во РУДН, 2006.– 105 с. // litredactor.wordpress.com.

формалашкан сөйләм. Аларның максат-бурычлары да шактый охшаган, шул ук вакытта аерымлыклары да бар. Әйтик, редакцияләү, гамәли стилистикадай, тормыш, аның реаль фактлары белән тыгыз бәйләнештә булса да, телдән сөйләмне бөтенләй тикшерми, бары тик автор тексты белән генә эш итә.

Әдәби редакцияләү кулъязманы матбугатта бастыруга, радиодан я булмаса телевидениедән ишеттерүгә хәзерләү барышында мөхәррирнең һөнәри эшчәнлек алымнарын, методологик нигезләрен ача. Ул автор текстын комплекслы өйрәнә, тикшерелүче объектны тирәнтен, киң анализлый, кәгазь өстендә эшкә күп вакыт бирә, әсәрне соңгы этапка – китап продукциясе рәвешендә чыгугача, интернет-сайтларда һәм реклама щитларында урын алугача илтә.

Әдәби редакцияләү студентларны, тыңлаучыларны язма хезмәткә төзәтмә кертүгә хәзерләү максатын куя, текст өстендә эшнең фәнни нигезләрен ача, әмма шул ук вакытта редакторның һөнәри эшчәнлегендәге гамәли якны да күз уңыннан ычкындырмый.

***Әдәби редакцияләү иҗади эш булып тора һәм текст төзәтүнең психологик алшартларын, методикасын, әсәрне анализлау тәртибен белүгә, автор хезмәтен аңлауга, мөхәррирнең чит кеше текстына кул тидерүенең нигезлелегенә таяна.***

Филологик дисциплинаның төп предметларыннан һәм башка бик күп ярдәмче фәннәрдән белем бирмәгән килеш, студентны мөхәррир һөнәренә хәзерләү мөмкин түгел. Болардан тыш, сөйләмне камилләштерү эшчәнлегенә юнәлтелгән башка махсус фәннәр дә бар, әмма әдәби редакцияләүнең гомуми курсы алар арасында иң мөһиме булып тора.

**Әдәби редакцияләү терминына карата.** Кайбер галимнәр, әдәби редакцияләү термины материалларга төзәтмә кертүне генә күздә тота, аның традицион мәгънәсен тагын да ныгыта, ә курсның асылын төгәл чагылдырмый, ди. Хәзерге заманда әдәби редакцияләү төшенчәсе белән текст өстендәге

башта автор үзе, аннан соң редактор башкарган киңкырлы иҗади эшне дә, типографияләрнең соң продуктына юнәлеш тоткан нәшрият эшчәнлеген дә, редактор хезмәтенә өйрәткән белемнәр системасын да атыйлар.

Редакцияләү термины, алдарак та язылганча, латин телендәге редактус, ягъни тәртипкә китерү мәгънәсендәге сүзгә барып тоташа. Әдәби редакцияләү автор текстын матбугатка хәзерләүне күздә тота. Ул шул эчтәлектә башта французларда кулланылган, алардан русларга кергән һәм бераздан татар теленә күчкән. Инкыйлабка кадәр татарлар гарәп сүзләренә нигезләнеп ясалган «мөхәррирлек кылу», «әдәби эшкәртү» һәм башка гыйбарәләрдән дә актив файдаланган, хәзер дә алар сөйләмебездә әдәби редакцияләү төшенчәсенә синоним сыйфатында яши.

«Зур совет энциклопедиясе»ндәге «редактор» терминының аңлатмасына кайбер галимнәр бик саклык белән якын киләләр, чөнки ул өлешчә авторның әдәби-иҗади хезмәтен һәм башка эшләрне оештыру өчен дә җаваплылыкны үз өстенә алган әлеге һөнәр иясенең бөтен функцияләрен чагылдырмый дигән караштa торалар.

Энциклопедиядә терминга аңлатма түбәндәгечә бирелгән:

«Редактор – лицо, исправляющее, обрабатывающее какой-либо текст и приводящее его в соответствие с правилами литературного слога, стиля, с назначением, характером и политической направленностью данного печатного издания»[1]. Бу билгеләмә редактор төшенчәсенә Россия фәнендә гомумкабул ителгәнчә якын килү үрнәге булып тора, шунлыктан анда мөхәррирлек гамәлиятендә барлык очракта да истә тотылмаган сәяси аспект махсус ассызыклана да.

Һәр заман редакторга төрле вазифалар йөкли. Бүгенге көндә, мәсәлән, шәхси нәшрият мөхәрриренең хезмәте

[1] Редактор // БСЭ. Третье издание. – М.: Советская энциклопедия. – 1969 – 1978 // http://www.rubricon.com.

XX гасыр башы мөхәррирләренекенә якыная бара: аның вазифалары текст белән эшләүдән күпкә читкә чыга, аннан талантның, талант-сәләтнең киңкырлыгы сорала. Эшмәкәрләр оештырган басмаханәләрдә редактор вазифасына алынучы текст белән өстән-өстән генә эшләргә, аңа күбрәк техник яссылыктан гына якын килергә дә мөмкин. Кайбер очракларда редакторларның вазифасы текстны карап чыгып кабул итүгә, автор белән китапның форматы һәм бәясе хакында килешү төзүгә, кулъязманы чыгыш саннары белән тулыландыруга, аның басылуы өстеннән күзәтчелек итүгә кайтып кала. Димәк, әдәби редактор урынында утырган кеше асылда офис-менеджер да, техник мөхәррир дә, басмаханәнең матди яктан җаваплы кешесе дә, исәп-хисапчысы да булырга мөмкин. Әлбәттә, бу төр күренешләр әлеге вазифаның чын мәгънәсен аңлаудан ерагайтырга тиеш түгел. Редакторга йөкләнгән бурычларның киңәюе, үзгәрүе шәхси басмаханә хуҗаларының, алар тарафыннан куелган идарәчеләрнең продукция җитештерү чыгымнарын киметергә тырышуына, китап эчтәлеге өчен җаваплылыкны авторга йөкләүләренә һәм башка максатларына барып тоташа.

Гомумән алганда, бүгенге көндә редакцияләү төшенчәсе берничә – киң һәм таррак мәгънәләрдә йөри. Бер яктан, ул басманы һәм радио-телетапшыруларны, кинофильмнарны чыгаруга җитәкчелек итүне, икенче яктан, язма материалларны әдәби эшкәртүне, өченчедән, текстны, басманы тиешле нормаларга китереп формалаштыруны һәм нәшрият эшчәнлегенең кулъязманы камилләштерү, бастыру буенча бөтен этапларын да үз эченә алган хезмәтне дә аңлата.

Шул ук вакытта әлегә зур нәшриятларның күбесендә хезмәт бүленеше традицион. Китапны техник һәм әдәби формалаштыру өчен аерым кешеләр билгеләнә, һәм аларның берсе – текстны калыпка салуны (техник редактор), икенчесе, форматка салынганчы һәм салынгач, аның тиешле дәрәҗәгә китерелүен (әдәби редактор) кайгырта. Басмаханәләр дә,

редакцияләр дә эчтәлекне һәм сәнгатьчә, һәм техник формалаштыру өчен җаваплы мөхәррирләрнең берлеге рәвешендә оеша. Алардан тыш, хезмәт коллективында грамматик, пунктуацион хаталарны төзәтүче корректорлар, басма өчен тулысынча җавап бирүче баш мөхәррирләр дә була.

Әдәби редакцияләү бигрәк тә мөхәррир белән авторның, хәтта күпмедер дәрәҗәдә укучының да уртак иҗаты санала ала, чөнки аларның үзара диалогын хәтерләтә. Бу вакытта фикернең иң дөрес, иң гүзәл һәм тыныш билгеләре урынлы куелган калыплары эзләнә. Н.С. Валгина «Литературное редактирование: Курс лекций» исемле китабында әлеге гыйбарәне түбәндәгечә аңлата: «поиск наиболее точного словесного выражения формулировок, определенных идей, конкретных суждений или понятий, а также аргументов, четко и убедительно доказывающих выдвигаемые автором положения»[1]. Термин хакындагы бу билгеләмә соңгы елларда чыккан барлык мөһим хезмәтләрдә, мәсәлән, И.Б. Голубта да чагылыш таба[2].

Филологик белем алучы шәкертләр яисә аспирантлар еш кына иҗат потенциалына ия, араларында әдәбият өлкәсендә таныла башлаганнары да очраштыра. «Әдәби редакцияләү»не үзләштерү аларга киләчәктә һөнәри үсү перспективасы тудыра. Курсны узучылар:

- предмет хакында күзаллаулар булдыра;
- әдәби редакцияләү методикасын һәм методологиясен үзләштерә;
- текст төзелеше хакында теоретик мәгълүмат туплый;
- нәшрият эшчәнлеге турында билгеле бер белемнәр ала;
- теләсә кайсы текст өстендә кыенлык кичермичә эшләргә күнегә.

---

[1] Литературное редактирование: курс лекций / Н.С. Валгина, А.В. Барандеев, И.Б. Голуб и др.; под ред. Н.С. Валгиной. – М.: Изд-во МПИ, 1989. – С. 4.

[2] *Голуб И.Б.* Конспект лекций по литературному редактированию. – М.: Айрис-Пресс, 2004. – С. 14.

## Икенче бүлек

# ӘДӘБИ РЕДАКЦИЯЛӘҮ – НӘШРИЯТ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ БЕР АСПЕКТЫ

**Мөхәррирлекнең коммуникатив эшчәнлек буларак проблемалары.** Киң катлам укучы хөкеменә чыгарылган басма продукция бик күпләрнең бердәм көче нәтиҗәсендә туа, әмма аның башлангыч этабында бары тик бер кеше – автор тора. Хезмәтенә җаваплы караган, аны халык, ил мәдәниятенә өлеш кертергә тиеш дип санаган әдип, шагыйрь, журналист һәм галим һәрвакыт үзендә эчке цензорны тоеп эш итә. Бу очракта хөкүмәт җитәкчеләре алып барган идеологиядән тайпылмаска, кемнәргәдер ярарга, хәзерләгән материалда аңа ихтыяҗлы кеше куйган таләпләрне дөрес санамаганда да үтәргә тырышуны гына түгел, авторның иҗатка җаваплылык белән якын килүен, тел кагыйдәләрен исәпкә алуын, язганының камиллегенә, бөтенлегенә һәм сәнгатьчә кыйммәтлелегенә омтылуын да күздә тотабыз.

Әлбәттә, талантлы каләм иясе һәр әйткәне, һәр җөмләсе, хәтта сүзе турында ныклап уйланмаска да мөмкин, әмма аның табигатьтән бирелгән, белем туплау дәвамында тәрбияләнгән, ныгыган, үстерелгән сәләтләре үзеннән-үзе хезмәтен җиңел һәм дөрес итеп яздыра. Гомумән, иҗат эшендә интуициянең роле бик зур. Ә ул, белгәнебезчә, шулай ук табигатьтән һәм тәҗрибә белән килә.

Йөргән таш шомара, ди халык. Язган каләм дә шомара. Даими рәвештә уку, төрле стильләр, төрле жанрлар белән яхшы танышлык, аларда иҗат итеп карау, теоретик белемнәрне һәрвакыт гамәли адымнар белән ныгыту язу эшен –

һөнәр, каләмгә осталыкны исә даими сыйфат дәрәҗәсенә җиткерә. Әнә шуларны күздә тотып, кулъязманы ук әдәби редакцияләүнең башлангыч этабы – башта автор үзе интуитив та, аңлы да рәвештә башкарган хезмәт дип карый алабыз.

Редакцияләрдә язу таланты булганнарның гына эшләве төп шарт итеп куелмый, әмма коллектив чын мәгънәсендә каләм ияләреннән тупланган икән – сөенечле хәл. Нәкъ менә талантлы шәхесләр эшләгән нәшриятларда яхшы китаплар чыга. Дөрес, кайбер прозаиклар һәм шагыйрьләр, камил редакцияләү мөмкинлекләре булган редакторларның да автор хезмәтенә артык күп тыкшынуы дөрес түгел дип саный, язмаларын, эшкәртеп бетерү өчен, үзләренә кире кайтаруларын хубрак күрә. Хәтта андый очракларда да мөхәррир кулъязманың җитешсез якларын каләм иясенә зур сабырлык белән дәлилле аңлатырга, вакытлы матбугатта бастырырлык сыйфатларга ия булмаганлыгын төшендерергә тиеш.

Газета-журналларга килгән, әмма басылмаган материал авторларына стандарт җаваплар биргән хатлар язу заманнары үтте. Интернет челтәре җәелүгә бәйле, күп редакцияләр мәкаләләрне электрон вариантта җибәрүне таләп итә һәм, билгеле ки, рецензияләми дә. Кайвакыт газета-журналларның тәүге яисә соңгы битләрендә килгән язмаларның басылу-басылмавы редакция хокукында икәнлек искәртелә. Әнә шулай итеп, кайбер баш мөхәррирләр язмача җибәрелгән материалларны саклау, кире кайтару кебек җаваплылыктан баш тарта.

Нәшрият хезмәткәрләре тамга салып һәм теркәп алып калган кулъязмаларны, басылмаган очракта, иясенә бирмичә кала алмый. Баш мөхәррир, теге яки бу хезмәтнең алга таба язмышын хәл иткәнче булса да, аны шәхси яисә редакция архивларында саклый. Кулъязма белән турыдан-туры эш итәргә сайланган редактор авторга әсәрен күпмедер дәрәҗәдә бәяләп кенә кире кайтарырга, аның белән эшлекле фикер алышырга, дустанә һәм киләчәккә иҗади хезмәттәшлек планнары белән уртаклашып хушлашырга тиеш.

Үзен талантлы дип бәяләмәгән кеше иҗат белән шөгыльләнми диярлек. Талантлар белән эшләү гаять авыр, алар тәнкыйтьне, бигрәк тә үзләре хаксыз дип инанган тискәре тәнкыйтьне авыр күтәрә. Иҗатчыга бик сак якын килергә, әсәрләрен дә, үзен дә түбәнсетми генә, аны әңгәмәгә тартырга, хезмәтенә бәяне, текстына хас җитешсезлекләрне әдәпле һәм йомшак формаларда әйтә белергә кирәк, ә бу – гомумән психологияне, шул исәптән иҗат һәм иҗатчы психологиясен дә яхшы белү дигән сүз.

Әдәби әсәр ничек язылса, аны кабат яхшыртып чыгу да шул эзлеклелектә бара диярлек. Әйтик, прозаик башта сюжет уйлап таба, геройлар составын билгели, эчтәлеккә лаеклы форманы ачыклый, аны башкарып карый, моның өчен кирәкле күренешләр, диалоглар, җөмләләр, тел-сурәтләү чаралары сайлый. Ахыргача тәмам иткәннән соң, ул текстны бербөтен хезмәт буларак укып чыга һәм күңеленнән яңадан таркату эшенә тотына. Ул аның аерым өлешләрен, төрле зурлыктагы берәмлекләрен тагын күз алдыннан кичерә, аларның үзара ярашу мәсьәләсенә җавап эзли; образларының сәнгати эшләнеш дәрәҗәсен, сөйләменең камиллеген бәяли һ.б. Соңыннан әлеге текстны анализлаучы редактор да шул ук юлларны уза.

Әдәби редакцияләүдә бигрәк тә ике кеше калкулана, шуңа күрә аны иҗатчы шәхесне тирән аңлаган; укучылар ихтыяҗын дөрес чамалаган; кабул иткән кулъязмасының тема-проблематикасын җиңел аерган; төрен, тибын билгеләгән; соңгы вариантын яхшы күзаллаган; текст төзәтү технологиясен белгән редактор белән әсәренең укучыга камил формада ирешүен теләгән автор берлектә эшләгән күпаспектлы процесс дип саныйлар да.

Мөхәррир язучы белән хезмәттәшлек юлларын ачыклый, басманың концепциясен эшли, аны калыплаштыруның гомуми юлларын билгели һәм дөнья күрәчәк «китап»ны нәшрият «конвейер»ына сала. Алга таба бу очракта нәрсә

күз алдында тотылганлык, әлеге хезмәттәшлекнең аерым бер тәртибе хакында сүз алып барырбыз.

Әйтик, редактор автор алып килгән кулъязмага карата таләпне күзалланган серия стандартларыннан башларга мөмкин. Шуларның берсе – китапның басма табагы. Икенчесе – басманың структурасы, ягъни аның кайсы әсәрләрне үз эченә алган ничә бүлектән торачагы, бизәлеше, өлешләрнең ничәнче биттән дәвам ителәчәге һәм башка мәсьәләләр. Мөхәррир китапка рәссам сайлауны мөстәкыйль дә, автор белән берлектә дә хәл итә ала. Кайвакыт язучылар бизәүче рәссамнарны үзләре тәкъдим итә яисә таба. Шунысы мәҗбүри: художник ясаган рәсемнәр авторга күрсәтелергә һәм аның ризалыгы белән генә китапта урын алырга тиеш.

Редактор кулъязманың автор үзенә куелган таләпләрдән чыгып хәзерләгән соңгы төзелешенә дә үзгәрешләр кертергә хаклы. Мәсәлән, ул, җыентыкны карап чыккач, әсәрләрнең жанр ноктасыннан чуарлыгын, әмма бер форманың өстенлек итүен күрде ди. Мөхәррир бу очракта әлеге жанрга караган текстларны гына калдырырга тәкъдим итәргә, кулъязманы шулардан гына калыплаштыру өчен кире борырга мөмкин. Әлбәттә, авторның да аның белән килешмәскә, әсәрләрнең тематик-проблематик охшашлыгын, төрлелекнең җыентык өчен отышлырак булуын дәлилләргә һәм мөхәррир белән килешмәвенең башка сәбәпләрен атарга хакы бар. Андый чакта мәсьәләне хәл итүгә башка редакторлар да тартыла ала.

Кулъязманы авторга кире кайтаруның кире кагылмаслык сәбәпләре дә була, билгеле. Мәсәлән, мөхәррирнең балалар өчен аталган шигырьләрдән тупланачак җыентыкны, адресатны билгеле бер яшьтәгеләр белән тарайтып, әйтик, кече яшьтәге мәктәп балалары өчен, дигән сериягә туры китертеп, яңадан эшләтүе бар. Теге яки бу әсәрнең яшь үзенчәлекләренә бәйле күзалланган адресатына мөнәсәбәтле дә, автор белән редактор фикерләре туры килмәскә, үзара бәхәс туарга мөмкин.

Авторга китапны кайчанга хәзерләп бетерү күздә тотылганны да, тиражын да, нинди биттә һәм нинди тышлыкта басылачагын да алдан әйтү лазем. Шәхси хисапка чыгучы басмаларны хәзерләгәндә, аларны эшләү, нәшер итү концепцияләрен мөхәррир алдына күпчелек очракта автор үзе куя. Редактор, тәкъдим-таләпләр килешмәгәндә, китапны башкача чыгаруның отышлырак икәнлеген дәлилләргә тиеш.

Нинди шартларда, кайда гына басылмасын, кулъязманың авторы исән булса, нәшрият эшчәнлегендә ике яклы сөйләшүләрнең алып барылуы – мәҗбүри шарт. Әгәр кулъязманы вафат авторларның варислары китерә икән, аларның китапка кагылышлы теләкләре шулай ук исәпкә алынырга тиеш. Шунысы да бар: бу теләкләрнең үтәлеше реаль булмау сәбәпле, арабыздан киткән кайбер классикларның китапларын яңадан бастыру эше соңгы елларда туктатылды.

**Мөхәррир һәм кулъязма.** Хезмәт белән танышуның беренче этабында редактор, аның җитешсез һәм уңышлы якларын ачыклау өчен, үз алдына текстны актив кабул итү максатын куя, соңыннан исә аның сыйфат ноктасыннан эшләнешен даими күзәтеп тора.

Кайбер әсәрләрне беренче танышу вакытында хәтта гомуми планда да – бәяли алмавың, ә инде авторның язу стиле синекенә туры килмәгәндә, аннан тәэсирләнмәвең дә бик мөмкин. Язучыга хезмәтен кире кайтарырга ашыгырга ярамый, аны яңадан уку – әдипнең стиленә күпмедер күнектерә, әсәренең төп сыйфатларын тотып алырга ярдәм итә. Кулъязмага күңел ятмаганда, бер үк редакциядәге башка мөхәррирләргә укытып фикер алышулар да китап язмышын дөрес хәл итүгә булыша.

Редактор кайсы төр кулъязма, ягъни әдәби, публицистик, фәнни... әсәрләр белән эш иткәнлеген һәрвакыт истә тота. Үз стильләренә корылык хас мөхәррирләр еш кына шагыйрьләр каләменнән төшкән сөйләмне бик үк кабул итеп бетерә алмый, аларның метафорик фикерләрен туры мәгънәсендә

аңлый. Шагыйрьләр исемлегендә йөреп тә, чын шигырьнең нәрсә икәнлеген һәм автор табышы булган образларны аңламаучылар бар. Хәтта кайбер талантлы кешеләргә дә башкалар стилен кабул итү хас түгел. Кызганыч ки, андый затлар да мөхәррирлек вазифаларын үти.

Тормышта автор фикерен, табышы булган образларын дөрес аңламауга, стилен кабул итмәүгә бәйле күренешләр гаять күп очрый. Редакторның публика эчендә әнә шундый әдәбияттан ерак торган, югары кимәлдә язылган рухи байлыгыбызны бәяләргә сәләтсез төркем барлыгын да белеп эш йөртүе кирәк. Ул, киң катлам укучыга аңлаешлы әсәрләрне бастырырга тырышканда да, аларның сәнгатилек дәрәҗәсен, һичшиксез, исәпкә ала. Авторлар нинди генә кульязма тапшырса да, акыллы мөхәррир аның язмышын, басылып чыкканнан соң, милли мәдәнияттә, алгарыштa, укучы зәвыгын, аңын үстерүдә уйнаячак ролен беренче урынга куя. Азсанлы милләтнең зыялы катламы һәрвакыт күздә тоткан бурычларның берсе – милләткә аңлы хезмәт итү.

Әлбәттә, укучыны әдәби әсәрне дөрес аңламавы өчен гаепләргә ярамый. Бу – аның фаҗигасе. Ул гуманитар белем алмаган булырга, әдәбият-сәнгать белән ныклап кызыксынмаска да мөмкин бит әле. Гүзәл әсәрләр укытып, баланың яшьтән үк зәвыгын үстерү, аны түбән сәнгать басымына каршы торырга күнектерү, талантлы язылган әдәбиятка күңелендә мәхәббәт уяту – әдипләребезнең, мөхәррирләребезнең мөһим бурычыдыр.

Бер караганда, нәфис текстны анализлау, бәяләү – гаять катлаулы, четерекле эш. Ул хәтта редактор өчен дә шулай. Аны бәяләү критерийлары башка төр әсәрләрнекеннән нык аерыла, әдәбият теориясен, стилистиканы, публика психологиясен белүне, әдәби зәвыкка ия булуны һәм тоемчанлыкны таләп итә.

Мөхәррир үз эшендә моңарчы булган традицияләрне онытмый, шул ук вакытта заман шартларын – аның әдәби

тел нормаларын һәм сәнгать әсәрләренә куйган таләпләрен дә исәпкә ала. Ул үз публикасын алдан ук күреп тора, чыгачак басманың кулланыш сферасын һәм максатын белә дип карала.

**Кулъязманың төп сыйфатларын ачыклау.** Мөхәррир редакцияләнгән хезмәтнең эчтәлеге һәм формалашуы өчен җавап бирә, ә бит кулъязманың шул ук сыйфатлары өчен язучы җаваплылыгы да бар. Редакторлардан, хезмәтен кабул иткәндә үк, авторның игътибарын шул мәсьәләгә юнәлтү сорала. Икенче яктан, әсәрнең мөхәррир тарафыннан эшкәртелмәгән варианты никадәр камилрәк, басмага әзер дип тапканы да шулкадәр сыйфатлы булачак. Тулы канлы эшләгән нәшрият архивларында мөхәррирләр тарафыннан бөтенләй үзгәрешләр кертелмәгән автор вариантлары очрамый да торгандыр, әмма идеалда инде кулъязма ук сәнгатьнең – бөтен таләпләренә, телнең барлык кагыйдәләренә җавап бирергә тиеш.

Бүгенге көн шартларыннан торып хөкем йөрткәндә, каләм иясе тапшырган хезмәтне турыдан-туры бастырып чыгарган яисә аны китап рәвешендә калыплаштыруны гына үз өстенә алган дистәләрчә нәшриятлар әле тиз генә башка, дөресрәге, элекке традицияләргә таянып яңарган эшчәнлек төренә күчәр дип өметләнеп булмый. Язу белән шөгыльләнүчеләрнең күплеге, хөкүмәт нәшриятларындагы эшнең тыгызлыгы, кайвакыт хәтта язу маһирлыгына ия булмаганнарның да матбугат тарихында эз калдырырга тырышулары, матди ярдәмчеләр хисабына кайвакыт кирәксез, укучы ихтыяҗына җавап бирмәгән әдәбият та чыгарырга омтылулары – басмаханәләр челтәрендәге җитешсезлекләрнең озын гомерлелегенә төп сәбәпләрдер.

Базар мөнәсәбәтләре шартларында шәхси матбагалар гамәлиятенә, китап хәзерләүнең техник ягына читтән тыкшынып булмый, ә аларны сыйфатсыз продукция чыгарганнары өчен ябу, әлеге продукциягә карата катгый таләпләр кую хуҗалары тарафыннан гына түгел, әдәбият сөючеләр,

авторлар ягыннан да цензура тыюлары дәрәҗәсендә кабул ителергә мөмкин. Шул ук вакытта без бу төр күренешләргә битараф калырга да тиеш түгелбез. Китапларның сыйфатлы эшләнеше проблемасын журналистларның күтәрүе, укучыларны һәм авторларны, мөхәррирләрне үзара сөйләшүгә, бәхәскә тартуы, уңай омтылышларга китерүе кирәк. Киләчәктә милләтнең укымышлы, мәдәни продукциянең сәнгати эшләнеше, әдәбиятның камиллеге өчен борчылган катламы аталган мәсьәләгә үзенең игътибарын юнәлтер әле дип өметләник.

Инде кульязмага килгәндә, мөхәррир автор тәкъдим иткән хезмәтнең түбәндәге якларын:

• яктырткан темасының актуальлеген, тирәнлеген;

• күтәргән проблемаларының мөһимлеген һәм принципиальлеген;

• материалының байлыгын, яңалыгын, хакыйкатькә туры килүен, тәгаенлеген, чынга охшавын;

• сәнгати-тәрбияви ноктадан кыйммәтлелеген һәм башкаларны бәяли.

Редактор шулай ук әсәрнең композиция һәм логик сыйфатларына – бөтенлегенә, текстның бәйләнешле булуына, күләменә, бүлек һәм бүлекчәләрнең үзара мөнәсәбәтенә, материалны җиткерү юлларына, нәтиҗәләрне фактлар белән ныгытуга да төпле бәясен бирә. Ул текстта төшенчәләрне бутау, фактларда хата җибәрү, сүзләрне дөрес кулланмау тыелганны, аның логик-стилистик хаталардан да азат булырга тиешлеген бервакытта да исеннән чыгармый.

Сәнгать әсәрләрендә конфликт оешу һәм аның үсеш схемасын, ни рәвешчә чишелешен күздә тоту, бигрәк тә беренче пландагы геройларның эш-гамәлләрен мотивлаштыру, ә икенче дәрәҗәдәгеләрен әдәби каймага кертүнең кирәкмеюкмы икәнлеген ачыклау лазем.

Язма сөйләмдәге тел чаралары төрле – лексик, морфологик һәм синтаксик – яссылыкларда бәяләнә. Тел-сурәтләү

чараларына да, сәнгати образларга да, хезмәтнең билгеле бер стильне ахыргача саклый алу-алмавына да игътибар итү мөһим.

**Басманың тибын билгеләү** редактор эше булып тора. Инде узган гасыр ахырында ук бастырырга хәзерләнгән материалларга, шул исәптән автор текстына, китапка һәм нәшрият эшчәнлегенә куелган **норматив-техник таләпләрне** чагылдырган яңа тип белешмәлекләр дөнья күргән иде[1]. Россия җитештергән продукциянең халыкара критерийларга җавап бирергә тиешлеген күздә тотып, 2003 елның 1 июлендә 184-ФЗ санлы «Техник регуляцияләү турында» Федераль закон чыгардылар, һәм ул 2002 елның 27 декабрендә гамәлгә керде. Әлеге канун стандартлаштыру принципларын шактый үзгәртте[2]. Соңгы чорда тәкъдим ителгән стандартлар да кайтып-кайтып карала, камилләшә, тулыландырыла. Бүгенге көндә нәшриятлар 15 мөһим дәүләти һәм шуның тугызы халыкара саналган стандартларны туплаган төрле белешмәлекләргә таяна[3]. Күзәтүләр стандарт буенча 1998 елгы хезмәтләрнең дә кулланыштан чыкмавын күрсәтә.

Басмаларның нинди төркемгә каравын китап тибының түбәндәге билгеләре сөйли:

• басманың нинди максатка юнәлтелгәнлеге;

• информацияне аналитик-синтетик эшкәртүнең дәрәҗәсе;

• тамга табигате;

• мәгълүмати характеры;

• хезмәтнең структурасы, күләме, төп өлешенең композиция сыйфатлары керә.

---

[1] Стандарты по издательскому делу.– М. : Юристъ, 1998.– 376 с.

[2] Основные стандарты по издательскому делу / сост.: А.А. Джиго, С.Ю. Калинин.– М.: Университетская книга, 2009.– 326 с.

[3] Основные стандарты по издательскому делу: дополнено двумя новыми стандартами / сост.: А.А. Джиго, С.Ю. Калинин. – М.: Университетская книга, 2010.– 326 с.

Бер-берсенә шактый якын торган дәреслек, методик ярдәмлек, хрестоматия яисә антология, җыентык, сүзлек, белешмәлек, энциклопедия һәм башкаларның сыйфатламаларын да махсус стандартлар ачыклый. Кулъязма белән эш иткәндә, мөхәррир кабул ителгән мәҗбүри нормаларга таяна. Алга таба сүз билгеле бер күләмдә алар турында да барачак.

Әйтик, басманы төрләргә бүлгәндә, аның кемгә һәм ни өчен адреслануын исәпкә алырга кирәк. Мәсәлән, мәктәп укучылары, укытучылар, юл хезмәткәрләре, аерым бер социаль төркемнәр өчен чыгарылган басма продукция була ала. Россиядә китапларны шулай ук масса-сәяси, фәнни, фәнни-популяр, рәсми, уку-укыту, информатив, җитештерүгамәли, реклама төрләре дип атыйлар, ял иткәндә кулланылучы әсбапларга, белешмәлекләргә һәм матур әдәбиятка бүләләр.

Мәгълүмат характеры буенча полиграфик продукцияне түбәндәгечә төркемлиләр: дәреслекләр, уку-укытуның күрсәтмә әсбаплары яисә методик ярдәмлекләре, сүзлекләр, белешмәлекләр, сөйләшмәлекләр, юлкүрсәткечләр, каталоглар, монографияләр, фәнни хезмәт тупланмалары, гамәли ярдәмлекләр, документаль-нәфис басмалар, альманахлар, антологияләр, күзәтү характерындагы яисә реферативхезмәтләр... Аларның үз эчендәге төркемчәләрен дә билгеләп булыр иде. Мәсәлән, сүзлекләрне энциклопедияләргә, тел сүзлекләренә, аңлатмалы яисә терминологик характердагыларга бүлү очрый. Каталогларның, гамәли әсбапларның, сөйләшмәлек һәм белешмәлекләрнең дә төрлеләре бар.

Тупланмаларның, монографияләрнең төркемнәрен, әйтик, бастыру максатыннан чыгып күрсәтергә мөмкин. Кайвакыт бүленешкә нигез итеп жанр һәм жанр формасын, тираж һәм авторлар санын алалар. Китап продукциясен беренчел һәм яңадан чыккан басмаларга бүләргә була. Соңгыларының тулыландырылганы, үзгәрешләр кертелгәне, төзәтелгәннәре очрый.

Кулъязма турында сөйләгәндә, төшенчәнең шартлы кулланылышын, традицион эчтәлеккә генә ия түгеллеген дә билгеләп узарга кирәк. Хәзерге вакытта, кулъязма дигәндә, каләм белән язылган материал гына күздә тотылмый, ул күбрәк автор вариантын, басмага тәкъдим ителгән хезмәтне аңлата. Кулъязмаларның каты дискка, кассетага язылганнары бар, алар компьютерда саклана һәм интернет яисә телефон челтәре аша да килә. Андый төр кулъязмаларны электрон вариантлар дип атыйлар. Интернет-сайтка чыгарылган материаллар да чимал – кулъязма хәлендә генә була ала.

Кайвакыт телетапшыруларда телефон аша төрле рекламага яисә башка бер текстка конкурслар уздыралар һәм аларның отышлыларын, әлегә кулъязма рәвешендә генә эшләнгәннәрен, реклама такталарында дөнья күргәнче, эфирдан да яңгыраталар.

Кулъязмаларның хәзергә каләм белән башкарылган төрләре дә яши, әмма инде аларны кайбер редакцияләр генә, анда да авторга ташлама рәвешендә генә кабул итә. Конвертта килгән гади укучы хатлары бик сирәк кенә газета-журнал битләрендә урын ала. Киләчәктә бер генә нәшрият һәм редакция дә каләм белән язылган материалларны кабул итмәс дип уйларга кирәк; хәтта ки, эш барышын тизләтү максатыннан, аларны интернет-почта аша гына җибәрүне сораулары, авторлар белән күзгә-күз очрашу традициясеннән тулысынча баш тартулары мөмкин.

Бүгенге кулъязмаларның зур күпчелеге – компьютерда җыелган һәм кәгазьгә күчерелгән әсәрләр. Аеруча нәшрият редакцияләре аларны ике вариантта – электрон һәм басма формада алып килүне таләп итә.

«Зур энциклопедик сүзлек»нең узган гасыр ахырында чыккан басмаларында (1997, 1998...) кулъязма төшенчәсенә элек үк кабул ителгән түбәндәге билгеләмә бирелгән:

«Рукопись, 1) в широком смысле – текст напечатанный от руки или перепечатанный на пишущей машине.

2) Произведение письменности; изучением древних Р. занимается полиграфия. 3) В издат. деле – авторский текст, представленный в издательство»[1].

Беләбез ки, хәзер электрон җайланмаларның махсус программалары кульязмаларны әйтеп яздыру аша да хәзерләү мөмкинлеге бирә.

Соңгы вакытта тупланмаларда басылачак фәнни тезисларның яисә докладларның форматын алдан ачыклау гадәткә кереп бара. Төрле конференцияләрнең материалларын китап сыйфатында чыгаруны планлаштыручылар потенциал чыгыш ясаучыларга кульязма кабул ителүнең ахыргы көнен һәм башка шартларын хәбәр итәләр, редакторлыкны авторның үзенә тапшыралар. Мондый шартларда исә рәсми булмаган редакторлар барлыкка килә: кайберәүләр текстларын мөхәррирлек белән шәхси планда шөгыльләнүчеләргә биреп эшкәрттерәләр.

Фәнни чыгышларның тулы вариантларын һәм аеруча тезисларын, гадәттә, TIMES NEW POMAN шрифтында 1,5 интервал белән язылган, библиографик аппарат һәм искәрмәләр соңгы битләрдә урнашкан текстлар рәвешендә интернет челтәре аша җибәрүне үтенәләр, күпчелек очракта кырларны компьютерның үзендәге А4 битенә туры килүче стандартлар белән формалаштыруны сорыйлар. Доклад күләме дә ачык билгеләнә. Әлеге таләпләрне үтәүне редакторлык хезмәтенә караган заманчалык дип санарга кирәк.

Редакцияләр дә материалларны югарыда аталган стандартларда китергәнне ярата. Таләпләр кысасында башкарылган язманың күләмен алдан төгәл беләсең һәм аны тege яки бу газета-журнал битләрендә күзалларга җиңел. Икенчедән, мәкаләнең күләме аерым биткә сыярлык булмаганда, рубрикалар өчен махсус калдырылган өлгеләрне тотырып

---

[1] БСЭ. – М.: Большая Советская Энциклопедия, 1997. OCR Палек // twirpx.com.

бетермәгәндә яисә башка бер-бер шарт үтәлмәгәндә, мөхәррир, үзгәртү үтенече белән, аны авторына кире кайтара ала. Дөрес, әлегә башка форматлардагы кулъязмаларны да кабул итәләр, чөнки һәр күләмле матбугат үзәгенең штат тәртибенә элеккечә үк машинисткалар да, редакторлар да кертелгән.

Әлбәттә, электрон варианты да булган кулъязманы бастыру газета-журнал редакцияләреннән азрак көч сорый, шул ук вакытта әле ул барыбер редактор каравын узачак, күпмедер үзгәртеләчәк, кыскартылачак. Элекке басмаларның кәгазьдә сакланган вариантларын электрон форматка күчерү дә инде җиңел, чөнки бүгенге көн вакытлы матбугат үзәкләре, бигрәк тә дәүләт карамагындагылары яисә гамәлгә куючылары бай оешма булганнары электрон техниканың бар төрләре белән дә тәэмин ителгән көчле нәшрият системалары сыйфатын алган.

**Редакторлык эшендә дәүләт стандартлары.** Басма сүзне калыплаштыруга карата рәсми кабул ителгән таләпләрне, мәҗбүри нормаларны, ягъни китапларга, рисаләләргә һәм полиграфиянең башка төр продукциясенә кануни кертелгән үлчәм-өлгеләрне *дәүләт стандартлары* дип атыйлар.

Инглизчәдән алынган стандарт сүзенең һәм күренешенең ерак тарихы бар. Кеше яшәешендә гадәткә кергән зурлыклардан башланып рәсми кабул ителгән, үсеш-үзгәрешләр кичергән нормаларга барып тоташа ул. Бөек Кытай диварының үлчәме төгәл билгеләнгән кирпечләреме, әллә каберлекләрдәге бер тип теракот сыннармы, кайбер илләрдәге социаль чыгышка я булмаса милләткә бәйле максималь биеклеге күрсәтелгән йорт-торакларммы, җир үлчәмнәреме һ.б.мы – «тәртипкә салынган» зурлыклар белән кешелек җәмгыятенең барлык чорларында да очрашабыз. Аларның үрнәкме, калыпмы рәвешендә яшәве социаль-сәяси, психологик мохит, табигать шартлары һәм башка бик күп сәбәпләр белән билгеләнә.

Баштарак аерым тирәлек өчен генә уйлап табылган үлчәмнәр тора-бара кешеләрне канәгатьләндерми башлый,

бер ил, кыйтга һәм хәтта дөньякүләм стандартлар барлыкка килә. Без бүгенге көндә физикада, математикада һәм башка өлкәләрдә кабул ителгән гомумнормалар белән эш йөртәбез. Дөрес, кайбер стандартлар озак еллар дәвамында илнең мөстәкыйльлеген билгеләүгә хезмәт иткән, һәр алга киткән милләт теге яки бу өлкәдә башка халыкларның да үз үлчәмнәрен өлге сыйфатында алуына омтылган. Борынгырак чорларда җитештерелгән әйберләрнең формасына һәм эчтәлегенә кагылышлы кайбер отышлы нормалар мәдәни аралашу, сәүдә вакытында үтеп кергән һәм ихтыяри рәвештә камил үрнәк дип табылган.

Галимнәр һәм җитәкчеләр, халык вәкилләре тарафыннан бик уйлап эшләнгән, бергәләп кабул ителгән кагыйдәләр дә искерергә мөмкин. Шунысын да игътибарга алыйк: кайбер үлчәм-өлгеләрнең гомере иҗтимагый системаның яшәү дәверенә бәйле. Әйтик, СССРда дәүләт стандартлары 1962 елдан алып кабул ителә, әмма Үзгәртеп кору елларында башкаларныкыннан аерылып торган стандартларны дөньяныкылар белән яраштыру эшенә керешәләр.

Глобальләштерү чорында халыкара берләшмәләргә керүнең бер шарты – алга киткән дәүләтләрдә кабул ителгән стандартларны тану һәм үз илеңдә гамәлдә куллану. Без хәзерге вакытта, мәсәлән, мәгариф системасын дөньякүләм стандартларга нигезләп яңадан коруны башкарабыз. Мондый процесслар төрле тип киртәләрне сүтеп ташлау аша бара, әмма әлеге юлда иң авыры һәм тулаем юкка чыга алмый торганы – психологик киртәләрдер, чөнки төрле шартларда яшәгән, төрлечә фикер йөрткән, төрле үсеш дәрәҗәсенә ия халыкларны яңалыкларга бердәй җиңел күнектерү, ризалаштыру – реаль булмаган гамәлдер.

Кайбер үлчәмнәрне аларны чагылдыручы төшенчәләр белән бергә генә кабул итәргә мөмкин. Әйтик, озынлыклары туры килмәгән километр һәм чакрым сүзләренең мәгънә эчтәлеген үзгәртеп булмаслыгы көн кебек ачык, шунлыктан

рәсми исәпләүләрдә беренчесе генә кулланыла ала, чакрым, озынлык сыйфатламасын саклаган хәлдә, көндәлек сөйләмебездә әйләнештә йөри.

Юл билгеләрендә, машина төзелешләрендә һәм башка бик күп предмет-күренешләрдә кешеләрнең үзара аралашуы арткан бер заманда билгеле бер таләпләрне катгый кую, югары дәүләт органнарында канунилаштыру бәхәс уятмаска тиеш, чөнки ул – куркынычсызлык кагыйдәләрен саклауның, хәтта бер-береңне хөрмәтләүнең, санга сугуның, көндәлек тормышыбызны тәртипкә китерүнең, эшләребезне җайга салуның мөһим шарты.

Әлбәттә, үз стандартларыңнан баш тартып, башкаларныкын алуның һәм уңай, һәм тискәре яклары бар. Әйтик, япон машиналарында сул якка куелган руль аларның гасырлар дәвамында ныгытылган күнекмәләре белән билгеләнә, гарәп китапларының уңнан сулга укылышы, битләренең икенче яктан ачылышы безнең өчен гадәттән тыш хәл тоелырга мөмкин, әмма ул мөселман халыкларының менталитетына, хәрефкә-язуга мөнәсәбәтенә, уйлау-уку үзенчәлегенә нигезләнә һәм гасырлар дәвамында какшамаслык ныгыган. Язу төрләрендә һәр халыкның тарихы саклангонны да онытырга ярамый.

Бар нәрсәне тәңгәлләштереп бетерүгә ихтыяҗ юк. Бу басма продукциягә дә кагыла. Гарәп язуы белән кириллицада җиткерелгән текстта хәрефләр биеклеге, алар арасындагы бушлыклар тәңгәл була алмый. Дини һәм дөньяви эчтәлектәге әдәбиятны бастыруга бер үк таләпләрдән якын килү дә дөрес түгел.

Нәшриятлар эшен оештыруда кыенлыклар, каршылыклар булуга карамастан, алга китеш сизелерлек. Бу техник база, китап чыгару технологиясе яңарышына гына карамый. Әйтик, соңгы елларда төрле илләрдәге басма продукциягә карата нормаларны үзара тәңгәлләштерүгә игътибар артты. Шулар нигезендә үз илебездә дә бу төр стандартларны

яңадан ныклап эшләделәр, аларны чагылдырган рисаләләрне, китапларны сату киң җәелдерелде. Әйтик, рәсми кәгазьләрне, эш документларын формалаштыруга куелган таләпләр аерым һәм күмәк җыентыкларда дөнья күрде; стандартларның һәр төре интернет челтәрендә урын алды.

Кайбер оешмалар, институтлар, гомуми таләпләргә таянып, үз басмаханәләрендә чыгарга тиешле китапларга мөнәсәбәтле махсус стандартлар уйлап таба. Әйтик, югары уку йортларының, ГОСТ 7.4-95, 6.30-2003, 7.1-2003, Р 7.05-2008 һәм башкалардан чыгып башкарылган дәреслек, ярдәмлек, уку-методик ярдәмлек, күрсәтмә әсбап, эш дәфтәре, хрестоматия, практикум, мәсьәләләр җыентыгы, уку программасы, уку комплекты һәм башка төр басмаларның кульъязмаларына куелган таләпләр исемлеге бар. Ул институт-университетларның басмаханәләр сайтында урын алган. Мәсәлән, К(П)ФУның Фәнни-мәгълүмати үзәге оешуының беренче көннәреннән үк махсус сайтын эшләде.

Мәгълүмат, китапханәчелек һәм нәшрият эшчәнлеге стандартлары (СИБИД – Стандарты по информации, библиотечному и издательскому делу) шактый күләмле система тәшкил итә, һәм бу юнәлештәге яңартылган стандартлар системасы белән ГОСТ ИСО 8601-2001 аша танышып була.

Китап басуда нормалар сакланмаса, редактор, автор һәм техник хезмәткәрләр бер-берсен тиешенчә аңлый алмас иде. Ул чагында төрле үлчәмдәге китапларны кулланучы да кыен хәлгә калачак, чөнки басма продукция өчен җиһазларны махсус эшләтергә тиеш булачак. Басмаханәчелек катгый нормаларга нигезләнгәнлектән, китап киштәләре, шкафлары бүгенге көндә билгеле зурлыктагы басмаларны күздә тотып ясала. Гомумән, бер өлкәдә стандартларны кабул итү, эзлекле рәвештә, икенче һөнәрләргә мөнәсәбәтле нормалар барлыкка китерә.

Нәшриятның төрле тармакларында эшләүче барлык кешеләрнең хезмәтен җайга салучы техник таләпләр, төгәл

үтәлергә тиешле кагыйдәләр продукциянең сыйфатын арттыра, аны кулланучыга сәнгати камил калыпта җиткерергә булыша, һәм алар аерым бер шифр белән билгеләнә. Мәсәлән, 7.4–95 саны белән билгеләнгән дәүләт стандартлары чыгарылыш мәгълүматларына карый, титул төзелеше турында сөйли.

Беренче биттә автор, китап, нәшрият исеме урын алырга тиеш дип карала. Болардан тыш, басмаханәнең торак пункты, продукциянең дөнья күрү вакыты аталырга мөмкин. Титул артында УДК, ББК (күпчелек очракта өстә яисә аста, сул якта), халыкара нормаларны чагылдыручы ISBN (аста, сулда, соңгы вакытларда библиографик тасвирлама эчендә дә), авторлык хокукын саклаучы © (копирайт – аста, уңда), хокук иясенең атамасы (мәсәлән, нәшрият исеме) яисә махсус билгесе (фамилиянең сан белән тамгаланган баш хәрефе – югарыда, аннотация янәшәсендә яисә фамилия рәвешендә копирайт янында) кебек тамгалар бирелә.

Аннотацияле каталог карточкасының макеты (АККМ) китапханәчеләрнең эшен шактый җиңеләйтә, китап продукциясен пропагандалауда кулланыла һәм мәҗбүри өлешләрнең берсе булып тора. Яңа кәгазь карточкалар белән махсус формаларга салынмаган искеләре арасында зур үзгәрешләр юк. Алардан хезмәтнең китапханәдә саклану урынын, санын, авторын, башка чыгыш мәгълүматларын һәм эчтәлеген ачыкларга мөмкин. Татарча иске китапларның барысы да аннотация белән әлегәчә тәэмин ителмәгәнне дә билгеләп узарга кирәк.

Кайбер, бигрәк тә шәхси китапханәләр каталог карточкаларының, аларда чагылырга тиешле мәгълүматны истән чыгармыйча, үзләренә кулай форматтагыларын эшли. Дәүләт стандартлары белән бөтенләй хисаплашмаганнары да юк түгел. Басма продукция яисә аның белән танышуга вакыт сатуны күздә тотып башкарылган карточкалар формаль таләпләргә шулай ук җавап бирми.

Хәзерге вакытта китапханәләрдән басма хезмәтләр хакында белешмә бирүче карточкаларның электрон вариантларын хәзерләү сорала. Укучыга, гомумән, электрон версияләр генә тәкъдим иткән китапханәләр дә юк түгел. Ул төр карточкалар, гадәттә, ачыклык, мәгълүмати тулылык белән аерылып тора. Б. Ельцин исемендәге Президент Библиотекасының китаплар каталогыннан шуңа бер үрнәк китерик:

*Автор Адамович Фридрих Эрнестович*

*Описание Адамович, Фридрих Эрнестович*

*География: для начальных училищ / Ф. Адамович. – Рига: Книгоиздательство «Педагог», 1914. – [2], 114, [2] с., 1 л. карт. : ил., карт. ; 23 .*

*1. Территория (коллекция). 2. Учебники по географии (коллекция). 3. География – Учебные издания для средней школы.*

*ББК 26.89(0)я72*

*Источник электронной копии: ПБ*

*Издательство Книгоиздательство «Педагог»*

*Объект в каталогах  Страноведение. Краеведение*

Басма хезмәт хакында шактый мул мәгълүмат бирсә дә, дәүләт стандартлары таләп иткән барлык нормаларны ахыргача үтәмәгән каталоглар да җитәрлек. Мәсәлән, түбәндәге карточкада классификатор кодлары (ББК, УДК) юк:

*Автор: Энн Стюарт*

*Жанр: Зарубежные любовные романы*

*Издатель: «Издательство «Эксмо»*

*Год выпуска: 1999*

*ISBN книги: 978-5-699-73334-7*

*Тип: Книга*

*Наследник знатной фамилии Александр Макдауэлл навсегда запомнил тот день, когда его мать привезла в их особняк сироту Каролин: крохотную голубоглазую девочку, смотревшую на мир с какой-то недетской покорностью.*

*Они росли вместе, но их разделяла пропасть. В глубине души Алекс всегда знал, что ни один из них никогда по-настоящему не был частью этой семьи. Подростком он сбежал из дома, чтобы раскрыть тайну своего рождения, и пропадал почти двадцать лет. Но вот пришло время попрощаться со смертельно больной матерью, и Александр возвращается в семейное гнездо…*[1]

Аннотациядә әдәби тәнкыйть фәне тарафыннан танылган сыйфатламалар да саклanырга тиеш, ә алар стандарт куйган таләпләр белән тәңгәл килә. Кызганыч ки, соңгы елларда каталог макетларында еш кына хезмәт ачкан тема-проблемалар я бөтенләй чагылдырылмый, я китап эчтәлеге кирәгеннән тыш тасвирлана, югыйсә 7.51-98 стандарты аннотацияле каталог карточкасының эчтәлек һәм калыбына бәйле таләпләрне төгәл ачыклый.

Кайбер электрон каталогларны эшләүчеләр, басма эчтәлеген ачасы урынга, интрига уятырлык, укучыны сюжетка алып кереп китәрлек җөмләләр белән чикләнә. Мәсәлән, «Книги-Самиздат»та Жасмин Майерның «Подари мне чудо» китабына шушындый аннотация язылган: «Это была бы такая же заурядная новогодняя ночь, как и другие в их жизни, но в какой-то момент и у нее, и у него все пошло наперекосяк. И больше нельзя было закрывать глаза на то, что раньше старались всеми силами не замечать. А новогодняя ночь лучшее время для чуда и самое время исполнить мечты наяву, ведь как Новый Год встретишь, так его и проведешь»[2]. Язманың каталог вариантында исә дәүләт стандартларына җавап бирмәгән шушы төр аннотациядән дә беренче җөмлә генә калдырылган.

7.1-2003 халыкара стандарты библиографик тасвирламалар төзү алымнарын күрсәтә – мәгълүматларны нинди

---

[1] http://ebookbox.ru/books/zarubezhnye-lyubovnye-romany/

[2] Подари мне чудо // https://litnet.com

эзлеклелектә бирү, сүзләрне ни рәвешле кыскарту, тыныш билгеләренең ниндиләрен кую анда ачык чагыла. Түбәндәге тасвирлама иң соңгы таләпләргә туры китереп эшләнгән:

***Галиуллин Т.Н.***

***Мәкер: повестьлар һәм хикәяләр*** */ Тәлгат Галиуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 302 б. – 2000 д. – ISBN 978-5-298-01725-1*

ISBNны, тираж санын тасвирламага кую соңгырак елларда гына гамәлгә керде, шунлыктан укучы һәр китап титулында да аларны очратмаска мөмкин. Басылу датасы узган чорларга караган китапларның тасвирламаларында Татарстан китап нәшрияты Татгосиздат; Тат. кит. нәшр. рәвешендә күрсәтелә, библиографиядә аларны шулай калдыру отышлырак, чөнки элек дөнья күргән китаплар китапханәләр фондында да шул ук формада тасвирланган.

Диплом яисә курс эше язучылар астөшермәләрдә кайвакыт, иренепме, таләпләрне белмичәме, Казан сүзен «К» хәрефе аша белдерә. Болай эшләү катгый тыела, чөнки ул очракта Казан шәһәре, әйтик, Киев дип фаразланырга мөмкин. Шуларны күздә тотып, редакторлар гомумкабул ителгән төрле тип кыскартулар исемлеге белән тәэмин ителә. Мәсәлән, М. – Мәскәүне, Л. – Ленинградны аңлата. Бер тамга ярдәмендә, гадәттә, зуррак калалар, пайтәхетләр билгеләнә. Әгәр тасвирламада охшаш авазга башланган барлык шәһәрләрнең атамасын баш хәреф белән генә язсак, кулланучы төрле кыенлыклар алдында калыр. Әйтик, әлеге калаларда уртак исем белән аталучы нәшриятлар да булса, укучыда, электрон почта аша теге яки бу китапка үтенечнамә-заказ юллыйм дигәндә, кайсы шәһәр басмаханәсендә чыккан соң, дигән сорау туачак.

Тасвирламада авторларны ике урында күрсәтүнең уңайлылыгына дәлил рәвешендә китапны эзләү юлларының артуын атыйлар иде, әмма интернет челтәрендә технологияләр,

мөмкинлекләр көннән-көн алга киткәч, моның мөһимлеге юкка чыкты.

7.01-2003 автор хокукын саклау тамгасына кагылышлы нормаларны кулланышка кертә һәм төп авторга, тәрҗемәчегә, төзүчегә, бизәүчегә, текст өстәмәләрен язучыга, наширгә, лицензиячегә, редакция-нәшрият хезмәткәрләренә карый.

Авторлык билгесенең хәрефләре XIX гасырда америкалы Ч. Кеттер төзегән, рус варианты Л.Б. Хавкина тарафыннан эшләнгән, һәм аны Татарстан Милли китапханәсе хезмәткәрләре татар алфавитына җайлаштырган. Әлеге тамга шулай ук китапханә кулланучыларының һәм хезмәткәрләренең эшенә уңайлыклар китерә. Китаплар киштәләргә аларга мөнәсәбәттә урнаштырыла, һәм заказлар шифрларга нигезләнеп үтәлә. Басма исемен, авторын дөрес язып та, авторлык билгеләрен яисә аларга таянып куелган саннарны билгеләгәндә хаталансак үтенечләребез канәгатьләндерелмәскә мөмкин.

Бер үк авторларның китаплары, төрле псевдонимнар астында чыкканда, китапханәче дә, укучы да, бигрәк тә библиографик белешмәлекләр төзүчеләр кыен хәлдә кала, чөнки авторлык тамгалары титул битендәге мәгълүматка таянып башкарыла. Титул стандартындагы хәреф элементы фамилиядәге беренче тамгага нигезләнә, хезмәт күмәк язылса, аны тәүгесенең фамилиясеннән алабыз.

Аерым бер китап битенең титулын карап узыйк:

*ББК 84.3 Тат*
*М.57*

***Фәрваз Миңнуллин. Талантлар юлы:*** *әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 272 б.*

*Әдәби тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллинның бу китабына бүгенге прозабыз, әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтьнең үсешенә караган мәкаләләре, шулай ук күренекле язучыларыбызның иҗат портретлары туплап бирелде. Аларда бүгенге әдәби процессның мөһим яклары яктыртыла, күп*

*кенә әсәрләргә анализ ясала. Җыентык әдәбият белән кызыксынучы киң катлау укучылар өчен чыгарыла.*

$$М \frac{4702510000}{М\ 132\ (03)–\ 84} 114–84 \qquad ББК\ 84.3\ Тат$$

*© Татарстан китап нәшрияты, 1984*

Укучым, бер үк саннарның, хәрефләрнең берничә урында кабатлануыннан чыгып, эчтәлекләренә үзең үк төшенгәнсеңдер. Әйтик, 1984, 84 саннары – әсбапның басылу елын аңлата, М – Автор фамилиясе башланган хәреф. Ике урынлы сан алда телгә алынган, алфавит тәртибенә нигезләнгән һәм фамилиянең ике-өч хәрефе буенча ачыкланган махсус таблицадан алынган.

Хезмәткә халыкара стандарт саны куелмаган. СССР да аны алу норма сыйфатында яшәмәде. Дөрес, хәзер дә авторлыгын дөньякүләм танытуны максат итмәгән басмалар еш очрый.

Ә менә Фәрваз Миңнуллинның 1994 елда чыккан «Балта явызлар кулында...» китабында халыкара стандарт саны түбәндәгечә: ISBN 5-298-00486-5. Биредә 5 – илне (Россия), аннан соңгы сан – нәшриятны (Татарстан китап нәшрияты) аңлата, чираттагысы – шул нәшриятта басылуның тәртип саны, соңгы цифр – тамганың дөреслеген тикшерү шифры.

Тәлгат Галиуллинның югарыда аталган китабының титул битенә 7.53-2001 халыкара стандарт саны ноктасыннан күз ташласак, Фәрваз Миңнуллин авторлыгында чыккан хезмәтнекенә туры килмәгән детальләр табарбыз, чөнки унөч цифрдан торган ISBN 2007 елдан кертелде, һәм ул штрих-код рәвешендә дә кабатлана.

Кайвакыт авторлык хокукы берничә затка, оешмага карый ала. Мәсәлән, Э.Р. Каюмованың «Татарская народно-песенная культура Нового времени: Проблемы традиционного мышления и жанровой атрибуции» дип аталган китабында ике

© тамгасы бар. Алар, ИЯЛИ АН РТ, 2005 һәм Каюмова Э.Р., 2005 билгеләре белән берлектә, авторлык хокукын ике субъектка нисбәтлиләр.

Әгәр без төрле елларда, бигрәк тә Үзгәртеп коругача һәм аннан соң чыккан басмаларны үзара чагыштырсак, нииндидер аермалыкларны күрми калмабыз. Төрлелек таләпләр үтәлешенең катгыйлыгында да чагыла.

Китапны формалаштырудагы барлык элементларда, мәсәлән, астөшермәләрдә дә нормалар үзгәрә, әмма еш кына авторлар аларны элеккечә калыплаштыруын дәвам итә. Бу очракта сноскаларга, библиографик аппаратка, эчтәлекнең урнашуына һәм башка кайбер элементларга куелган таләпләрнең катгый үтәлмәвен дә билгеләп узыйк. Интернет челтәре илне биләп алганнан соң, аннотация өлешендә, соңгы биттәге чыгыш мәгълүматларында авторны ике мәртәбә (инициаллардан яисә фамилиясеннән башлап) язуны да кайберәүләр, хәтта кечерәк нәшриятлар да, баштан ук мәҗбүри норма сыйфатында кабул итмәде. Тора-бара ул гамәлгә дә керә башлаган иде, әмма якын киләчәктә катгый үтәлер дип көтелгән әлеге язылыш, тасвирламалардагы кебек үк, катгый таләпләрдән алып ташланды.

Укучы, кертелгән үзгәрешләрнең кирәге юк дип уйлаганда, өстәмә мәгълүматларны иске традицияләр буенча калыплаштыруын дәвам итә. Нәшрият хезмәткәрләре исә, теләгән очракта, тиеш дип тапканда, аларны үзгәртә. Бу урында белешмәлекләрнең зур роль уйнавын билгеләргә кирәк, чөнки аларда еш кына элементларны формалаштыруның берничә варианты тәкъдим ителә һәм авторның шулардан берсен сайлап алырга хокукы барлыгы әйтелә.

Нәшрият эшчәнлеге түбәндәге стандартларга нигезләнә:

- басманы библиографик тасвирлама белән тәэмин итүгә;
- продукцияне классификацияләүгә (УДК);
- мәгълүмат алмашуга;
- ачык системаларга нисбәтле стандартларга.

Чыгыш саннары – күләм, тираж, формат, гарнитура; басмага кабул ителү, басылу вакытлары һәм реквизитлар – китапның соңгы битенә урнаша. 5773-90 тармак стандарты басманың үлчәменә бәйле таләпләрне куя. Хезмәтнең адресатына бәйле рәвештә кертелгән нормаларга хәреф сурәтен (гарнитура), тамга һәм шрифт (кегель) зурлыгын, багана арасындагы киңлекләрне, юл аралары биеклекләрен, юлларның озынлыкларын, тышкы кырларны, эчке чикләрне кертәбез. Әлеге үлчәмнәр бигрәк тә балалар өчен чыккан китапларда, мәктәп дәреслекләрендә катгый саклана. Аларга адресланган әсбаплар төсле форматта эшләнә, буяулар җетелегенә һәм сайланышына, сурәтләр ачыклыгына, аңлаешлылыгына нык игътибар ителә. Бу төр басмаларда әдәп-әхлак нормалары сакланышы да катгый бер таләп рәвешендә башкарыла.

29.106.90 (сурәт); 29.115.88 (текст); 29.124.94 (техник) стандартлары китап формасына караган таләпләрне үз эченә ала. 5773 – 90 стандарты нәшер итүнең максатын, адресатын, форматын билгели, ә инде 7.62 – 90 тармак стандарты корректура тамгаларын ачыклый.

Типография үтәргә тиешле таләпләргә йөзлекнең дөрес киселеше, битләр төпләнгәннән соң калырга тиешле кырлар киңлеге саклану, битләр тәртибе буталмау һ.б. керә. Дөрес, үз кул астында чыккан китапның техник эшләнеше өчен мөхәррир дә дә җаваплы. «Сигнал» нөсхәләре (берничә тәүге басма) килгәч, ул, үз чиратында, җентекләп карап чыга, танышу өчен барлык җаваплы кешеләргә, шул исәптән авторга да бирә. Шәхси нәшриятларның әлеге таләпләрне һәрвакыт үтәмәве – макет эшләнүгә үк, тулы тиражны басуы күзәтелә.

Дәүләт нәшриятларында стандартлар тупас рәвештә бозылмый диярлек, чөнки аның өчен җавапка тарту каралган. Күзгә ташланып торырлык хаталы нөсхәләр табылганда, кибетләр аларны кире кайтара. Соңгы елларда андый китапларның бәяләрен төшереп сату эше дә гадәткә керде. Басылып беткән хезмәттә төпләнгәнче табылган хаталар,

махсус кәгазьләрдә күрсәтелеп, иң ахырга куелып, башка битләр белән берлектә төпләнә.

Шуны билгеләп үтмичә булмый: бигрәк тә ризограф яисә башка аз санда тиражлау машиналары белән генә тәэмин ителгән, махсус белгечләр эшләмәгән шәхси нәшриятларда дәүләт стандартлары шактый еш бозыла. Кайвакыт альтернатив уку-укыту әсбаплары, ярдәмлекләре дә бу төр хезмәтләргә куелган таләпләргә тулысынча җавап бирми. Соңгы елларда моңа чик куела башлады. Элегрәк илкүләм таратылган дәреслекләрне белем бирү процессыннан читкә чыгару шуның бер дәлиле булып тора.

Кыска гомерле нәшриятларны каләм иясен дөньяга таныту, автор хокукын саклау, басманы сыйфатлы итү кебек проблемалар борчымый. Алар, аз чыгым тотып, күп табыш алырга тырыша. Һәммәбезнең текстлары тегелгән, битләре буталган яисә төбеннән купкан, буяулары кырылган, рәсемнәре төссез, тышлыклары таушалырга торган китаплар белән очрашканы бар. Каләм ияләренең басма продукциянең тиешле таләпләргә җавап бирмәвенә битарафлыгы мәсьәләсе дә хәл итүне сорый. Ә бит шәхси нәшриятлар тарафыннан да дәүләти стандартларның саклануын юридик рәвештә җайга салырга мөмкин.

Милли азчылык телендә басылган китапларга кагылышлы мөһим мәгълүматларның дәүләт телендә дә бирелүе шулай ук стандарт буларак билгеләнгән. Тәрҗемә китапларына, җыентыкларга, сайланмаларга, күптомлыкларга – һәрберсенә кагылышлы һәм үтәлеше мәҗбүри таләпләр бар. Алар белән, беренче чиратта, техник хезмәткәрләр яхшы таныш булырга тиеш, шуңа да карамастан басма өчен җаваплы редактор кулъязманың китап рәвешендә чыкканчыга кадәр узган юлына контрольлек итә.

**Редактор һәм автор.** Каләм иясе, хезмәтен тәмамлагач, эчтәлегеннән, жанрыннан чыгып, аны билгеле бер редакциягә яисә басманың тиражына, тибына бәйле специальләшкән

нәшриятка илтә. Баш редактор автор текстын иң тәүдә танышу йөзеннән укып чыга. Чираттагы аналитик уку авторга беренче искәртүләр ясарга мөмкинлек бирә. Боларны башкаргач, текст белән эш итәчәк редакция билгеләнә. Кулъязма баштан ук кайсы да булса редакция мөдиренә бирелергә, киләчәк язмышы хәл ителгәндә, аның фикеренә генә таянылырга мөмкин. Кайбер нәшриятларда яңа тапшырылган кулъязмалар белән махсус кешеләр шөгыльләнә, кайвакыт алар хәтта директор тарафыннан да карала.

Китапны басмага хәзерләү бурычы йөкләнгән редактор, автор белән үзенең диалог кору маһирлыгын күрсәтә, язучыны нәтиҗәле хезмәткә юнәлтә. Алар бергәләп текст концепциясен сайлыйлар, әдәби форманың һәм көтелгән продукция калыбының эчтәлеккә туры килүе турында сөйләшәләр. Редактор текстны аудиториянең ничек кабул итәчәген фаразлый.

Эшлекле хезмәттәшлек барышында автор һәм редактор үзләре башкарачак вазифаларны виртуаль алмаштырып карыйлар: бер-берсенең күзаллауларын һәм шул күзаллауларның логикасын аңларга тырышалар, бигрәк тә мөхәррир язучының шәхси стилен һәм әдәби зәвыгын кабул итәргә омтыла, язганына аның биеклегеннән һәм үз заманы мәдәнияте югарылыгыннан карый. Кыскасы, ул кулъязмаларга, иң беренче чиратта – авторның хаклыгы позициясеннән, автор исә редактор дөреслеге яссылыгыннан дәвам иттерелә.

Мөхәррир, тапшырылган кулъязма хакында ниндидер фикергә килгәннән соң яисә ике арада аңлашу булмаганда, берсенең карашын икенчесе кабул итмәгәндә, сөйләшүгә өченче кешене чакыра. Ул автор текстына редакция хезмәткәрләре һәм кулъязма иясе өчен генә эчке рецензия яза.

Алга таба эш рецензентның тәкъдимнәрен исәпкә алу я булмаса кабул итү сыйфатында – шуларга таянып, китапның яңа концепциясен эшләү, вакытлы матбугат аркылы хезмәтнең аерым өлешләрен апробацияләү рәвешендә бара ала.

Вакыйгалар башкача да борылыш алырга мөмкин: автор, хезмәтен тәүге үзгәртүне үзе башкармаса, редакторга тапшыра. Шуннан соң төзәтмә кертүче икенчесен камилләшкән кулъязма белән таныштыра, һәр үзгәрешне дәлилләп бирә. Бу вакытта, әйтик, редактор ике вариантны янәшә куя, теге яки бу проблеманы чишкәндә, автор карашларын һәм теләкләрен дә исәпкә алуын белдерә. Шушы сөйләшүдән соң мөхәррир каләм иясеннән хезмәтне тагын бер карап чыгуын, төзәтмәләргә риза яисә риза түгеллеген ачыклавын үтенә.

Редактор хезмәтендә тапталган юллар юк, һәр китапны хәзерләүгә төрлечәрәк ысулар белән якын киленә, чөнки кулъязмалар да, авторлар да бер-берсен кабатламый, язучының статусын, язу куәсен, талант мөмкинлекләрен дә исәпкә алмыйча булмый. Тәҗрибәле мөхәррирләр теләсә кайсы кискен хәлдән чыгу юлларын таба белә.

**Редактор һәм укучы.** Мөхәррир һәм укучы, автор һәм публика арасында һәрвакыт этик нормаларның саклануы кирәк. Еш кына журналистикадан ерак торучылар да редакцияләргә төрле тип язмалар – мәсәлән, басылып чыккан китапларга бәяләмәләр – җибәрә. Кайбер очракларда рецензияләрне, иясенә әйтми генә, нык үзгәртәләр. Әдип белән конфликтка кермәс өчен, әсәрен урынлы тәнкыйтьләгән өлешләрне дә кыскартырга, йомшартырга тырышалар, язма авторы галим түгел бит әле, ничек төзәтсәк тә ярар, дип уйлыйлар. Болай эшләү – бердән, әдәпсезлек, икенчедән, авторлык хокуклары белән дә тыела, өченчедән, язмага объектив якын килергә кирәк.

Әлбәттә, әдәби әсәр тирән эчтәлекле, сәнгатьчә югары эшләнгән булырга, ә китап сөюче аны дөрес бәяләмәскә һәм урынсыз тәнкыйтьләргә дә мөмкин. Шуны белгән килеш тә, редакторның теге яки бу хезмәткә тискәре бәя биргән рецензияне басарга тәкъдим итүе шулай ук дөрес эш булмас. Рецензент шәхесенә каты бәрелсә, әсәрен тупас-дорфа

тәнкыйтьләсә, хәлбуки вакытлы матбугат органы язмалардагы җитешсезлекләр өчен җаваплылыкны үз өстенә алмавы турында алдан махсус хәбәр иткәндә дә, каләм иясе, мәкалә авторыннан тыш, редакцияне дә хөкемгә тарта ала.

Башка төр очракларга да тукталыйк. Дөнья күргән китап, чыннан да, тиешле таләпләргә җавап бирми, һәм укучы аның җитешсезлекләрен бик оста тоткан ди. Бу очракта бәя бирүченең хаклыгын исәпкә алырга, әдиптән курку, аның каршында уңайсызлану хисен җиңәргә тырышырга кирәк. Әлбәттә, материал тупас тел белән иҗат ителсә, аны эшкәртмичә һәм этик нормаларга туры китермичә булмый, әмма әдәбияттан ерак торучы икәнлегенә карап кына, укучы язмасына тупас тыкшыну да килешми.

Кайвакыт әдәбиятны яхшырту, халыкка якынайту теләгеннән чыгып кына эш йөрткән гади укучының китапка бирелгән бәясе шәхси мәнфәгатьләрен күздә тотучан, үзара мөнәсәбәтләр басымынннан чыга алмаган, субъектив фикер йөртүче әдәбиятчыларныкына караганда гаделрәк була. Публика фикеренең әдипләр өчен мөһимлеген онытмаска, язманы вакытлы матбугат органында чыгарырга кирәк.

Тәнкыйтьләнгән хезмәтне башкачарак аңлаган редактор, рецензент карашлары белән килешмәгәндә, аңа оппонент була яисә китап иясен авторецензия язуга чакыра ала. Шулай да ул, мәкалә белән беренче танышканда, автор хаклылыгыннан чыгып фикер йөртергә, әйткәннәрен ныклап анализларга тиеш. Мөхәррир, шушы эшләрне башкаргач кына, иң башта кабул итмәгән карашларга үзенең гадел мөнәсәбәтен булдырырга, киләчәктә мөхәррирлек эшендә укучы киңәшләрен дә исәпкә алырга тиеш.

Редактор гамәлләрендә хезмәт урынына, материалны башкаручыга бәйле башка үзенчәлекләр дә бар. Нинди дә булса вакытлы матбугат редакциясендә укучылардан килгән хатларны эшкәртү белән нәшриятта танылган автор тексты өстендә эш арасында аерма бик зур. Гади укучы, журналист

һәм күренекле язучы газетагамы, журналгамы тапшырган язмаларның теле бер үк камиллектә булмый.

Укучылар катламы редакциягә даими рәвештә материаллар хәзерләүчеләрнекеннән дә чуаррак, аларның язу осталыгы да бер-берсенекеннән нык аерыла. Кемдер фикерен үтемле, төгәл һәм дөрес итеп оештыра алмый, кемдер темадан читкә китә, проблеманы ачык билгеләми, берәүләрнең кулланыштагы сүзлек байлыгы ярлы... Шулай да укучылар арасында шагыйрьләр, язучылар дәрәҗәсендә камил иҗат итүчеләр дә очрый.

Абунәчеләрнең китапларга мөнәсәбәте, бәяләмәләре әдәби барометр ролен башкарса, исәпкә алынса, нәшрият эшчәнлегендә дә, әдәби барышта да алга китеш күзәтеләчәк. Укучы хатларын туплау, анализлау, төрле гыйбрәтле нәтиҗәләр ясау – редакторга үз хезмәтендә бик кирәкле бер эш.

Герман Гессеның «Китап магиясе»ендә «Китап кешесе» («Книжный человек») дип исемләнгән язма бар. Автор анда укучы зәвыгының басма продукциягә кагылышлы яисә шәхси тормышындагы үзгәрешләргә бәйле алмашынуы хакында фикер йөртә. Башта, әйтик, кеше борынгы авторларның китапларын укый, алар акылына исе китә, өен төрле басмалар белән тутыра. Менә бервакыт ул, китап эзләп барган чагында, театрга кереп чыгарга була. Анда Шекспир пьесасын сәхнәләштергәннәр икән. Инде «китап кешесе» әлеге драматург әсәрләрен җыярга тотына, чөнки сәхнәдән яңгыраган автор фикерләренә таң кала. Антик әдәбияттан икенче чор әсәрләренә күчү өчен бердәнбер сәбәп була ул.

Бераздан укучы иске китапларга яңадан әйләнеп кайта һәм алардан элек алган ләззәтне тоймый, римлыларның, грекларның зәвыгын инде башкача кабул итә. Аптыраганнан үз чорының китапларын укып карый – алары вак нәрсәләр хакында язылгандай тоела, хикәяләү калыплары да әллә ни түгел...

Инсанның яңа әсәрләрдән тәэсирләнәсе, китап сүзенә кабат гашыйк буласы килә, эзләнергә керешә һәм норвегияле

язучы хезмәтләренә тап була. Кнут Гамсун үз дөньясын тасвирласа да, Шекспирга охшамаса да, әйткән сүзе вакыты белән аны шулкадәр үзенә ияртә ки, ул әле газаплана, әле көләргә тотына.

Тора-бара укучы башка әдипләр, башка әсәрләр белән таныша, әкренләп заман әдәбиятына күнегә. Өен яңа китаплар белән тутыра һәм көннәрнең берендә «кәгазь» яшәештә көн иткәнлеген аңлый.

Бу язманың гыйбрәтле фикере: чын тормыш бервакытта да әдәбиятта тасвирланган белән тиңләшә алмый, әмма укучы зәвыгы укыган әсәрләре белән турыдан-туры бәйләнештә.

Шул ук Герман Гессе «Китапханәне чистарту» («Чистка библиотеки») исемле язмасында үзенең, вакытлар үтү белән, хәтта атаклы әдипләр язганнар арасында да укучы өчен кирәксез хезмәтләр барлыгын аңлап, бик күп китапларны киштәләреннән алып атканлыгын әйтә. Ә бит ул чыгарып ташлаган басмалар арасында Гёте алышкан хат тупланмалары да, Бернард Шоу әсәрләре дә, Л. Толстой трактатлары да булган.

Герман Гессе кемнәргә бөтенләй кагылмый соң? Болар: Арним, Виланд, Стендаль, Монтень һ.б. Ул бигрәк тә соңгы ике язучының әсәрләрен үзе өчен бик кирәкле дип саный, рус әдәбияты ядкярләренең дә күпчелеген калдыра.

Укучы әдәби мирасханә туплаганда, мәкаләдән күренгәнчә, әсәрләрнең мәгънәсенә, сәнгатьчә эшләнешенә, дөньякүләм дәрәҗәсенә, үз зәвыгына карый. Герман Гессе, мәсәлән, сугыш турында китапларны иң түбән, бәһасез әдәбият саный һәм бөтенләй юк итә. Ул аларны очраклы рәвештә генә җыйган һәм егермедән бер өлешен дә укымаган булып чыга.

«И только через несколько дней, закончив, я увидел, как сильно изменилось за эти годы мое отношение к книгам. Выявились целые литературные жанры, которые я раньше по

дружбе терпел, а теперь расстался с ними смеясь. Выявились авторы, которых принимать всерьез больше нельзя»[1], – дип яза Герман Гессе.

Әлбәттә, кешеләрнең китапка таләпләре дә, сәнгатькә зәвыклары да туры килми. Шулай да укучысы аз яисә бөтенләй булмаган китаплар да юк түгел. Кибет киштәләрендә элек чыккан әсәрләре өелеп торса да, кайбер каләм ияләре, төрле юлларын табып, дуслыкларыннан файдаланып яисә үз акчаларына, һаман да китап бастыруларын дәвам итәләр. Базар шартларында бу хәлләр бигрәк тә дәүләт нәшриятларының эшчәнлегенә һәм матди базасына зыян сала; укучыларын аз гына да тапмаган авторлар, башкалар өлешенә кереп, әдәбият үсешен дә тоткарлый.

Редактор укучының зәвыгын алдан ук чамаларга, укылышлы һәм милләт өчен файдалы китапларны беренче чиратта бастыру мәсьәләсен җитәкчеләр алдына куярга тиеш. Ул бу очракта фикерен халыктан килгән хатлар, мөрәҗәгатьләр, рецензияләр һәм кибетләрдән алынган статистика мәгълүматлары белән нигезли. Укучының, шулай итеп, әдәби барышка да, китаптагы җитешсезлекләрне бетерү эшенә дә тәэсире зур була ала.

**Редактор һәм корректор.** Корректор, корректура терминнары да латин теленнән чыккан. Корректура бастыру, саклау, тиражлау өчен хәзерләнгән текстлардагы һәм график материаллардагы хаталарны төзәтү процессын, ягъни искечә эшләүче типографияләрдә җыелган текстлардагы җитешсезлекләрне бетерүне дә, компьютерда макетка салынган басмаларны төзәтүне дә күздә тота. Сүзлекләрдә аның компьютер материаллары өстендә дә эшләүне аңлаткан мәгънәләре әлегә юк.

Корректор, димәк – текстны төзәтү, өлешчә үзгәртү белән мәшгуль нәшрият хезмәткәре. Ул мөхәррир күрсәтмәләрен

---

[1] *Гессе Г.* Магия книги. – М.: Книга, 1990. – С. 76.

башкара, мөстәкыйль рәвештә дә редактор күрми калдырган, ялгышлык белән өстәгән орфографик һәм пунктуацион хаталарны таба.

Редактор һәм корректор мөнәсәбәтләре бер-берсенә ышануга, кеше хезмәтенә хөрмәт белән карауга нигезләнә. Мөхәррирнең үзенә күпмедер буйсынган һәм эшләренең сыйфаты аның белемлелегеннән дә торган кешеләр белән әдәпле сөйләшүе, үзен дөрес тотуы кирәк.

Редакторның биргән күрсәтмәләре – төгәл, кабул иткән карарлары – гадел, хаталарны юкка чыгару юллары һөнәри дәрәҗәдә сайланган булырга тиеш. Болар корректор хезмәтен тизләтәчәк, ә мөхәррирнең эшләнеп бетмәгән материалны корректорга тапшыруы икесен дә, бигрәк тә соңгысын авыр хәлгә куячак.

Һәм корректор, һәм редактор гомумкабул ителгән төзәтү кодлары белән генә эш итә. Бу билгеле бер хаталарны тиз, дөрес табарга, юкка чыгарырга булыша, хата төрләрен тәңгәл аңлауга китерә.

**Редактор хезмәтендә яңа технологияләр.** Яңа технологияләрнең барлыкка килүе мөхәррирлеккә һәм нәшрият эшчәнлеге системасына гаять зур үзгәрешләр кертте. Хәзерге вакытта авторлар, материал саклаучылар, әдәби мираска хокуклылар белән техник юллар, бигрәк тә электрон чаралар ярдәмендә бәйләнеш тоту матбугат хезмәткәрләре өчен мәҗбүри шарт булып тора, һәм аңа осталык профессиональ үсешкә алып килә.

Компьютер, ноутбук, планшет, кесә телефоннары, принтер, сканер, ксерокс, санлы фотоаппарат яисә диктофон һәм видеокамера кебек техник кораллар; интернет, кәрәзле яисә чыбыклы телефон челтәре, спутник телевидениесе һәм башка коммуникация чаралары; электрон язма төрләреннән саналган, күпсыешлы CD, DVD дисклар, флешкалар; төрле операцияләр башкарырга ярдәм итә торган программалар, аларның инструментлары рәвешендә хәтта шәхси өстәл

нәшриятлары барлыкка килә ала. Безнең заманда бу – татар дөньясында да киң таралган система.

Газетаны гасыр дәвамында төрле белгечлек ияләреннән (рәссам, техник редактор, фотограф, корректор, машинистка, җаваплы секретарь, тәрҗемәче...) оешкан күпсанлы редакция коллективы чыгарса, бүген әлеге эшне бик кыска вакыт аралыгында бер яки ике кеше дә башкарырга мөмкин, әмма редактор профессиясе бервакытта да яшәвеннән туктамый, бары тик универсальләшә, һәм аңа ия зат башка эш алымнарын да үзләштерергә мәҗбүр була. Мәсәлән, тәрҗемә программалары төрле телләрне яхшы белгән профессионаллардан баш тартуга китерә – компьютер ярдәмендә рус теленә күчерелгән язманы бары тик редактор гына камилләштереп бетерә. Әлбәттә, аның теге яки бу телнең грамматик кагыйдәләрен яхшы белүе бик кирәк. Кызганыч ки, татарчага тәрҗемә программалары эшләнгән булуга карамастан, аларның җитешсезлекләре шактый һәм шул сәбәпле дә алар киң кулланышта түгелләр.

Бизәлешне дә компьютерга тапшырырга мөмкин. Рәссамнар махсус программалар ярдәмендә эшләрен төрләндереп җибәрә, оригинальрәк итә ала. Дизайнерларның да төп инструменты бүгенге көндә – компьютер. Дөрес, кайбер редакцияләрнең бу үтә кирәкле һөнәр ияләре хезмәтеннән тулысынча баш тартуы, интернеттан алынган рәсемнәрдән, әзер калыплардан гына файдалануы, аларга үзгәрешләр кертмәве газеталарның үзара охшашлыгына китерә.

Интернет-газеталар, басмаларның электрон вариантлары һәм яңа технологияләр зур темплар белән нәшриятларга үтеп керә, әмма татар вакытлы матбугатында заман технологияләренең барлык мөмкинлекләре кулланылмый әле. Хәтта кече тиражлы газеталарны чыгарганда да өстәл нәшриятларыннан тулы файдалану җайга салынмаган. Бу проблеманың чишелеше еш кына киң профильле махсус белгечләр юклыкка кайтып кала.

Шәхси компьютерлар, интернет һ. б. автор хезмәтен нык кызулата. Текстны турыдан-туры клавиатурада иҗат итүче оригиналны каләм ярдәмендә язучыдан, күләм ноктасыннан караганда, нәтиҗәлерәк эшли. Аның тәүге кат хаталар төзәтүе дә тизрәк һәм мониторда гына бара, шунлыктан башкарган хезмәтен кат-кат карап чыгу өчен вакыты күбрәк кала. Ул төзәтүләрне язу белән янәшә дә үти ала. Әгәр каләм иясе дизайнерлык, рәссамлык яисә башка сәләтләргә ия икән, ул редакторга бу юнәлешләрдә дә үз тәкъдимнәрен кертәчәк, хәтта чыгачак китабын формалаштырырга, бизәргә дә мөмкин.

Заман технологияләре һәм чаралары барлыкка килгәнгә, басмаханә инструментларын хәтта аерым кешенең дә сатып алырга байлыгы җиткәнгә, эшчәнлек өчен лицензия алу җиңеләйтелгәнгә, бары тик бер затка, кече предприятиегә хезмәт итүче шәхси нәшриятлар барлыкка килде. Язганнары белән укучыны интернет аша гына таныштыручылар яисә исемнәрен популярлаштыручылар, китапларын сатучылар да юк түгел. Әйтик, прозаик Марат Кәбировның әдәби мирасы, танылган татар каләм ияләре арасында беренчеләрдән булып, шәхси сайтында урын алды, ул укучыга интернет аша тәкъдим иткән әсәрләр көннән-көн күбәя бара, һәм әдипнең китабын кулына төшерә алмаучылар әлеге сайттан актив файдалана.

Илфат Фәйзрахмановның – «Безнең гәҗит», Габделфәт Сафинның «Акчарлак» хезмәткәрләре, «Раннур»да басылучы күптөрле газеталарны чыгаручы коллектив һәм башкалар оештырган редакцияләр югарыда телгә алынган мөмкинлекләрне кулланып эшли. Татарча шәхси басмалар күпчелек очракта редактор-универсалларның хезмәт нәтиҗәсен чагылдыра.

Яхшы сортлы, җете ак кәгазьләрнең барлыкка килүе газаталарның да формасына зур тәэсир ясады. Дөрес, яңа шартларда вакытлы матбугат органнарының чыгымнары аңа бәйле дә шактый артты, әмма ул гомуми сыйфат аркылы үзен

аклады. Татарча укучылар мәйданы тарайганда һәм яңа технологияләрне куллануның башында теге яки бу басманың үзкыйммәте үсә, ә аны киметү эшен нәкъ менә аерым билгечләрне кыскарту, редакторларны киң профильле итү аша алып баралар.

Компьютерлар, төрле тип форматта басу, кисү, төпләү аппаратлары җитештерелү аркасында, газетаның, китапның мәйданын, бит санын үзгәртү мөмкинлекләре зурайды. Атналык, айлык басмалар янында ял сәгатьләрендә уку өчен чыгарылган һәм үлчәме моңа кадәрге стандартларга туры килмәгән вакытлы матбугат та барлыкка килде.

Әдәби редакцияләү хакында сүз йөрткәндә, оригиналларның электрон вариантларына куелган таләпләргә дә тукталмыйча булмый. Соңгы вакытта интернет челтәре аша таралган гыйльми газета-журналларның, җыентыкларның язмаларны бастыру шартлары үзара шактый охшаш. Таләпләр, нигездә, текстны биттә формалаштыруга, шрифт үлчәменә, төренә, авторлык тамгаларын кай урынга куюга, библиографияне калыплаштыруга, хезмәтне башкаручы хакында нинди мәгълүмат һәм ничек бирүгә кайтып кала. Потенциал авторларны кульязманың форматы хакында һәр редакция алдан ук искәртә. Кайберләре электрон вариантларны үзләренә илтеп биргәндә дә кабул итми, бары тик электрон почта аша гына җибәрүне таләп итә, бу мәсьәләдә беркемгә дә ташлама ясамый. Гыйльми матбугат органнарының хезмәткәрләре еш кына авторлар белән турыдан-туры аралашырга теләми, моны дөрес һәм кирәкле гамәл дип санамый. Алар мәкалә язмышын бәйсез экспертларга укытып, автор язмасы белән бергә килгән рецензияләргә таянып кына хәл итә яисә язманы чыгару-чыгармау проблемасын чишүне галимнәрдән төзелгән махсус редколлегиягә тапшыра.

Интернеттагы хезмәтләрне редакцияләүнең шулай ук спецификасы бар. Текстка, информатив форматка, мәгълүматның үзенә, материалны саклауга куелган таләпләр дә

үзгәрәк һәм сайт хуҗалары тарафыннан мөстәкыйль эшләнгән. Бу алардагы язмалар белән танышканда ук ачык күренә. Кызганыч ки, һәм русча, һәм татарча ачылган сайтларда чын мәгънәсендә коррекцияләнгән материаллар әлегә юк дәрәҗәсендә. Мәгълүматлар берсеннән-берсенә күчкәндә дә, күпчелек очракта хаталары төзәтелми.

Интернетта урын алган газеталар өчен материалларның электрон вариантта хәзерләнүе төп шарт булганга, заман эшне кызу тотуны таләп иткәнгә, каләм һәм карандашның роле көннән-көн кими бара. Хәзер «кульязма» төшенчәсе бик шартлы кулланыла. Ул күбрәк тәүге вариант гыйбарәсендә йөри. Каләм ияләре текстны баштан ук компьютерда җыюга тулаем күчеп килгәндә, аның ярдәмендә иҗат иткәндә, икенче төрле була да алмый. Шул ук вакытта кульязма төшенчәсе беренче һәм төп мәгънәсендә дә шактый вакыт яшәр әле дип фаразларга кирәк. Һәрбер өлкәдә инструментлар гасырлар дәвамында камилләшә. Текстны компьютер клавиатурасында җыюның да гомере мәңгелек булмаска мөмкин.

Электрон варианттагы кульязмаларның хаталары алда күрсәтелгән схема тәртибендә төзәтелә, аңа алдан ук фотолар, рәсемнәр сайлана. Редакциядә рәссам штаты булмаганда, автор, редактор яисә дизайнер үз архивыннан фотолар тапмаганда, хуҗаның бизәлешкә зур чыгым тотасы килмәгәндә, әмма материалларны бизәү, схемалар белән баету кирәк дип саналганда, тексттан тыш элементларны интернеттан гына алалар. Бу вакытта авторлык хокуклары бозылырга тиеш түгеллекне онытмаска, киң кулланылышка кертү тыелган байлыктан файдаланмаска, чыганакка сылтама ясарга кирәк. Рәсемнәрне камилләштерүгә килгәндә исә, моның өчен хәзергәчә иң оптималь саналган Photoshop программасы кулланыла.

Газетачылар киңәйтү кичергән (расширенные) фотолар белән эш итә. Аларның сыйфаты кечерәйтелгәндә – югалмый, ә зурайтылганда – тискәре якка үзгәрә. Фотоларны сайлау, сыйфатларын яхшырту буенча техник редакторларга,

версткалаучыларга (китапны биткә салучыларга) киңәшләр бирү редактордан сәнгати зәвыклылык, язма материалның эчтәлеген яхшы белүне таләп итә. Ул фотосурәтне урнаштыруга, зурлыгын һәм төсен көйләүгә мөнәсәбәтле дә үз фикерен белдерергә тиеш.

Газетаның макеты алдан ук әзерләнгән калып рәвешендә булмаса, аны башта кәгазьдә салырга яисә күңелдә генә тотарга мөмкин. Макет төзүче махсус программалар инде шактый. Кулдан ясалган калып буенча, материаллар битләргә урнаштырыла һәм электрон версиягә күчерелә. Газета-журналларны форматка салучы дистәгә якын вариантлы Adobe Page Maker – Windows системасында иң киң кулланылышта йөрүче программа. Нәшриятларда аның классик варианты хисапланган 6.5 санлысы кулланыла.

Электрон газеталар структурасында, традицион эшләүче вакытлы матбугаттагы кебек, почта, архив бар. Редакция составы берничә кешедән торганда, эш бүленешен чагылдыручы бүлекләр оештырырга мөмкин.

Архив килгән материалларны, дөнья күргән газеталарны саклый ала. Укучы язмаларын басылган һәм басылмаган материалларга бүлеп тупларга мөмкин. Иң яхшысы: аларны бүлек архивларында саклау. Дөрес, техника ватыла, шунлыктан дисклардагы, башка төр электрон туплавычлардагы архивтан да баш тарту дөрес булмас.

Газета махсус калыпта чыкса (ә бу, гадәттә, шулай) да, саннан санга кертелгән ниндидер үзгәрешләр кулланучыларның игътибарын җәлеп итәргә, укучыда һәрвакыт кызыксыну уятып торырга, басмага язылучылар санын да арттырырга мөмкин.

Мәкаләләрне биткә салганда даими рәвештә уртак шрифт кулланыла. Ул, бер яктан, эшне тизләтә, икенчедән, материал күләмен алдан чамаларга ярдәм итә. Текстлар эчендә шрифт үлчәмнәре, колориты бердәй була һәм мәкалә, шигырь, хикәя исемнәрендә әһәмиятлелегенә, төп текстның күләменә

мөнәсәбәттә сайлана. Атама материал уртасында гына түгел, аның сул яки уң ягында да урын алырга мөмкин. Рубрикалар, төрле авторларга караган язмалар сызыклар белән аерымлана.

Электрон газеталар чыгарганда да, хатаны кәгазьдә төзәтүдән тулаем баш тартырга ярамый, чөнки мониторда бар җитешсезлекне дә күреп бетерү мөмкин түгел. Әнә шуңа күрә, газета биткә салынгач, аларны принтер аша А4 форматта бастыралар, текстны тагын бер кат күздән кичерәләр, очраган хаталарны төзәтәләр.

Интернет челтәре аша гына таратылмаганда, газета постскриптум файлларга яздырылырга, аннан күләм ягыннан кечерәк һәм әзер басма сүз саналган акробат төргә күчерелергә, типографиягә тиражлау өчен тапшырылырга мөмкин. Хәзерге вакытта хәтта өй шартларында да газетаны, китапны тиражлау мөмкинлекләре зур: кибетләрдә кисүче һәм төпләүче инструментлар, җиһазлар бар.

Электрон газеталарны хатадан арындыруны кәгазьдәге текстны камилләштерү тәртибендә алып барырга кирәк. Бу формада мәгълүмат таратканда иҗатчы әхлагын, журналистларның төрле оешмалары тарафыннан кабул ителгән нормаларны һич кенә дә истән чыгарырга ярамый. Интернет челтәрендә ил кануниятен бозу очраклары әлегә күп күзәтелә, әмма гаеплеләрне табу һәм хөкем итү эше дә җайга салына бара.

## Өченче бүлек

# ӘДӘБИ РЕДАКЦИЯЛӘҮНЕҢ ГОМУМИ ТӘРТИБЕ

**Текстны анализлау һәм төзәтүнең билгеле бер схемасы, методикасы.** Текст өстендә эш ***эчтәлек һәм композиция белән танышу***дан башлана.

Хезмәтне тәүге тапкыр кулга алгач, мөхәррир үзен гадәти укучы кебек үк хис итә. Аңа әле әсәрдән тәэсирләнү, эчтәлегенә, аны ирештерү юлына гомуми бәя бирү һәм шуларга мөнәсәбәт булдыру мөһим. Ул автор тапшырган кульязманы, мондый хезмәт укучыга кирәкме, аның укучысы булырмы, кебегрәк сораулар куеп укый. Аларга уңай җавап биргәннән соң, текст белән яңабаштан, бөтен игътибарын туплап, инде тирәннән таныша.

Икенче этапта редактор әсәрнең һәрьягын анализларга тырыша, бигрәк тә әдәби эшкәртелү дәрәҗәсен бәяли. Моның өчен җөмләләр төзелешенә игътибар итә, авторның грамматикадан белемлелеген ачыклап бара, әмма әлегә хаталарны төзәтү эшенә керешми. Ул нәкъ менә икенче кат уку барышында язучының моңа кадәр үзенә чит тоелган стиленә күнегергә, хәтта аны бик тә якын итәргә, шул стильне тудыру юлларын җитешсезлек түгел, авторга хас үзенчәлек дип саный башларга мөмкин.

Редакторларның беренче укуда ук, орфографик һәм пунктуацион хаталарны төзәтә-төзәтә, текст белән танышканнары да очрый. Ул кешенең холык сыйфатларына, хәтта бала чактан ук күнеккән эш стиленә дә бәйле. Шулай да текстны камилләштерүне аталган тәртиптә башкаруның дөрес түгеллеген тагын бер кат ассызыкларга кирәк. Вак хаталарга

игътибар бирү зуррак хаталарны күз уңыннан читкә җибәрә, әсәрне гомуми планда дөрес бәяләүгә комачаулый. Бу – ризыкның тәмен исәпкә алмаган, әмма өстәлгә бирелешенә игътибар иткән пешекче гамәле белән бер.

Композицияне бәяләмәгән килеш, сөйләмне стилистик коррекцияләү артык эш булып чыгарга мөмкин. Бәлки, текстның нәкъ менә сез тикшереп чыккан җире кыскарыр, аңа тиеш дип табылган яңа абзацлар кушылыр, өлеш урыннары алмаштырылыр, һәм инде әсәргә хәтта хаталар өстәлер яисә авторның әлеге эшләрне башкаруы вакытында җөмлә төзелешләренә дә күпмедер үзгәрешләр керер. Ул чагында тыныш билгеләрен дә яңадан ныклап карарга туры килер.

Редактор, әсәрне укып чыккач, иң башта аның автор билгеләгән жанр, тип, төр үзенчәлекләренә җавап бирү-бирмәү мәсьәләсен куя. Бу проблеманы чишмичә һәм адресатны ачык билгеләми торып та, ул кулъязманы төзәтү эшенә керешми. Татар әдәбиятында ниндидер жанр тамгасы салынган, әмма аның сыйфатламаларына җавап бирмәгән әсәрләр бихисап. Бу күренеш, әдәбият тарихын язганда, дөрес булмаган нәтиҗәләр ясауга китерә. Әйтик, соңгы вакытта повестька якын торган, роман булып җитмәгән әсәрләр күбәя, дигән фикерләрне еш ишетергә туры килә. Бәлки, аларның берише – чынлыкта повесть кынадыр, ә автор хезмәтен халыкка роман дип танытырга телидер? Мондый очракта, әлеге әсәрләрне укып, башта кайсы жанрга карауларын ачыкларга кирәк. Кулъязманы басмага хәзерләгән редакторларның аңа тупланган нәфис текстларның жанр формасын төгәл билгеләүне авторга гына йөкләүләре дөрес түгел. Алар һәр әсәрнең төзелешенә, төп сыйфатламаларына игътибар бирергә, кирәк очракта, автор билгеләмәсен кире кагарга да тиешләр.

Мөхәррирләр кайвакыт үзләре дә, нәфис текст сыйфатламаларыннан чыгып, аның хикәягәме, повестькамы, романгамы каравын зур авырлык белән билгели. Син, әдәбият галиме буларак, язган хезмәтеңнең нинди жанрга кергәнлеген

төп-төгәл беләсең, шулай тамгалыйсың, ә менә китабыңны хәзерләүче фикерең белән килешми, хәтта ризалыгыңны да сорап тормыйча, аны повесть дип әйтәсе урынга – хикәя, ә хикәя дип әйтәсе булганда – повесть дип атый. Күпчелек очракта әлеге төгәлсезлекләр редакторларның жанрны билгеләүдә күләмгә таянуларыннан, ә жанрны ачучы төп сыйфатларны игътибарга алмауларыннан килә.

Әдәбият белеменең жанрларга мөнәсәбәттә гомумкабул ителгән терминологиясендә бервакытта да күренмәгән төшенчәләрнең соңгы вакытларда еш очравы – шулай ук каләм ияләрен һәм мөхәррирләрне борчырлык күренеш. Бу хәл күбрәк, әдәби калыплар кичергән үзгәрешләрдән битәр, авторның теориядән белемсезлегенә, галимнәр һәм редактор фикере белән исәпләшмәвенә, нәфис текстның кайсыдыр ягына басым ясарга теләп, яңа терминнар «уйлап чыгаруы»на барып тоташа. Кайвакыт әсәрнең теге яки бу жанр сыйфатламаларына тулысынча ия булмавы да редакторга төрен ачыклауда кыенлык тудыра.

Романның повестька якыная баруы һәм инде XX гасыр башында ук бары тик повестьлар гына калачагы яисә юка романнар гына язылачагы хакындагы кискенрәк яңгыраган фикерләрне заманыбыз кире какты. Әлбәттә, яшәү ритмы тизләнгәндә, кешенең күләмле хезмәтләр белән танышырга вакыты калмый, ул бер утыруда укып чыгарлык әсәрләрне кулына күбрәк ала, әмма романнар ятучылар да бөтенләй юкка чыкмый. Һәрхәлдә, алар әлегә бар. Шул ук вакытта повесть-хикәяләрнең торган саен күбрәк язылуы, укылуы белән дә килешергә кирәк.

Эпик материал булганда күләмле әсәрләр туачагын ике гасыр чигендә Җ. Рәхимов, В. Имамов, К. Кәримов һәм башкаларның күпсанлы романнары раслады. Иҗат юнәлешенең киң катлам укучы зәвыгы һәм ихтыяҗы белән генә билгеләнмәвен, автор мөмкинлекләренә, теләгенә, чагылдыру өчен сайланган, тупланган материал таләпләренә, аның эчтәлек

киңлеге һәм тирәнлегенә бәйлелеген дә онытырга ярамый. Иҗтимагый катаклизмнар, милләт язмышында тетрәнүләр чорында я шул узып китүгә үк, күләмле әсәрләр аеруча күп языла. Халык кичергән фаҗига-афәтләр хакында тирән фәлсәфәле, мәйданлы яктырткан хезмәтләр иҗат итүне талантлы һәм милләтпәрвәр каләм ияләре гражданлык бурычлары дәрәҗәсендә саный. Соңгы ике гасыр чиге моның шулай икәнлеген раслады.

Үз заманында борчылып чаң сугучылар булса да, повестька якын торган романнар саны әлегә артык күп түгел. Аларны укып чыкканннан соң, чыннан да, эшнең еш кына, роман сыйфатлары үзгәрүдә булмыйча, авторның үзе язган әсәр жанрын дөрес билгеләмәвендә икәнлегенә игътибар итәсең. Роман дип аталып та, бары тик повесть кына саналырга хаклы әсәрләр арасында Флүс Латыйфиның «Хыянәт»ен, Марат Әмирхановның «Тәкъдир»ен күрсәтергә мөмкин. Шәхси фикерләвем буенча, алар романга тартмый. Әдәбият турында сөйләшкәндә, «Тәкъдир»нең титул битендәге тамгага күз ташламыйча, повесть сыйфатында телгә алуларына игътибар иткәнем булды. Мәсәлән, бер студент чыгарылыш квалификациясе хезмәтенең буеннан-буена әсәрне повесть дип атаган иде. Бу хакта искәртү ясагач, дипломчы комиссия әгъзаларына, роман дәрәҗәсендәге катлаулы һәм тармаклы сюжет юк ич анда, дип каршы төште. Әгәр хәтта, язучыга һәм галимнәргә каршы барып, студент та шулай дип әйтә икән, димәк, уйланырлык урын бар.

Жанры дөрес ачыкланмаган әсәрләр саны татар әдәбиятында, гомумән алганда, шактый һәм алга таба тагын да артыр сыман. Бигрәк тә хикәя һәм повестьларны, поэмаларны шушы яссылыкта анализлап чыгарга кирәк. Әйтик, Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәре повесть таләпләренә туры килә сыман, ә хикәя дип билгеләнгән, әнә шуңа күрә берәүләр аны хикәя дип йөртә, икенчеләр повесть буларак телгә ала.

Рус филологиясен тәмамлаган кайбер белгечләрнең, милли әдәбиятыбызга үтә үзенчәлекле якын килеп, бигрәк тә Ә. Еники әсәрләренә, аерым алганда «Әйтелмәгән васыять»кә таянып, татарда хикәя янәшәсендә «озын хикәя» дигән махсус, башка халыкларныкыннан аермалы жанр бар, дигән «табыш»лары, шул табышларны терминологиягә кертергә маташулары әнә шул сәбәпле килеп чыга да. Белемле редактор әдәби әсәрләрнең жанрын дөресли яисә композициясенә һәм күләменә үзгәрешләр керттерә ала һәм керттерә дә.

Әлбәттә, ике жанр арасында торган әсәрләр дә була. Аларны кайсыдыр якка үзгәртү текст бөтенлегенә, аның сәнгатьчә эшләнешенә зыян салырга мөмкин. Жанр сыйфатламаларын һәрвакытта да нык ачыклап бетерүне автордан таләп итү кирәкмидер. Монда автор хокукы да истә тотылырга тиеш. Икенче яктан, нигә әле ике жанр арасындарак торган әсәрләрнең яшәргә хакы юк, дигән сорау да туа. Прозаны хикәя, повесть, романга бүлү нигезләрен галимнәр билгеләгән, әгәр һәрбер әсәр алар тәкъдим иткән бүленеш таләпләренә төгәл җавап бирми икән, жанрлар классификациясе проблемасына, бәлки, яңадан әйләнеп кайтырга кирәктер? Шул ук вакытта ниндидер төркемчәгә каравы бәхәссез әсәрләрнең икенчесенә кертелүе белән килешү дә ярамас.

Әсәрләрне классификацияләүдәге кыенлыкларны аны икенче стандартларга салып карау аша чишәргә мөмкин, чөнки жанрларны төркемләвебез дөнья әдәбиятларында танылган, гомумкулланыштагы бүленешкә бик үк туры килми. Әгәр без күләмле прозаны ике генә төркемдә күрсәтүне гамәлгә куябыз икән, повестьлар хикәя һәм роман арасында «эриячәк». Дөрес, ул чагында русча һәм татарча терминологик белешмәлекләрдә ике жанрны билгеләүче төшенчәләрнең мәгънә эчтәлегенә үзгәреш кертергә туры киләчәк.

Филологик белемле редактор аталган проблеманы жанр формасына куелган таләпләрне истә тотып чишә ала, билгеле. Автордан эчтәлекне һәм композицияне камилләштерүне,

аларга теге яки бу үзгәрешләр керттерүне мәҗбүри башкарту – шуның бер юлы, әмма язучыда каршылык тудырырга мөмкин юлдыр.

Инде редакторның кулъязмага адресат ноктасыннан якын килү проблемасына киңрәк тукталыйк һәм бу хакта мисаллар ярдәмендә сүз алып барыйк. Татар телендә китап бастыручы барлык нәшриятлар да теге яки бу хезмәтнең кем өчен икәнлеген һәрвакытта да күрсәтми, ә бит моны басмаханә эшчәнлеге нормативлары катгый таләп итә. Дәүләт басмаханәләрендә моңа игътибар тиешле дәрәҗәдә, әмма шулай да адресат һәрвакыт дөрес ачыклана дип булмый. Мәсәлән, Р. Мингалимнең «үсмерләр өчен пьесалар һәм хикәяләр» рәвешендә чыккан «Шүрәлеләр үч алмый» китабын кулга алуга ук, әдипнең әкият характерындагы пьесалары билгеләнгән аудитория өчен кызыклы микән, дип уйлап куясың. Китап белән танышкач, чынлыкта да, андагы артык гади әсәрләрне түбән сыйныф укучылары гына яратып укыр кебек тоела.

Җыентыктагы «Бер сызгырсам» дип аталган шигъри драманың адресатын ачыклау кыенрак. Фәлсәфәсе, язылу рәвеше белән, өлкәннәр әдәбиятына тарта, каһарманнар системасы, сюжеты үсмерләргә якындыр шикелле, мифик геройлы аерым күренешләре кече яшьтәге балалар, түбән сыйныф укучылары өчен язылган әкият-пьесаларны хәтерләтә.

Әдипнең «Соңгы чиктә» шигъри драмасын балаларга түгел, үсмерләргә дә аңлау шактый авыр. Хыял тудырган образлар катнашындагы вакыйгалар тасвирлануы белән, мәктәп яшендәгеләргә кызыклыдыр да, әмма теле катлаулы, фәлсәфә артык тирәнгә яшерелеп бирелә, образлы рәвештә җиткерелә, укучының киң мәгълүматлылыгын, эрудитлыгын таләп итә. Ярар, үсмерләр өчен дип кабул да итик ди...

«Самолётлар» хикәясенең адресаты олылар гына була аладыр. Бик җитди проблемалар күтәрелә, реаль тормыш вакыйгаларын фәлсәфи кабул итәрлек өлгергәнлек кирәк.

«Яшел күзле әнкәем»нең үсмерләргә юнәлгәнлеге исә бәхәс уятырлык түгел.

«Шүрәлеләр үч алмый» – юка гына хезмәт. Ул ничек тә китап чыгарырга кирәк бер чакта, Р. Мингалимнең балалар һәм үсмерләр өчен язылган әзер әсәрләре азлыктан, аннан-моннан тартып-сузып җыелган тупланма кебегрәк фикер уята.

«Шүрәлеләр үч алмый»ның соңгы битенә русчага тәрҗемәдә «издание для детей и юношества» дип куелган. Монысы әле әсәрләрне үз эченә күбрәк ала икән... Ә бит китапның төре, адресаты татарча да, русча да тәңгәл билгеләнергә тиеш... Тагын бер фразага тукталыйк һәм аның татарчадан отышсыз тәрҗемә ителгәнлеген билгелик: «Пьесы для подростков и рассказы». Китапның беренче әсәрләре – үсмерләргә, калганы теләсә кемгә атап язылган, диюме бу? Шунда ук сорау туа: редактор кая караган?

Әлбәттә, балаларның һәм үсмерләрнең примитив эчтәлекле, һәркемгә ачык аңлашылып торган китаплар гына укуы мәҗбүри түгел, әмма адресат һәрвакыт ачык билгеләнергә тиеш. Ә укучы өлкәннәр өчен язылганны сайлыймы, башкасынмы – аның эше. Ул һәркем өчен индивидуаль: кешенең белеменә, талантына, әдәби зәвыгына, төрле яктан өлгергәнлек дәрәҗәсенә карый.

Югары сыйныфларда гына түгел, башлангычта да әкиятләрне дә, хәтта әле балалар һәм үсмерләр әдәбиятын да укырга яратмаучылар очрый. Кайберәүләр, бик иртә хәреф таныганлыктан, укырга кергәнче үк, фольклор белән күп танышып, әдәбиятны өйрәнүдә тәүге баскычны узган һәм олылар өчен язылган китапларны укый башлаган була. Бу һәр сәнгать төрендә шулай. Кайбер дөньякүләм танылган композиторлар һәм музыкантлар да, мәсәлән, дүрт-биш яшьтә әле нота да белмәскә мөмкин, шул яшьтә хәтта бик катлаулы музыкаль әсәрләр башкаручылар, халык алдында чыгышлар ясаучылар, дөньякүләм фестивальләрдә катнашучылар

һәм җиңүчеләр дә очрый. Кеше төрлечә өлгергән кебек, анда талант та төрле вакытта ачыла, зәвыгы да үзенә генә хас була.

Хезмәтне яратачак аудитория составын ачыклау һәрвакытта да җиңел түгел. Бигрәк тә әдәби әсәрләрнең кайсы яшькә караганлыгын билгеләү авыр. Бүгенге мәктәп дәреслекләреннән чыгып эш йөртсәң генә дә, редакторларның һәм хәтта авторларның баланың уйлау дәрәҗәсен күзаллаудан шактый ерак торганлыгын күрәсең. Дәреслекләрне югары уку йортында эшләүчеләр язса, гадәттән тыш катлаулы, терминнар белән чуарланган тел булыр, мәктәп баласы өчен кирәксез информация тутырылыр. Ул эшне укытучыларга тапшырсаң, алар эчтәлекне артык җиңеләйтү ягын карар.

Совет чоры дәреслекләренең уңай яклары бик күп иде. Авторлар күбрәк җирле материалга, балаларга таныш дөньяга таянырга тырышты, алган белемнәрнең тормышта кирәклегенә басым ясады. Хәзер, мәсәлән, биология фәненнән балага үз гомерендә бервакытта да күрмәячәк, исемен дә ишетмәячәк җан ияләре турында сөйлиләр, әле бөтен сүзлекләргә дә кертелеп бетмәгәннәре хакында тестлар төзиләр. Фикерләү үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча, иҗтимагый фәннәр буенча бик катлаулы дәреслекләр язалар. Озак еллар дәвамында балалар, яшьләр белән эшләгәндә аларның дәрестә узган материалны олылар уйлаганча кабул итмәүләре, үзләренчәрәк аңлаулары күренде. Бу контроль эшләр вакытында да, әңгәмәләр барышында да ачыла.

Югары уку йортларына керүчеләр өчен МДУ (МГУ) галимнәре хәзерләгән һәм 2006 елны «Зерцало-М» нәшриятында М.Н. Марченко җаваплылыгында чыккан «Обществоведение» ярдәмлеге бар. Аннан репититорлар хәзер дә актив файдалана. Хезмәтнең беренче битләрен ачуга ук, студентларга аталган лекцияләрдән генә тупланган икән, дигән фикергә киләсең. Ә бит укырга керүчеләр өчен программа буенча язылган! Укытучылар балаларга «Җәмгыять белеме» фәнен мәктәп дәреслекләре буенча үзләштерүнең

дә кыенлыгын сөйли. М.Н. Марченко редакциясендәге китап исә алардан дистәләрчә тапкыр катлаулырак, авыррак. Ярдәмлекнең бик күп җөмләсе мөһим, еш кына – ятларга тиеш кагыйдә дәрәҗәсендә. Һәр бите мәгълүмати тыгыз, фәнни терминнарга мул; җитмәсә, күп җире алынмалар белән чуарланган. Һәм нәкъ менә чит сүзләр фәнне аңлауны, аңлаганны сөйләп бирүне кыенлаштыра да.

Яхшы укучыларга, тиешле белем запасына ия балаларга әлеге китаптагы фикерләрнең күпчелеге аңлашыладыр да, ә бит авторлар тарафыннан алар фәнни мәгълүмат тыгыз тутырылган текстны балалар тулаем истә калдырыр, имтихан вакытында яңадан сөйләп бирер дип тә фаразлана. Шуны да исәпкә алыйк: хәзерләнү өчен ярдәмлек рәвешендә генә «кыскача» башкарылган хезмәт вак хәрефле 666 биттән тора! Гадәти, уртача бәяләнерлек гыйлем туплаган балага түгел, тирән белемле чыгарылыш укучысына да бу кадәр күләмле текстны тулысынча хәтердә калдыру мөмкин түгел.

Мөхәррир әсәрнең адресатын билгеләү гамәлендә, беренче чиратта, интуициясенә, тормыш тәҗрибәсенә таяна. Бала чагында нинди китаплар укыган, үз балалары нәрсәне аңлый, нәрсәне аңламый һ.б. Редакцияләгәндә, тексттагы сүзлек составын исәпкә алу бик мөһим. Җиде-ун яшьлекләр өчен язылган әсәрләр артык абстракт булырга тиеш түгел. Метафоралары тыгыз урнашкан, берсенә-берсе ялганып килеп, баскычлы ассоциацияләр тудырган нәфис әдәбият әле өлкәннәргә дә җиңел аңлашылмый, мәктәп укучыларына да шулайдыр дип уйларга кирәк. Бүгенге көндә татарча китапларны инде кулланыштан төшеп килгән гарәп-фарсы алынмалары белән дә тутыра алмыйбыз. Бигрәк тә шәһәр кешеләренең актив кулланыштагы татарча сүзләр байлыгы аз булганда, авторга – моны истә тотып язу, ә редакторга кульязма белән эшләү шактый кыен.

Поэтик җыентыкның адресаты кечкенә балалар икән, текстларның сюжетлы, шаян мәгънәле, ачык эчтәлекле булуы

яхшы. Шул ук вакытта балалар өчен шигырьдә дә образлы сүзгә урын калырга тиеш. Сабыйларны баштарак – таныш, аннан гадәти үк булмаган эпитетлар аша, көндәлек тормышта ишетелгән асмәгънәле конструкцияләрне кулланып кына, әдәби дөньяга әкренләп алып керергә кирәк. Бу урында Бари Рәхмәт, Саҗидә Сөләйманова, Шәүкәт Галиев кебек шагыйрьләрнең баланың яшь үзенчәлеген яхшы күзаллауларын билгеләп узасы килә.

Адресатны ачыклауны, әгәр ул билгеләнгән булмаса, мөхәррир авторның алдан ук кемне күздә тотып язганлыгын сораудан башлый. Кайбер шагыйрьләр һәм прозаикларның әсәрләре үз балалары яисә оныклары белән «олыгая бара». Аларга үз гаиләләрендә күзәтелгән күренешләр, бергәләп кичергән хәл-вакыйгалар әдәби материал сыйфатында хезмәт итә, улларына һәм кызларына хас сөйләшү рәвеше әсәрләренең теленә тәэсир ясый. Балалар әдәбиятын иҗат иткәндә реаль тормышка нигезләнү бигрәк тә кирәк.

Фәнни яисә фәнни-популяр әдәбият чикләрен ачыклау шулай ук анда чагылыш тапкан информациягә һәм стильгә бәйле. Киң катлам укучыга юнәлтелгән гыйльми ачышлар хакындагы хезмәтләрдә сөйләм мавыктыргыч, кызыклы булса яхшы. Анда, бер яктан, инде хак дип табылган материал күбрәк урын ала, икенче яктан, күпмедер күләмдә фаразлар да җиткерелә, әмма аларның фараз икәнлеген укучы аңларга, канун, чынбарлык рәвешендә кабул итмәскә тиеш.

Фәнни әдәбияттагы материалга карата да әйтер тәнкыйть сүзе бар. Мәктәпләр өчен чыгарылган «Введение в литературоведение» кебек уку әсбапларын кулга алгач, кайвакыт аларның төрле «Әдәбият теориясе» китапларыннан «күчкән» материаллардан торуын аңлыйсың. Димәк, авторлар балаларның психологик үзенчәлекләрен исәпкә алмаганнар, аларны югары уку йортында белем бирүчеләр һәм аларның шәкертләре янәшәсендә күргәннәр, текстларны яңа адресатка яраклаштырмаганнар.

Кече яшьтәге балалар өчен дәреслек язучылар аларда урын алырлык материал юклыгыннан зарлана. Бу төр хезмәтләрне башкарганда, авторлары белән килешеп, катлаулырак тоелган текстка үзгәрешләр кертергә кирәк. XX гасыр башында бу шулай эшләнгән дә. Балалар өчен тупланмаларга хәтта олыларга атап язылган әсәрләрдән өзекләр урнаштырганнар, әмма гадиләштергәннәр, кирәксез дип табылган яисә катлаулы өлешләрне кыскартканнар. Мәсәлән, балалар өчен чыккан басмада Гаяз Исхакыйның «Арган атлар» хикәясе бар, ә бит ул – әдипнең «Мулла бабай» романыннан өзек. Мондый мисалларны тагын да китерергә булыр иде.

Гомумән алганда, редактор текстны түбәндә күрсәтелгән тәртиптә редакцияләргә мөмкин.

***1. Әсәр композициясенә бәйле эш.*** Кулъязма төзелешенә характеристика бирү; төрен, жанрын, жанр формасын, адресатын билгеләү; текст композициясенә һәм басманың гомуми структурасына якын килү концепциясен эшләү; композиция элементларын, төп принципларын, алымнарын ачыклау, аңа җавап бирмәгән урыннарны камилләштерү.

***2. Атама сайлау.*** Хезмәт исеменең эчтәлеккә туры килүенә, яңгырашлылыгына, мәгънәви тирәнлегенә ирешү.

***3. Текст телен камилләштерү.*** Эчтәлек җиткерүнең хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү, аңлату кебек яисә катнаш характердагы юлларын ачыклау, бәяләү ; аларның үзара ярашуын, гармоник көчешен тәэмин итү.

***4. Материалны логик ягын тиешле дәрәҗәгә китерү.*** Сөйләмне фикер эзлеклелеге ноктасыннан характерлау һәм җибәрелгән хаталарны юкка чыгару. Тулы текстка, өлешләренә, синтаксик конструкцияләргә, аларның үзара бәйләнешенә стилистик ноктадан бәя бирү; стилистикага кагылышлы җитешсезлекләрдән котылу.

***5. Фактлар белән эш.*** Сөйләм лексикасын күзаллау, лексик төркемнәрне барлау; сүз кулланудагы хаталарны бетерү,

төшенчә һәм категорияләрнең мәгънәләрен төгәл ачыклау; саннар белән җиткерелгән мәгълүматны дөресләү.

***6. Тел-сурәтләү чаралары өстендә эш.*** Әдәби бизәкләрне стильгә белән яраштыру, кирәкмәгәннәрен алып ату, отышлылары белән алмаштыру, аларның аңлаешлы кулланылышына ирешү, хата төзәтүләр вакытында барлыкка килгән үзгәрешләрнең төгәл калыпларга салган зыянын юкка чыгару.

***7. Текстны компьютерда һәм кәгазьдә төзәтү.*** Әсәрнең аерым өлешләрен компьютерда алмаштыру, кыскарту, үзгәртеп кору, артык лексемаларны төшереп калдыру, сүзләр язылышын һәм тыныш билгеләрен дөресләү. Бу вакытта һәр гамәлне төзәтү принципларына һәм үзгәреш кертүгә куелган техник таләпләргә нигезләү. Компьютер программалары ярдәмендә дә хаталарны тагын бер кат барлау һәм киметү.

Кәгазьгә кабат чыгарылган текстны редакцияләү. Хезмәтнең биттә урнашуына, форматына һәм башка төр формаль таләпләргә җавап бирү-бирмәвенә игътибар итү.

Корректорларның, техник хезмәткәрләрнең берничә этаптагы эшеннән соң, китап битенә салынган текстны урнашу, бизәлеш, форма зәвыклылыгы ноктасыннан бәяләү; басма продукция өчен җаваплы башка кешеләр белән берлектә эш итү.

Дөрес, югарыда тәкъдим ителгән һәм киң кулланыштагы схема текстне камилләштерүдә катгый тәртип түгел. Редакцияләү этаплары, аларның эчтәлеге нәшрият структурасы, эчке тәртипләр, коллективта кабул ителгән вазифалар бүленеше, кайвакыт автор һәм нәшрият арасындагы килешү белән билгеләнә. Шунысы ачык: китап өчен җаваплы мөхәррирнең, кульязманы соң ноктасына кадәр камилләштергәнче, басарга дип кул куюга җиткергәнче, продукция хәзерләү барышын күз уңыннан чыгармавы мәҗбүри.

**Әсәр композициясенә бәйле эш.** Теге яки бу гамәлләрне ниндидер схема рәвешендә күрсәтү – билгеле ки, катлаулы барышны гадиләштерү ул, чөнки бигрәк тә әдәби редакцияләү вакытында текстны һәр планда төзәтү авторны һәм

мөхәррирне яңадан башка төр корректировкаларга алып килә. Сөйләмне камилләштерү әнә шуңа күрә бер үк юлдан кат-кат әйләнеп йөрүгә тиң. Кайберәүләр, бигрәк тә язучылар әдәби текст белән берьюлы һәр планда да эшлиләр, чөнки аны тулаем һәм детальле күз алдында тоталар.

Әдәби текст белән эшләүнең төрле тәртипләре булса да, аның әсәр композициясен камилләштерүдән башланганы кулайрак. Әсәр композициясенә бәйле эшнең гомуми схемасын тагын бер кат искә төшерик. Бу:

• кулъязма композициясенә сыйфатлама бирү: хезмәтнең төрен, жанрын, жанр формасын, адресатын ачыклау;

• текст композициясенә һәм басма продукция структурасына якын килү концепциясен эшләү;

• композиция элементларын, төзелешнең төп принципларын һәм алымнарын ачыклау;

• композицияне жанр таләпләре ноктасыннан камилләштерү.

Алдагы өч баскыч редакторның кулъязма белән танышу этабына караса, соңгысы аның автор, җитәкчелек, техник хезмәткәрләр белән берлектә башкарган һәм күп вакыт сораган төрле эшләрен үз эченә ала.

Мөхәррир хезмәт композициясенә бәйле эшенең тәүге баскычында материалга беренче мәртәбә формальрәк рәвештә күз ташлый. Әгәр оригинал нәшрият куйган таләпләр кысасында башкарылмаганлыкны күрсә, форматка мөнәсәбәтле туган барлык сорауларына җавап тапмаса, ул аны, дөрес калыплаштыру өчен, шунда ук иясенә тапшырырга мөмкин. Әйтик, бүгенге көндә редакторлар инде аннотация язу, эчтәлекне эшләү, җыентыкның гомуми төзелешен ачыклауны да язучыга йөкли.

Чисталамалар белән генә эш иткән басмаханәләрдә редактор шрифт калыбына, биеклек-киңлегенә, калынлыгына, юл арасына, текстны биткә салуга, сәхифә саны куелу урынына, форматка һәм бик вак башка техник якларга игътибар итәргә

мөмкин. Шуннан соң ул һәрбер битне, өстән-өстән генә булса да, чисталык, ачыклык ноктасыннан бәяләп чыга. Кайбер нәшриятларда редакторлар корректор эшен дә башкара, һәм, хаталы битләрне барлаганнан соң, кулъязманы авторга кире эшләү өчен кайтара. Бу очракта без бизәлеш, китап композициясе турында сүз алып бардык. Кулланучыларга традицион рәвештә хезмәт күрсәтүче нәшриятларда боларны теге яки бу китапны чыгару өчен җаваплы редактор һәм техник редактор, рәссам башкара, ә инде редакторның композиция өстендә эшенә текстка анализ ясау һәм аны композиция ноктасыннан камилләштерү керә.

Сәнгатьтә, әдәбиятта һәм тел белемендә композицияне анализлау аерым бер юнәлеш дәрәҗәсенә җиткән. Редактор да, кулъязма белән эш иткәндә, текстка нәкъ галим кебек якын килә: төзелешен, состав өлешләрен, аларның фикер һәм хис җиткерүдә, әсәрне бөтен итүдәге ролен, үзара бәйләнешләрен өйрәнә, композиция чараларына автор әйтергә теләгән фикерне җиткерүгә хезмәт итәләрме дигән ноктадан күз ташлый.

Текст композициясе дигәндә, әсәрнең гомуми төзелешен, структурасын, күзгә ташланырлык калыбын барлыкка китерүче һәм теге яки бу мәгънәгә ия фрагментларның эчтәлеген какшамас бәйләүче, links бербөтен итүче эзлеклелеген күздә тоталар, әнә шуңа күрә композиция төшенчәсе турында сүз йөрткәндә, аны тел формасын эчтәлек белән бәйләүче универсаль категория дип атыйлар да.

Композиция ярдәмендә текстны тәшкил итә торган җөмләләр чылбыры мәгънәви бербөтен булып оеша. Композиция – ул формаль күренеш түгел, сөйләм формасын һәм эчтәлекне үзара бәйли торган универсаль категория, ди В.И. Максимов[1].

[1] Стилистика и литературное редактирование: учебник / под ред. проф. В.И. Максимова. – М.: Гардарики, 2007. – С. 521.

Композиция термины латин теленнән (componere) алынган һәм төзү, урнаштыру мәгънәләрен аңлата. Текст композициясе язма өлешләренең урнашу тәртибе булып чыга. Әдәби әсәрдә ул сюжетны, геройларны, детальләрне, сөйләмне билгеле бер тәртиптә сала, үзара беркетә һәм автор концепциясенә буйсындыра.

Композицияне камилләштерүче редактор күз уңында өч проблеманы тотарга тиеш. Беренчедән, ***тема тулысынча ачылганмы?*** Әгәр юк икән, димәк, аңа яңа состав өлешләре кертеләчәк яисә текст идея эчтәлеге ачылырлык дәрәҗәдә камилләштереләчәк: җөмләара бәйләнешләр, җөмләләрнең мәгънәви эчтәлекләре үзгәртеләчәк; структур өлешләрнең урынын алмаштырып та, эчтәлекне ачыклый төшәргә мөмкин.

Композициягә әйтелгән яссылыкта якын килгәндә үк, ***материалның логик эзлеклелек*** проблемасы чишелә башлый. Шул ук вакытта икенче мәсьәләне хәл итү редакторны әсәрне укучыга ***эмоциональ һәм әдәби яктан тәэсирле*** җиткерү этабына якынайта. Детектив әдәбиятны гына искә төшерик. Традицион сюжет композициясеннән баш тартып, әсәрне төенләнештән яза башлау укучыда кызыксыну уята, аның аңын нигә, кем, ни өчен уйлары белән ахыргача кыбырсытып тора.

Шигъри әсәрдәге төрле тип кабатлаулар, символистлардан ук килгән яңгыраш һәм хис чиратлашулары, аваз-хәрефкә мөнәсәбәтле уйланмалар һәм башка композицион-әдәби чаралар мәгънә җиткерүдә искиткеч зур хезмәт үти. Бигрәк тә кечкенә күләмле язмаларда композиция күзгә нык ташлана һәм текстның мөһим бер аспекты булып тора, аның каравы күләмле әсәрләрне форма ягыннан оештыру каләм иясеннән талант һәм тоем, тырышлык кебек сыйфатлар таләп итә. Үзе язучы булмаган мөхәррир өчен композиция проблемасын чишү – гаять тә катлаулы бер эш.

«Композицион алымнар әсәрнең мәгънәсен тирәнәйтә, еш кына үзгәртә дә. Шулай ук әсәр кабул итүне оештыра,

аны аңлауга юнәлеш бирә»[1]. Димәк, автор, нәфис әдәбиятны эшкәрткәндә, текст формасына караган барлык элементларның бербөтен итеп җыелган хәленә ирешергә һәм, әгәр теге яки бу состав өлешләре автор концепциясенә (идеягә, фикергә) буйсындыру өчен хезмәт итмәсә, кулъязманы иясенә кире кайтарырга, үзе үзгәрешләр керткән очракта, ни өчен шулай эшләгәнен аңлатып бирә алырга тиеш.

Текстны төзелеш ноктасыннан камилләштергәндә дә, редактор аның адресатын, һичшиксез, күздә тота. Балаларга, үсмерләргә, өлкәннәргә атап язылган хезмәтләрнең структурасы бер үк була алмый. Шул ук кроссвордлар һәм шарада, ребус кебек фикер-хәтер үстерү уеннарын алыйк. Әйтик, кроссвордлар өчен сайланган сүз-гыйбарәләр күп вакыт теге яки бу һөнәри һәм гыйльми өлкәгә карый, сораулар да – фәннирәк куела яисә төшенчә билгеләмә рәвешендә белдерелә. Димәк, чишү өчен шактый катлаулы. Сканвордларның адресаты – гавам. Аларны еш кына компьютер программалары төзи, шунлыктан бер үк сүзләрнең сканвордтан сканвордка кабатлануы еш очрый. Балалар өчен сканвордларга мультфильм, сугыш турындагы кино геройлары, яшелчә һәм хайван исемнәре, уенчык атамалары... кертелергә мөмкин.

Текстлы ял уеннарының формалары төрле катлаулылыкка ия, һәм әлеге калыплар куелган проблемаларны чишә алу-алмауда, ягъни сөйләм берәмлекләрен табуда бик зур роль уйный.

Әсәр композициясенә куелган таләпләр эчендә өлешара мөнәсәбәтләр саклану, төзелеш элементларының эзлеклелеге, урынлы кулланылышы, ягъни үзара төгәл бәйләнеше, бәйләнешләрнең нигезләнгәнлеге һәм башкалар бар. Редактор, хәтта ятланып беткән калыплы рәсми текстлар белән эш иткәндә дә, төрле тип инструкцияләрне камилләштергәндә

[1] Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / төз.: Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 77.

дә, өлешләргә, хәтта абзацларга-юлларга бүлүне дә механик үтәмәскә тиеш.

Эчтәлек формалаштыруда зур роль уйнаган композициянең төп алымнары сыйфатында охшашлыкны, тәңгәллекны, капма-каршылык нигезендә янәшә яисә каршы куюны күрсәтергә кирәк. Композициянең мондый принциплары фольклордан ук килә.

Редактор композицияне ике яссылыкта – әсәрнең тышкы формасыннан, ягъни текст структурасыннан һәм эчке ягыннан, ягъни эчтәлегеннән чыгып тикшерә. Төзелеше катлаулы, калыплары төрле, идея мәгънәсе тирән, эчтәлеге киң булган әдәби әсәр композициясен камилләштерү шактый кыен. Бигрәк тә күләмле хезмәтләр, әйтик, повесть һәм романнар белән эш иткәндә, структур өлешне бер җирдән икенчесенә күчерү, төшереп калдыру һәм башка төрле гамәлләр текстны шактый нык үзгәртә. Әлеге гамәлләрне башкарганда, стильгә, сюжет элементларының урынына бәйле килеп туган проблемаларны чишәргә һәм башка моментларны истә тотарга кирәк.

Строфаларның урыннарын алмаштыру ярдәмендә дә поэтик әсәрне бөтенләй башкача яңгыратып була. Шигырьне камилләштерүдә гади, әмма иң отышлы юлларның берсе исә – сәнгати эшләнеше түбән өлешләрне кыскарту. Кайчакта ул әсәрне шактый оригинальләштерә. Дөрес, аерым очракларда төрле кыскартулардан соң строфаларның үзара бәйләнешләре югалырга, йомшарга, элекке гүзәллекләре кимеп киткәндәй тоелырга мөмкин. Шунысын онытырга ярамый: хезмәткә структур яссылыкта нинди генә үзгәреш кертсә дә, мөхәррир аны кабат игътибар белән укырга, яңа шартларда барлыкка килгән җитешсезлекләрне юкка чыгарырга тиеш.

Композициягә кагылышлы гамәлләр аркасында, төп өлешнең атама белән ярашуы проблемасы да килеп туарга мөмкин. Кайвакыт шигырь нәкъ менә атамада чагылган темага сыймаган урыннарны алып ату юлы белән камилләшә.

Кыскарту үзе үк үлчәмне үзгәртү дигән сүз. Бәлки, аннан соң текстны яңа өлешләргә бүлгәләргә яисә аңа бөтенлек төсмере бирүче икенче өлешләр өстәргә, кабатлаулар һәм башка төрле формаль бәйләнеш элементлары кулланырга кирәк булыр.

Инде редакторлар тарафыннан камилләшкән дип саналганнан соң нәшер ителгән, сайламыйча гына кулга алган китаптан һәм аның шулай ук очраклы ачылган битеннән шигырь китереп узыйк. Фәнис Мотыйгуллинның «Сердәш төннәр» җыентыгындагы «Хушлашабыз, ахры, иртәрәк…» әсәре ул. Лирик герой иң соңгы строфада чыгарачак нәтиҗәнең җөмлә рәвешендә әсәр атамасында чагылыш табуы укучының шигырьгә карата кызыксынуын күпмедер сүрелдерә дип саныйбыз. Инде аның үзе белән танышыйк:

*Бүтән сиңа язмам, дигән идем,*
*Хатларым гел моңсу булганга.*
*Элек тә мин язган идем бары*
*Сагышлардан күңел тулганга.*

*Алларыңа чыкмам, дигән идем,*
*Уңсын, диеп, барыр юлларың.*
*Тик бәхетле иттеме соң сине*
*Миннән башка үткән юлларың?*

*Очрашулар эзләмәгән идем,*
*Очраштык без күңел тулганда.*
*Без иртәрәк, ахры, хушлашканбыз,*
*Йөрәкләрдә сөю булганда.*

Бер караганда, строфаларның шушы тәртиптәлегеннән бернинди зыян юк кебек. Шул ук вакытта, исем аркасында интрига юкка чыкканлыктан, соңгы строфаны алга күчерү, нәтиҗә ясатырлык эш-хәлләргә таба хәрәкәт итү отышлырак булыр, ул чагында шигырь бермә-бер кызыкланыр кебек. «Очрашу»лы ике строфаның башта һәм ахырда килүе аның бөтенлек сыйфатын куәтләндереп җибәрәчәк, текстны каймаландырачак, аерым бер мотивны дәвамлы итәчәк.

Җитмәсә, көтелмәгән очрашу турында текст башында ук бирелгән хәбәр, алга таба хис-кичереш хәрәкәте кай якка таба үсәр микән, кебегрәк сорау да уятачак.

Шигырьнең башка җитешсезлекләре дә юк түгел. Әйтик, рифмалар бик тапталган, тәүге һәм соңгы строфада охшаш кушымчага ия «булган-тулган» сүзләренә корылган. Уртадагысында рифманы исем төркемчәсенә караган «юлларың» төзегән. Редактор боларга, һичшиксез, игътибар итәргә тиеш иде.

Шигырьнең тәүге строфасын янәшә куеп булмый торган ике җөмлә формалаштырган сыман. Әлеге янәшәлек фикерне буталчыкландырган, һәм монда аңлатуы шактый кыен каршылык тоемлана. Интуитив сизелгән җитешсезлекнең нәрсәдә икәнлеген ачыкларга тырышып карыйк. Тәүге җөмләдә үк лирик мин юллаган хатларының һәрберсе моңсу икәнлекне әйтә. Алай икән, чираттагы җөмләдә каһарман, үзүзенә каршы төшкәндәй, элек тә шулай иде, дип белдерергә тиеш түгел. Соңгы ике юлның шушылай яисә башка бер рәвештә яңгыравы дөресрәк булыр: *Электән үк яздым, әйе, бары // Сагышлардан күңел тулганда.*

Эчтәлеккә күбрәк игътибар бирсәк, лирик миннең, бер яктан, сагышлы килеп чыккан хатлар язарга теләмәвен, икенче яктан, сагышлы чагында шундый гына хатлар язылганлыгын белсә дә, бу эштән туктамавын күрербез. Элек тә язган, хәзер дә дәвам итә. Тәүге строфа укучыда, нигә соң әле сагышланган саен лирик мин хат яза, кебегрәк сорау тудырса яхшырак түгелме? Моның өчен, текстка нибары бер хәреф (н) өстәп, сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше тудырырга мөмкин. Шулай да без башкача эшлик һәм өченче юлны күпмедер үзгәртик:

*Бүтән сиңа язмам, дигән идем,*
*Хатларым гел моңсу булганга.*
*Электән мин яздым сиңа бары* (яисә: *чөнки*)
*Сагышлардан күңел тулганда.*

Авторның тәүге строфасы лирик миннең адресатны бөтенләй яратмавы, сагышлы чагында гына, юаныч рәвешендә генә искә төшерүе турында сөйли, ә шигырь логикасы буенча, ул нәкъ менә аны өзелеп ярәтканга, шул хистән сагышланганга күрә хат язган булырга тиеш иде. Бу төр җитешсезлекләрдән кисәкчәләрне үзгәртү юлы яисә башка чаралар ярдәмендә котылырга мөмкин.

Шигырьдә иң игътибарга алынырлык өлеш – икенче строфаның сорау җөмләсе. Әсәрнең шунда тәмамлануы яңгырашны, текст белән танышканнан соң калган тәэсирне көчәйтеп җибәрәчәк һәм, шигырь тәмамлангач, укучыны уйга да салачак.

Автор текстын бик нык камилләштермичә, икенче вариантын тудырып карыйк – лексик кырны шул килеш диярлек калдырып, төп үзгәрешне текст композициясенә, җөмлә төзелешенә, тыныш билгеләренә кертик:

*Очрашулар эзләмәгән идем…*
*Очраштык без күңел тулганда.*
*Без иртәрәк… иртә (!) хушлашканбыз –*
*Йөрәкләрдә сөю булганда.*

*Бүтән сиңа язмам, дигән идем,*
*Хатларым гел моңсу булганга –*
*Мин аларны язган идем сиңа*
*Сагышлардан күңел тулганда.*

*Алларыңа чыкмам, дигән идем,*
*Уңсын, диеп, барыр юлларың…*
*Әйт: бәхетле иттеме соң сине*
*Миннән башка үткән елларың?*

Әсәр күзгә күренеп яхшырды. Әлбәттә, ул шигъриятебездә күтелмәгән оригинальлек белән аерылып тормый, әмма һичьюгы укылышлыга, тәэсирлегә әйләнде!

Нәфис әсәр төзелеше турында сүз йөрткәндә, аның кайсы әдәби төргә, төркемгә каравын исәпкә алмыйча булмый.

Эпик формаларны тәртипкә китерүче редакторлар түбәндәгеләргә игътибар итә:

• персонажларның катнашу тәртибенә, ягъни авторның каһарманнар системасы белән оста эш йөртүенә;

• хәлләр, вакыйгалар чиратына – ә бу сюжет композициясендә чагылыш таба;

• хикәяләү формасындагы автор стиленә бәйле күренешләргә;

• детальләр, геройлардан тыш образлар композициясенә;

• стиль алымнарына, ягъни сөйләм композициясенә;

• сюжеттан тыш элементларның оешу тәртибенә.

Нәфис әсәрләргә хас төзелеш һәм рус, һәм татар галимнәре тарафыннан җентекле өйрәнелгән, аның хакында бихисап гыйльми хезмәтләр язылган. Шул ук вакытта бездә, кайсы яктан гына карасаң да, бик чуар, төрле манерада иҗат ителгән газета материаллары, бигрәк тә синкретик характердагы публицистик язмалар композициясе турында тирәннән һәм мисаллы сүз алып бару юк дәрәҗәсендә. Сәбәбе – бу эшнең шактый кыенлыгында. Матур әдәбият, фән һәм публицистика кисешкән мәйданда яшәгән әдәби тәнкыйть материалларының элементлар бәйләнеше дә җентекле өйрәнелмәгән.

«Идел» журналының 2018 елгы март санынннан Анастасия Ивановaның КФУ доценты Ләйсән Арсентьева хакындагы язмасына күз ташлыйк. Сөмбел Әхмәтҗанова тәрҗемәсендә бирелгән әлеге хезмәт һәм ул урын алган сәхифә төзелешенә мөнәсәбәтле кайбер фикерләребез белән уртаклашыйк. Язманың Керешендә чыгарылыш (сан) герое хакында кыскача мәгълүмат китерелә. Ул һәм фоторәсем битнең яртысын алып тора, мәкаләнең калган өлеше чираттагы биттә тәмамлана. Төп текст, хәрефләрне калынайту ярдәмендә, сигез кисәккә бүленгән. Кызыклы гына алым да кебек, әмма юка шрифтлы юллар махсус аерып куелганын һәрвакытта да ачмый, киңәйтми, күбрәк алда яңгыраган фикерләрне һәм

сүзләрне кабатлый. Бер үк вакытта алар арасында күләм мөнәсәбәте дә отышлы түгел.

Укучы язманы күпмедер күзалласын өчен, мәкаләдән ике өлешне карап узыйк:

*ГЛОБАЛЬ ШЕЙПЕРЛАР БЕРЛӘШМӘСЕ – ЯШЬ ЛИДЕРЛАРНЫ ГЛОБАЛЬ ПРОЦЕССЛАРГА ҖӘЛЕП ИТҮ ҺӘМ УРТАК ИНИЦИАТИВАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ӨЧЕН ОЕШТЫРЫЛГАН БӨТЕНДӨНЬЯ ПЛАТФОРМАСЫ.*

*Һәр елны Global Shapers Community инициативасы әгъзалары арасында Бөтендөнья икътисади форумга сайлау үткәрелә. Бу лоторея билеты белән бер: анда дөньядан илле кешегә генә форумда катнашу мөмкинлеге бирелә. Быел мин Русиядән бердәнбер катнашучы булып, әнә шул илле бәхетлеләр исемлегенә кердем.*

*ФОРУМДА КАТНАШУ – ҮЗ ТАВЫШЫҢНЫ ЗУР ДӨНЬЯГА ИШЕТТЕРҮ, ҮЗ ИЛЕҢНЕ, ВАТАНЫҢНЫ ТАНЫТУ МӨМКИНЛЕГЕ ДӘ.*

*Форумда кагылып үткән глобаль сораулар даирәсе киң иде, ләкин алар барысы да икътисад белән бәйле булды: илләрнең көндәшлек сәләтенә, һөнәр сайлауга, кешенең тормышын үзгәртүгә бу тенденцияләр ничек йогынты ясар – шул хакта фикер алыштык.*

Күргәнегезчә, ике кече кисәкне берләштерергә һәм кабатланган сүзләрдән арындырырга кирәк. Алынмаларның гаять күплеге, бертөрлелеге күзгә ташлана. Текстның күпчелек өлешләре әңгәмәче исеменнән аның алга таба үстереләчәк фикернең башы кебек калыплашкан. Бу урында да аны саклау отышлы булыр, чөнки автор яңадан шул формага күчә. Ләйсән, сораулар мәйданы киң иде, дисә дә, артыннан ук аның тарлыгын дәлилләүче факт китерә. Текстны, күпмедер камилләштереп, алынмалардан, кабатланган һәм әһәмиятсез сүз-гыйбарәләрдән, логик-грамматик чатаклыклардан бераз арындырып карыйк:

*ГЛОБАЛЬ ШЕЙПЕРЛАР БЕРЛӘШМӘСЕ ФОРУМЫНДА КАТНАШТЫМ.*

*Әлеге берләшмә яшь әйдәманнарны дөньяви барышка җәлеп итү һәм уртак гамәлләрне тормышка ашыру өчен оештырылган. Һәр елны Бөтендөнья икътисади форумына аның әгъзаларыннан вәкилләр сайлыйлар. Лоторея билеты белән бер ул, чөнки анда илле кеше генә катнаша. Быел мин Русиядән бердәнбер вәкил булдым – бәхетлеләр исемлегенә кердем.*

*Форум үз тавышыңны зур дөньяга ишеттерү, илеңне, ватаныңны таныту мөмкинлеге тудыра. Катнашучыларга бирелгән сораулар икътисад өлкәсе белән чикләнде: илләрнең көндәшлек сәләтенә, һөнәр сайлауга, кеше тормышын үзгәртүгә йогынты ясаган шартлар хакында фикер алыштык.*

Редакцияләнгән текст алдагы ике өлешнең бер генә фикерен, мәгънә төсмерен дә киметмәде, ә менә күләм ягыннан күзгә күренерлек кыскарды. Язма, тулаем шул юл белән камилләштерелгәндә, рәсеме кечерәйтелгәндә, бер биттә урын алган хәбәрчек кенә булып калачак. Кызганыч ки, күпчелек татар журналистлары үз язмаларында, кызыклы фикерләре булмаса да, күләм артыннан куып, буш яза.

Структурага куелган таләпләрне, редакцияләү алымнарын белү генә текстны төзелеш яссылыгында камил итүгә китерми. Композициянең ниндилеге әсәрнең гомуми идея-сәнгатьчә эшләнешенә дә барып тоташа, ә ул исә авторга, аның мөмкинлекләренә, талант дәрәҗәсенә, зәвыгына бәйле. Бер генә редактор да автор өчен китапны яңадан язып утырмый, ә бары киңәшләре белән ярдәм итә. Икенче яктан, мөхәррир, текстны аз гына үзгәртеп тә, тәэсирлелек һәм аңлаешлылык дәрәҗәсен бермә-бер арттырып җибәрергә мөмкин.

Монографик пландагы фәнни хезмәтләрне редакцияләүчеләр текст эчтәлегенә бик тыкшынмый, әмма алар галимнәргә фикерне артык катлаулы җиткерү хас икәнлеген

күздән ычкындырмаска тиеш. Текст композициясенә гап-гади үзгәреш кертеп – хәтта абзацларны ваклап та, аның укучыга ныграк аңлашылуына ирешергә мөмкин. Бигрәк тә фәнни җыентыклар белән эш йөрткәндә, редактор галим күзаллаган китап концепциясеннән хәбәрдар булырга, аны ошатмаганда, альтернатив вариант тәкъдим итәргә тиеш.

Гыйльми тупланмалар уртак теманы төрле яктан ачкан язмалардан яисә бер-берсеннән ерак торган проблемаларны яктырткан мәкаләләрдән оешырга мөмкин. Икенче очракта, композиция үзгәрешләренә бәйле рәвештә, хезмәтнең атамасы да үзгәргәли. Кайчагында фәнни җыентыкка мөһим теманы ачкан, актуаль проблемаларны чишкән мәкалә исемен куялар. Әгәр ул тупланмадан төшереп калдырылса, икенче атама эзләргә туры килә. Статьялар нindидер тематик ояга карамаса, китапка исем биргәнен я алга чыгару, я үзәккә кую отышлырак дип карала.

Кайвакыт эчтәлек ноктасыннан үзара ерак торган текстларны да бергә туплау принципларын уйларга кирәк була. Әйтик, автор китапны иң күләмле мәкалә исеме белән атаган һәм аның отышлылыгын берничек аңлата алмаган ди. Шәхси карашына нигезләмә тапса, редактор аны, һичшиксез, үзгәрттерергә тырышачак. Ул, мәсәлән, автор тапкан вариантны мөһим бүлектәге, кечкенә булса да, төп һәм актуальрәк идеяне яктырткан язма исеме белән алмаштырырга мөмкин. Дөрес, китап дәүләт нәшрияты планына теге яки бу атама белән кергән икән, инде аны үзгәртмәячәкләр, шул сәбәпле әлеге мәсьәләне план кабул ителгәнче чишәргә кирәк.

Җыентыкларда фәнни һәм публицистик язмаларны жанр формасы, күләм буенча да, тасвирлау объектына, стильгә, текстларның язылу вакытына бәйле дә төркемлиләр, һәм мөхәррир үз эшендә композиция принципларының төрлелегенә омтылырга тиеш.

Редактор, үз эшен гадиләштерү һәм аңлаешлы калыпка кертү өчен, текст планнары төзи. Андый сызымнар теләсә

кайсы хезмәт урыннарында башкарыла. Әйтик, проспект план. Бу мөгаллимнәрнең, галимнәрнең үзләре укыткан фәннәре буенча тематик планнарына охшаган, чөнки шулай ук гомуми структура һәм эчтәлекне күрсәтүне максат итә. Проспект планнар нәшриятларда һаман да актив кулланыла. Мәсәлән, төрле тип календарьларның, юбилей уңаеннан бастырылган буклетларның, методик ярдәмлекләрнең һәм башкаларның проспект планнары була. Алар еш кына редактор тарафыннан төзелә һәм социаль заказ рәвешендә теге яки бу хезмәт язучы авторлар кулына алдан ук тоттырыла.

Нәшриятларда шулай ук ниндидер серия рәвешендә чыгучы китапларның, күптомлыкларның проспект планнары эшләнелә. Кайвакыт әлеге гамәл кулъязма авторларына, мәсәлән, галимнәргә тапшырыла. Алар хәзерләнгән сызма, ягъни башлангыч рәвешендәге хезмәт коллектив тарафыннан тикшерелә, бәясен ала һәм камилләштерелә. Андый планнар – басма продукция өчен акча түләүче тарафыннан башкарылырга, тәкъдим ителгәне – бәяләнергә, заказ рәвешендә редактордан яисә башка бер белгечтән эшләтелергә дә мөмкин.

Икенче төрле эш тәртибенең караламасы кулъязма план дип атала. Редактор аны текстны уку барышында хәзерли һәм структур өлешнең эчтәлегенә, төзелешенә бәйле кимчелекләрне үзенә кулай тәртиптә билгели. Бу төр гамәлне башкару өчен, автор китергән кулъязманың мәгънәви-структур нигезен табарга кирәк. Әлбәттә, һәр мөхәррир үз хезмәтендә аталган эш этапларын башкарып чыга дип кистереп әйтеп булмый. Без нәшрият редакцияләрендә электән урнашкан, әмма хәзер бигрәк тә шәхси басмаханәләрдә катгый куелмаган хезмәт эзлеклелеген мисалга китерәбез.

Билгеле ки, теләсә кайсы эшне планлы башкару хезмәт нәтиҗәләрен яхшырта. Караламалар хәзерләнгән очракта, редактор автор сайлаган композиция нигезләмәсенең әсәр темасына, идеясенә туры килү-килмәвен үз вакытында

ачыклар, жанр өчен мөһим булган эчтәлек аспектларын да барлар. Ул билгеле бер дәрәҗәдә сөйләм логикасының саклануы, композицион алымнарның дөрес сайланышы, стиль эзлеклелеге, аңа кертелгән үзгәрешләрнең нигезлелеге, теге яки бу якның камилләшеп бетү-бетмәве кебек мәсьәләләргә дә тукталыр. Әле бит хезмәтләрне җитенкерәмәү күренешеннән битәр артыклык боза. Аңа детальләрне, тел-сурәтләү чараларын кирәгеннән тыш куллану, текстны проблема чишелгәч тә тәмамлый алмау, әһәмиятсез күренеш һәм персонажлар, бернинди функциясез кертелгән автор сөйләме һәм чит текстлар... карый. Мөхәррир эшлекле хезмәттәшлекнең башында ук әлеге күренешләргә дә күпмедер игътибар бирәчәк.

Кулъязма план редакторны үзе керткән яисә автор кертергә тиешле үзгәрешләрнең планын төзүгә этәрә. Бу каләм иясенә һәм җитәкчелеккә аңлату өчен дә, алга таба хезмәтне камилләштерү өчен дә кирәк. Әгәр план белешмәлек, юлкүрсәткеч, төзелеш схемасы һәм башка ярдәмлекләргә карата төзелә икән, ул өстәлергә яисә сызып ташланырга тиешле мәгълүмат, техник таләпләр рәвешендә булырга мөмкин.

**Атама сайлау.** Исемнәр китапларның, әдәби әсәрләрнең, газета-журнал бизәлешенең күзгә нык ташлана торган өлешен тәшкил итә – продукциянең йөзен билгели. Алар эчтәлекне фаразларга, төп фикергә ачкыч табарга булыша; теге яки бу образдан тәүге тапкыр хәбәр бирә; әсәр тональлегенә алып керә ала һ.б. Бер үк каләм иясе тапкан атамалар аның стиле, фикерләү рәвеше, басма сүз культурасы турында сүз йөртергә мөмкинлек тудыра.

Текстның исеменнән чыгып кына да, укучы аның белән танышудан баш тартырга яисә, кызыксынып китеп, кулына алырга мөмкин. Татар басма китаплары исемнәрдә оригинальлек белән артык мактана алмый. Озак еллар дәвамында анда метафорик эчтәлеккә ия сүзләр, аз лексемалы атау җөмләләр өстенлек итте.

Ниһаять, боз урыныннан кузгалды шикелле. Дөрес, аеруча үзенчәлекле шәхес буларак танылган язучылар элегрәк тә китапларына башкаларныкына охшамаган, бөтенләй үзгә яңгыраган исемнәр куярга тырышты. Мәсәлән, Нурихан Фәттах үзен киң катлам укучыга танытхан әсәрен «Сезнеңчә ничек?» дигән сорау җөмлә белән атады. Әхсән Баяновның «Тавыш – табигать бүләге», Миргазыян Юнысның «Занзибар зәңгәр болытлар артында», «Теләп алган давыл», «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» кебек китаплары исемнәре белән генә дә татар әдәбиятына саф сулыш өргәндәй булды.

Татар китапларының атамаларындагы охшашлык, кайвакыт хәтта тәңгәллекләр кулыгыздагы хезмәт авторын үз заманында китаплары аша яңа тип исемнәр кертүгә җилкендергән иде. Аның «Шук алма, моңсу алма», «Сиңа», «Болытка ятып йокласаң», «Мине генә уйла!», «Коела йолдыз», «Йолдызлар төстән язганда», «Таулар һаман ерак» һәм башка китаплары исемнәр мәйданын шактый төрлеләндереп җибәрде. Тора-бара китап шүрлекләребездә үзенчәлекле аталган татарча җыентыклар күбәйде. Инде исемдәге яңалык белән бүгенге укучыны артык шаккатыра алмыйсың, әмма барыбер күпмедер сөендерәсең.

Татар вакытлы матбугатында язма атамаларындагы охшашлык һаман да яшәвен дәвам итә. Кульязма хуҗасының отышлы куйган исеменнән баш тартып, редакция хезмәткәрләре еш кына теге яки бу мәкаләне тапталган фразалар белән атыйлар. Бу вакытта, билгеле ки, авторлык хокуклары тупас рәвештә бозыла. Атама сайланышының укучы игътибарын җәлеп итүдә зур роль үтәвен онытырга ярамый.

Бүгенге көндә бигрәк тә сары прессада, басма сүз культурасына ия булмаган газета-журналларда әсәр эчтәлегенә туры килмәгән атамалар еш очрый. Ул, әлбәттә, материалга мөмкин кадәр күбрәк укучы тарту, эчтәлектәге бушлыкны каплау, теге яки бу товарны кулланучыга рекламалау, шаккатыру кебек максатлардан чыгып башкарыла.

Атама исеме белән укучыны үз материалларына җәлеп итү һәм акча эшләү блогерларның, интернет-сайт авторларының да яраткан алымнарына әверелде. Тирән мәгънәле, оригиналь яңгырашлы, коточкыч вакыйгадан хәбәр рәвешендәге исемнәргә алданып, теге яки бу файлларны ачкан кулланучы күпчелек очракта мәкаләләрнең бушлыгына, кайвакыт хәтта бер-ике җөмләле хәбәрдән генә торуына, атама эчтәлегенең язманыкы белән кисешмәвенә тап була. Базар шартларында һәм демократик җәмгыятьтә мондый ямьсез һәм алга таба юкка чыгарылырга тиеш күренешләргә каршы көрәшү нәтиҗәсез, алга таба блогерларның, журналистларның һәм язма авторларының намуслары уянуга гына өметләнергә кала. Икенче яктан, интернет хәбәрләргә карата ашыгыч рәвештә яңа катгый кануннар кабул итү һәм элек кабул ителгәннәренең дә үтәлүенә ирешү кирәк.

***Баш исеменә куелган төп таләпләрнең*** тәүгесе – аның эчтәлеккә туры килүе һәм бер үк вакытта яңгырашлылыгы. Татар мөхәррирләре китапның соңгы битенә чыгарылыш мәгълүматы биргәндә зур кыенлык кичергәлиләр. Кайчак бер телдә шулкадәр отышлы табылган исем икенчесендә бөтенләй яңгырамый, аңа күпмедер үзгәреш кертергә я башкасын уйлап табарга кирәк була. Әйтик, Рифә Рахманның «Төнге кояш» китабы русча «Солнце в ночи» дип аталган. Икенче төрле грамматик форма кулланылса да, оригинал мәгънәсе дөрес чагылган дигән фикердәбез. Әдибәнең тормыштагы онытылмаслык хәлләр турында сөйләгән «Онытырмын димә» («Вряд ли забудется») атамасына исә, кат-кат кисәтүенә, каршы төшүенә карамастан, тиешсез өтер куелды («Онытырмын, димә») һәм шунлыктан, исемгә, тәрҗемәгә мөнәсәбәтле махсус искәртү хаты да исәпкә алынмыйча, редактор аны русча шушылай бирде: «Не говори, что забудешь». Шушыңа охшаш мисалларны тагын китерергә мөмкин. Әгәр бер каләм иясенең китап исемнәренә аның ризалыгыннан тыш яисә килештермичә кертелгән үзгәрешләр

шактый икән, ил масштабында бу төр тыкшынулар зурлыгын күзаллау да кыен.

Теләсә кайсы текстка куелган баш, һичшиксез, матур яңгырарга һәм мәгънәви тирәнлеккә ия булырга тиеш. Журналистлар бигрәк тә диалог рәвешендәге материалларда кайсы да булса әңгәмәдәшенең яисә интервьюерның ниндидер җөмләсен атамага чыгару уңышлы дип саный. Мондый киң таралган фикер шулай ук әңгәмә исемнәрен сайлаудагы бертөрлелеккә алып килә. Журналистлар яисә бүлек мөхәррирләре авторны искәртмичә, аннан ризалык алмыйча атамага сайлаган җөмләләр күп очракта текстның төп мәгънәсен чагылдырмый. Кайвакытта пародоксаль күренешкә дә юлыгасың: әлеге фикер хәтта төп эчтәлеккә капма-каршы килә. Бигрәк тә «сары пресса» материалдан исемне шул рәвешчә «сөзеп ала» ки, ул үтә көлке яңгырый, ниндидер сенсация рәвешен ала, укучы игътибарын гамьле уйлардан читкә, буш әйберләргә күчерә. Тексттан махсус рәвештә «умырылып» сайланган җөмлә-атамалар әңгәмәгә чакырылган кунак турында начар фикер уятуга хезмәт иткән, аны ямьсез яктан сыйфатлаган очраклар да юк түгел..

Татар вакытлы матбугатында озак еллар «Колхоз рәисенең бер көне», «Мәктәп укытучысының бер елы» тибындагы охшаш атамалар модада булып алды. Алар әле дә күренгәли, кайчак биттән биткә кабатлана да. Бер үк санда охшаш исемнәрнең очравына төп сәбәп – газета битләрен берничә бүлек һәм редактор эшләве. Мондый хәл килеп чыкмасын өчен, кизү торучы мөхәррир һәм баш редактор, номерга кул куйганчы, газетаны яңадан диагональ буенча күз алдыннан кичерергә тиеш. Элек саннар кәгазьдә салына һәм берничә мәртәбә тикшерелә иде. Компьютерда версткалансалар да, күп редакцияләрдә текст әле дә кәгазь өстендә дә кат-кат эшкәртелә, әмма аңа элек булган игътибар, гомумән алганда, шактый кимеде.

Публицистик материалларның исеменә тәгаенлек, игътибарны җәлеп итү таләбе куела. Аларны башта текстның идея

эчтәлегеннән чыгып сайларга кирәк. Отышлысы табылмаган очракта, хезмәтнең үзеннән фикерне ачардаен эзлисең. Кайвакыт мәкалә исеме язганчы ук ачык була, һәм ул текстның идея бөтенлегенә, эчтәлегенә, композициясенә нык тәэсир итә. Мондый материалларга ахырдан исем сайлап газапланырга да туры килми.

Текстларны композицион бербөтен иткән кабатлауларны атама сыйфатында сайлау да үзен аклый. Җитмәсә, ул төп яисә кызыклы фикерне тагын бер кат ассызыкларга ярдәм итә. Кызыклы күренеш: тәүге газета-журналларда исемсез язмалар еш очраган. Әйтик, хәбәр алдына географик урын исеме, торак пункт атамасы куелган. Соңрак материалга «баш»лар беренче биттә афиша рәвешендә бирелә башлый. Бу – хәзерге анонсларның баба формасы. Тора-бара афишалар газеталарның калган битләрендә дә күренә һәм әкренләп мәкалә-хәбәрчекләрнең исемнәре булып китә.

Фоторәсемнәргә кытлык заманда, китап традициясенә дә ияреп, вакытлы матбугатта да баш исемнәрен бизәкле хәрефләр белән бирү гадәте булган. Компьютер версткасына күчкәнче, ул традиция билгеле бер күләмдә яшәп тә килде. Моннан чыгып, атаманың хәтта бизәлеш функциясе башкаруын, бу вазифаның бер көчәеп, бер кимеп китүен әйтә алабыз.

Исемнәрне матур итеп язу өчен, редакция коллективлары элегрәк штатка каллиграф һәм рәссамнарны кертәләр иде. Оригинальлеккә омтылган иҗат төркемнәрендә рәссам хезмәтеннән файдалану әле дә очрый, әмма алар материалга яңа шрифтлар уйлап табу белән инде шөгыльләнми диярлек.

Вакытлы матбугатта атамаларның әһәмиятлелек ноктасыннан төрле дәрәҗәдәгеләре (язма, рубрика, исем астыныкылар...) бар. Редакторлар, гадәттә, аларның һәм китаптагы бүлек-бүлекчә исемнәренең үзара охшашмавын таләп итә. Китап белән мөһим бүлек атамасының тәңгәллеге начар да түгел кебек, әмма күбесе моның белән дә килешми. Традиция буенча, бигрәк тә проза җыентыкларының атамасы күпчелек

очракта тупланмага кергән иң кызыклы, иң мәгънәле яисә иң яңгырашлы әсәрнеке белән туры килә.

Газеталардагы рубрика атамалары даими кулланылучы төргә керә. Алар астында чыккан язмалар һәм исемнәр тематиканы төрле яссылыкларда ачарга мөмкин. Исем һәм асисемнәр дә үзенчәлекле мөнәсәбәттә. Беренчеләре материалның гомуми эчтәлеге, темасы турында тәүге мәгълүматны бирә, икенчеләре исә тематиканы, өйрәнү объектын тәгаенләштерә. Кайвакыт рубрика, язма атамалары һәм асисемнәр бик оригиналь комплекслар тәшкил итә.

Вакытлы матбугат битләрендә даими рәвештә урын алган рубрикалар була. Аларның исемнәре үк укучыга мәкалә эчтәлегеннән шактый зур мәгълүмат бирә. Атамалар газетаны гамәлгә куючылар ихтыяҗына, чыгаручылар зәвыгына, басманың төренә һәм язмаларның жанр формасына карап та аерыла. Мәгълүмат җиткерүче материаллар тышында еш кына саннар, «Игътибар!», «Таныш бул!» тибындагы боерык җөмләләр, гайре табигый фактлар урын ала. Соңгы вакытта бу тип язмаларда да оксюмороннар, башка пародоксаль яңгыраган исемнәр кую мода дәрәҗәсенә җитте.

Исемне полосага дөрес урнаштыру, техник яктан тиешле рәвештә калыплаштыру бик мөһим. Ул газета битендәге, буендагы (полосасындагы) урынына, төп текстка карата позициясенә, шрифтына, кегеленә, төсенә, җирлегенә бәйле рәвештә, укучы игътибарын җәлеп итәргә дә, итмәскә дә мөмкин.

Вакытлы матбугат материалларының атамаларында текстара бәйләнешләр еш күзәтелә, экспрессив сүзләр, фразеологизмнар, сөземтәләр, цитаталар һ.б. кулланыла. Аларның хисси эчтәлеге язманың гомуми яңгырашына үзенчәлекле төсмерләр бирә. Шул ук вакытта кызыклы тоелган, аһәңле исем дә, хезмәт жанрына туры килмәсә, текст бөтенлегенә зыян сала.

Ял иттерүне күздә тоткан хезмәтләргә исем кую юллары башкачарак. Беренчедән, газета, китапчык форматындагылар

күп очракта серия рәвешендә басыла, шунлыктан саннан санга бер үк атама күчеп килә. Аларның үтә отышлы булуы, сатып алучыны тартып торуы кирәк. Бигрәк тә сканвордларның, юлкүрсәткечләрнең укучы колагына ятышлы һәм эчтәлектән дә күпмедер хәбәр бирүче атамалары табылган инде. Рус телендә дөнья күргән «Крот»ны тәү мәртәбә сатып алучы ук аны чишү әлеге җанварга хас тырышлык, үзсүзлелек, башлаган эшне ахырынача җиткерү, маһирлык, казынучанлык сыйфатларын таләп итәр дип фаразлый торгандыр.

Товар исемнәре билгеле бер дәрәҗәдә кулланучыны да фаразлатырга тиеш. Бала-чагага адресланган басма продукциягә туры килсә дә, өлкәннәргә адресланган кроссвордсканвордларны «Кашкарый», «Куянкай», «Тапкыр малай» рәвешендә атау ятышлы булмас. Текстлар белән тәэмин ителгән һәм исемләнгән кайбер өстәл уенарының кулланучыларын чамалау кыен түгел: «Оста куллар» («Умелые руки»), «Җенесләр сугышы» («Война полов»), «Эрудит», «Активити»...

Балалар өчен иҗат ителгән китапларга исем сайлаганда, бигрәк тә яшь үзенчәлекләре, сабыйларның зәвыгы, заман модалары исәпкә алынырга тиеш. Бу урында аеруча кече яшьтәгеләрне күздә тоткан хезмәтләргә автор табышы булган яңа сүз кую очракларын билгеләргә кирәк. Балалар яратып укыган кайбер китаплар, дусларыдай якын иткән әдәби каһарманнар еш кына чит әдәбиятка карый. Италия балалар прозасындагы «Суган-малай»ны сурәтләгән «Чипполино», «курчак» герой хакындагы «Бураттино» (бездә – «Буратино») китапларын, русларга канадалы рәссам-әдип Палмера Кокс комиксларыннан Анна Хвольсон тәрҗемәсендә килеп кергән һәм соңрак Николай Носов файдаланган кәтәнә-каһарман Белмәмеш-Незнайка турындагы әсәрләрне («Приключения Незнайки и его товарищей», «Незнайка на луне») искә төшерү дә җитә. Аларның атамалары балалар өчен үтә якын, образларны уңышлы характерлый. Бу төр хезмәтләрнең «Белмәмешнең Айга сәяхәте» кебек татарчага отышлы

тәрҗемәләре дә очрый, әмма аз, чөнки ана телебездә матур яңгыраган вариантларны уйлап табу шактый авыр. Әйтик, «Мойдодыр»ны «Тишеккәчәю» дип татарчалаштырыргамы, башкачамы? Әллә автор вариантында гына калдырыргамы? Яңа сүз уйлап табу отышлырак булырмы? Редактор, телдән телгә күчерелгән әдәбият белән эш иткәндә, тәрҗемәче кебек үк, үз-үзенә шушындый сорауларны бирергә тиеш.

Басма продукциянең беренче бите үк адресатының бала икәнлеген һәм аның якынча ничә яшьтәлеген әйтеп торырга тиеш. Бу «хәбәр»дә бизәлешнең аерылгысыз бер өлешенә әверелгән атама да бар. Китап никадәр тирән эчтәлекле булмасын, исеме үзенчәлекле яңгырамаса, тонык һәм төссез тоелса, мәктәп баласы аны кулына да алып карамаячак. Кыскасы, атама һәрвакыт эчтәлектән алда йөри һәм аның турында башлап сүз әйтә.

Соңгы ун ел эчендә татар телендә иҗат конкурслары еш уздырыла башлады. Укучылар бигрәк тә «Илһам» бәйгесендә актив катнаша. Атама исемнәренең шушы ун ел эчендә генә түгел, хәтта алдарак оештырылган бәйгеләрдән башлап туктаусыз кабатлануы күзәтелә. Югары сыйныф укучылары, мәсәлән, хикәя-повестьларына – «Яралы язмышлар», мәкаләләренә – «Авылым чишмәләре», «Әтием һөнәре», «Үз эшенең остасы», «Сау бул, мәктәп», «Исәнме, тормыш!», ә шигырьләренә «Онытмыйм», «Сагыш»… кебек башлар куя. Урта сыйныф укучылары «Көзге урманда», «Әбием истәлеге», «Дуслык ничек сынала?» дип аталган хикәяләр яза, мәкаләләре күбрәк «Яраткан укытучым», «Батырлар онытылмый», «Ул җиңү алып кайтты», «Җәлил батырлыгы», «Тукай – халык күңелендә» дигән темаларга була, ә инде шигырьләре «Авылым», «Оста куллы әтием», «Әниемне яратам», «Яз», «Тукай», «Шатлык» кебек моңа кадәр күп очраган, туйдырган гыйбарә һәм сүзләр белән исемләнә.

Сабыйлар «Дәү әнием», «Песием», «Безнең көчек», «Яз», «Мәктәптә», «Укытучы апа» кебек темаларга тезмә әсәрләр

яза. Сәләтләре ныклап ачылып бетмәгән кечкенәләрдән үзенчәлекле атамалар таләп итеп тә булмый, әлбәттә. Әле бит алар күзаллаган, белгән дөнья өлкәннәрнекеннән шактый тар. Иҗат итүләре дә укытучы апалары кушкангарак. Шул ук вакытта сабыйлар прозасында исемнәр, шактый кабатланса да, төрлерәк. Түбәндәгечә аталган һәм елдан елга кабатланган публицистик һәм нәфис әсәрләр «өй эше» буларак язылган дип уйларга кирәк: «Куянның койрыгы нигә кыска?», «Ел фасыллары», «Февраль белән март», «Якын дустым», «Чана шуабыз», «Кар бөртеге хикәясе», «Урманда көз», «Сәяхәтче яфрак», «Аю белән төлке», «Керпе нигә энәле?» һ.б.

Югарыда саналган атамаларның күбесе, күргәнебезчә, мәктәптә бирелгән инша кысаларыннан чыкмый. Димәк, укучы өчен әсәрне исемләү аны язуга караганда да авыррак. Хәер, күп иҗат иткәндә, шигырьләргә баш табу талантлы каләм ияләренә дә җиңел түгел, әмма алар ситуацияне ничек тә хәл итә, һичьюгы әсәренә исем куеп тормый. Укучыларның эшләре белән даими танышу шундый фикергә этәрә: алар язучы булырга хыялланмыйдыр, мөгаллимнәр боерыгын үтәп, алар сайлаган темаларга гына язадыр яисә китаплардагы бирем эшләрен, мәҗбүр иткәнгә генә, конкурсларга җибәрәдер.

Теге яки бу бәйгеләрдә күзгә күз очрашканда, укучыларның күпчелегендә иҗатка теләк бөтенләй юклык, чыннан да, үзен сиздерә. Җитмәсә, аларның җиңүе өчен мөгаллимнәре җан тартыша, балалар үзләренә бирелгән сорауларга татарча җавап таба алмыйча аптырый. Әнә шуңа күрә, күпчелек эшне укытучылар башкарган икән, дигән нәтиҗәгә киленә.

Кайчак балалар язган хезмәтләргә атамаларны остазлары куя. Монысы белән ризалашырга буладыр, чөнки исем сайлау – четерекле гамәл. Өлкән әдипләр дә, бу эшне башкарганда, дусларына мөрәҗәгать иткәли. Хәтта талантлы, мөстәкыйль иҗат итүче балаларның да язу тәҗрибәсе азлыгын онытырга ярамый. Әле бит укытучы – әдәби тәҗрибә мәктәбе узучы яшь каләмнең тәүге редакторы да.

Түбәндә, авторын атамыйча гына, минем тарафтан инде камилләштерелгән (кыскартылган, рифмалаштырылган, тыныш билгеләре куелган) бер шигырьне карап узыйк:

***Мәктәптә***

*Ләйлә мәктәпкә барган,*
*Китабы өйдә калган,*
*Дәфтәрләрен оныткан,*
*Ашарга гына тыккан.*

Игътибар иткәнегезчә, текстта Ләйлә, аның эш-гамәлләре, холкы турында сөйләнә, аны кызның сумкасы турындагы әсәр кебек тә кабул итәргә мөмкиндер. Кыскасы, шигырьдә мәктәптә нишләү турында бернинди сүз юк. Әлбәттә, фикер укырга килгән кыз тирәсендә куера, әмма бу гына әле хезмәтне авторы шикелле исемләргә нигез була алмый. Шулай да аны, теманы ачкан «Оныткан», «Ләйлә», «Ләйлә мәктәпкә барган…» һәм башкалар янәшәсендә отышсызрак булса да, «Ләйлә – мәктәптә» дип атарга булыр иде.

Кече күләмле әсәрләрдә исемнәр кабатланышы ешрак очрый, чөнки авторның аларны табу мөмкинлекләрен тема һәм проблема тарлыгы, текстта кулланылган сүзләр һәм мөһим фикер җиткергән юллар азлыгы чикли. Проза әсәрләренә атама сайлаганда, анда төп теманы, лейтмотивны («Сугыш һәм солых») чагылдырырга яисә эчтәлекне ачучы ачкыч сүзләр («Әйтелмәгән васыять», «Бер ананың биш улы») табарга тырышалар, текстның гомуми аһәңенә ятышлы яңгыраган җөмләләр («Әтәч менгән читәнгә») уйлыйлар. Р. Рахман фольклордан алган «Тауның башын болыт кисә» кебек атамаларда төп фикер асмәгънә рәвешендә килә, метафориклыгы белән укучыда кызыксыну уята. Чыганагы халык авыз иҗаты булган «Итил суы ака торур» (Н. Фәттах), «Кояш көн дә чыга» (Э. Касыймов) кебек роман-повестьларның исемнәре исә лирик яңгырашы белән үзенә җәлеп итә.

Бик күпләр, проза һәм драма әсәрләренә каһарманнарының исемнәрен куя. Бу, бер яктан, текстка атама сайлауда артык җиңел юл. Икенче яктан, ул төр әсәрләр инде татар әдәбиятында җитәрлек. Авторларын атамый гына искә төшереп узыйк: «Таһир-Зөһрә», «Айбиби», «Нурҗиһан», «Сөембикә», «Алтынчәч»… Шул ук вакытта бигрәк тә тарихи романнарга, герое калку һәм үзенчәлекле тасвирланган прозага андый атамалар килешеп тә тора. Төп каһарманыныкына тәңгәллеге аркасында, әсәрнең исеме истә кала. Күләмлерәк булган саен, текстларга атама сайлау мөмкинлеге зуррак, шунлыктан төрле вариантлар уйларга һәм, киңәшеп, отышлысын калдырырга кирәк.

Вакытлы матбугатта гына түгел, махсус реклама продукциясендә дә исем зур роль уйный. Товар тәкъдимнамәсе характерындагы басма атамалары эчтәлекне бигрәк тә ачык чагылдырырга тиеш. Бүгенге көндә Казанда почта ящикларына «Ва-банкъ», «Икеа», «Бәхетле», «Информгазета» һәм башкалар таратыла. Аларның берише, исемнәреннән күренгәнчә, теге яки бу кибеттә сатылган продукцияне алырга чакыра.

«Из рук в руки» газетасының нәрсә хакында икәнлеге һәр җирдә билгеле, чөнки ул озак еллар дәвамында илкүләм чыгучы, гамәлгә куючысы бер булган реклама басмасы сыйфатында яшәде, зур тиражлар белән сатылды. Казанда соңгы елларда аның эш эзләү, йорт-җир сату-алу һәм башка бүлекләре аерым газета рәвешендә дөнья күрә башлады. Бу укучының кирәкле мәгълүмат табу эшен шактый җиңеләйтә. «Стройка», «Интерьер», «Тв – реклама» басмаларының исемнәре эчтәлекләре турында ачык сөйли. Ул төр газета-урналларның атамаларына куелган төп таләп – товарның яисә сатучы оешманың исемен беренче биткә чыгару.

Дөрес, кәгазь варианттагы реклама газета-журналларының көне бетеп бара, чөнки андагы рубрикаларның барысы да интернет челтәрендә чагылыш таба, һәм күп кеше, теге яки бу товар эзләгәндә, электрон версияләргә мөрәҗәгать итә.

Икенче яктан, отышлырак форматларда эшләгән башка сайтлар яисә товар хакында канунсыз ысуллар белән мәгълүмат таратучылар моңа кадәр яшәп килгән реклама газеталарының, сайтларының мөмкинлекләрен гаять чикләде. Товар пропагандалау хисабына көн иткән блогерлар, оператив эшләп, рекламаларга баш исемнәрен дә игътибарны җәлеп итәрлек табып һәм үз битләрендә халыкка кызыклы башка төр мәгълүмат та биреп, кулланучыларны күпләп үзләренә тарта башлады.

Вакытлы матбугат битләрендә урын алган әдәби әсәрләргә исем сайлауның да спецификасы юк түгел. Бигрәк тә шигырь тупланмаларын уртак исем астында берләштерү зур мәгънәви көчкә ия. Тормыш язучыга биргән актив кулланыштагы тематиканың чикләре тар. Кабатлану куркынычы килеп туганга, әсәрне исемсез калдыру традициясе ныгыганнан-ныгый.

Кайберәүләрнең иҗаты, гомумән, тасвир объекты ноктасыннан чикләнгән була. Мәсәлән, күбрәк мәхәббәт, әни, бала, туган җир кебек һәркемгә якын темаларга гына иҗат итүчеләр дә бар. Шагыйрь күпчелек әсәрен охшаш кодлаштыра алмый, билгеле. Кабатланганчы, текстка туры килми торган исемнәр куйганчы, шигырьне өч йолдыз белән генә тамгалап китү дөресрәк тә. Теге яки бу әдип мирасындагы бердәй атамалы текстлар фәнни эзләнүчеләргә эш барышында кыенлык тудыра. Гыйльми хезмәт авторлары, аларны телгә алганда, язылу елларын даимән күрсәтергә мәҗбүр.

Тезмә текстларга исем табу – чишүе иң авыр проблемалардан, чөнки сайлаганың теманы тарайтырга, син теләгәннән артыграк киңәйтеп җибәрергә, хәтта үзгәртергә дә мөмкин. Кайвакыт авторлар моны махсус та эшли. Төп тексттагы төшенчәләр эчендә очрамаган сүзләрне атамага куеп, әсәр эчтәлеген укучы көтмәгәнчә тудыруны әдәби алым иткән шагыйрьләр дә юк түгел. Бу төр әсәрләргә отышлы мисалны Р. Фәйзуллиннан китерик:

***Тулай торакта***

*Кызлар күптән йоклый.*
*Кефир шешәсендә*
*Гөлләр таңны көтә...*

Редакторлар «өч йолдызлы» шигырьләрне исемләп чыгуны таләп итми. Гадәттә, «Эчтәлек»тә аларны беренче юллары, сүзләре белән чагылдыралар, әлеге әсәрләрнең атамасы сыйфатында кыскартылып яисә тулысынча китерелгән тәүге юллары йөри дә.

Фәнни хезмәтләрдә генә түгел, әдәби текстларда да төп һәм ярдәмче исемнәр очрарга мөмкин. Әйтик, «Гаяз Исхакый» публицистик яисә гыйльми мәкаләгә атама булып килә ди. Бу – бик гомуми исем. Теманы тарайту, проблеманы ачыклау, тәгаенләштерү максатыннан, алга таба, аннан аска һәм ваграк хәрефләр белән түбәндәге җөмләләр языла алыр иде: «Әдип портретына штрихлар», «Каләм иясенең юбилее илә милләт өметләре»... Зур теманы шушы рәвешчә дә тарайтырга мөмкин: «Гаяз Исхакый: язучының стиль алымнарына карата» һ. б. Икенче вариантта, беренче карашка, тематик бәйләнеш сакланмаган да кебек. Без әлеге бәйләнешкә эчтәлек аша ирешәчәкбез. Мәсәлән, Гаяз Исхакый үз иҗатында чагылдырган милли идеология белән авторның, хәзерге зыялыларның карашларын янәшә куярга мөмкин. Әдип юбилее уңаеннан исемен мәңгеләштерәчәк эшләр турында сүз йөртеп була. Фәнни язмаларда зур теманы шушы рәвешчә тарайту традициясе яши: «Гаяз Исхакый: язучының стиль алымнарына карата» һ. б.

Ике структур өлештән торган атамаларны сәхифәдә ничек чагылдыру турында уйлану редактор вазифасына да керә. Әйтик, «Чүплектә яшәү җиңелме?» әсәрнең төп атамасы сыйфатында шрифт ярдәмендә калкуландырылды ди. Ул чагында «Фәйзулла абый ярдәм көтә» ярдәмче атамасын, күзгә артык ташланмаган кечерәк һәм тоныграк язу рәвешендә, аннан аска урнаштырабыз.

Соңгы вакытта татарча вакытлы матбугат та реклама белән чуарлана башлады. Материал өчен заказчы акча түли икән, продукциясе һәм хезмәте хакындагы текстның кеше күзенә нык ташланып торуын да таләп итә. Реклама кыска вакыт аралыгында күп кешенең игътибарын яуларга тиеш, шунлыктан гомумән текстны, һәм инде бигрәк тә аннан исем рәвешендәрәк аерылып чыккан тәүге җөмләне (күбрәк ул боерык, эндәш, тойгылы әйтелгән товар атамасы калыбында) оригиналь, тәэсирле, кыска, үтемле, төгәл итеп оештырабыз.

Психологик тәэсир көченә ия риторика тиз арада куллачы белән тәэмин итүче арасында арадашлык тудырачак. Кызганыч ки, оригиналь булырга тырышып, рекламачылар мәгънәсез һәм буш сүз уйнатулар белән мавыга. Мәсәлән, башта бер нәрсәне атыйлар, артыннан икенче продукцияне тәкъдим итәләр. Кайбер текстлар милли әхлак нормаларына җавап бирми. Бу бездә реклама культурасының җитенкерәмәве турында сөйли. Ә бит психологик тәэсирле риторика нәфис әсәрләргә дә игътибарны тарта. Мәсәлән, үз заманында Нурихан Фәттахның «Сезнеңчә ничек?» романын исеме үк популярлаштырган, укучы игътибарын тиз арада җәлеп иткән, чөнки аудитория автор белән диалогка керергә теләгән.

Реклама продукциясе өчен тәүге җөмләләрне яисә чын мәгънәсендәге атамаларны сайлау текст төрләренә дә бәйле. Вакытлы матбугаттагы реклама белдерү, мәкалә, күзәтү кебек күләмле язмалар рәвешен алырга мөмкин. Яшерен реклама еш кына әңгәмә һәм башка төр материаллар эчендә бирелә.

Басма реклама текстларын редакцияләгәндә аларга формат ноктасыннан күз ташлыйбыз – каталог, проспект, буклет, плакат, листовка, афиша, бүләк-басма, календарь, котлау кәгазьләре буларак тәртипкә китерәбез, текстларның исем белән генә түгел, рәсем белән дә үзара гармониясен күз уңыннан ычкындырмыйбыз.

Аудио-радиорекламаларда радиобелдерү-ролик-журнал-тапшыру һәм кино-видео-слайдфильм, телеролик кебек төрләр кулланыла. Аларны, эфирга хезмәт күрсәтүче редакторлардан да бигрәк, реклама агентлыклары хәзерли. Кайбер каналларда шуның белән шөгыльләнүче махсус төркемнәр дә оеша, һәм бу эшкә журналистика факультетларында махсус өйрәтәләр.

Базар мәйданын яуларга булыша дип санап, редакторларны гына түгел, халыкны да кайвакыт күргәзмә һәм ярминкәләргә, аларда урын алачак сувенирларга, төрле фирма продукцияләренә, компанияләрнең үзләренә атама сайлауга тарталар; брендларга һәм сәүдә маркаларына рекламага төрле конкурслар уздыралар. Фабрика-завод эшләнмәләре генә түгел, тышкы реклама исемнәре дә хосусый булырга һәм оешмаларда теркәлергә тиеш, шунлыктан аларга төзәтмә кертүдә, дизайнер-редакторлар янәшәсендә, дәүләт инспекторлары да катнаша.

Реклама теләсә нинди чара һәм форма ярдәмендә таратылган мәгълүмат булса да, төп өлешен текст тәшкил итә. Рекламаның иң таралган жанры – кыска белдерү, һәм әлеге белдерүләр атамага тиң: «Бал», «Күпкатлы тәрәзәләр», «Эш кораллары», «Бакча кирәк-яраклары», «Орлыклар, үсентеләр»... яисә бераз киңәйтелгәнрәк исемнәр: «Үзе белеп кисә торган пычкы», «Янмый торган Кукмара табасы», «Иң баллы бал»... Бу очракта рекламаның башка шрифттагы текстында телефон һәм адреслар гына бирелә.

Укучы игътибарын тагын да ныграк җәлеп итим дисәң, атау җөмләләрдән китеп, башка калыплар белән эш итәргә кирәк: «Бу табаны алырга өлгермәсәң, иртәгә калмаячак!», «Айгөл» фирмасы соңгы күлмәкләрен очсыз бәядән сата!», «Идел буе товарлары» күргәзмәсе «Йолдыз» сараенда бер генә көн эшли!», «Өеңдәге табаң янса, «Кукмара табасын ал!», «Безнең кирпечләрне күрми торып, башка фирмаларга мөрәҗәгать итмә!», «Хатыныңа ышанма: күршең тәрәзәсе яхшы түгел, без ясаганы бер дигән»...

Атамаларны редакцияләү сөйләм штампларын, урынсыз кабатлауларны отышлырак сүзләргә алмаштыру, күләмле исемнәрдән артык сүзләрне кыскарту, киң кулланышта йөргән, инде кемдер тарафыннан файдаланылган атамаларны бераз үзгәртеп, яңачарак яңгыраш бирү кебек төрле алымнар ярдәмендә башкарыла.

**Сөйләмнең функциональ-мәгънәви типлары, аларны текстта камилләштерү.** Талантлы каләм иясе, теге яки бу стильгә ятышлы тел-сурәтләү чараларын берәмтекләп сайламаса да, тупланган материалны чагылдырырлык сюжет-композиция хакында озак уйланмаса да, бик оригиналь әсәрләр тудыра ала, гадәттә, җиңел яза. Әлбәттә, һөнәри әдипнең баш мие иҗатка нык күнеккән, гаять тиз уйлый, әнә шуңа күрә теге яисә бу әсәрнең тууы кемгәдер гайре табигый, күктән төшкән бер нәрсә – илаһи күренеш сыман тоела да. Бигрәк тә һөнәри әдип өчен хәтта көн саен нидер язу кыенлык тудырмый. Шулай да һәркем, югары дәрәҗәдәге осталыкка ия булганчы, зур тәҗрибә мәктәбен үтә һәм төрле өлкәләрдән яисә үзе сайлаган юнәлештә кирәкле белемнәр туплый.

Әдәби текстларны редакцияләүче әлеге дә баягы илаһият ярдәм иткән кебек эшнең тәртибен күзалларга тиеш. Ул үз хезмәтен фәнни эзләнү кебек башкара. Башта игътибарын кульязманың эчтәлегенә, композициясенә – эчке структурасына юнәлтә. Ул текстның нинди характерда, формада булырга тиешлеге авторның максатына һәм сурәтләнгән объектка бәйле икәнлекне онытмый. Әсәр теленә анализ ясаганда, мөхәррир иң элек хезмәтнең хуҗасы тарафыннан кулланылган сөйләмнең функциональ-мәгънәви төркемнәрен билгели, аларның әлеге максатка ярашлымы-юкмы икәнлеген ачыклый, әсәргә хас булырга тиешле стиль бөтенлеге турында уйлана.

Сөйләмнең өч функциональ-мәгънәви төре бар дип санала: хикәяләү, тасвирлама, хөкем йөртү. Аларның һәрберсе текстта нindiдер функция башкара. Сөйләмне дөрес

оештыру проблемаларын эшләгән антик риторика ук аның хакында берникадәр мәгълүмат җиткерә. Әйтик, борынгы галимнәр предметның төп сыйфатлары тасвирламада бирелүне ачык күзаллаган; билгеле бер вакыт эчендә эзлекле барган күренеш-вакыйгаларның сурәтләнүе хикәяләү икәнлекне, ә предметның эчке сыйфатларын ачыклау, күренешләргә аңлатма бирү һәм теге яисә бу хәл-торышны исбатлау аңлатма-фикерләүдә чагылыш табуны аңлаган.

Рус тел белеменә караган элеккерәк хезмәтләрдә дә сөйләмне төрләргә аеру күзәтелә, шуңа да карамастан «сөйләмнең функциональ-мәгънәви төрләре» гыйбарәсе лингвистикада узган гасыр ахырында гына киң кулланышка кергән. Тел калыпларын өйрәнүче буларак та билгеле М.В. Ломоносов, мәсәлән, аларны «сөйләм төрләре» дип атаган һәм хикәяләү, тасвирлау кебек сөйләм оештыру формалары турында сүз йөрткән[1].

Хәзерге вакытта текст теориясенең сөйләм төрләре проблемасы белән бик күпләр актив шөгыльләнә. Шулардан А.Э. Мильчин «Методика и техника редактирования текста» (1972) хезмәтендә сөйләмнең функциональ-мәгънәви типларын шулай ук өчкә бүлә. Ул хикәяләүгә вакыйгаларны теге яисә бу вакыт эзлеклелегендә чагылдырган язмалар телен нисбәтли; предметларны, күренешләрне һәм процессларны һәрьяклап, детальләп җиткерүне *тасвирлама* дип саный; *аңлатма* төрендә язылган әдәбиятка – принципларны, предмет-күренешләргә мөнәсәбәтне аңлатып һәм фикерләү ярдәмендә укучыны билгеле бер нәтиҗәгә китерә торган әсәрләрне кертә.

«Текст теориясе» китабының авторы Н.С. Валгина, сөйләмнең мәгънәви-функциональ төрләрен аерып чыгарганда, автор максатын һәм ниятен исәпкә алырга кирәклекне

---

[1] *Ломоносов М.В.* Полное собрание сочинений: в 20 томах. Т. 7 / М.В. Ломоносов. – М., Л., 1952. – С. 347.

әйтә. Галимә текст билгеле бер коммуникатив максатларны реальләштерә дип саный:

• хәбәр итү, констатацияләү (тасвирлама – описание);

• сөйләү, сурәтләү (хикәяләү – повествование);

• чагыштыру, резюме ясау, гомумиләштерү (билгеләмә, аңлатма);

• нигезләү, дәлилләү, кире кагу, фаш итү (аргументлаштыру, фикерләү – аргументация, рассуждение);

• өндәү-илһамландыру, үтенү, әмер бирү (инструктаж)[1].

Н.С. Валгина тәкъдим иткән төркемләнеш теге яки бу өлкәгә, жанрга караган хезмәтләрдә өстенлек алучы язу алымнары турында нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге бирә.

В.В. Одинцов сөйләмнең функциональ-мәгънәви типларын текст структурасының логикасына буйсындырып төркемли һәм түбәндәге таблица рәвешендә тәкъдим итә[2]:

| | | | |
|---|---|---|---|
| билгеләмә | нәтиҗә | сыйфатлама | хәбәр итү |
| аңлатма | фикерләү | тасвирлама | хикәяләү |

Таблицадан текст структурасының һәм горизонталь, һәм вертикаль юнәлештәлеге ачык күренә. Югарыдагы рәт логик доминанталы, катгый төзелешле төрләр булса, түбәндәгесе «өстәмә, психологик бурычлар»ның[3] аларны трансформацияләвен чагылдыра.

К.М. Накорякова текст типологиясен публицистик хезмәтләргә таянып эшли. Ул аның сурәтле (изобразительные) төренә – хикәяләү (хәбәр итү) һәм тасвирламаны (мәгълүмати тасвирлама), ә логиклаштырылганына – хөкем йөртү (нәтиҗә ясау) белән аңлатманы (билгеләмә) кертә. Галимә, беренче төркем эмоциональ тәэсирне максат иткән нәфис

[1] *Валгина Н.С.* Теория текста. – М.: Логос, 2003. – С. 77.
[2] *Одинцов В.В.* Стилистика текста. – М.: Наука, 1980. – С. 91.
[3] Шунда ук.

текстларга якын тора, ә икенчесенә мәгълүмат бирүче язмалар, рәсми документлар, фәнни публикацияләр керә, ди[1].

***Тасвирлама.*** Тасвирлама – сөйләмнең функциональ-мәгънәви типларыннан иң мөһиме һәм еш кулланылганы. Ул предметның, күренешнең тышкы һәм эчке үзенчәлекләре турында мәгълүмат җиткерә. Тасвирламалар арасында аерымлыкларга, аның сәбәпләренә инде күптән игътибар иткәннәр. Мәсәлән, шул ук М.В. Ломоносов тасвирламаны дөрес һәм язучы тарафыннан уйлап чыгарылган төрләргә бүлгән. Монда тел күренешләренә әдәби әсәр тудыру алымнары ноктасыннан якын килү күзәтелә: галим әдәби чынбарлык һәм шартлылык турында сүз алып бара, күзаллауларны чагылдыру юллары турында яза.

Кайбер галимнәр һәм иҗатчылар, аерым алганда Ф.И. Буслаев, Е.В. Белявский, С.В. Преображенский, Н.С. Державин һ.б. тасвирламаны укучыларга тәкъдим ителә торган сочинениеләрнең аерым төре дип билгеләгәннәр яисә шул сыйфатта тикшергәннәр, теге яки бу теманы мәктәп балаларына я тасвирлама, я хикәяләү формасында аңлату кулайрак дип тапканнар[2].

Тасвирлама, хикәяләү һәм хөкем йөртү кебек функциональ-мәгънәви сөйләм төрләрен инша стиле итеп карау соңрак Е.В. Белявский хезмәтләрендә дә очрый. Әлбәттә, галимнәр алга таба аларның үз эчендәге төркемчә саннарын объектка бәйле рәвештә һаман арттыра бара. Тасвирламаны иншага бәйләп карау XX гасырда да дәвам итә, әмма бу вакытта

---

[1] *Накорякова К.М.* Литературное редактирование. Общая методика работы над текстом. – М.: Изд-во МГУ, 2011. – С. 99.

[2] *Галахов А.Д., Буслаев Ф.И.* Конспект русского языка и словестности для руководства в военно-учебных заведениях, составленный А. Галаховым и Ф. Буслаевым на основании наставления для образования воспитанников военно-учебных заведений, высочайше утвержденного 24 декабря 1848 года. – СПб., 1852. – С. 75.

аны мәктәптә языла торган иншаларның жанр формасы дип саныйлар[1].

Яңа заман филологиясендә сөйләм типларын аларның «прагматик функция»ләре аера дип карала. Тасвирлама предметларның билгеләрен санаса, хикәяләү вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтә, ә хөкем йөртү күренешләр арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен ача. Кыскасы, сөйләмнең мәгънәви-функциональ типларында түбәндәгеләр өстенлек итә: «тасвирламада – синхронлык, хикәяләүдә – диахронлык, фикерләүдә – каузальлек»[2]. Саф төрләр янәшәсендә аларның контаминацияләре дә яши.

О.А. Нечаева инша төрләрен сөйләмнең функциональ-мәгънәви типларына тиңләштереп карауга каршы чыга. В.В. Бабайцева, Е.И. Никитина алга таба аның карашларын тагын да үстерәләр: «В описании изображаются предметы, люди, животные, природа... Типы речи можно различать по вопросам: к повествованию ставится вопрос что произошло?; к описанию – какой?; к рассуждению – почему?»[3].

Хәзерге вакытта русларда гына түгел, татар тел белемендә дә сөйләмнең функциональ-мәгънә төрләре яхшы өйрәнелгән, аларга отышлы билгеләмәләр бирелгән. Әйтик, ***тасвирлама*** – нәрсәне дә булса сурәтләү алымы; аның максаты – эзлекле рәвештә, билгеле бер вакыт аралыгында аңа гына хас сыйфатларны, күзгә күренгән билгеләрен санау юлы белән, объект сурәтен укучы күз алдына китертү. Чагылдыру объектына бәйле рәвештә, портрет (кеше), пейзаж (табигать), тирәлек (йорт, бүлмә, интерьер…), тотыш һәм холык (җан иясе) тасвирламалары була.

---

[1] Система обучения сочинениям на уроках русского языка (IV–VIII классы): пособие для учителей / под ред. Т.А. Ладыжской. – М., 1978. – С. 252.

[2] *Нечаева О.А.* Типы речи и работа над ними в школе. – Красноярск, 1989. – С. 142.

[3] *Никитина Е.И.* Русская речь. – М., 1996. – С. 47.

Тасвирламалар сәхнә әдәбиятында зур роль уйный. Анда санап узган төрләрнең барысы да очрый. Драматурглар, диалоглы текстлардан махсус аерып алып, күренеш барачак урынның, геройларның ниндилеген ача. Бу төр тасвирламалар режиссёрларга да ярдәмгә килә, эчтәлекне аңлауга һәм күзаллауга да булыша. Соңгы вакытта сәхнә әсәрләрендәге тасвирламаларга игътибар кими бара. Түбәндә Рәдиф Сәгъдинең «Гүзәл Аппаксылу» китабында урын алган «Соңгы шүрәле» әсәрендәге беренче күренеш тасвирламасын китереп узабыз:

*БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ*
*Беренче күренеш*
*Сәхнәдә урман күренеше. Ерактан күл күренеп тора. Сәхнә аланны хәтерләтә. Кошлар сайрый. Күкеләр күкелди. Тукраннар тукылдый. Браконьер Билмур күренә.*

Билмурның браконьер икәнлеге, вакыйганың урманда баруы алдагы җөмләләрдә – катнашучылар исемлегендә һәм алхәбәрдә әйтелгән. Артык фактлар «Сәхнә бирелеше»н бизәми. Аның текст яссылыгында нык үзгәргән, форма ноктасыннан камилләшкән, әмма мәгънә эчтәлеге сакланган вариантын тәкъдим итәбез:

*БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ*
*Беренче күренеш*
*Урман аланы. Алан артында – күл. Кошлар сайраганы, тукран һәм күке тавышлары ишетелә. Билмур күренә.*

Тасвирламада сурәтләнүче объект төрле дәрәҗәдә ачылырга мөмкин. Бу язучы иҗат иткән методка да, аның стиль алымнарына да, чагылдыру объектын белү дәрәҗәсенә дә, сөйләм максатына да бәйле. Фәндә каләм иясе китергән билгеләрне тасвирлама элементлары дип йөртәләр. Аларны тасвирлама юнәлешләре нигезендә төркемлиләр.

- Гомуми тасвирдан – тәфсиллеккә;
- алгы планнан – арткы планга;

• зур предметлардан – вагракларына;
• өстән – аска;
• уңнан – сулга;
• әһәмиятледән – әһәмиятсезрәккә;
• бөтеннән – өлешкә һәм һәрберсенең киресенчәсенә юнәлтелгән тасвирламалар булырга мөмкин.

Объектның хәл-торышына бәйле рәвештә, тасвирламаларны статик һәм динамик төрләргә аералар. Статик тасвирламада предметлар тынычлык халәтендә сурәтләнә, шунлыктан фигыльләр арткы планга күчә, сыйфат, исем сүз төркемнәре төп урынны ала. Динамик төрдә исә предметлар, табигать күренешләре хәрәккәттә күрсәтелә, алгы планга инде фигыль чыга.

Тасвирламалар текстта раслау, инкяр итү яисә яңа информация бирү вазифаларын да үти, шунлыктан гыйльми хезмәтләрдә мәгълүмати тасвирлама гыйбарәсе дә очрый. Шул юлдан барып, раслаулы һәм инкяр итүле тасвирламалар гыйбарәләрен дә кулланырга мөмкин.

Кайбер галимнәр тасвирламаның аналитик һәм синтетик төрләрен аерып чыгара. Әйтик, объектның гомуми сыйфатламасы аерым өлешләренең сурәтеннән алда бирелсә, беренче ояга карый, ә инде аннан соң бирелсә, синтетик тасвирлама була.

Редакторның тасвирлама төрләрен үзгәртеп җибәрүе, әйтик, статик тасвирламаларны динамик төрдәгегә алмаштыруны таләп итүе, мәсәлән, прозадагы гомуми хәрәкәтне көчәйтеп җибәрергә мөмкин. Күңелдәге үзгәрешләрне чагылдырган әсәрләрдә ул хисләр агышын, аның укучыга тәэсирен дә арттырачак. Шул ук вакытта шигырьдәге статик тасвирламалар яшәешнең хәрәкәтсез мизгелен, кешенең өнсез калган чакларын сурәтләү өчен кулай. Әдәби редактор һәр төр алымның нәрсәгә хезмәт иткәнлеген яхшы белеп эш йөртергә тиеш. Галимнәр әдипләргә шул юнәлештә киңәшләрен еш бирә, фундаменталь гыйльми хезмәтләрдән дә тәҗрибә алу мөмкинлеге зур.

Түбәндә статик һәм динамик тасвирламаларга мисаллар китерелгән:

*1. Кичке урам. Салкын. Тын. Бушлык. Бар нәрсә хәрәкәтсез. Күлдәвекләрдә – төнге җил койган яфраклар өеме. Шуларның берсендә иртәнге суыктан өшегән чыпчык җылыныр урын тапкан.*

*2. Кичләрен капка төбенә чыгам. Бу вакытка салкынайта, табигатьтә тынлык һәм бушлык урнаша, бар нәрсә хәрәкәтсез кала, төнге җил койган яфраклар күлдәвекләрдә өши, чырык-чырык килеп, чыпчыклар шулардан ясалган өемнәрдә җылына.*

Икенче текстта, күргәнегезчә, фигыльләр кулланылган, теге яки бу эшләр саналган, әмма хәрәкәт үстерелеше юк, эш-гамәлләр барысы да бер үк вакытта бара. Охшашрак тон белән язылган ике тасвирлама да табигатьтән үзенә якынлык эзләгән кеше күңелендәге бушлыкны, моңсулыкны, тормышындагы бертөслелекне чагылдырырга булыша.

А.Э. Мильчин билгеләвенчә, укучылар тасвирламаның аналитик төрен кулайрак күрә. А.Я. Дудец исә, кеше хәтерендә информация тирән сеңеп калсын өчен, аналитик һәм синтетик формаларның үзара керешүе, кушылуы мөһим, дигән карашны яклый. Ул вакытта беренче сыйфатлама – гомуми пландарак, икенчесе детальләштерелгән була. Редактор әсәр анализында бу сыйфатларның үзара ярашуын кайгыртырга тиеш, чөнки укучының, әйтик, геройга аерым детальләр җыелмасы аша туган бәясе авторның гомуми планда биргән бәясенә туры килүе кирәк.

Әдәби әсәрләрдә тасвирлама кайвакыт структур берәмлек булып тора. Мәсәлән, башлам һәм бетем өлешләрен формалаштыруда катнаша. Ул әсәргә тон сала, сюжет сызыкларының экспозиция өлешендә геройлар, вакыйга барган урын һәм вакыт белән таныштыру вазифасын башкара. Тасвирлама әдәби әсәрнең төрле җирләрендә – диалоглардагы җанлы сөйләмдә,

автор текстларында кулланылырга, геройның эчке кичерешләре рәвешендә бирелергә мөмкин. Г. Исхакыйның «Хәлимә туташ» әсәренең башлам өлеше бу очракта бик отышлы мисал булыр. Ул әсәрнең экспозициясе вазифасын да үти:

*Хәлимә туташ уянып киткәндә, көн бик иртә иде. Камыш пәрдә аша үтә торган кояш нуры да әле көнгә өйрәнмәгән кебек, көннән оялган кебек кенә, зәгыйфь кенә яктылык берлә бүлмәне яктырта иде. Пәрдә ашасыннан салкынчарак чык исе исә иде. Бер тәрәзәдән ерак кына чишмәләрнең чыкырдаулары ишетелә иде. Тирә-яктагы тынычлыкны сирәк-сирәк кенә мөгри торган сыер тавышы да бераз боза иде.*

Күргәнебезчә, китерелгән тасвирлама вакыйга-күренеш барачак урынны (авыл, йорт, бүлмә), вакытны (ел фасылын, таңны) атый. Табигать сурәтләнеше кыз холкына да ачкыч булып тора. Өзектәге «яктырта иде», «исә иде», «ишетелә иде», «боза иде» калыбындагы ике составлы хәбәрләрнең янәшә җөмләләрдә килүе XX гасыр башында табигый булган. Бүгенге көндә дә ит, итә, икән, имеш, иде ярдәмче фигыльләрен актив кулланалар, әмма сөйләмдә аларның тыгыз ешлыкта кабатлануы яңгырашны ямьсезләтә дип санала.

Кайвакыт тасвирлама сөйләмнең башка функциональ мәгънәви типлары эчендә очрый яисә алар белән тыгыз үрелә, шул сәбәпле текстны төрләндереп, үзенчәлекләндереп җибәрә, инде укучы күнегеп килгән аһәңне һәм сөйләм агышын үзгәртә. Тасвирлама төрле характердагы геройларны аңларга, автор идеясен тотып алырга булыша. Ул әдипнең күзәтүчәнлеге, рухи һәм мәдәни дөньясында алга куйган кыйммәтләре турында сөйли.

Язучылар тасвирлама ярдәмендә иҗат ителгән әсәрләрдә тиңдәш кисәкләрне, сүз төркемнәреннән исемнәрне, сыйфатларны аеруча киң кулланалар; портретларны – үзенчәлекле детальләр, пейзаж-күренешләрне метафора-символлар белән баетырга тырышалар.

Нәфис һәм публицистик текстлардагы тасвирламалар бер-берсеннән аерыла. Вакытлы матбугат язмалары укучыны сурәтләнгән ситуация, вакыйгага тартып кертү белән генә канәгатьләнми, аларның тере шаһитына да әйләндерергә тырыша. Публицистиканың кайбер жанрларында, мәсәлән, репортажларда, фактлар, мәгълүмати тулылык, хәбәр ителгән информациянең дөреслеге мөһим роль уйный һәм журналист бәяләмәсе чагылмаска тиеш дип карала. Әгәр бу таләпләр үтәлсә, аларда урын тапкан тасвирламалар артык хисси яңгыраш алмый.

Редакторга кайвакыт тасвирламада элементлар эзлеклелеген билгеләү кирәк була. Язучы махсус рәвештә аларны билгеле бер схемага таянып иҗат итәргә мөмкин. Мәсәлән, производство темасын ачачак романдамы, повестьтамы технологик процессны чагылдырырга кирәк ди. Моның өчен башта гамәлләр эзлеклелеген бирәсең, эшкәртелүче деталь үзгәрешләрен күрсәтәсең һ.б. Хезмәт батырлыгын яктырткан әсәрләрдә бу төр тасвирламалар еш очрый. Узган гасырда, алар тормышчан булсын өчен, әдипләр завод-фабрикаларда эшләгән. Бигрәк тә социаль заказ рәвешендә иҗат иткәндә, каләм ияләре махсус оештырылган дәвамлы командировкаларга барган, эшчеләр белән бергә көн күргән, теге яки бу төзелешләрне йөрепкүзәтеп чыккан. Технологик процессның, шәһәр һәм авыл хезмәтчәннәре башкарган эшләрнең өлешчә тасвирлары хәтта күләмле шигъри текстларга, әйтик, поэмаларга да үтеп кергән. Димәк, аларны редакцияләүче автор сурәтләгән эш-хәлләрне күпмедер күзалларга, аңларга тиеш булган.

Тасвирлама схемалары белешмәлекләр, юлкүрсәткечләр хәзерләгәндә дә кулланыла. Истәлекле урыннар буйлап сәяхәт буклетында, мәсәлән, еш кына маршрут эзлеклелегендә һәйкәлләр хакында сөйләнә. Редакторлар исә шул эзлеклелектә өзеклекләр юклыгын кайгыртырга тиеш. Алардан тарихи урыннарның, ядкярләрнең сәяхәтчеләрнең юл уңаенда калу-калмавын яхшы белү көтелә.

Тасвирламаларның функциональ-мәгънәви вазифаларны үтәү дәрәҗәсе аларның текстта биләгән урынына бәйле булырга мөмкин. Бу исә композиция анализы һәм аңа үзгәрешләр кертү вакытында күз уңында тотыла. Нәшрият белгечләре, басма продукциянең яисә текстның композициясен дөрес күзаллау өчен, иң элек тасвир(лама) нигезендә яткан принципны, планны билгеләргә кирәк, дигән караштa тора. Редактор китап концепциясендәге яисә автор уйланмасындагы эзлеклелекнең саклану-сакланмавын ачыклый һәм үзе дә хезмәтне билгеле бер схема буенча анализлый: текст, фотографияләр, рәсемнәр, сызымнар... Мөхәррирнең тасвирламаларга төзәтмәләр кертүе кирәкмәгән, артык яисә объектка туры килмәгән детальләрне кыскарту, отышлылары белән алмаштыру, яңаларын өстәү; зур өлешләрне абзацларга бүлү; текстны отышсыз стиль үзгәрешләреннән арындыру рәвешендә бара.

Тасвирламалар, гадәттә, күләмле җөмләләр рәвешендәрәк оеша, аларда тиңдәш кисәкләр мул кулланыла, һәм редактор тыныш билгеләрен дөрес кую турында да онытмаска тиеш.

***Хикәяләү.*** Хикәяләү – вакыйга-күренешләрне билгеле бер эзлеклелектә сурәтләү дигән сүз. Аның жанр формасына бәйле үзенчәлекләре бар. Хикәяләү публицистикада – төрле тип информацион материалларда, мәсәлән, хроникаль хәбәрләрдә…; фәндә – экспериментлар, ачышлар, танылган шәхесләрнең тормыш-хезмәт юллары турында сөйләгәндә…; рәсми документларда – әйтик, протокол язуларында, аңлатмаларда… кулланыла. Ул әдәби әсәрләрнең һәр төрендә зур урын алып тора, ә проза өчен төп функциональ-мәгънәви сөйләм тибы санала.

Вакытны бик киң иңләүче, ягъни үткәнне, бүгенгене, хәтта киләчәкне дә тасвирлаучы нәфис әдәбият фигыльләрнең күпсанлы формалары белән эш итә һәм аларның төрле мөмкинлекләрен ача. Каләм ияләре, мәсәлән, үткән заман фигыльләре ярдәмендә генә түгел, хәзерге заманны кулланып

та, тормышның узгандагы җанлы картиналарын яңадан торгызырга мөмкин. Язучының осталыгы укучыларга үзләре белмәгән, күрмәгән вакыйга-хәлләрне, күренешләрне шактый тулы һәм дөрес күз алдына китертә алуында чагыла да. Әдипнең заман категорияләрен хаталанып яисә уңышсыз куллануы текстка хилафлык кертә, сөйләмне аңларга комачаулык итә, стиленең җитешсезлегенә булып тора.

Хикәяләү функциональ мәгънәви сөйләм тибы балалар шигъриятендә уңышлы кулланыш таба. Мисалга Г. Тукайның «Иртә» исемле әсәрен китерергә мөмкин:

*Иртә. Дөнья җанлана,*
*Мәшрикъ ягы аллана,*
*Кояш чыгып, нурлары*
*Төшеп җиргә ялгана.*

*Яктыра кала. Урамнар,*
*Кырлар, якын урманнар,*
*Таулар, багълар, бакчалар*
*Нурга гарык булганнар.*

*Торды халык, уянды:*
*Шау-шу һәрбер төшләрдә;*
*Көтү-көтү менмәктә*
*Күккә җитез кошлар да.*

*Шушы вакыт балалар*
*Мәктәп таба баралар;*
*Букчалары артында,*
*Алар – гыйлем дәртендә.*

Текстны тагын да ныграк камилләштерәм дип, фигыль заманнарын, калыпларын бердәй итәргә дә мөмкин, әмма язылганча калдыру да зыянлы түгел. Шагыйрь хәрәкәт, күренешләрне бер-берсенә эзлекле ялгый, балалар заман күчешләренә артык игътибар итмәслек чагылдыра, җиңел укылышлы яза, ә болар зур осталык сорый. Әлбәттә,

югарыдагы мисалда, фикерне аңлауга кыенлык тудырмасалар да, грамматик дөрес калыплаштырылмаган, аерым сүзләре килеш яисә күплек кушымчасы өстәүне таләп иткән (мәктәпкә, артларында) җөмләләр бар, әмма андый үзгәреш кертү ритм-рифма чатаклыгына китерәчәк. Димәк, башка юл табу кирәк. Мәсәлән, строфаның икенче юлын «Мәктәпләргә баралар» дип төзәтергә булыр иде.

Әдип текстка керткән вакыйгаларны хикәяләү төеннәре дип атыйлар. Аларның саны текст озынлыгына, жанрга, иҗатчының язу манерасына бәйле. Редактор вакыйгалар яисә хәл-күренешләр арасындагы логик бәйләнешне, эзлеклелекне тикшерергә, төзәтүләр кертергә, артык тоелганнарын, текст бөтенлегенә зыян салганнарын кыскартырга тиеш. Ул, проза әсәре белән эш иткәндә, болардан тыш, аерым детальләрнең сюжет сызыгындагы ролен билгели, хикәяләү төеннәренең кайсын калкуландырырга, кайсын тоныкландырырга яисә теге яки бу урынга күчерергә мөмкинлеген ачыклый. Әлбәттә, мөхәррир бу үзгәрешләрнең һәрберсен автор белән килештерә.

Хикәяләүнең сурәтләү объектын алмаштырганда, сөйләм логикасын саклау хакында онытмаска кирәк. Монда текст өлешләрендәге тема-рема бәйләнешләрен дөрес оештыру проблемасы килеп туа. Әле генә теркәгән җөмләгездән соң тулы булмаган, иясе яисә башка җөмлә кисәкләре алмашлык белән белдерелгән җөмлә язганда аеруча сак булырга кирәк: хәбәрнең башка бер затка каравы бар!

Гакыйль Сәгыйров көндәлегендә 1966 елның 10 августында калдырган язмадан бер өзек китерик: *Үткән ял көнне тагын Наил кайткан иде. Түшәм такталарын кысты. Шунда биш такта югалу беленде. Чама белән кемнәр кереп чыкканын белеп була. Бирәдән дә килеп алгач инде, ул, мескен, такта юклыгыннан тәмам тинтерәгәндер.*

*Кичә әни белән күрше Мәрьям апа «борчак» бәрешеп алдылар. Аның бозаулары безнең бакчада «йөзгәннәр» икән.*

*Вәли икенче мичебезне чыгарып маташа. Иртәгә бетерер иде дә, кибет артын «сакларга» китмәсә...*[1]

Текстта фикерне аныксызрак итүче хаталар бар. Аларны ничек төзәтергә, дигән сорау туа. Моны автор ярдәменнән тыш башкарып булмый, чөнки көндәлек иясе генә сүзнең кем һәм ничә кеше хакында барганлыгын белә. Автор я «ул, мескен»не – «ул мескеннәр»гә я «кемнәр»не – «кем»гә үзгәртергә тиеш: *Үткән ял көнне тагын Наил кайткан иде. Түшәм такталарын кысты. Шунда биш такта югалу беленде. Чама белән кем кереп чыкканын белеп була. Биредән дә килеп алгач инде, ул, мескен, такта юклыгыннан тәмам тинтерәгәндер.*

Болай гына үзгәрткәндә, бер сорау җавапсыз кала: текстның алдагы өлешендә Гакыйль Сәгыйровның башка җирдәге байлыгын да урлау хакында язылган идеме, юкмы? Юк икән, ни өчен «биредән дә» дип әйтә? Әллә каләм иясе «авыру кеше каралтысыннан да» дияргә телиме? Бу төр хаталарны төзәтүгә караганда булдырмый калу җиңелрәк шикелле.

Публицистикада текст коруның күптөрле алымнары булса да, журналистлар барыбер гадәткә кергән калыплар беләнрәк эш итә. Бу күренеш вакытлы матбугат битләрендә хикәяләү клишелары кирәгеннән тыш ныгуга, хикәяләүне текстның башка функциональ-мәгънәви сөйләм типлары эченә кертү юлларының да күпмедер дәрәҗәдә кабатлануына китерә.

Газета-журналларда хикәяләү еш кына «Нәрсә кайда кайчан нишләгән?» чылбырында килгән сорауларга җавап бирү рәвешендә туа. Аеруча газеталарның кече күләмле рубрикалардан торган тәүге сәхифәләренә хикәяләүнең шул рәвешчә оештырылган гади калыплары хас.

Әдәбиятта зур урын алып торган хикәяләүне максатка бәйле төркемләргә мөмкин. Ул чагында комментарийлар

---

[1] *Сәгыйров Г.* Үзе турында һәм барысы да аның турында. – Самара: Медиа-Книга, 2015. – Б. 73.

шуларның бер оясы булып тора. Алар журналистикада да кулланыла. Комментарийлар кушып хәбәр итү соңгы вакытта теле-радио дулкыннарында да, интернет челтәрендә дә нык активлашты.

Хәбәр итү, хикәяләүдән башка радио-телевидение эшчәнлеген күз алдына китереп тә булмый. Узган чорларда яшәгән талантларны искә алган роликлар, хәзерге көндә танылган кешеләрдән үткәннәрен искә төшертүгә корылган авторлык программалары, теге яки бу вакыйгаларны шәрехләгән «сәяси сәгатьләр», редакторларның үзләре сайлаган кешеләр белән «күзгә-күз очрашулар»ы – шуларның бик аз өлеше генә.

Кайбер галимнәр хикәяләүнең ***эпик, биографик, сәхнә*** төрләре бар дип саный. Алар карашынча, беренчесе – хәл-күренеш, вакыйгалар турында гомуми, икенчесе – ым-ишарәләрне, геройларның үзләрен тотышындагы, йөзләрендәге үзгәрешләрне файдаланып, ә инде өченчесе – аның тәрҗемәи хәленнән мөһим вакыйгаларны сайлап җиткерә. Мондый бүленеш, принцибының буталчыклыгы аркасында, үзен акламый. Аларны белү-белмәү, төркемли алу-алмау редактор эшендә мөһим роль уйнамавын да әйтик.

Галимнәргә, студентларга, аспирантларга тәрҗемәи хәлне чагылдырган текстларны еш хәзерләргә туры килә. Редакцияләү вакытында, беренче чиратта, автобиографияләр юлланачак оешманың алдан куелган таләпләре, сораулыклары белән тагын бер кат ныклап танышырга һәм язманың аларга җавап бирәме-юкмы икәнлеген ачыкларга кирәк. Бигрәк тә кече күләмле биографик язмалар төгәллек таләп итүче сорауларга җавап табу рәвешендә башкарыла. Күп очракта аларда кайсы урында нинди кыскартылма кулланырга тиешлек күрсәтелә; аббревиатурага бәйле таләпләр атала, таныкнамәләрдәге мәгълүматны җиткерү тәртибе билгеләнә. Ирекле иҗат ителгән биографияләргә, биографик җирлекле әсәрләргә шулай ук жанр таләпләреннән якын килenә.

Хикәяләүнең үзен дә, әдәби төр, жанр һәм жанр формаларына мөнәсәбәттә өйрәнергә, сыйфатларга мөмкин. Аның диалогка, монологка һәм полилогка бәйле үзенчәлекләре бар. Гомумән алганда, хикәяләү манерасы, аңа корылган текстның нинди күләмдәге сөйләм берәмлекләреннән оешуы, беренче чиратта, авторның индивидуаль стиленә бәйле.

Әдәби әсәрләрдә хикәяләү автор сөйләменең төп өлешен тәшкил итә. Ул диалогик текстларны гомуми сөйләм белән ялгау вазифасын башкара. Аның аша без хикәяләүченең кемлеген ачыклыйбыз, хикәяләүдән чыгып, автор шәхесенә билгеле бер дәрәҗәдә сыйфатлама бирә алабыз. Нәфис текстларда хикәяләүче алмашынырга, фикерләү ноктасы күчәргә мөмкин. Редактор бу күчешләрнең уңышлы булуын кайгыртырга тиеш.

А.Э. Мильчин, хикәяләүдә композициянең бер элементыннан икенчесенә күчү вакыт үзенчәлеге белән билгеләнә, аңлатыла, ди. Аныңча, һәр яңа элемент инде икенче вакыт периодына карый башлый. Бу бигрәк тә хронологик тәртипкә корылган тарихи китапларга хас күренеш икән. Автор билгеләвенчә, хикәяләүдә вакыт агышы туры (алга) һәм кыек (кирегә) тәртиптә булырга мөмкин. Бу авторның вакыйгаларны алга таба барып яисә үткәнгә кайтып тасвирлавына бәйле. Кире тәртиптәге хикәяләү, гомумән алганда, аз кулланыла, күбрәк традицион туры хикәяләү эчендә очрый, һәм аннан детектив әдәбиятта уңышлы файдаланалар.

Хикәяләүгә урын шигъри әсәрләрдә дә мул бирелә. Бигрәк тә балалар поэзиясен, лиро-эпик әсәрләрне аннан башка күз алдына да китерү мөмкин түгел. Поэзиягә тормыш прозасын, көндәлегебезне күп керткән, аның тормышчан һәм тәгаен эчтәлеккә ия булуын якын күргән шагыйрьләр лирикада да хикәяләүгә зур урын бирә.

Фәнис Мотыйгуллинның шул ук «Сердәш төннәр» китабыннан «Кайтма, энем, авылга!» әсәренең башын карыйк:

*Авылдан чыгып киттең дә*
*Югалдың бит син, энем.*
*Кайларда гына йөрисең,*
*Кайда күрәсең көнең?*
*Син киткәндә, хәтерләсәң,*
*Авыл матур, зур иде.*
*Җырларда җырлап мактадык,*
*Әллә инде күз тиде?*
*Тракторлар йөрми хәзер*
*Авыл урамын изеп.*
*Колхоз булса, юлсызлыкка*
*Булыр да иде түзеп.*
*Урамнарны чирәм басты,*
*Таптар кеше булмагач.*
*Авылдашлар кими бара,*
*Яшь сабыйлар тумагач.*
*Яшь-җилкенчәк китеп тора,*
*Үзенә тарта шәһәр...*

Әлбәттә, бик примитив, әдәбияттан ерак иҗатчылар дәрәҗәсендә генә язылган бу шигырьне, ничек кенә актуаль яңгырашлы булмасын, зәвыклы әдәбият сөючеләр өчен укылышлы, кызыклы итү мөмкин түгел. Ул образларга ярлы, анда моңа кадәр күрелмәгән табышлар бөтенләй юк. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булса да, авылның үткәнен һәм бүгенгесен автор үзешчән шагыйрь дәрәҗәсендә генә хикәяли. Шигырь җыентыкларын хәзерләгәндә, иң яхшысы – бу төр әсәрләрне тупланмадан төшереп калдыру.

***Фикерләү*** нинди дә булса уйны үстерә, нигезли, кире кага. Ул – максат-төзелеш һәм тел-сурәтләү чаралары яссылыгыннан караганда, сөйләмнең функциональ-мәгънәви типлары арасында иң катлаулысы. Фикерләү кешенең аң үсешен, уйлау сәләтен күрсәтеп тора; автор белән редактордан җөмләләрне төгәл калыплаштыруны, уй сөрешендә эзлеклелек саклауны, текст темасын һәм хөкем йөртү алымнарын үзара яраклаштыруны, дөрес нәтиҗә чыгаруны таләп итә.

Белгечләр, аның төп максаты – төрле вакыйга-күренешләр арасында бәйләнеш булдыру, ди. Бу вакытта субъект башка кешеләрнең дәлилле нигезләмәләреннән файдалана яисә үзе дә шул рәвешчә үк хөкем йөртә.

Фикерләү барлык фәнни өлкәләрдә дә кулланыла, һәм гыйльми тармаклар, үз чиратында, аны төрле аспектларда яктырта. Мәсәлән, логика фикерләүне аргументлаштыру ноктасыннан ача: аның типик юлларын – дедуктив исбатлау-раслауны яисә кире кагуны, анализ ярдәмендә яисә аналогия буенча нәтиҗә ясауны күрсәтә.

Текст стилистикасы хөкем йөртү нигезендә яткан логик мөнәсәбәтләрне ачыклый, функциональ-мәгънәви сөйләмнең бу төрен куллануга сөйләм камиллеге ноктасыннан якын килә. Фикерләүгә мөнәсәбәтле тел схемаларын шулай ук стилистика эшли. Антитеза, альтернатива, аналог, төшереп калдыру, янәшәлек, тәңгәллек, риторик фигуралар, гипотезалар һәм башкалар буенча нәтиҗәләр чыгару фикер йөртүнең эчтәлеген тәшкил итә. Димәк, автор һәм редактор шулардан актив файдаланырга тиеш.

Риторика борынгы заманнарда ук фикер йөртүнең төрле якларына, шул исәптән аргументлаштыруның эмоциональ алымнарына да зур игътибар биргән.

Редактор автор язмасына логиканың дәлилләү төзелешенә куйган таләпләреннән чыгып якын килә, әнә шуңа күрә бу төр сөйләм тибын кулланып башкарылган язмаларны фикерләү-исбатлау текстлары дип йөртү дә гадәткә кергән.

Төзелеш тәртибенә карап, фикерләүнең ***эксплицит*** һәм ***эмплицит*** формаларын аерып чыгаралар. Беренчесендә структур өлешләр сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә килә һәм аларның мәгънәви бәйлелегенә ишарәләүче лексик чаралар (бәйләгечләр, бәйләгеч ролендә килүче сүзләр, теркәгечләр һ. б.) була. Икенчесендә структур өлешләрнең мәгънәви бәйләнеше лексик-грамматик катламда түгел, ә логик-мәгънәви яссылыкта ята.

Эксплицит фикерләү төренә бер мисал: «Камил салкын тиде дип укырга килмәгән. Ул, аз гына авырса да, дәрескә йөрми. Камил бик күп лекция калдырды, шуның өчен аны зачетка кертмәүләре дә мөмкин».

Г. Сәгыйров көндәлегеннән эмплицит төргә мисал:

*5 август. 1966 ел.*

*Бүген иртүк бер сәбәпсез башым әйләнергә тотынды. Бик начар хәл бу. Күрәсең, минем тормышымның да соңгы ноктасы куелырга күп калмаган*[1].

Тексттан аңлашылганча, сәбәпсез башы әйләнүне автор начар хәл дип саный һәм, шуннан чыгып, аянычлы фикергә килә. Кереш сүз соңгы җөмләнең фаразлы нәтиҗә икәнлеген күрсәтә.

Фикерләүле текстларга стилистик чаралар тема, жанрдан чыгып һәм сөйләүченең индивидуаль үзенчәлекләренә бәйле сайлана. Әйтик, вакытлы матбугат материалларында аудиторияне ышандыру, теге яки бу фикерне ныгыту, тарату максаты куела. Журналистлар ышандыруның һәм рациональ, һәм иррациональ алымнарыннан актив файдалана.

Рациональ алым дип, кеше аңына тәэсир итүче логик аргументлар куллануга әйтәләр. Сәяси эшлеклеләрнең үзара көрәшендә әлеге алым мөһим роль уйный, шунлыктан пропаганда текстларында еш чагылыш таба. Радио һәм телеэкраннардан теге яки бу кануннарның әһәмиятен халыкка логик аргументлар ярдәмендә аңлатырга тырышу да киң таралган. Пенсия фонды диварыннан алынган текст хезмәт яшендәгеләрне өстәмә пенсия туплау, озаграк эшләү кирәклегенә шушы рәвешчә ышандыра:

*Бүгенге пенсияләр күпчелек халыкның яшәү ихтыяҗларын канәгатьләндерми, шунлыктан аны арттыру юлын*

[1] *Сәгыйров Г.* Үзе турында һәм барысы да аның турында. – Самара: Медиа-Книга, 2015. – Б. 73.

*алдан күрергә кирәк. Эшләү дәверендә пенсия фондына өстәмә акчалар кертү киләчәктә пенсиягездә чагылмый калмас. Хөкүмәтнең бергәләп финанслаучы программасы буенча кертелгән акча икеләтеләчәк. Пенсиягә үз вакытында чыкмасагыз, һәр эшләгән елыгыз өчен балл язылачак, пенсиягез дә артачак. Стажыгыз 41 елга җиткән очракта, сез шактый югары пенсия алачаксыз.*

Рациональ фикер йөртү фәнни текстларда, халыкны мәгълүмати агартуны максат иткән теле-радиотапшыруларда күп кулланыла. Иррациональ (нигезсез) аргументлаштыру аңга функциональ-ирекле тәэсир ясауны максат итә: *Хөкүмәтнең кеше язмышына битарафлыгы соң чиккә җитте. Шуның нәтиҗәсендә, Кемерово сәүдә йортында чыккан янгын никадәр кешенең, иң кызганычы, балаларның гомерен өзде!*

Иррациональ аргументларга бигрәк тә социаль калыпларга нигезләнгән фикерләр керә, чөнки күпчелек кеше, теге яки бу гамәлне башкарса, җәмгыятьтәге статусын, сәламәтлеген, матди хәлен яхшыртам дип ышана, төрле ихтыяҗларын канәгатьләндерә аласына өметләнә. Бу төр аргументлар массакүләм мәгълүмат чараларында, реклама текстларында мул кулланыла. МММның пирамидаларын яшәтү максатыннан эшләнгән видеороликларда яңгыраган сөйләм шуның типик үрнәге булып тора. Аның каһарманнары – гади хезмәт кешесе Лёня Голубков (Владимир Пермяков), хатыны Рита Голубкова (Елена Бушуева) һәм башкалар, халыкны әлеге оешма ярдәмендә, «халявага» (бушка килгәнгә) яшәмичә, ә партнёр сыйфатында хәрәкәт итеп, «яңа итекле, машиналы һәм Парижда йортлы» итү белән хыялландырдылар. Кыска метражлы әлеге язмаларда хәтта дөньякүләм билгеле мексикалы актриса Виктория Руффо да катнашты.

Видеороликларда халыкка ирештерелгән рекламада дәлилсезлек, рациональ фикер булмау хакында Мавродига бәйле күп күренеш-хәлләр сөйли. Бервакыт аннан: «Реклама кемгә ориентлашырга тиеш?» – дип сорыйлар, ә ул: «Бар

кешегә дә. Акыллылардан кала. Алар – аз»,– дип җавап бирә. МММ рекламаларының һәрберсе бик оста табылган, дәлилсез булуына карамастан, ышандыргыч көчкә ия текстларга нигезләнә. Аларны иң талантлы иҗатчылар эшләгән, редакторлар камилләштергән. Татарларда бу төр рекламалар юк дәрәҗәсендә.

Фикерләү нигезендә логик кануннарга таянып чыгарылган нәтиҗәләр ята. Төзелеше буенча хөкем йөртү ике төрле булырга мөмкин: дедуктив һәм индуктив.

***Дедуктив метод*** гомуми фикерне таркатуны күздә тотса, ***индуктив*** метод, аерым фикерләрне кушып, гомуми нәтиҗәгә китерә. Фикерләү барышында алар бер-берсе белән чиратлашырга мөмкин. Фәнни текстта теге яки бу нәтиҗә чыгарылганнан соң, кире юлдан китеп, биремгә барып чыгу традициясе бар. Нәфис әдәбиятта дедуктив һәм индуктив фикерләү бер җөмләдә, абзацта, бүлектә, хәтта тулы хезмәттә дә очрый ала. Әдәби әсәрдә тасвирлау, хикәяләү һәм фикерләү кебек төрле сөйләм типларын куллану авторга үзе җиткергән вакыйга-күренешләргә, эш-хәлләргә карата мөнәсәбәтен эмоциональ чагылдырырга мөмкинлек бирә. Шулай да антик чорда ук кайбер авторлар тарафыннан теләсә нинди вакытта фикерләүгә бирелүнең уңышсыз булуы ассызыкланган.

Тукайның «Лермонтовтан үзгәртелгән» «Соңра» әсәрендә иң тәүдә нәтиҗә ясала, шуннан соң шагыйрь тәүге җөмләдә ирештергән гомуми фикерен расларга, таркатырга керешә:

***Бер мәхәббәтнең газабын, михнәтен сизгән кеше,***
***Бер сөеп арган вә җөмлә нәрсәдән бизгән кеше –***

***Күңле бозланган кешедер:*** *һич тагын бер кат сөймәс,*
*Инде ул беркем өчен дә гамь йимәс һәм «Аһ!» димәс.*

*Бетте әүвәлге очынмаклар,– авыр ул гер кеби;*
*Һич эчелмәскә мәхәббәткә йомылган керпеги.*

*Сүзләре салмак аның – койган кеби кургаш белән!*
*Күзләре инде юешләнми аның күз яшь белән.*

*Һәрвакыт ул инде ялгызлык сөя, золмәт сөя;*
*Бер пигамбәр яки бер дәрвиш кеби – газләт сөя.*

*Файдасы юк төрле хиссият уты берлән янып,*
*Күңле калган көл-күмергә әйләнеп, хиссезләнеп.*

*Мисле шул: урман эчендә бер яшен суккан агач,*
*Бер хәятының суы коргач, юешлек булмагач,–*

*Инде ул мәңге тамыр җәймәс, ботакланмас тагын;*
*Бер янып сүнде – икенче кәррә ярмас яфрагын.*

Бәхәс характерындагы материалларда фикерләү еш кына автор тәкъдим иткән аңлатмалар белән кушылып киткәнгә, кайберәүләр фикерләүнең дәлилләү, рациональ аңлатма формасындагыларын аерып чыгара. Беренчесе белән эш иткәндә, мөхәррир сөйләмнең функциональ-мәгънәви тибына:

- тезис һәм аргументларның төгәллегеннән;
- дәлилләрнең үзара каршы килмәвеннән;
- исбатлау барышында тезисның алмаштырылмавыннан;
- мөстәкыйльлегеннән чыгып бәя бирә.

Тезис хаклыгына бәхәссез аргументлар китерелсә, автор шик тудырмый торган фактларга таянса, дәлилләү «туры» төргә керә. Тезисның дөреслеге «киресен исбатлау мөмкин түгеллек» аркылы аңлатылганда, дәлилләүне «кыек» дип саныйлар.

Фикерләүнең мәгънәви структурасы белән эшләү аның предметын һәм максатларын, китерелгән элементларның ни өчен бәяләнүен ачыклаудан башлана. Тема аныксызлыгы, беренчел мәгънәдән читләшү, эчтәлек композициясен уңышлы сайламау, фактларны тиешеннән күп кулланып, мәгънә аңлауны катлауландыру яисә дәлилләүнең юклыгы, җитенкерәмәве кебек кимчелекләрдән арындыру – редактор алдында торган мөһим бурычлардан.

Мөхәррир үз эшендә фикерләүнең мәгънәви элементларны һәм тел чараларын төгәл куллануга корылганлыгы принцибыннан да чыгып эш йөртә. Мөмкин булганда, ике

төрле аңлауга китергән сүзләрне кыскарта, синонимнары белән алмаштыра, ә тапмаса, җөмләне яңадан кора, хезмәтнең төшенчә урын алган өлешен үзгәртә.

Фикерләү текстларында:

- тезиска;
- аргументларга;
- күрсәтү-демонстрацияләүгә кагылышлы хаталар очрарга мөмкин.

Алар, мәгълүм булганча, исбатлау формуласының состав өлешләренә карый. Тезис – исбатланырга тиеш торыш, текстның аргументлаштыру өлеше – дәлилләнүче халәте, ә инде демонстрация – тезис һәм аргументлар бәйләнешенең логик формасы дип санала.

Ышандыру өчен аргументлары җиткән фикерләүне – тулы, тыңлаучыны ышандырырга да, ышандырмаска да мөмкин булганын бәхәсле төргә кертәләр. Текстны коррекцияләүче бәхәсле хөкем йөртүгә аеруча сак якын килергә тиеш.

Дәлилләрнең өстәмә элементларына фикерләүнең структур өлешләренә караган күрсәтмәләр, мисаллар, исбатлауны таләп итми торган, гомумкулланышта йөргән нәтиҗәләр керә. Бу төр белемнәргә ия булу аеруча фәнни хезмәтләр редакторына кирәк.

Кайбер текстларда бер үк нәрсәне әллә ничә вариантта дәлилләү күзәтелергә мөмкин. Фәндә бу алым аудиторияне ышандыру максатына хезмәт итә. Автор уйланмасыннан, теге яки бу теләктән чыгып башкарылса, әдәби текстлардан да кабатланып килгән дәлилләрне кыскартмыйбыз.

Кайвакыт фикерләүдә аргумент һәм тезисның урыннары алмаша. Тема белән таныш түгел аудитория каршында чыгыш ясаучы хөкем йөртүне аргументтан башларга тиеш дип карала. Безнеңчә, бу шулкадәр мөһим түгел, хәтта бәхәсле. Фикерләүнең нинди рәвештә корылуы күпчелек очракта автор сайлаган сөйләү һәм язу манерасы белән билгеләнә. Фән теге яки бу карашларны, бер расланган кебек

теоремаларны, хакыйкатьләрне кире кага-кага үсә. Шунысын да өстик: хөкем йөртүнең инкяр итү калыплары гыйльми эзләнү эшләренә генә түгел, вакытлы матбугат язмаларына да хас.

Кире кагу алымнарыннан каләм иясенең оппонентлары, фәнни хезмәтләргә бәя бирүчеләр актив файдалана. Кайбер очракларда алар ниндидер тезиска каршы икенчесен тәкъдим итә һәм исбатлап та бирә. Бу очракта аргументлар, мәгънәви һәм структур яссылыктан чыгып, антитезисны дәлилләргә тиешле һәм «ялган»ны кире кагучы өлешләргә бүленә.

Фән фаразлар булдыру һәм аларны исбатлау юлы аша да үсә. Галимнәр билгеләвенчә, гипотеза – җитәрлек дәрәҗәдә нигезләнмәгән күзаллау ул. Димәк, аны раслау өчен, яңа дәлилләр кирәк. Әдәби һәм публицистик текстлардагы фаразлау исә, фәнгә кагылышлы булмаганда, исбатлауны таләп итми. Ул текст оештыру, укучыны уйландыру, вакыйгаларга алып керү, нәтиҗә ясау һәм башка вазифалар үти. Түбәндә шагыйрь, хыялда туып, шигырьне мотивлаштырган ситуацияне фараз рәвешендә бирә:

*Кайтырсың да, баш астыңа салып*
*Китабымны минем, йокларсың.*
*Анда синең хакта сюжетлар юк:*
*Синле битне үзең ерткансың.*

(*Рифә Рахман.* Кайтырсың да)

Гомумән алганда, фәнни һәм әдәби текстлардагы фаразларга төрлечә, билгеле бер дәрәҗәдә жанр сыйфатларын, гыйльми өлкә спецификасын, аның үсеш биеклеген дә исәпкә алып якын киләбез.

***Аңлатма*** – текстның алгы өлешендә әйтелгәннәргә нигезләнгән, дәлилләү рәвешендәге уй агышы дигән сүз. Анда һәр элемент үзеннән алдагысын тулыландыра яки яңасын тудыра. Аңлатма гыйльми хезмәтләрдә мөһим урын алып тора, чөнки фәнни эзлекле фикер агышы безне ниндидер

нәтиҗәгә китереп җиткерергә тиеш. Алга таба сөйләм авторы теоретик төстә барлыкка килгән нәтиҗәне фактлар, аргументлар белән исбатлаячак.

Аңлатма төрле тип текстларда – әйтик, белем бирү әсбапларында, әңгәмәдә, әдәби һәм публицистик әсәрләрнең диалогларында актив кулланыла. Фәнни анализны, бәяләмәне, шуны аудиториягә җиткерүне әлеге сөйләм төреннән тыш күз алдына да китереп булмый. Моны аңлатмага бирелгән билгеләмә дә ачык күрсәтеп тора.

И.Б. Голуб аңлатма башка формалар белән, гадәттә, янәшә килә, ә сөйләмнең функциональ-мәгънәви төрләренең классик типологиясе текст төзү алымнарының барысын да үз эченә алып бетерми дигән караштa тора[1]. Белгәнебезчә, аңлатма бигрәк тә фикерләү белән тыгыз үрелә.

Аңлатманың тар һәм киң мәгънәләре бар. Бердән, ул – функциональ-мәгънәви сөйләм тибы, икенчедән, шуның махсус формасы булып тора һәм аңлатмага караган билгеләмәнең әдәбиләштерелгән тармагы дип тә санала. Сөйләмебездә, төрле күренешләрне белдерү өчен, бер үк атамалар куллану фикерне җиткерүдә зур кыенлыклар тудыра.

Кайбер галимнәр аңлатманы билгеләмәнең бер төре дип санауга каршы төшә, шул ук вакытта аларның үзара охшашлыгын да билгели. Алар фикеренчә, аңлатма билгеләмәне алмаштырып килми, ә аны тулырак, эчтәлеген ачыграк итә. Аңлатманың әлеге максаты киң катлам кешеләргә аңлаешсыз, моңарчы очрамаган терминнарны мәгълүм, һәрдаим кулланылышта йөргән сүзләр ярдәмендә шәрехләү юлы белән ирешелә[2].

Аңлатманы да ***дедуктив*** һәм ***индуктив***ка аералар. Беренче төрдә фикер гомуми нәтиҗәдән аерым фактлар белән

---

[1] *Голуб И.Б.* Конспект лекций по литературному редактированию. – М.: Айрис-Пресс, 2004. – С. 90.

[2] *Челпанов Г.И.* Учебник логики. Построение определения подчиняется правилам. – М.: 2000. – С. 99.

дәлилләүгә таба хәрәкәт итә. Икенчесендә шуның киресе күзәтелә. Аңлатмалар күбрәк фәнни китапларда һәм дәреслекләрдә очрый. Аларны редакцияләүче адресатның күзаллаулар өлкәсен, киңлеген-тирәнлеген һәм материалның характерын исәпкә алырга тиеш. Белем дәрәҗәсе югары укучыларга катлаулы материалны ирештерү өчен, аңлатманың индуктив төрен кулланалар, ә инде мәгълүматның яңасын җиткерү һәм укучыларның хәтеренә ныграк сеңдерү максатыннан, индуктив-дедуктив синтезыннан файдаланалар.

Викикитап сайтының «Габдулла Тукай шигырьләре төркеме»ннән алынган түбәндәге мисал «Пар ат»ка фәнни аңлатма үрнәге булып тора. Ул 2018 елның ноябрендә турыдан-туры, грамматик хаталары төзәтелмичә, материал төзелешенә хас кимчелекләре сакланган хәлдә күчерелде:

*Гыйрфан – аң-белем, мәдәният. «Фикер» газетасының 1907 елгы 17 нче (6 май) санында һәм «Әлгасрел-җәдит» журналының шул ук елгы 5 нче (25 май) санында, аннары (соңгы юлындагы «нечкә билләр» «нечкә белем»гә үзгәртелеп) 3 нче дәфтәрдә (1907) басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст 3 нче дәфтәрдән алынган.*

*«Пар ат» Җаек шәһәрендә язылып, Г. Тукайның туган ягын сагыну истәлеге булып тора, чөнки инде ун ел чамасы гомерен читтә уздырган кешедә туган ягын кайтып күрү тойгысы гаҗәп зур була. Габдулла Тукайга шагыйрь булып тагын да күтәрелү өчен инде борынгы Казан һәм татар халкының үзәгендә булу зарур.*

*Тукайның әлеге шигыре «Фикер»дән алынып Петербургтан нәшер ителүче «Нур» газетасы битләрендә басылып, әдәбиятыбызны баетучы уңышлы шигырь дип тәкъдим ителә.*

*«Пар ат» шигыре инглиз теленә дә тәрҗемә ителеп, Англиядә чыга торган «Россияне күзәтү» исемле журналда, Тукайның кыскача биографиясе белән бергә басылып чыккан (1914. – № 1. – III том).*

Иң башта формаль җитешсезлек күзгә ташлана: текстта бүгенге укучыга аңлаешсыз сүзләрнең тәрҗемәләре әсәргә язылган гыйльми аңлатмага кушылып китә. Тукай бер үк фикерне, мәгънәне чит телләрдән кергән якынча яисә тәңгәл мәгънәгә ия төшенчәләр аша кат-кат ныгытырга яраткан я алар ярдәмендә үзенчәлекле градацияләр төзегән. «Пар ат»ның соңгы строфасында, мәсәлән, башкаланың мәгърифәт учагы икәнлеге берничә сүз ярдәмендә аңлатыла, ассызыклана:

*Монда хикмәт, **мәгърифәт** һәм монда **гыйрфан**, монда **нур**;*
*Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...*

Татар теленә гарәпчәдән алынган «гыйрфан»ның аңбелем, мәгариф, мәгърифәт, тәрбия, белем чагылышы, яктылык һәм акыл яктысы кебек мәгънәләре бар. Ул алар ярдәмендә шигырьдәге мәгърифәт, нур сүзләре белән тыгыз бәйләнешкә керә. Тукайга хас стиль алымнарын күздә тотканда да, «Пар ат»та әлеге лексема яктырткыч, яктылык, мәгърифәт яисә аң яктысы, мәгърифәт аркасында барлыкка килгән сәләтләр буларак аңлашыла, һәм эчтәлеген мәдәният дип тә билгеләү артыграк сыман. Кыскасы, без бу очракта шушы рәвештәге антиклимакс белән очрашабыз: мәгърифәт, мәгърифәт яктысы, нур.

Алга таба төп текст булырга тиеш өлешне тел ноктасыннан камилләштерик:

*Шигырь 1907 елда «Фикер» газетасының – 6 май (№ 17), «Әлгасрел-җәдит» журналының – 25 май саннарында һәм, соңгы юлындагы «нечкә билләр» «нечкә билем»гә үзгәртелеп, «3нче дәфтәр»дә басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст «3 нче дәфтәр»дән алынган.*

Әсәргә язылган аңлатманы мәгълүмати төгәлләштерү, баету зарур. Тукай, әлбәттә, туган ягын сагынгандыр, әмма «Пар ат»ны Җаекта, шагыйрь генә түгел, рәссам да булган Лермонтовның «Тройка»сыннан әсәрләнеп иҗат иткән. Бу

хакта Тукайның баштагы җыентыкларында әйтелгән, әмма соңрак тәэсир чыганагына ишарә төшереп калдырылган**.**

Инде чираттагы абзацларны шулай ук күпмедер камилләштерик:

*«Пар ат», «Фикер»дән алынып, Петербургта дөнья күргән «Нур» газетасы битләрендә* (чыгыш саннарын күрсәтергә!) *әдәбиятыбызны баетучы уңышлы шигырь буларак тәкъдим ителә. Ул, инглизчәгә күчерелеп, Англиядә чыга торган «Россияне күзәтү» журналында Тукайның кыскача биографиясе белән бергә басылган (1914. – № 1. – III том).*

Текстка мөнәсәбәтле яңа мәгълүмат өстәлгәч, кулланылган фактларның төгәллеге ачыклангач, табылган хаталар тексттан юкка чыгарылгач, редактор бу аңлатманы тагын бер кат күздән кичерергә, камилләштереп бетерергә тиеш.

***Билгеләмә.*** Руслар билгеләмәне соңгы чорда активлашкан алынма сүз ярдәмендә – дефиниция яисә, традицион рәвештә, определение дип атый. «Русча-татарча сүзлек»тә определение – билгеләмә, объяснение аңлатма буларак тәкъдим ителгән[1]. Без дә шушы сүзлеккә таянып эш итәрбез, тар аудиториягә әлегә билгесезрәк яңа төшенчәләрне куллanышка кертмәбез.

Сөйләмдә предметны вакытлыча алмаштырып килгән билгесыйфатларны атаучы билгеләмәгә катгый таләпләр куела: анда сүзләр туры мәгънәсендә генә кулланылырга тиеш, юклык кисәкчәләре һәм тавтология тыела, билгеләмә күләменең билгеләнүче күләме белән мәгънә ягыннан тәңгәллеге кирәк.

Билгеләмәдән фәнни һәм фәнни-популяр текстларда төшенчәнең эчтәлеген, асылын ассызыклау максатында файдаланалар. Мөхәррир теге яки бу билгеләмәне кире кагу, камилләштерү алдыннан төрле сүзлекләргә, танылган

---

[1] Русско-татарский словарь: ок. 47000 слов / Э.М. Ахунзянов, Р.С. Газизов, Ф.А. Ганиев и др.; под ред. Ф.А. Ганиева. – М.: Рус. яз., 1986. – С. 352, 340.

галимнәрнең китапларына, дәреслекләргә мөрәҗәгать итә. Аларда да җитешсезлекләр, каршылыклар барлыгын ачыклаганда, белгечләр белән киңәшә яисә проблеманы хәл итүне авторның үзенә тапшыра.

Текст теориясендә дә билгеләмәне логикадагыча төркемләүдән файдаланырга мөмкин. Әйтик, сөйләмне җитешсезлекләрдән арындырганда, мөхәррир ***сөйләмә, күрсәтмә-ишарә, мәгънәви, реаль*** билгеләмәләр белән эш итә. Кызганыч ки, билгеләмәләрнең төрләрен ничек атау мәсьәләсе һаман да ахыргача чишелмәгән.

Билгеләмәләрне, вазифаларына карап, түбәндәгечә төркемлиләр:

• ***теркәүче*** – предмет-күренешнең моңа кадәр билгеле сыйфатларын саный (регистрирующее опеределение);

• ***аныклаучы*** – өстәмә мәгълүмат бирә (уточняющее...);

• ***нигезләүче*** – күренеш-вакыйгаларның асылын, эчтәлеген ачучы яңа мәгълүмат алып килә (учреждающее).

Теркәүче билгеләмәләрне аерым аудиториягә таныш түгел төшенчәләрнең эчтәлеген ачканда кулланалар. Редактор, бу эшнең отышлы башкарылмаганлыгын күрсә, төшенчәне зур күпчелеккә аңлаешлы башка сүз белән алмаштырырга мөмкин. Әгәр текстның ул өлеше төп фикерне җиткерү өчен мөһим түгел икән һәм аның юклыгы текст бөтенлегенә зыян салмаса – яңа термин, лексема кергән әлеге сөйләм берәмлеген (җөмләне яисә абзацны) сызып ташларга да була.

Ачыклаучы билгеләмәләрдән гомумкулланышта йөргән төшенчәне тагын да тирәнрәк аңлатырга һәм үзең теләгәнчә шәрехләргә кирәк вакытта файдаланалар. Әлеге төр теркәүче билгеләмәләр артыннан да килергә мөмкин.

Нигезләүче билгеләмә тар белгечлек өлкәсенә хас яисә гомумән яңа гына барлыкка килгән терминнарны аңлату өчен кирәк, һәм ул рус фәнендә формалаштыру, кертү, оештыру кебек үзара якын сүзләрдән торган синонимик оядагы «учреждающее» термины белән белдерелгән дә.

***Инструктаж*** текстлар гомумәдәбият эчендә зур урын алып тормый, әмма еш кына китапның («Мине генә уйла!» – Р. Рахманның шигырьләр тупланмасы), тамашаның («Көлсәң – көл, көлмәсәң – ела! » – спектакль, радиотамаша; текст авторы: А. Гыйләҗев), рубриканың (Айга кырын карама // Мәдәни җомга), мәкаләнең (Салым түлә дә тынычлап йокла // Шәһри Казан. – 2018. – 31 октябрь) исемнәрендә бу төргә хас сыйфатлар чагыла.

Инструктаж катгый таләп, эш тәртибе, киңәш, кагыйдә характерында була. Алар аш-су рецептлары, кул эшләренә өйрәтмә җыентыкларында, дәвалануга, ялга бәйле яисә башка төр киңәш китапларында, брошюраларында дөнья күрә. Инструкцияләү кайвакыт рәсми документларда да очрый. Нәрсәгә дә булса катгый таләп куйган текстларда боерык фигыльләр мул кулланыла.

Без төрле тип инструктажлар белән һәр көнне очрашабыз. Алар товар язуларында, урам белдерүләрендә, биналарның эчке диварларында урын ала. Кеше, рәсми күрсәтмәләр белән танышкач кына, төрле тип хокукларга ия була: машина йөртә, газдан файдалана, парашюттан сикерә... Куркынычсызлык кагыйдәләрен белми торып, хуҗалык итәргә, торакны эксплуатациягә тапшырырга, төрле инструментларны кулланырга, дәваланырга, спорт белән шөгыльләнергә ярамый. Димәк, көндәлек тормышта өйрәтмәләр, күрсәтмәләр бик кирәк.

Кызганыч, хәзерге вакытта инструктажлар күпчелек очракта рус телендә языла. Узган гасырның алтмышынчы елларында авыл урамнарында, бигрәк тә беренче йорт капкасында, стенасында колхозлашу елларыннан калган һәм такталарга язылган татарча боерыклар, таләп мәгънәсе дә тоемланган шигарьләр еш очрый иде. Мәсәлән, «Тәмәкене урамнарда йөреп тартмагыз!», «Су буйларын, ерганакларны пычратмагыз! Чүпләрегезне махсус чокырларга илтегез!», «Һәрбер хуҗалыкта янгын сүндерү чараларын булдырыйк!» һ. б.

Инструктажларның төрләре һәм саны көннән-көн арта бара. Алардагы җөмләләр адресатка, гамәлгә бәйле рәвештә төрле катгыйлыкта була, һәм бу тыныш билгеләре ярдәмендә дә белдерелә.

Совет чорында төрле оешмалар, бигрәк тә сәяси-иҗтимагыйлары, үз кануннарын кабул итә, әгъзаларының хәтта көндәлек тормышын, үзара мөнәсәбәтләрен дә бер тәртипкә салырга омтыла иде. Коллектив көч белән язылган, җыелышларда кабул ителгән, җитәкчелек раслаган әлеге кануннар, боерык фигыльләрдән төзелмәгәндә дә, үтә катгый үтәлергә тиеш дип саналды. Мәсәлән, «Советлар Союзы пионерлары кануннары» асылда өлкән иптәшләр, беренче чиратта, комсомоллар тарафыннан пионерларга җитди рәвештә куелган таләпләр иде. Аңа бирелгән һәм, үзгәртелмичә, хәзерге сүзлекләргә, интернет-белешмәлекләргә дә теркәлгән аңлатмадан да бу катгыйлык тоемлана кебек:

*Законы юных пионеров – свод основных правил жизни и деятельности члена Всесоюзной пионерской организации им. В. И. Ленина. В образной и доступной пониманию детей форме изложены цели и задачи детской коммунистической организации, основные принципы коммунистической нравственности, морально-этические нормы поведения юных пионеров*[1].

1957 елда Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр берлеге Үзәк комитетының (русча: ЦК ВЛКСМ) 8 пленумында кабул ителгән «яшь пионер кануннары»н шул чорда татарчалаштырылган һәм иң киң таралган вариантта китерербез:

*СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ПИОНЕРЛАРЫНЫҢ ЗАКОННАРЫ*
*Пионер Туган илгә, партиягә, коммунизмга турылыклы.*
*Пионер комсомол булырга әзерләнә.*
*Пионер көрәш һәм хезмәт геройларына тигезләнә.*

[1] Законы пионеров Советского Союза // stydopedia.

*Пионер һәлак булган көрәшчеләрнең истәлеген хөрмәт итә һәм Туган илне саклаучылар сафына басарга әзерләнә.*

*Пионер – укуда, хезмәттә һәм спортта иң алдынгы.*

*Пионер – тәртипле.*

*Пионер – намуслы һәм турылыклы иптәш, дөреслекне һәрвакыт кыю яклый.*

*Пионер – октябрятларның әйдәүчесе һәм иптәше.*

*Пионер – пионерларның һәм бөтендөнья хезмәт ияләре балаларының дусты.*

*Пионер намуслы һәм гадел.*

Русча кануннардан соңгысындагы «Его слово – как гранит» («Аның сүзе – гранит кебек») өлеше, тәрҗемәдә яңгырамый дипме, күп җирдә татарча әйтелми иде.

Пионерларның яшәү тәртибе шулай ук канунилаштырылды. Ул мәктәп, сыйныф диварларына махсус такталарга язылып эленде. Әлеге көн тәртипләрен коммунистлардан, комсомоллардан торган коллектив хәзерләгәндер, редакцияләгәндер дип фаразлыйк. «Пионерларның гадәтләре», октябрятлар өлкәнрәкләр оешмасына кабул ителгәнче үк, сыйныф сәгатьләрендә катгый кагыйдә сыйфатында аңлатылды, ятлатылды һәм үтәлеше даими тикшерелде. Инструктажның оригиналдагы аһәңен күрсәтер өчен, түбәндә оригиналда китерәбез:

*ОБЫЧАИ ПИОНЕРОВ*

*Пионер не валяется в постели утром, а поднимается сразу, как ванька-встанька.*

*Пионеры стелют постели своими, а не чужими руками.*

*Пионеры моются тщательно, не забывая мыть шею и уши, чистят зубы и помнят, что зубы – друзья желудка.*

*Пионеры точны и аккуратны.*

*Пионеры стоят и сидят прямо, не горбясь.*

*Пионеры не боятся предлагать свои услуги людям. Пионеры не курят; курящий пионер – уже не пионер.*

*Пионеры не держат руки в карманах; держащий руки в карманах не всегда готов.*

*Пионеры охраняют полезных животных.*

*Пионеры помнят всегда свои обычаи и законы.*

Текст интернет челтәрдән алынды, әмма андагы «ванька-встанька» сүзе татарча тәрҗемәләрдә юк иде. Димәк, мөхәррирләр тәрҗемәдә уңышлы сүз тапмаган. Шушындый ук яшәү кануннары һәм көндәлек гамәл тәртипләре мәктәпләрдә октябрятлар һәм комсомоллар өчен дә эшләнде.

Саф инструктаж текстлар янәшәсендә башка төр язмаларга урнаштырылган инструкцияләр дә бар. Өйрәтмәләр хәтта әдәби текстлар эчендә дә очрый. Инструктаж фикерләү, хикәяләү, аңлатма, билгеләмәгә өстәмә төсмер бирә. Кайбер текстлардан кемдер тарафыннан бирелгән боерыкларны тоеп алу кыен түгел. Мисалга партия таләпләрен үтәүне чагылдырган «Пионер анты»н китерергә мөмкин:

*Мин, Фәлән Фәләнова, Бөтенсоюз Пионерлар оешмасына кергәндә, үземнең иптәшләрем каршысында тантаналы рәвештә ант итәм: Ватанымны кайнар яратырмын, бөек Ленин кушканча, Коммунистлар партиясе өйрәткәнчә укырмын һәм көрәшермен, Советлар Союзы пионерлары законнарын һәрвакыт үтәрмен!*

Алга таба «Шәһри Казан»ның электрон вариантыннан алынган «Кыскача яңалык»ны китерербез. Күләме белән әлеге рубрикага бик үк туры килмәгән инструктаж текст белән эш тәртибе түбәндәгечә барыр. Уку белән янәшә:

- якын торган төгәл кабатлауларны, тамырдаш сүзләрне калынайтырбыз;
- җөмләдән кыскартырга кирәкле яисә мөмкин, алмаштырырга тиешле берәмлекләрнең астына сызарбыз;
- җәяләр эчендә җитешсезлекләрдән арындырачак вариантлар бирербез;
- төшеп калган хәрефләрне, тыныш билгеләрен өстәрбез:

***Салым** түлә дә тынычлап йокла*

*Автор, 31 октябрь 2018 – 17:09*

*3 декабрьгә кадәр барлык **салым**нарны* (бурычларны) *да түләп бетерергә кирәк, ди Татарстанның Федераль **салым** хезмәте идарәсе.*

*Транспорт, җир налогларыннан тыш, **салым салына** торган милек булып торак йорт, фатир, гараж, машина кую урыны һәм башка объектлар да санала.* (Налог салынучы объектларны беррәттән санап, салым сүзен юкка чыгарырга мөмкин: «Налог транспортка, җиргә, торак йортка… салына»). ***Салым**ны* (Аны) *банклар, терминаллар, почта бүлекләре, электрон дәүләт порталы **аша түләр**гә була. **Шулай ук** федераль **салым** хезмәте сайтында теркәлгән шәхси кабинет **аша** да **түлә**үләр кабул ителә.*

*Советлар Союзы Геройларына, Россия г(Г)еройларына, Дан орденының тулы кавалерларына, **шулай ук** Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннарга, **инвалид**ларга, **инвалид*** (аларның) *балалары*(на), *опекунлыкка сабый алган әти-әниләр*(гә) *өчен **салым** түләүдә **ташламалар** каралган.* (Чираттагы абзацны монысына тартып китерәбез, чөнки тема дәвам ителә.)

*Пенсия реформасынна соң, пенсионерларга **ташламалар*** (алар) *сакланамы (,) дип кызыксынучылар күп булды. III чакырылыш Казан шәһәре Думасының сессиясендә моңа ачыклык кертелде кебек. 2019 елның 1 гыйнварыннан 55 **яшькә** җиткән хатын-кызларга һәм 60 **яшьләре** тулган ир-атларга алты сутый җир **салым**ыннан азат итүдә **ташламалар** карала, дигән карар кабул ителде.*

***Салым** түләгәндә истә тотарга **кирәкле*** (Налог түләүчеләргә) *киңәшләр:*

– ***салым** түләргә **киркә**леген* (кирәклеген) *искәрткән белдерүнең почта аша килгәнен көтеп тормаска кирәк, ул бөтенләй* (Салым квитанциясе почта ящикларыгызга) ***килмәскә** мөмк*(и)*н. Әмма, бу* (Бу) *кеше **салым**нан* (аны

түләүдән) *азат итела диган суз түгел* (Җөмләне кыскартырга да була). ***Федераль салым хезмәте сайтында** теркәлеп, шәхси кабинетын **булдырган** кешеләргә **салым** түләү **турында** белдерүләр электрон формада гына җибәрелә* (Федераль салым хезмәте сайтында шәхси кабинеты булган кешеләргә белдерүләр электрон формада гына җибәрелә). ***Салым*** (Алар) ***турындагы** мәгълүматны **федераль салым хезм**(**ә**)**те сайтыннан** да тикшерергә **була*** (мөмкин).

*– һәркем **үзе өчен үзе салым**ны **үзе** түләргә тиеш. Хатын **өчен** ирнең* (һәм киресенчә дә) *банк картасы белән **салым** түләргә киңәш ителми. **Салым** хатынның милке өчен килсә дә, карта ир исемендә булгач, салымны ире түләгән кебек исәпләнә (.)*

Әлбәттә, нәрсәдер өчен кем акча кертсә, шул түләгән була да. Бу факт кемдә бәхәс уятсын?! Ирме ул, күршеме, баламы – аерма юк. Хәтта чит кеше дә синең үтенечеңне тыңларга мөмкин. Соңгы җөмләдән укучыга һичбер файда алмый, анда, иң мөһим булырга тиешле киңәш чагылыш тапмый. Журналист, кемдер икенче кеше өчен акча күчергәндә, банк хезмәткәрләренә, исәпләү машиналарына документациядә әлеге түләү счётка ялгыш киткәндәй күренгәнлекне, шул сәбәпле субъектның бурычы капланмаска мөмкинлекне искәртергә тиеш иде. Бу төр кисәтү шуннан да килеп чыга: почта клиентлары, бигрәк тә өлкәннәр, банкомат төймәләренә ашыгып басып яисә саннарны начар күргәнгә, акчаларын тиешсез счётларга юллый, аннан кире кайтару артыннан йөри. Исәп-хисап җайланмалары гаилә исемлекләре белән эш итми, теге яки бу семьяның нинди әгъзалардан торуын исәпкә алмый, төрле кешеләрдән килгән түләүләрне янәшә куеп карамый. Электрон хезмәттә, барыннан да битәр, түләүченең исем-фамилиясе, шәхси счётлары һәм файдаланган карта саннары мөһим.

«Кыска яңалык» кына да «Шәһри Казан» газетасы хатага батканлыкны күрсәтә. Камилләшеп беткән текст идеал булып

калса да, бу кадәр җитешсезлекләр гафу ителерлек түгел. Материалның русча язмаларга, «өстән» төшкән документларга нигезләнеп башкарылганлыгын да онытырга ярамый: авторның эше җиңеләйтелгән, аңа ни дә булса эзләп йөрисе юк. Ул, хөкүмәт документларының эчтәлеген аңлатканда, хезмәтенә аеруча җитди якын килергә тиеш. Элекке чорларда рәсми инструктажларда хаталар бу кадәр күп очрамый иде.

**Текстны логик яктан камилләштерү** дигәндә, мөхәррирнең ***логик анализ берәмлекләрен ачыклавын***, аннан соң әсәрнең мәгънәви бөтенлеге мәсьәләсен хәл итүен күздә тотабыз. Бу вакытта ул эзлекле фикер йөртүгә хас тәңгәллек, каршылык, өченчене юкка чыгару, нигезләүнең җитәрлек булуы кебек кануннардан файдалана. Редактор текстта алар белән исәпләшмәү очракларының әдәби чарага карыймы-юкмы икәнлеген һәм логикага сыешмаган, аермачык төзәтелергә тиешле урыннарны билгели, автор алдына текстны бу төр җитешсезлекләрдән арындыру бурычын куя. Хезмәтнең иясе бер кат төзәтмәләр керткәннән соң, мөхәррир текстны яңадан күз уңыннан кичерә һәм калган хаталарын юкка чыгара.

Язма һәм телдән сөйләм эзлеклелеген галимнәр узган гасырның илленче еллары ахырында гына тирәннән өйрәнә башласалар да, хәзерге көндә инсанның логик культурасы дигән гыйбарә актив кулланышка кергән инде. Редакторның логика кануннарын белүе исә һөнәрилек дәрәҗәсен билгели, әнә шуңа күрә студентлар логиканы фән буларак үтәләр, аның кануннарыннан риторика һәм сөйләм әдәбе күнекмәләрен үзләштергәндә дә файдаланалар.

Текстта логик эзлеклелек – иң мөһим аспектларның берсе, һәм аның саклануы катгый таләп ителә. Беренчедән, тиешле тәртиптә корылган юллар хезмәтнең тәүге битеннән үк аның белән алга таба танышу теләген сүндермәскә тиеш. Укучыга информация җиткерүче, тотыш әдәбе нормаларын тәкъдим итүче, матурлык тойгысы тәрбияләүче вакытлы матбугат һәм әдәбият, сөйләм эзлеклелегенә ия булмаса, үзләренә

йөкләнгән вазифаларны да тиешле дәрәҗәдә башкармый. Эпик әсәрдә логикасызлык геройларның эш-хәрәкәтләре мотивлаштырылмауда, сюжет өзеклегендә, текст өлешләре арасында бәйләнешләр юкка чыгуда һәм чишелешнең тормышчан түгеллегендә, нигезсезлегендә чагылыш табарга мөмкин. Фәндә исә логик эзлексезлек хәтта хата нәтиҗәләргә китерә, текстны таркау итә. Эзлекле фикер йөртү сәләте галим кеше өчен иң мөһим сыйфатлардан санала.

Төп эше текстны камилләштерү булган мөхәррир логика фәненең төп өйрәтмәләрен, терминологиясен, кануннар системасын яхшы истә тотарга, үз гамәлендә һәрдаим кулланырга тиеш. Әлбәттә, редактор бәйләнешле фикергә ирешү вазифасын үз өстенә тулысынча алмый, әмма аның сөйләмдә логика кануннары бозылуны тоя белүе мәҗбүри. Авторның эзлекле хөкем йөртүен әсәренең грамматик, стилистик һәм прагматик бәйләнешләре чагылдыра, һәм алар ук текст аңлаешлылыгының табигый сыйфатлары да булып тора.

Редакторның төп вазифасы – материалның мәгънәви һәм логик сыйфатларын һөнәри дәрәҗәдә бәяләү генә түгел, язмасына хас кимчелекләр хакында авторына әдәпле рәвештә җиткерә белү һәм анда сөйләмен алга таба камилләштерүгә теләк-ихтыяҗ уяту да.

**Логика кануннарын үтәү.** Сөйләм төгәл, аңлаешлы булсын өчен, логика кануннары сакланырга тиеш. Алга таба сүз алар хакында барыр.

**1. *Тәңгәллелек канунын*** охшаш, тәңгәл карашларны янәшә кую дип тә атыйлар. Автор бер әйткән фикерен шул ук хезмәттә яңадан кабатларга мөмкин. Ул чагында текст укучыга җиңелрәк аңлашыла, эчтәлеге дә яхшырак истә кала. Логиканың тәңгәллек кануны дәреслекләр язганда аеруча активлаша. Ул кайвакыт информацион үзәкләрне ассызыклауга хезмәт итә; әдәби әсәрләрдә теге яки бу хәрәкәтләрне, күренешләрне мотивлаштырганда, бигрәк тә үтәли мотивлар тудырганда чагылыш таба.

Тәңгәллек кануныna нигезләнүнең матур үрнәкләре шигъри текстларда еш очрый. Шагыйрьләр теге яки бу карашларын төрле җөмләләр белән ныгыталар, сүз уйнату ярдәмендә кабатлыйлар. Бер үк фикерне төрлечә һәм төрле урында җиткерү текстка эзлеклелек, бөтенлек, тәмамланганлык төсе бирергә, строфаларны үзара тыгызрак бәйләргә ярдәм итә. Бу урында Тукайның һәркемгә билгеле «Көз» шигыренең үзара күпмедер аерылган, әмма охшаш беренче һәм соңгы строфаларын искә төшерик:

*Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;*
*Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.*

/.../

*Көзге төн, ямьсез, караңгы... Өй түрендә җил җылый,*
*Җил – хәбәр ул: ач үлемнең куркусыннан ил җылый!*

**2. *Капма-каршылык кануны:*** капма-каршы фикернең берсе дөрес булса, икенчесе – һичшиксез, хата. Сөйләмгә мөнәсәбәтле болай дип әйтергә мөмкин: текст эчендә фикерләр бер-берсенә капма-каршы килергә тиеш түгел. Редакторга ялгышлык белән кергән каршылыкларны табу, әлеге проблеманы чишү, дөрес фикерне сайлап алу эше йөкләнә. Ул бигрәк тә гыйльми хезмәтләрдә яңгыраган карашларга, төгәллекне таләп иткән документлардагы мәгълүматларга игътибарлы булырга тиеш.

Дөрес, капма-каршылык канунын «бозу» әдәби чара вазифасын да башкара ала. Мәсәлән, язучы кеше күңелендә барган конфликтны бирергә тели икән, героеның акылына таянмавын, ягъни логика таләпләре белән исәпләшмәвен, хисләр колы икәнлеген күрсәтәчәк, аннан капма-каршы фикерләр әйттерәчәк. Бигрәк тә шагыйрьләр «лирик мин» җанында барган бәрелешләрне аның эзлексез сөйләме һәм үзара каршылыклы фикерләре аша чагылдырырга ярата.

Капма-каршылык кануны әдәби геройларның үз арасындагы бәхәстә, хәтта автор белән хикәяләүче позициясендә

чагылыш табарга мөмкин. Язучы, каһарманнар арасындагы конфликтны чишә-чишә, әсәр ахырында вакыйгаларда катнашучыларны, үзен, хикәяләүчене, укучыны нинди дә булса фикергә алып чыга. Нәтиҗә исә һичбер вакытта да ике төрле була алмый.

Кеше күңелендә барган каршылыкларны һәм лирик геройның холык сыйфатларын чагылдыру максатыннан, «берсен-берсе кире кагучы фикерләрнең дөреслеген исбатларга маташулар»га мисаллар бихисап. Түбәндә поэтик тексттан китереләчәк өзек «лирик мин»нең үзендәге сөю тойгысын танырга теләмәвен, күңелендә капма-каршы хисләрнең, теләкләрнең бәргәләнүен күрсәтә. Лирик каһарман үзе белән якын мөнәсәбәттәге кешене, бер караганда, яратуына, икенче караганда, яратмавына ышандырмакчы. Кыз егетне кискенлек белән кире какканда да, укучы асылда «лирик мин»дә чынлыкта сөю хисләре өстенлек иткәнне ачык аңлый. Автор аны героеның яратуына һаман да сөйгәнен уйлавын, хәтта тамчы тавышларында да исемен ишетүен тасвирлап, әйтеп ышандыра һәм аның яратмау турындагы сүзләрен юкка чыгара:

*Мин яратам сине! Юк, яратмыйм!*
*Юк яратмыйм сине тамчы да!*
*Зур үпкәм бар таңда исемеңне*
*Тәрәзәмә чирткән тамчыга.*
(*Рифә Рахман*. Тамчы)

**3.** Өченче катгый кагыйдә: бер үк вакытта кулланылган ике капма-каршы фикернең берсе дөрес икән, икенчесе – хата, һәм читтә торган өченче хакыйкать була алмый. Аны **«төшеп калган фикер»** кануны буларак та аңлаталар.

Моны гап-гади әдәби текст ярдәмендә ачып карыйк:

*– Кояш сүнеп бара,– диде Марат.*

*– Юк, кояш сүнүгә таба бармый!– дип каршы төште Алия.*

Әгәр Марат дөресен сөйли икән, Алия хата фикер йөртә, һәм киресенчә дә. Югарыдагы текстка өченче төрле фикер кыстырсак, ул хакыйкать булмаячак, ә бәхәсне башка яссылыкка күчерәчәк. Мәсәлән, Алсу: «Әлеге карашларның берсе дә исбатланмаган», – дип әйтсен ди. Бу очракта сүнүсүнмәүнең исбатлану-исбатланмавы бәхәс темасына әверелә.

Өченче кагыйдә матур әдәбияттан тыш текстлар өчен катгый булса да, тормыштан алынган күренешләрне чагылдырган әдәби әсәрләрдә «төшеп калган фикер кануны» һәрвакыт исәпкә алынмый. Югарыдагы әңгәмә барышында өченче кеше, бәхәсне көлкегә борырга, аны туктатырга чакыргандай: «Кояш сүнә дә, сүнми дә», – дип тә әйтергә мөмкин.

**4. *Төпле дәлилләрнең җитәрлек булу кануны*** аеруча фәнни һәм коры мәгълүмат белән эш иткән публицистик текстлар өчен мөһим. Нәфис әдәбиятта исә логика кануннары үтәлмәү, әйткәнебезчә, сәнгати алым рәвешендә яши. Мәсәлән, сатирик һәм юмористик эчтәлектәге әсәрләр тормыш логикасын аңламауга, сөйләм логикасын бозуга нигезләнә ала.

Нәфис текстны камилләштерүче зевгма, ягъни мәгънә ягыннан төрле зурлыктагы сүзләрнең тезүле бәйләнешкә керүе; каламбур, ягъни сүзнең текст эчендә берничә мәгънәдә кулланылышы, логик чылбырны өзүче сүзләрдән файдалану кебек төрле әдәби алымнардан хәбәрдар булырга тиеш.

Текст төзүдә, максималь берәмлекле җөмләләр белән беррәттән, минималь берәмлекле тәгъбирләр дә катнаша. Тәгъбир – хәбәрлекле мөнәсәбәткә нигезләнгән һәм билгеле бер мәгънәгә ия, ниндидер максатка хезмәт иткән сөйләм берәмлеге, реальләшкән җөмлә. Теләсә нинди тәгъбир җөмлә рәвешен алса да, теләсә нинди җөмлә тәгъбир булмый. Шул ук вакытта җөмлә эчендә берничә тәгъбир дә очрарга мөмкин.

Тәгъбирләр мәгънәви басымнар ярдәмендә ясала. «Алсу китап язган» җөмләсенең мәгънәви басымын өч сүзнең һәрберсенә дә куярга мөмкин. Ул вакытта без субъектны,

объектны һәм предикатны ачыкларбыз. Мәгънәви басымнарны күчергәндә, тойгы үзгәрешләре кискен дә була ала. Бу очракта текстта хис, аһәң тыныш билгеләре белән тамгалана. *Алсу (!) китап язган.* Бу җөмләдә субъектның шундый сәләткә ия булуына шаккату яисә соклану тоемлана. *Алсу (?) китап язган.* Бу хәлгә аптырау, кызның бу эшенә ышанмау сизелә. Инде басымны уртага куеп карыйк: *Алсу китап (!) язган.* Автор ниндидер кызның китап кадәр китап язганлыгын яисә хезмәтнең нәкъ менә китап, брошюра да, буклет та түгел икәнлеген хәбәр итә. *Алсу китап (?!) язган.* Җөмлә авторы бу хәлгә ышанырга-ышанмаска белми. *Алсу китап язган!!!* Монда исә эшнең башкарылганлыгы көчле, ышандырырлык итеп ассызыклана. *Алсу китап язган?!* Җөмләдә бу хәлләргә шикләнеп карау тоемлана. Аның иясе әңгәмәдәшеннән үзе ишеткәннәрне кабатлавын, сүзенә ышандыруын көтәргә дә мөмкин. Уйланулы җиткерелгән фикерне шушы рәвешчә тамгаларга булыр иде: *Алсу китап язган...* Һәм җөмлә дә инде бөтенләй башкачарак, соңгы сүзе сузылыбрак, тынычрак әйтелер.

Сөйләмебездә сүзләрнең калыплашкан тәртибе булганга, татарча текстларның тәгъбирләрен аңлатып бирү авыр саналмый. Шулай да монда бер куркыныч сагалый. Көндәлек аралашуда мәгънәви басымнарны төрле урынга куябыз һәм җөмләдәге мөнәсәбәт яссылыгын үзебез теләгәнчә корабыз, ә шул ук җөмлә басма вариантта автор ирештерергә теләгән фикерне, мәгънәне бирә алмаска мөмкин. Андый очракта без басымны график билгеләргә тиеш булабыз. *(<u>Мин</u> китап укыйм. Мин китап <u>укыйм</u>. Мин <u>китап</u> укыйм. <u>Укыйм</u> мин китап!)* Дөрес, болай эшләү, бигрәк тә соңгы чорга караган әдәби-публицистик хезмәтләрдә логик басымны апострофлар яисә башка бер махсус тамга ярдәмендә күрсәтү күзәтелми диярлек. Диалогларда, аеруча сорау-җавап рәвешендә барган җанлы сөйләм текстларында моның кирәге дә юк, әңгәмәдәшләрнең ни әйтергә теләве, нәрсәгә басым ясаганы

ачык аңлашыла. Тойгылы җөмләләрдә, тыныш билгеләре ярдәмендә, логик басымнарны билгеләүгә мисалларны басма нәфис әдәбияттан шактый табарга мөмкин. Мәгънәви басым, сорауның эчтәлегенә бәйле рәвештә, җөмлә ахырындагы яисә эчендәге тыныш билгесе ярдәмендә, шушы рәвешчә күрсәтелә алыр иде: *Син мине яратасыңмы?; Син мине (?) яратасыңмы?; Син (?) мине яратасыңмы?; Син (?) мине (?) яратасыңмы?*

Җәяләр эченә төрле тыныш билгеләре куйганда, мәгънә төсмере, әйтелеш шунда ук үзгәрәчәк: *Син (!) мине (!) яратасың?* Гомумән, тыныш билгеләре ярдәмендә сүзләргә төшкән басымнарны тәңгәлләштерергә дә, төрле дәрәҗәдә итәргә дә, юкка чыгарырга да була: *Син (!) мине (?) яратасың?!; Син... мине... яратасың...; Син (!) мине яратасың!!!*

Татар теленә хас сүзләр тәртибе язма текстларда да үзгәрә ала. Бу күбрәк поэтик әсәрләрдә күзәтелә, һәм инверсия аның иң мөһим сәнгати чараларыннан санала. Чәчмә текстлардан да әлеге күренешкә мисаларны күп китерергә мөмкин. Хәбәр, мәсәлән, сөйләм акценты предикатка төшкәндә, җөмләнең алдына куела. Бу алым әйтелгән фикерне раслау, дәлилләү, мөнәсәбәт өстәү максатыннан кулланыла.

Ничә вакыйга чагылдыруларына карап, тәгъбирләр ***беробъектлы*** һәм ***күпобъектлы*** була. *Дәрес хәзерләп утырам* – эш-хәл турында хәбәр. *Телевизор карап, дәрес хәзерләп утырам* – янәшә ике эш турында хәбәр. *Телевизор карап һәм ашый-ашый, дәрес хәзерләп утырам* – янәшә өч эш турында хәбәр. Чәчмә сөйләмдә очраган бу төр тәгъбирләрдә, янәшә эшләрне җиткерүләренә карамастан, хәбәрләр алмашына алмый. Урыннарын күчергәндә, грамматик формалар үзгәрә, мәгънәви басым башка сүзгә күчә: *Телевизор карап һәм дәрес хәзерләп ашыйм.*

Мөхәррир, текстның логикага буйсынуын тикшергәндә, аны әнә шундый тәүге карашка вак тоелган, чынлыкта үтә мөһим һәм сөйләм структурасын чагылдырган

берәмлекләрне анализлап укый. Ул бу вакытта текст теориясе предметының төп мәсьәләләреннән саналган тема-рема бәйләнешләрен һәм тәгъбир компонентларының темадан ремага таба бару юнәлешендә төзелергә тиешлеген истә тота.

Тәгъбирләр коммуникатив яссылыкта ике төргә бүленә.

• ***Информатив (хәбәри, мәгълүмати)*** – вакыйганың эчтәлеген җиткерүче, ягъни текстны яңа мәгълүмат белән баетучы тәгъбирләр. Алардан тасвирлау, хикәяләү, аргументлаштыру, анализлау вакытында файдаланалар.

• ***Верификатив (раслаучы, кире кагучы)*** – раслау, инкяр итү яки нинди дә булса бүтән модаль мәгънә белдерү максатыннан кулланылган гыйбарәләр. Алардан бәяләүче категория рәвешендә файдаланалар, ә төп вазифалары теге яки бу сөйләмгә мөнәсәбәт күрсәтү дип санала. Икенче төрле әйткәндә, фикергә төзәтмә кертү яисә тикшерү юлы белән раслау.

Төрле тип гыйбарәләрне кулланганда да, укучыга алда җиткерелгән сөйләмне, фикерне, мәгълүматны истә тотарга кирәк, югыйсә авторның яңа дигәне – иске, раслыйм дигәне кайчандыр кире кагылган хакыйкать булырга да мөмкин. Мөхәррир тексттан шул җитешсезлекләрне дә эзли.

Тәгъбирләр нигезендә фразаара бөтенлекләр хасил була. Алар – текстның икенчел семантик-синтаксик берәмлекләре – берничә тәгъбир берләшүеннән туа һәм тематик-структур бәйләнеш хасил итә. Фразаара бөтенлек тема-рема эзлеклелеге рәвешен ала, һәм, сөйләм җөмләдән артып киткән очракта, реманың темага әйләнү процессы башлана.

Тема берлеге редактор тарафыннан микротема дәрәҗәсендә дә, макротема яссылыгында да тикшерелергә мөмкин. Иң кечкенә хосусый тема фразаара бөтенлектә карала. Ниндидер микротемадан икенчесенә күчү вакытында фразаара бөтенлекнең чикләре билгеләнә. Фразаара бөтенлек исә текст өлешендәге уртак теманы яктыртуга хезмәт итә. Берничә микротема үзара кушылгач, тулы текстның төп

темасы, ягъни макротема ачыклана башлый. Мөхәррир, тексттагы логик эзлеклелекне тикшергәндә, темара бәйләнешләрне, аларның үзәк темага хезмәт итәргә тиешлеген күз уңында тота.

Текстта очраган һәр тәгъбир алдагысы белән бәйләнә барса гына, ягъни билгеле хәбәрдән этәрелеп китсә генә, укучы өчен моңарчы таныш булмаган яңалык җиткерә. Тема-рема эзлеклелеге әнә шул рәвешчә туа да. Текстның һәр яңа берәмлеге билгеле вакыйганы минималь күләмдә сакларга һәм яңалыкны максималь күләмдә алып килергә тиеш. Түбәндәге мисал бу ноктадан шактый уңышлы сыман:

*Урманга <u>көз</u> килгән. Быелгы <u>көз</u> әллә нинди <u>моңсу</u>. Бу <u>моңсулык</u> иртә саргайган агачлардан, ботакларында күңелсезләнеп утырган кошлардан, болытлар артына гына качып караган кояштан – бөтен-бөтен нәрсәләрдән саркыла сыман.*

Тексттагы тема һәм рема эзлеклелеге ассызыкланган сүзләр ярдәмендә күрсәтелде. Әлеге бәйләнешне һәрвакытта да саклый алмау, моны гомумән белмәү күпчелек татар журналистларына хас. Чираттагы җөмләнең алдагысына ялганмавы – татар матбугаты өчен типик күренеш. Түбәндәге өзектән бу төр хатаны тотып алу кыен булмас. Ул «Шәһри Казан»ның интернет-сайтыннан алынды һәм әлеге газета өчен бу төр хаталар ясау бик табигый:

*КЫСКАЧА ЯҢАЛЫКЛАР*
*Автор, 9 апрель 2018 – 13:50 .*

*Читтән килеп эшләүчеләр китереп чыгарган юл һәлакәтләрендә 524 кеше һәлак булган.*

*Аварияләр кими бару фонында юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә яңа тренд барлыкка килде: БДБ гражданнары гаебе белән килеп чыккан аварияләр саны арта.*

*Россия Эчке эшләр министрлыгының юл хәрәкәте иминлеге фәнни үзәге аналитик хисабында шундый мәгълүмат*

*китерелә. Бу хакта «Коммерсант»ка сылтама белән «Татар-информ» хәбәр итә.*

*Мондый аварияләр саны 4,2 процентка (4,2 меңгә) арткан, аларда 524 кеше һәлак булган, 5,93 меңе төрле тән җәрәхәтләре алган. Әлеге проблема 2016 елда да билгеләп үтелгән: ул чагында төзелгән хисапта әйтелгәнчә, биш авариянең берсендә БДБ илләреннән килгән машина йөртүчеләр катнашкан.*

*«Алар Россиягә акча эшләргә килә, бик нык ашыгалар һәм юл йөрү кагыйдәләрен начар беләләр, – диде Дәүләт Думасы дәүләт төзелеше комитеты рәисенең беренче урынбасары Вячеслав Лысаков. – Әлегә бу проблемадан чыгу юлын күрмим. ЮХИДИне акрынлап вәкаләтләреннән мәхрүм итәләр, тиздән кагыйдә бозуларга чик куярлык кеше дә калмаячак».*

Текстны бәйләнешләр ноктасыннан камилләштергәнче, хәбәр башламындагы тренд сүзенә тукталып үтик. Ул үзгәреш тенденциясен аңлата: «Тренд – основная тенденция изменения чего-либо: например, в математике – временного ряда. Тренды могут быть описаны различными уравнениями – линейными, логарифмическими, степенными и так далее»[1]. Әлеге төшенчә бигрәк тә фонд базарында, мода өлкәсендә, икътисадта киң кулланыла. Инглизләрдән таралган тренд лексемасының рус телендәге башка мәгънәләре: омтылыш, юнәлеш. Журналистның үзен чит телләрне белүен күрсәтү өчен генә керткән алынмасы мәгълүм текст берәмлеге өчен табигый яңгырашлы түгел. Ул авторның татар сүзләрен аз белүен дә күрсәтеп тора.

Хәзер тексттагы җөмләләрне үзләре торырга тиешле урынга күчерик һәм кабатланган, охшаш тамырлы-нигезле сүзләрнең астына сызыйк, төшереп кенә дә калдырырга мөмкиннәрен билгелик, аерым сүзләрне алмаштыру вариантларын күрсәтик:

[1] Тренд // Википедия // ru.wikipedia.org

*Читтән* *__килеп__* *эшләүчеләр китереп чыгарган юл һәлакәтләрендә 524 кеше һәлак булган. Россия Эчке эшләр министрлыгы Юл хәрәкәте иминлеге фәнни үзәгенең аналитик хисабында шундый мәгълүмат китерелә. Бу хакта «Коммерсант»ка сылтама белән «Татар-информ» хәбәр итә.*

*__Аварияләр__* *кими бару фонында* (шартларында) *юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә яңа тренд* (күренеш) *барлыкка* *__килде__*: *БДБ гражданнары гаебе белән* *__килеп__* *чыккан* (туган) *__аварияләр__* __(һәлакәтләр)__ *__саны__* (кыскартырга мөмкин) *__арта__* (ешайганнан ешая). *__Мондый аварияләр__* *__саны__* (сызарга кирәк) *4,2 процентка* (4,2 меңгә – тексттагыча) *__арткан__*, *__аларда__* *524 кеше һәлак булган, 5,93 меңе* (5930 юлчы) *төрле тән җәрәхәтләре алган.*

Текст алга таба стилистик-синтаксик яссылыктан тагын да ныграк камилләштерелде:

*Юл һәлакәтләрендә чит ил кешеләренең гаебе зурлыкны статистик мәгълүматлар да сөйли: 2016 ел хисабында биш авариянең берсендә БДБ мәмләкәтләреннән килгән машина йөртүчеләр катнашуы теркәлгән.*

Журналист Вячеслав Лысаковның чынлыкта Дәүләт Думасының **Конституцион законнар җыелмасы һәм дәүләт төзелеше комитеты** рәисенең беренче урынбасары икәнлеген «онытып җибәрә» һәм аның сүзләрен дә эзлекле җиткерә алмый.

Чит ил кешеләренең Россиягә акча эшләргә килүләрен бик нык ашыгулары һәм юл кагыйдәләрен белмәүләре янәшәсендә атау табыш эзләүне дә юл иминлеге хезмәткәрләре алдында торган мәсьәләгә «әйләндерә». Проблемадан чыгу юлы урынына, аны чишү турында сүз йөртү уңышлырак кебек. Җитмәсә, дәрәҗәле кәнәфи биләгән депутат кагыйдә бозучылардан яңадан имтихан бирдерергә, аларга гаепләренә бәрабәр штраф салырга, башка төр җәзалар кулланырга мөмкинлекне башына да китерми икән, дигән фикер туа.

*ЮХИДИне акрынлап вәкаләтләреннән мәхрүм итәләр, тиздән кагыйдә бозуларга чик куярлык кеше дә калмаячак* җөмләсе алдагысына мәгънә ноктасыннан ялганмый. Монда әлеге оешмага бирелгән кайсы вәкаләтләрнең юкка чыгуы һәм ЮХИДИдә хезмәт итүчеләрнең саны кыскару турында сүз барырга тиеш кебек тоела. Укучыга автор фикерен фаразларга гына кала. Әлеге җөмләне: *Шушындый кыен хәлләрдә ЮХИДИне акрынлап кайбер вәкаләтләреннән мәхрүм итүләре, андагы кыскартулар аптырашта калдыра. Эшләр болай барса, тиздән кагыйдә бозуларга чик куярлык кеше дә калмаячак,* – дип үзгәртү иң отышлысы булыр.

Редактор, текст логикасын камилләштергәндә, тема-рема эзлеклелегендәге һәр бәйләнешне исендә тотарга тиеш. Болар: бер-бер артлы, янәшә, үтәли темага нигезләнгән эзлеклелекләр. Әлеге бәйләнешләр кабатлауларга нигезләнә, аларның янәшә (контактлы), янәшә булмаган яисә аралы (дистантлы), тулы һәм өлешчә төрләре бар. Югарыда китерелгән мисал бу күренеш турында ачык сөйләде дип уйлыйбыз.

Түбәндәге текстта тема-рема бәйләнешләре бозылуның типик очрагы чагылыш тапкан:

*Кремль урамы буйлап киләм. УНИКСта бүген Айдар Галимов икән. Концерт башланганчы, барып җитәргә кирәк.*

Казанның тарихи үзәген, Айдар Галимовның кемлеген яхшы белүче язма авторы ни әйтергә теләгәнне аңласа да, текст дөрес оештырылмаган. Башкалабызны белмәгән кеше, тема-рема өзеклеге аркасында, Кремль урамыннан атлау, Айдар Галимовның кайдалыгы, ниндидер концертка барып җитү кирәклеге турындагы фикерләрнең янәшә килүенә аптырарга, сөйләм хаталы корылган дип уйларга, ә УНИКСны шәһәрнең бөтенләй башка бер җирендә дип фаразларга да мөмкин. Хәтта һичкем шулай дип фикер йөртмәгәндә дә, аны шушы рәвешчә төзәтү дөрес булыр:

*Кремль урамы буйлап УНИКСка таба атлыйм. Аның концерт залында бүген Айдар Галимов җырлый икән. Тамаша башланганчы, барып җитәргә кирәк.*

Шулай итеп, җөмләләр теге яки бу сүзләр ярдәмендә бер-берсенә матур ялганды, һәм текст инде Казаннан читтә яшәүче кеше өчен дә яхшы аңлашылырлык.

Сөйләм логикасын ныгытуга һәм теге яки бу әсәрнең композиция бөтенлегенә хезмәт иткән чаралар арасында тематик кабатлаулар мөһим урын алып тора. Аларда лексемаларның текстта семантик яктан ярашу законы чагылыш таба. Сөйләмдә уртак функциональ парадигма барлыкка килсен өчен, сүзләрнең бер-берсенә мәгънәвиятышлыгы, тематик якынлыгы кирәк. Бер темага караган төшенчәләр муллыгы текстта гомуми образ, картина тудыруга һәм шул ук вакытта теманы ачыклауга да хезмәт итә.

Мисалга күк тасвирын китерик:

*Көн уртасы. Кояш иң югары ноктасына күтәрелгән. Тиздән ул кире төшә башлар һәм түбәндә йөзгән болытларга килеп кунаклар. Бераз ял итеп алыр да офык артына тәгәрәп югалыр сыман.*

Текстта күккә хас предмет исемнәре, анда барган эш-хәлләрне атаучы сүзләр өстенлек итә. Шулай да кайбер галимнәрнең, теманы, аңа караган сүзләр саныннан чыгып, һәрвакыт төгәл билгеләргә мөмкин, диюләре белән килешү кыен. Әйтик, кемнеңдер анага, Ватанга, сөйгән ярына, ниндидер җан иясенә, үсемлеккә булган хисләрен бер үк төшенчәләр ярдәмендә тасвирларга мөмкин, теманы ачканда иң мөһиме – ачкыч сүз. Без, текстка төрле атамалар куеп кына да, төп өлештәге бер җөмләгә үзгәреш кертеп тә, язмага яңа сөйләм берәмлеге өстәп тә, андагы теманы алмаштыра алабыз. Хәтта мәхәббәт темасына караган сүзләр ярдәмендә нәфрәт темасын яисә чиксез нәфрәт хисен ачарга мөмкин:

*Алсуланып торган бит алмаларың... Татлы иреннәрең... Назлы күзләрең... Аларның оялчан да, мут та караулары. Керфекләреңне сирпеп-сирпеп алуларың... әйтелгән һәм әйтелмәгән матур-матур сүзләр... Гыйшык, мәхәббәт, күрәсе килү, сагыну, бер-береңнән башка яши алмау, җаныңны да бирергә әзер булу... Болар барысы да сиңа хас. Синең шундыйлыгыңны сөймим, хәтта күралмыйм; һәм нәфрәтем шулкадәр көчле ки, чөнки аларның башка кешегә икәнлеген беләм.*

Текстны теманы атамада чагылдырып бирик:

*Мин һәркайсына нәфрәтле*

*Алсуланып торган бит алмаларыңа... Татлы иреннәреңә... Назлы күзләреңә... Аларның оялчан да, мут та карауларына. Керфекләреңне сирпеп-сирпеп алуларыңа... әйтелгән һәм әйтелмәгән матур-матур сүзләреңә... Гыйшык, мәхәббәт, күрәсе килү, сагыну, бер-береңнән башка яши алмау, җаныңны да бирергә әзер булуларга... Сиңа.*

Алдарак китерелгән текстны, яңа җөмләләр, бик тә мөһиме – «син» сүзен өстәп, кыз портретына әйләндерик, аңа егетнең мөнәсәбәтен белдерик:

*Көн уртасы. Кояш иң югары ноктасына күтәрелгән. Тиздән ул кире төшә башлар һәм түбәндә йөзгән болытларга килеп кунаклар. Бераз ял итеп алыр да офык артына тәгәрәп югалыр сыман. Кояшны мин син дип күзаллыйм. Син дә миннән әле биектә, әле якынаясың, әле ерагаясың. Кояшым! Син минем күгемне мәңгегә ташлап китәрсең, офыкларда югалырсың сыман. Кояш, болыт, офык... Барысы да синең-минем турыда сөйли.*

Күргәнегезчә, тексттан күк предметларын атаучы лексемалар юкка чыкмады, әмма без, язмада табигать яисә күк темасы ачыла, дип нәтиҗә ясый алмыйбыз.

Исемне алмаштырып яисә нибары соңгы җөмләне үзгәртеп, бер үк иншада хәтта уннарча теманы чагылдырырга

мөмкин. Бу төр осталык чыгарылыш имтиханнарына әзерләнгәндә бик ярдәм итә. Кыскасы, лексик кырга таянып кына, һәрвакытта да теманы дөрес билгеләп булмый. Редакторга моны да белеп торырга кирәк.

Синонимик, антонимик, дейктик кабатлаулар, ягъни алмашлыклар ярдәмендә теге яки бу төшенчәне җиткерүләр шулай ук текстның семантик логикасын оештыруга ярдәм итә. Аның мисаллары Тукайда аеруча күп.

Гамәли дәресләрдә даими рәвештә текст өстендә төрле югарылыктагы логик бәйләнешләрне өйрәнми торып, студентларны һәм аспирантларны камил иҗат итәргә, үзара культуралы аралашырга күнектерү мөмкин түгел. Сөйләм логикасына игътибарлылык бигрәк тә яшь галимнәр, булачак укытучылар, журналистлар, тәнкыйтьчеләр, әдәби редакторлар өчен кирәк. Аларның язма продукциясе бөтен илне тел әдәбенә өйрәтә. Камиллектән ерак торган текстларның гадәттән тыш күбәеп китүе укучылар аудиториясен алардагы җитешсезлекләргә битараф итә, хәтта ки тора-бара халыкның зур катламы хаталарны тоймый башлый, нормага салынган сөйләм дип кабул итә.

Барлык басма продукция дә мөхәррирләр тарафыннан әзерләнгән булуга карамастан, һәр яктан камил текстлар бик сирәк очрый. Журналист язмаларының хатасызлыгы – гомумән, гадәттән тыш күренеш. Үз эшләренә таләпчән һәм талантлы каләм ияләренең нәфис мирасы, публицистикасы гына идеалда эшләнергә тиеш текстларга якын тора. Бүгенге көн каләм ияләреннән телгә соң дәрәҗәдә сак килүгә омтылыш Марсель Галиевтә күзәтелә. Күрәсең, талант һәм таләпчәнлек, тел язмышы өчен борчылу янәшә йөри. Флүс Латыйфи, Мәгъсүм Хуҗин, Миргазыян Юныс, Тәүфикъ Әйди һәм башка кайбер авторлар тудырган әдәбият та тел матурлыгы, аны калыплаштыру камиллеге белән шактый аерылып тора. Әлеге әдипләрнең вакытлы матбугатта бастырган язмалары да әнә шундый.

Газета-журналда чыккан материал язучыныкы, журналистныкы я булмаса үзе дә иҗатка тартылган укучыныкы гына түгел. Ул редактор кулы аша уза һәм, кызганычка каршы, еш кына ялгыш куелган тыныш билгеләре, орфографик хаталар, төрле тип кабатлаулар белән «баетыла». Мәсәлән, тиңдәш кисәкләрне бәйләүче «да» теркәгече артыннан килгән өтерләр татар матбугатының бер җитешсезлеге булып тора.

Мөхәррирнең уңышсыз кыскартулары, автор белән киңәшмичә керткән кирәксез өстәмәләре, мәгънәне үзгәртеп җибәргән сүз алмаштырулары, төшенчәләрнең эчтәлеген дөрес аңламыйча кулланулары текстның логик бәйләнешләренә зур зыян сала, хәтта эчтәлеген дә күпмедер үзгәртә ала. Әйтик, «исә» һәм башка кисәкчәләрдән соң куелган өтерләр ия белән хәбәрнең бер-берсеннән аерылуына гына китермәскә, хәтта бер җөмләне икегә әйләндерергә, ияне үзгәртергә яисә тиңдәш кисәкләр барлыкка китерергә мөмкин. Бу күренешне аерым мисал ярдәмендә карап узыйк:

*Челлә. Кояш, көченнән килсә, бар нәрсәне көйдермәкче. Кайнар җил исә күлмәк эчендәге тәнне дә пешерә – Челлә. Кояш, көченнән килсә, бар нәрсәне көйдермәкче. Кайнар җил исә, күлмәк эчендәге тәнне дә пешерә.*

Күргәнебезчә, соңгы җөмләдә *исә* һәм *пешерә* фигыльләре тиңдәш кисәкләргә әверелә. Шул ук вакытта текстның *күлмәк эчендәге тәнне дә пешерә* өлешен берсоставлы җөмлә дип кабул итүчеләр дә табылыр.

Каләм ияләре белән уздырган әңгәмәләр аларның, игътибарга алынмаган хәреф хаталарыннан, дөрес куелмаган тыныш билгеләреннән битәр, текстны зур кыскартулар белән бастырулары өчен борчылуларын күрсәтте. Барысы да әлеге күренеш һәр очракта да сөйләм логикасын бозуга, теге яки бу фикернең үзгәрүенә, ачылып бетмәвенә, авторга уңышлы күренгән урыннарның юкка чыгуына китерә дип саный.

Текстны төрле яссылыкта өйрәнгәннән һәм бәяләгәннән соң, мөхәррир аның белән җентекле эшләү этабында төп көчен иң башта җөмләара бәйләнешләрне камилләштерүгә куя. Сөйләм логикасындагы кимчелекләр юкка чыгарылганда, үзеннән-үзе башка төр хаталар да кими. Әйтик, аерым җөмлә төзелешендәге җитешсезлекләрдән арыну сөйләмнең гомуми эзлеклелеген көчәйтә, тыныш билгеләрен куюны җиңеләйтә.

Укучыларның басма сүзне кабул итүе психологик үзенчәлекләренә, профессияләренә бик бәйле. Яшь балалар гына түгел, хәтта үсмерләр дә күләмле текстның гомуми логикасындагы хаталарны сизмәскә яисә ул хакта уйланмаска мөмкин. Вакытлы матбугат текстлары җөмләара бәйләнешләргә журналистлар тарафыннан игътибар җитмәвен сөйли. Бигрәк тә әдәби мөхәррирләр, сөйләм кимчелекләрен яхшы күрә, аларның күплеге аркасында, сәнгать әсәреннән ләззәт тә ала алмый. Алар күпчелек очракта башта тулы текст белән таныша, аңа бөтенлек ноктасыннан якын килә һәм, хезмәтне шул бөтенлеккә зыян китергән җитешсезлекләрдән арындыргач, аерым өлеш, абзац, җөмлә эчендәге хаталарны төзәтүгә күчә.

Бар тип җитешсезлекләрне истә тотып, язмаларны һәр ноктадан беррәттән камилләштерә алучылар да очрый. Әлеге гамәлнең юллары шулай ук төрле. Әйтик, аерым җөмләне төзәткән саен, кечерәк күләмдәге хезмәтне тулаем укып чыгып, янәшә рәвештә башка төр хаталарны киметергә мөмкин. Ике җөмләне бәйләнештә карау гына да үзеннән-үзе җөмләләр, абзацлар бөтенлеген, логикасын көчәйтәчәк. Шул ук вакытта тулы текст та камилрәк калыплашачак.

Махсус белем алган, теоретик күзаллауларга ия, язучылык эше белән балачактан ук шөгыльләнгән кайбер каләм ияләренең дә, кызганыч ки, сөйләме камиллектән ерак тора. Бик күпләр тыныш билгесе куюның гади очракларында да каушап кала. Ә бит язма сөйләм барлык таләпләргә җавап бирмәсә, пунктуация үзеннән-үзе аксый. Кайберәүләр текст төзәтүне башта чит кеше эшен редакцияләүгә авырсынмаган

каләмдәшләренә йөкли, аннан нәшрият мөхәррирләренә тапшыра. Кыскасы, синтаксиска караган кагыйдәләрне кат-кат искә төшерү, онытылган очракларны кабатлау, истә калдыру һәм җөмлә өстендә башкарылган эш аша ныгыту редактор өчен һәрвакыт көн кадагында кала бирә.

Н. Гыйматдинованың «Манара» хикәясенә гамәли дәресләрнең берсендә студент язган рецензия белән танышыйк һәм аны логик ноктадан камилләштерүнең кайбер юлларын күрсәтик. Әлбәттә, беррәттән, текстның башка хаталары да юкка чыгарылыр.

***Н. Гыйматдинованың «Манара» хикәясенә рецензия***

*Алдымда Н. Гыйматдинованың чираттагы әсәре – «Манара» хикәясе. Мин аны зур кызыксыну белән укып чыктым. Хикәя миңа совет чорында дингә булган карашларның нинди булуын, кеше күңелен, икейөзле кешенең әхлагы, намусы ни дәрәҗәдә булуын аңларга ярдәм итте. Нәбирә апа – минем иң яраткан язучыларымның берсе. Шуңа да мин аның әсәрләрен җиңел укыйм. Манара хикәясе 1989 нчы елда язылган. Әсәрнең сюжеты аңлаешлы. Хикәянең исеме «Манара» дип куелган. Әсәрдә күбрәк Нурулла, аның эшләгән кара эшләре турында сөйләнелә. Ә аның кылган начарлыгы нәкъ менә манара белән бәйле.*

*Нуруллаunion дәрәҗәсе социаль яктан югары булса да, авыл халкы арасында зур казаныш яулый алмый. Ә бит барысы да аның үз кулында иде. Нурулланың мөхтәрәм ил карты буласы килә, ләкин аны беркая да чакыручы, эндәшүче юк. Очраганда да күрмәмешкә салынып китәләр. Аның бар дөньясы ишекалды белән генә чикләнә. Бу тормышка ул үзе гаепле. Үзенең никадәр генә күңеле сызласа да, айны кире урынына кую турында уйламый да. Ә боларның барсын да ул үзенең ялагайлыгы, куркуы, икейөзлелеге белән эшли. Якын дусты Зарифулла ясатып куйган айны, район секретаренә ярыйм дип, юкка чыгара. Үзенең иң якын дустын сата. Манараны*

*торгызганын әләкләп төрмәгә озаттыра. Авыл халкыннан ягымлы караш күрә алмаган Нурулла йодрыгын эшкә җигә. Зарифулланы үз иткән авыл Нуруллaны күрә алмый. Бары тик аның «йодрыгыннан» гына шүрләп яши. Нурулланы авыл халкының күрә алмавы гына түгел ә ае урланган манараның көн саен төшенә кереп йөдәтүе дә шомландыра, һәрвакыт өстенә авар кебек тоела. Нурулла соң булса да картлыгында җир йөзеннән керле килеш китәсе килмәгәнлектән, айны урынына кую өчен төнлә манарага менеп китә. Һәм такталар ычкынып, манара белән бергә җиргә ава.*

*Әлеге сюжеттан без Нурулланың никадәр кансыз киәнлеген күрәбез. Аның эшләгән начарлыгының ни дәрәҗәдә булуын белү өчен, безгә тамак өчен теләсә нинди эш эшләргә риза булган зимагур Шакирҗанның әйткән сүзләрен искә төшерү дә җитә. Нурулла аңа мәчетне яндырырга кушкач, Шакирҗан ризалашса да, вакыты җиткәч, бу эшне эшләми. Ә Нурулла бит аңа «ипигә коендырам» дигән иде. Ә аңа каршы зимагур «аен урлаган имансызга әйт, ай тиклем айны урлагач, бусын да булдырыр. Мәчет манарасын яндырганчы, ачлыктан үләм мин, абзый...» дип җавап бирә.*

*Автор әсәрдә безне ике герой белән таныштыра: Зарифулла һәм Нурулла. Ул аларны төрле яктан ачып бирергә тырышкан.*

*Әсәрдә автор шул чорның дингә карашын, яхшы кешеләрен дә чор колы булуын чагылдыра. Кешенең дәрәҗәсе үсү белән әхлагы югалуын күрсәтә. Аллаһ йорты булган мәчетнең аен урлауның, гомумән, мәчеткә кул тидерүнең нәтиҗәләрен ачып күрсәтә. Әсәрнең буеннан-буена без укучыларга гыйбрәт, сабак булырдай фикерләр күренә.*

*Әсәрне укыгач, үзең генә түгел, сине авыл председателе итеп куйганнар икән – авыл халкы мәнфәгатьләрен дә кайгыртып яшәргә, намуслы булырга, ата-баба мирасын сакларга (Зарифулла бу матурлыкны югалтсак, оныклар гафу итмәс», – ди.) дигән уй-фикерләр туа.*

*Әсәр бар яктан да камил эшләнелгән. Җөмләләр гади һәм аңлаешлы, җиңел укыла. Кыска гына китеп әйткәндә – бер тында укып чыгарлык. Укучыга тәэсир итә, уйландыра торган гыйбрәтле әсәр.*

Иң башта янәшә җөмләләрдә кабатланган тамырдаш сүзләрне, абзацта артык күп кулланылган төшенчәләрне, тыныш билгеләре онытылган һәм хаталы язылган урыннарны ассызыкларбыз:

*Алдымда Н. Гыйматдинованың чираттагы әсәре – «Манара» хикәясе. Мин аны зур кызыксыну белән укып чыктым. Хикәя миңа совет чорында дингә булган карашларның нинди булуын, кеше күңелен, икейөзле кешенең әхлагы, намусы ни дәрәҗәдә булуын аңларга ярдәм итте. Нәбирә апа – минем иң яраткан язучыларымның берсе. Шуңа да мин аның әсәрләрен җиңел укыйм. Манара хикәясе 1989 нчы елда язылган. Әсәрнең сюжеты аңлаешлы. Хикәянең исеме «Манара» дип куелган. Әсәрдә күбрәк Нурулла, аның эшләгән кара эшләре турында сөйләнелә. Ә аның кылган начарлыгы нәкъ менә манара белән бәйле.*

Ә теркәгече һәм теркәгеч вазифасында кулланылган *шуңа да* (шуңа күрә) мөнәсәбәтле сүзе ике җөмләне берберсенә ялгарга тиеш. Димәк, аларны кечкенәдән язарга, теркәүче чара алдына өтер куярга кирәк. Күргәнебезчә, беренче өч җөмләдә генә дә берничә тамырдаш сүз кабатлана. Автор, Н. Гыйматдинованың китабын укуы аркасында, «булганның нинди булуын аңлавы» турында язмыйча, «дингә мөнәсәбәтнең нindилегенә төшенүе» хакында хәбәр итсә, шунда ук саннарын киметәчәк. Рецензент әдибәне икейөзлеләрнең «намус»(лылык) рейтингын (дәрәҗәсен) билгеләп бирүче кебегрәк күрсәтә, югары материяләр хакында бик үк табигый сөйләми. «Әсәрне кызыксынып уку» хакындагы җөмләләр, алар кергән башламнар рецензияләрдә еш очрый, артык шаблон.

Текстның аерым урыннары хакында әнә шул рәвешле фикер йөрткәннән соң, үз вариантларыбызны да тәкъдим итә барырбыз. Алар күпмедер дәрәҗәдә кыскалыкта осталык икәнлекне исбатлаган сөйләм берәмлекләре булыр. Өченче җөмләне, мәсәлән: «Хикәя совет чорында хөкем сөргән карашлар, кеше күңеле, намус, әхлак турында уйланырга мәҗбүр итте»,– дип үзгәртергә мөмкин.

Чираттагы ике җөмлә абзац башындагыларга бик тартым. *Нәбирә апа – минем иң яраткан язучыларымның берсе*, дигәндә «минем» алмашлыгы артык, ул инде «язучыларым»дагы тартым кушымчасы ярдәмендә белдерелгән. Җитмәсә, аннан соңгы җөмләдә дә әлеге алмашлык бар. *Иң* дигәч, бер генә язучы була ала, һәм *берсе* сүзенең кирәге бетә. Дөресе: *Нәбирә апа – иң яраткан язучым.* Рецензент, авторны яратканга, әсәрләрен җиңел укыйм, дип расламакчы, безнеңчә, ул Н. Гыйматдинованы прозасы җиңел укылганга сөя торгандыр. Димәк, автор сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләренең урынын алмаштырган. Җитмәсә, бу өлештә сөйләм логикасының дүртенче кануны бозылган: фикерне дәлилләү җитми.

Тексттагы теркәгечләрне кыскартып, үзара бәйләнешне йомшартырга да мөмкин. Янәшә ике җөмләне берничә төрле ялгыйк: а) *Нәбирә апа – иң яраткан язучым, чөнки аның әсәрләрен җиңел укыйм;* ә) *Нәбирә апа – иң яраткан язучым. Аның әсәрләрен җиңел укыйм;* б) *Нәбирә апа – яраткан язучыларымның берсе. Мин аның әсәрләрен җиңел укыйм;* в) *Әсәрләренең теле җиңел булганга, Нәбирә апа – иң яраткан язучым* һ.б. Күренә ки, бер мисалда, ияне ассызыклау рәвешендә, «мин»не калдырдык.

*«Манара» хикәясе 1989 нчы елда язылган* җөмләсенең алдагысы белән бәйләнеше юк – ул үзгә тема алып килә. Аны төзәтүнең иң җиңел юлы – яңа абзац башлау. Җөмләне *Аның 1989 елда язылган «Манара» хикәясе дә табигый тел агышы белән үзенә алып кереп китә,* дип үзгәртсәк тә, чираттагысы белән уңышлы ялганыр сыман. Бәлки, әлеге дә баягы сөйләм

логикасының дүртенче канунын кулланырга һәм, әсәр теленә хас сыйфатлар хакында язып, абзац оештырыргадыр?

Чираттагы җөмлә *Әсәрнең сюжеты аңлаешлылык* турында. Әлеге фикерне расларга тотынасы урынга, автор хикәянең исеме «Манара» дип куелганлыкны яза, шул сәбәпле дәлилләүне артка күчерә, ерагайта. Сөйләм бәйләнеше тагын бозыла. Җитмәсә, әсәр исеме укучыга инде билгеле, аның хакында әйтү, гомумән, артык. Ул синтаксик конструкция буларак та отышсыз – *Хикәягә «Манара» исеме куелган* рәвешендә калыплашыру дөресрәк кебек. Авторныкына якын вариант та тәкъдим итәргә мөмкин: *Хикәягә исем «Манара» дип куелган.*

Атамага яңадан игътибар иттерергә телибез икән, аның максаты булырга тиеш. Әйтик, укучының карашын исемнең озынлык-кыскалыгына, яңгырашына, идея эчтәлегенә юнәлтү. Мәсәлән: *Хикәя гади генә бер сүз белән – «Манара» дип аталган.* Фикерне киңәйтеп, сайланган исемнең отышлылыгын яисә отышсызлыгын ачыклау да кызыклыдыр сыман. Әсәрнең исеме гади генә булса да, идея эчтәлеге тирән икәнлекне исбатларга мөмкин. Бу очракта абзац башындагы *«Манара» хикәясе* дигән гыйбарәне төшереп калдырырга кирәк: *Алдымда Н. Гыйматдинованың чиратагы әсәре.*

Рецензент: *Әсәрдә күбрәк Нурулла, аның эшләгән кара эшләре турында сөйләнелә. Ә аның кылган начарлыгы нәкъ менә манара белән бәйле*,– дип белдерә. Димәк, *Манара образы әсәрнең композицион үзәге булып тора,* – рәвешендә ассызыклау аның өчен мөһим. Бу хакта язып китү дә яхшы булыр – рецензиянең фәнни яңгырашы көчәер. Икенче җөмләне беренчесенә кушу һәм кирәксез *ә* теркәгеченнән арындыру исә текстны матурайтып җибәрер. Бу өлештә эш тамырлы сүзләрнең дә санын киметергә кирәк.

Язарга өйрәнүнең башлангыч этабында, гадәттә, яшь каләм әһеле зур текстлар белән эш итми. Кечкенә әсәрләрдә хата күзгә ныграк ташлана, аларны күреп алу һәм төзәтү дә

җиңелрәк. Шул ук вакытта хикәяче ккә, мәкаләчеккә, кыска шигырьгә уйламыйчарак керткән азсанлы гына үзгәрешләр дә җөмләара бәйләнешләргә, гомуми композициягә, текст бердәмлекләренә зур зыян салырга мөмкин. Димәк, бала текстка яңадан әйләнеп кайтырга гадәтләнергә тиеш. Хезмәтен кат-кат тикшереп, ул зур тәҗрибә туплый, каләмен камилләштергәннән камилләштерә, игътибарлыракка, түземлерәккә әйләнә, үзе башкарган эш өчен җаваплылык тойгысын ныгыта, аның басма сүзгә хөрмәте, мәхәббәте арта.

Уку тизлеге йөгерек, биткә салынган текстны тулы күргән һәм текстны төзәтүдә тәҗрибәсе зур кеше җөмләләрдәге һәм үзара бәйләнешләрдәге җитешсезлекләрне берьюлы тота, кайсындыр төзәткәндә, башкаларын исәпкә ала. Студентлар һәм аспирантлар андый күнекмәләргә төрле дәрәҗәдә ия, шул сәбәпле дәрес барышында текстның кече өлешләрен генә бергәләп төзәтеп була. Мөгаллим укучыларын шулай ук җөмләләргә еш әйләнеп кайтырга, инде яңадан барлыкка килгән кимчелекләрне юкка чыгарырга гадәтләндерә. Без хәзер анализлаган, төзәткән язма, мәсәлән, яшь рецензентның ике-өч янәшә кыска җөмләне дә «бергә күрмәве» турында сөйли.

Мәкалә белән тулаем танышкач, шул аңлашыла: чыннан да, хикәянең манара дип аталуы бик мөһим. Димәк, өстәргә тәкъдим иткән җөмләбез дә отышлы. Рецензияне: *Атама исеме буларак сайланган гади генә сүзгә бик тирән мәгънә салынган, ул төп герой Нурулла гамәлләре аша ачыла,* – дип дәвам итәргә мөмкин. Бу урын, авторныкыча калганда да, инде бик матур яңгыраш ала. Абзацны яңадан карап чыгабыз һәм түбәндә рецензентныкына якын шушындый вариант тәкъдим итәбез:

*Нәбирә Гыйматдинова – иң яраткан язучым. Алдымда – аның 1989 елда язылган «Манара»хикәясе. Әсәрнең теле җиңел, сюжеты аңлаешлы. Хикәя мине совет чорында хөкем сөргән карашлар, кеше күңеле, намус, әхлак турында уйланырга мәҗбүр итте.*

*Манара образы әсәрнең композицион үзәге булып тора. Хикәядә төп герой Нурулланың кара эшләре турында сөйләнелә. Алар, беренче чиратта, манара белән бәйле.*

Текст алга таба: *Нурулланың дәрәҗәсе социаль яктан югары булса да, авыл халкы арасында зур казаныш яулый алмый,* – кимчелекле бәйләнештәге иярченле кушма җөмлә рәвешендә дәвам итә. Аның беренче кисәгендә сүз дәрәҗә турында бара, икенчесенең иясе төшеп калган, шунлыктан герой үзе түгел, ә аның «социаль дәрәҗәсе авыл халкы арасында казаныш яуларга тырышкан» шикелле килеп чыга. Җөмләне уйламыйчарак төзәтүче аңа түбәндәгечә өтер өстәргә һәм автор әйтергә теләгән фикерне инде чамаламаслык ук юкка чыгарырга мөмкин: *Нурулланың дәрәҗәсе, социаль яктан югары булса да, авыл халкы арасында зур казаныш яулый алмый.*

Җөмләне, урынсыз кулланылган *-ның* кушымчасын алып аткач һәм башка төр үзгәрешләр керткәч кенә, пунктуацион ноктадан камилләштерергә кирәк: *Нурулла, социаль яктан дәрәҗәле булса да, авыл халкы арасында зур казаныш яуламый.*

*Ә бит барысы да аның үз кулында иде.* Автор шушы урыннан башлап, төрле тип җөмләләрне уңышсыз янәшә куя, шул сәбәпле текстның аһәңе үзгәрә, рецензия инша төсен ала башлый.

*Нурулланың мөхтәрәм ил карты буласы килә, ләкин аны беркая да чакыручы, эндәшүче юк.* Җөмлә киресенчә төзелергә, нәкъ менә мөхтәрәм ил карты булмаганга, агайны бер кая да чакырмауларын җиткерергә тиеш. Бәлки, автор: *Нурулланың ил картларына күрсәтелә торган хөрмәткә ия буласы килә, әмма аны төрле мәҗлесләргә, авылда уздырылган чараларга олылыклап чакырмыйлар,* – дип әйтергә телидер? Болай язганда, чираттагы *Очраганда да күрмәмешкә салынып китәләр* җөмләсе алдагысының фикерен эзлекле үстерәчәк. Җәя эчендә автордан китерелгән текстта тыныш билгесе җитми.

Алга таба укыйбыз: *Аның бар дөньясы ишекалды белән генә чикләнә. Бу тормышка ул үзе гаепле. Манара башыннан ай урлаган өчен шулай ялгызлыкта герой.* Беренче җөмлә калькага бик тартым: «Его мир ограничивается двором». Өченчесе, гомумән, татар сөйләменә хас төзелмәгән. Анда җиткерелгән фикер белән дә килешеп булмый. Герой ай урлаган өчен түгел, ә шул вакыйга аркасында авылдашлары аннан йөз чөергәнгә ялгыз дип уйларга кирәк.

*Үзенең никадәр генә күңеле сызласа да, айны кире урынына кую турында уйламый да.* – Бу өлештә баш җөмләне иясез оештыру хата түгел, шулай да Нурулла исеме бик еракта калды, аны текстка кабат кертергә кирәк. Төзәтәбез: *Күңеле никадәр сызласа да, Нурулла айны кире урынына кую турында уйламый да.*

*Ә боларның барысын да ул үзенең ялагайлыгы, куркуы, икейөзлелеге белән эшли. Якын дусты Зарифулла ясатып куйган айны, район секретаренә ярыйм дип, юкка чыгара.* Өзектә соңгы өтерләр артык: хәл хәбәр белән янәшә тора. Икенче җөмләдә субъект тагын «онытылган». Даими рәвештә тулы булмаган җөмләләрдән файдалану рецензияләрдә үзен акламый, ә монда шул күренеш алга таба да дәвам итә: *Үзенең иң якын дустын сата. Манараны торгызганын әләкләп төрмәгә озаттыра.* Җитмәсә, автор туктаусыз *үзенең* сүзен куллана. Рецензент стильгә дә тоемсыз: тәнкыйть өлкәсенә караган мәкаләдәге кайбер җөмләләр матур әдәбият, бигрәк тә юмор-сатира әсәрләре өчен генә бата, хезмәтне түбәнәйтә: *Авыл халкыннан ягымлы караш күрә алмаган Нурулла йодрыгын эшкә җигә.*

*Зарифулланы үз иткән авыл Нурулланы күрә алмый* дигәндә, дусларның берсен үз иткәнгә генә, авылдашлар икенчесен яратмый кебек фикер аңлашыла. Аннан соңгы җөмлә кешеләрнең яшәү рәвешен отышсыз гомумиләштерә: *Бары тик аның «йодрыгыннан» гына шүрләп яши.* Без аны алдагысы – иялесе белән кушарбыз. Моннан тыш, студентка,

тирәлек мәчет манарасын кисүчедән шүрләсә, ягымлы булып кыланыр иде, дип каршы төшәсе килә. Кыскасы, я рецензент ялгыш фикер чыгарган, я ул чынлыкта да әдибәне генә кабатлый. Бу урында шуны да ачыклыйсы килә.

*Нурулланы авыл халкының күрә алмавы гына түгел, ә ае урланган манараның көн саен төшенә кереп йөдәтүе дә шомландыра, һәрвакыт өстенә авар кебек тоела* өзегендә дә алда күрсәтелгән кимчелекләр күзәтелә. Әйтик, беренче җөмләдә өтер юк. Икенчесенә, дөрес аңлашылсын, камилләшеп бетсен өчен, сүзләр җитми.

*Нурулла соң булса да картлыгында, җир йөзеннән керле килеш <u>китәсе</u> килмәгәнлектән, айны урынына кую өчен, төнлә манарага менеп <u>китә.</u>* Җөмлә матур корылмаган, кирәксез урыннары һәм кабатлау бар, аларны я үзгәртергә, я кыскартырга я башка урынга күчерергә кирәк: *Нурулла, җир йөзеннән керле килеш <u>китәсе</u> килмәгәнлектән, соңлап булса да айны урынына кую өчен, төнлә манарага менә.* Рецензент: *Һәм такталар ычкынып, манара белән бергә җиргә ава,* – дип дәвам итә. Аны алдагысына кушу «иясез» җөмләләр санын киметергә ярдәм итәчәк.

Кыскасы, өзекне абзацларга бүләргә, андагы охшаш сүзләрне киметергә һәм башка үзгәрешләр дә кертергә кирәк. Түбәндә әле генә анализланган өлешнең камилләштерелгән яңа вариантын бирәбез:

*Нурулла халык арасында зур казаныш яуларга, мөхтәрәм ил карты булырга тели, әмма башкача килеп чыга: авылдашлары аны, олылыклап, беркая да чакырмый, очраганда, күрмәмешкә салынып үтә. Ул ишегалдыннан чыкмыйча диярлек яши. Кешеләрнең бу рәвешчә мөнәсәбәтенә үзе сәбәпче булса да, моның өчен күңеле никадәр сызланса да, төп герой хатасын төзәтми: айны кире урынына кую турында уйламый да.*

*Ялагай, куркак, икейөзле Нурулла Зарифулла ясаткан айны район секретаренә ярыйм дип юкка чыгара. Алай гына да түгел, манараны торгызганын әләкләп, дустын төрмәгә*

*үк озаттыра – димәк, ул иң якын кешеләрен сатудан да тайчынмый.*

*Кылган гамәлләре аркасында, ягымлы караш күрмәгән, халык хөрмәтен казанган Зарифуллага үчле Нурулла авылдашларын куркыту эшенә керешә. Тора-бара аны, кешеләрнең үзен яратмавы гына түгел, ае урланган мәчетнең көн саен төшенә кереп йөдәтүе дә шомландыра башлый. Нуруллага манара көннәрдән бер көнне үз өстенә авып төшәр кебек тоела. Җир йөзеннән керле килеш китәсе килмәгәнгә, ул, ниһаять, айны урынына кую өчен, төнлә манарага менә, һәм шул вакыт, аяк астындагы такталар ычкынып, манара белән бергә җиргә ава.*

Автор текстыннан ерак китмичә, мәчеткә мөнәсәбәттә төгәл синонимы булмаган манара сүзеннән котылу шактый авыр, һәм аны урын-урын гына кабатлау – ассызыклап китү – яңгырашка зыян салмый.

Алга таба укыйк һәм хәреф хаталарын, төшеп калган тыныш билгеләрен, артык яисә дөрес кулланылмаган сүзләрне, бер-берсенә якын торган һәм стильне бозган кабатлауларны күрсәтик:

*Әлеге сюжеттан без Нурулланың никадәр кансыз киәнлеген күрәбез. Аның эшләгән начарлыгының ни дәрәҗәдә булуын белү өчен, безгә тамак өчен теләсә нинди эш эшләргә риза булган зимагур Шакирҗанның әйткән сүзләрен искә төшерү дә җитә. Нурулла аңа мәчетне яндырырга кушкач, Шакирҗан ризалашса да, вакыты җиткәч, бу эшне эшләми. Ә Нурулла бит аңа «ипигә коендырам» дигән иде. Ә аңа каршы зимагур «аен урлаган имансызга әйт, ай тиклем айны урлагач, бусын да булдырыр. Мәчет манарасын яндырганчы, ачлыктан үләм мин, абзый...» дип җавап бирә».*

Текстны кимчелекләреннән түбәндәгечә арындырырбыз:

*Сюжеттан Нурулланың бик кансыз икәнлеге күренә. Начарлыгының зурлыгын күзаллау өчен, тамак хакына*

*теләсә ни кылырга риза авыл зимагуры әйткән сүзләрне искә төшерү дә җитә. Нурулла мәчетне яндырырга кушкач, Шакирҗан ризалаша, әмма аңа кирәк вакытта моны эшләми, Нурулланың, ипигә коендырам, дигән вәгъдәсенә каршы: «Аен урлаган имансызга әйт, ай тиклем айны урлагач, бусын да булдырыр. Мәчет манарасын яндырганчы, ачлыктан үләм мин, абзый...» – дип җавап бирә.*

Күрәсез ки, махсус ассызыкланган *ай* сүзенең санын автордагыча калдырдык.

*Автор әсәрдә безне ике герой белән таныштыра: Зарифулла һәм Нурулла. Ул аларны төрле яктан ачып бирергә тырышкан.* Тәүге җөмлә тулы текстны башлау өчен генә отышлы, андагы мәгълүматларны әллә кайчан белүебез исәпкә алынмаган. Рецензиядә алмаштыруы бик җиңел булган *әсәр* сүзе бик еш очрый, алар чираттагы абзацта ук бар. Алдагы өлештән башка охшаш тамырлы төшенчәләрне дә билгеләрбез:

*<u>Әсәрдә</u> автор шул <u>чорның</u> дингә карашын, яхшы <u>кешеләрен</u> дә <u>чор</u> колы <u>булуын</u> <u>й</u>чагылдыра. <u>Кешенең</u> дәрәҗәсе үсү белән әхлагы югалу<u>ын</u> <u>күрсәтә</u>. Аллаһ йорты <u>булган</u> <u>мәчетнең</u> аен урлауның, гомумән, <u>мәчеткә</u> кул тидерүнең нәтиҗәләрен ачып <u>күрсәтә</u>. <u>Әсәрнең</u> буеннан-буена без укучыларга гыйбрәт, сабак <u>булырдай</u> фикерләр <u>күренә.</u>*

Кайсы гына иҗтимагый-тарихи этапны анализласаң да, дингә карашларның бертөрле генә булмаганлыгы күренә, шунлыктан «чор идеологиясе» яисә «шул чорда җәмгыятьтә өстенлек иткән карашлар» хакында фикер йөртү дөресрәк булыр. *Кешенең, дәрәҗәсе үсү белән, әхлагы югалуны күрсәтә* – тыныш билгеләре куелмау мәгънәгә, логикага зыян сала. *Кеше, дәрәҗәсе үскән саен, әхлагын югалта бара, ди,* – варианты матуррак, дөресрәк булыр. Инде чираттагы җитешсез урыннарны сызык белән билгелик: *<u>Әсәрне</u> укыгач, үзең генә түгел, сине <u>авыл</u> председателе итеп куйганнар икән – <u>авыл</u>*

*халкы мәнфәгатьләрен дә кайгыртып яшәргә, намуслы булырга, ата-баба мирасын сакларга (_Зарифулла_бу матурлыкны югалтсак, оныклар гафу итмәс», – ди.) дигән уй-фикерләр туа.* Ямьсез гомумиләштерү. Теләсә кем, хәтта рәис итеп куелмаганнар да аталган уңай сыйфатларга ия булырга тиеш, ә авылның чын мәгънәсендәге хуҗасы колхозчылар, ил, җәмгыять каршында тагын да җаваплырак. Җәя эче артык, урынсыз, аны башка абзац сыйфатында киңәйтеп бирергә мөмкин.

Чираттагы кисәктә тагын ике – «әсәр», өч «уку» тамырлы сүз очрый. *Әсәр бар яктан да камил эшләнелгән.* Фигыль формасы килешсез, җөмләне: *Әсәр бар яктан камил,–* дип язу матуррак. *Җөмләләр гади һәм аңлаешлы, җиңел укыла.* Әйтерсең, катлаулы җөмләләрне аңлаешлы, җиңел укылышлы язып булмый. *Кыска гына китеп әйткәндә – бер тында укып чыгарлык. Укучыга тәэсир итә, уйландыра торган гыйбрәтле әсәр.* Рецензентның «кыска» әйткән җөмләсе алдагы «җиңел уку» гыйбарәсеннән күпкә озынрак. Бер үк фикерне янәшә язу кирәк микән?..

Күрәбез ки, тәүге танышканда чагыштырмача кызыклы һәм камил тоелган текстның да, җентекләп укый башласаң, редакцияләнеп бетмәгәнлеге ачыклана. Югарыда студент рецензиясен җөмләара бәйләнешләр, шул бәйләнешләрне тудыруда аерым сүзнең, җөмлә кисәкләренең, тыныш билгеләренең роле ноктасыннан карап уздык. Текстны кирәкмәгән кабатлаулардан арындырдык.

Сөйләмнең логик сыйфатларын анализлау – бигрәк тә булачак мөхәррирләр эшендә мөһим бер гамәл. Тикшерелгән язма, фикерләү логикасы бозылганда, ясалган нәтиҗәләрнең уңышсызлыгын, ышандыру көченә ия түгеллеген ачык күрсәтә. Сүз-гыйбарәләрне дөрес, урынлы кулланмау һәм ия-хәбәр мөнәсәбәтләрен исәпкә алмау гына да текст бөтенлегенә, логикасына зур зыян салган. Әдәби тәнкыйть хезмәтен һөнәри дәрәҗәдә дөресләү татар теленең гамәли стилистикасын ныклап өйрәнүне таләп итә.

**Текстка стилистик якын килү.** Текст стилистикасын камилләштерү тулы текстка, аның аерым кисәкләренә, синтаксик конструкцияләргә бәяләмә, аларның үзара бәйләнешен ачыклау кебек эшләрдән башлана, аннан соң редактор авторның стилистикага кагылышлы типик хаталарын барлый.

Татар җөмләсендә сүз төркемнәренең билгеле бер урыны бар. Бу кагыйдә бигрәк тә язма әдәби телдә ныклы үтәлә, ә гади сөйләмдә сүзләр чагыштырмача ирекле урнаша, чөнки фикерне дөрес аңлауга-аңлатуга интонация нык ярдәм итә.

Сүзләрнең җанлы, шигъри, тойгылы сөйләмдә, җөмләдәге гадәти урыннарын үзгәртеп, башкача урнашуы, ягъни кире тәртибе, инверсия дип атала. Кульязма белән эш итүче редактор телдә сүз тәртибен билгеләүче факторларның стильгә тыгыз бәйлелеген, шул исәптән матур әдәбиятта җөмләне махсус рәвештә инверсия күренеше рәвешендә коруның сәнгати алым икәнлеген дә истә тота.

Ф.С. Сафиуллина «Татар телендә сүз тәртибе» (1974) хезмәтендә сүзләр тәртибен җөмлә кисәкләренең аралашу йөгенә, грамматик факторларга, шигырьдәге басым системасы, ритм, рифма һәм үлчәм кебек күренешләргә, тел традицияләренә һәм бер телнең икенче телгә тәэсиренә, сөйләм телендәге интонациягә бәйле ача. Бу хезмәт белән танышу яшь редакторлар өчен бик мөһим.

Тексттан, шуның бер өлеше булган җөмләдән автор фикере дөрес аңлашылсын өчен, каләм иясе, беренче чирата, мәгънәви факторны истән чыгармаска тиеш. Аралашуга юнәлтелгән җөмлә үз эченә сөйләм предметын һәм яңалыгын ала. Хезмәттә бу хакта билгеле бер дәрәҗәдә «тема-рема бәйләнешләре» яссылыгында алдарак та язылды. Җөмләдәге сөйләм яңалыгы аның төп мәгънә йөген белдерә һәм, гадәттә, хәбәр алдына урнаша. Әңгәмә барышында, чыгыш ясаганда сөйләмдәге яңалык тавыш ярдәмендә аерылып куела, ассызыклана, ягъни аңа логик басым ясала.

Грамматик факторга мөнәсәбәтле, җөмләдәге барлык сүзләрнең дә бер-берсе белән тыгыз үрелүен һәм әлеге бәйләнешләрнең аерым чаралар белән белдерелүен, ә бәйләүче чараларның җөмлә кисәкләренең грамматик урынын билгеләвен әйтеп узарга кирәк.

Татар телендә сүзләр хәбәрлекле мөнәсәбәттә торса, ияртүче иярүче сүздән – хәбәрдән, ә инде ачыклаулы мөнәсәбәттә иярүче ияртүчедән алда килә; аныклаулы мөнәсәбәттә иярүче сүз ияртүчедән соң урнаша. Шул таләпләргә җавап биргән җөмлә – «туры» дип санала. Хәбәрлекле, ачыклаулы мөнәсәбәттә торган сүзләр җөмләдә «кире тәртип»тә дә урнашырга мөмкин. Телчеләр, татар телендә катгый канун бар: аныклаулы мөнәсәбәттә инверсия була алмый, дип белдерә.

Уртак сүзгә ачыклаулы мөнәсәбәттәге сүзләр тәртибе турында да язый к. Тиңдәш булмаган аергычлар бәйләүче чараларының көченә һәм үз мәгънә йөкләренә карап урын ала. Тәмамлык һәм хәл ияртүче кисәктән алда килә, әмма аларның ияртүче белән янәшә торуы һәр очракта да мәҗбүри түгел. Әйтик, ияртүче кисәккә янәшә тору ярдәмендә ияргән тәмамлыклар һәм кайбер хәлләр, аңлашыла ки, аның янәшәсендә килә. Башка төрле тәмамлыклар һәм хәлләр, коммуникатив йөкләренә бәйле рәвештә, җөмләнең төрле урыннарында очрый.

Текстны редакцияләгәндә, җөмләдә сүзләрнең дөрес тәртибенә ирешү бик мөһим. Бу вакытта мөнәсәбәт төрләрен генә түгел, синтагмаларга бүленешне дә, мәгънәви басымны да, башка факторларны да исәпкә алып кына, җөмлә төзелешенә үзгәрешләр кертергә ярый. Әйтик, *Алия кигән <u>күлмәк</u> бик <u>матур</u>* һәм *Алия бик <u>матур күлмәк</u> кигән* җөмләләренең беренчесендә исем белән сыйфат хәбәрлекле мөнәсәбәттә тора, ә сүз тәртибе алмашынгач, әлеге мөнәсәбәт юкка чыга, аның урынына башкасы барлыкка килә.

Инде сүз тәртибен җөмләнең синтагмаларга бүленешенә мөнәсәбәттә карыйк. *Ял итеп алмыйча, дәрес планнарын*

*язарга тотына алмыйм, – диде Бәрия.* Бу мисалда җөмләнең «ял итеп алмыйча» кисәге үзе буйсынган сүздән ерак килгән һәм аерым синтагма төзегән. Кайбер мөхәррирләр аны үзе буйсынган сүз янәшәсенә күчерәчәк. Бу очракта ул аерым синтагма төзи алмас: *Дәрес планнарын ял итмичә язарга тотына алмыйм.* Әгәр без сүз тәртибенең стилистик ролен, авторның язу манерасын, сөйләм кору юлларының барысын да исәпкә алмыйча, мондый үзгәрешләр кертәбез икән, телебез, әдәбиятыбыз чиктән тыш ярлыланачак.

Татар җөмләсендә сүзләр тәртибен тагын бер кат ныгытыйк:

1) хәбәрлекле мөнәсәбәттәге сүзләрнең ияртүчесе – алда, иярүчесе – аннан соң;

2) ачыклаулы мөнәсәбәттәге сүзләрнең иярүчесе – алда, ияртүчесе – аннан соң;

3) аныклаулы мөнәсәбәттәге сүзләрнең аныкланмышы – алда, аныклагычы – аннан соң килә.

Җөмлә кисәкләренең бер-берсенә карата позициясе шушындый: ия – хәбәрдән, ә аергыч, тәмамлык, хәлләр үзләре ияргән сүздән алда килә; аныклагыч аныкланмыштан соң урнаша.

Кереш һәм эндәш сүзләр, бөтен җөмләгә карасалар – җөмлә алдында, теге яки бу кисәккә караганда – шул кисәк алдында килә.

***Ритм, рифма, үлчәм факторы.*** Белгәнебезчә, тезмә сөйләм төрле кагыйдәләргә буйсына, ритмик яктан махсус оештырыла. Поэтик таләпләрнең үтәлешенә электән ук игътибарлы булганнар. Мәдрәсә шәкертләре шигырьне тоярга һәм башкаларга оста җиткерергә яхшы күнектерелгән, моның өчен алар, бик тырышып, тезмә текст калыпларын ятлаган. Аларны күңелдән белү яңгырашка тоемсыз һәм тәҗрибәсез каләм ияләрен хәзер дә тексттагы иҗекләр санын бармак бөгеп санаудан коткара, укучыга исә танышкан әсәрләрендәге ритмик чатаклыкларны тотып алырга булыша.

Соңгы вакытта татар шигъриятен рифмасыз, рифмасы килеп җитмәгән, тапталган, ягъни еш очраган әсәрләр басып китте. Бигрәк тә җыр текстлары рифма ноктасыннан карaганда камил эшләнмәгән, ә бу эстрада сәнгатенең зәгыйфьләнүенә, һәвәскәр дәрәҗәдә генә яшәвенә китерә. Аеруча яшь авторлар охшаш яңгырашның ничек барлыкка килүен күзалламый сыман. Рифма камиллегендә юл азагында бер үк позициядә торган сүзләрдәге аерым авазлар мөһим роль уйный. Күпләр *килә – китә, ала – аша, сабый – саркый* кебек парларны хәтта бик уңышлы рифма дип саный, бу поэтик чарада сузык авазлар гына түгел, тартык авазлар да әһәмиятле икәнне исәпкә алмый.

Рифма позициясендә килгән сүзләрдә тартыкларның саңгыраулыкта-яңгыраулыкта ярашуы кирәк. Сүз кыскарак булган саен, бу тагын да мөһимләшә. Мәсәлән: *карлар, парлар, шарлар* сүзләре бер тартык белән аерыла, әмма алар рифманы бозмый. Тәүге авазларның, символист шагыйрьләр санавынча, табигатьтәге үзгәрешләрне, тормыштагы күренешләрне, әйтик, гөрселдәүне, шартлауны, дөбердәүне чагылдырганда исәпкә алынган «шартлаулы» яңгырашы яисә саңгыраулыгы рифмаларны үтә камил итә. Әгәр аларны башка төрлерәк аһәң өстәүче яңгырау тартыкка алмаштырабыз икән, аһәң охшашлыгы шунда ук кими: *зарлар – шарлар.* Саңгыраулы-яңгыраулы авазлардан башланган *бар* һәм *пар* да матур гына рифма ясый. Сәбәбе: әлеге тартыклар фонетик тандем тудыра, бәрү, дөбердәү тибындагы күренешләрне бирә ала. Сүз уртасындагы [гъ]/[къ], [б]/[п] тартыклары рифманы уңышлы яңгыратмый: *бага – бака, тәбә – әпә...* Сүз башындагы [б] белән уртадагысының әйтелешендә, ишетелүендә сизелерлек аерма бар. Ә менә кайбер рус галимнәре, фонемаларның үз сөйләмнәрендәге яңгырашыннан чыгып, бер урындарак ясалган әлеге авазлар сүз уртасында да зур роль уйный, диләр. Дөрес, алар да әлеге авазлар «төгәл диярлек» кенә рифмалар ясый дип саный.

Кыскасы, охшаш яңгырашлы сүзләр эзләгәндә, артикуляцион якны да исәпкә алу зыян итми. Әйтик, борын тартыклары булган бер позициядәге [м], [н], [ң] бервакытта да рифманы бозмый.

Үтә охшаш яңгырашлы сүзләр табу шактый авыр, шунлыктан шигърияттә якынча рифмалар мул кулланыла. Икенче яктан, теге яки бу рифманың шигырьгә бизәк булуын, төгәллеген яисә камил түгеллеген аңларга-аңлатырга мөмкин. Галимнәр, рифманы асылда авазлар түгел, ә телнең минималь мәгънә аергыч берәмлекләре – фонемалар ясый, ди. Аларның исә үз сыйфатламалары бар. Әлеге билгеләрнең күпчелеге туры килгәндә генә, төгәл рифмалар туа. Охшашлыклар кими барган саен, рифманың «якынчалыгы» арта. Тартык авазлар бер-берсеннән:

• ясалу урыны (ирен-ирен: [w], [б], [п], [м]; ирен-теш: [в], [ф]; тел алды: [д], [т], [с], [з], [ж], [ш], [щ], [ч], [җ], [л], [н], [р]; тел уртасы: [й]; тел арты: [к], [г]; кече тел (увуляр): [къ], [гъ], [ң], [х]; бугаз (ларингаль): [ء] (һәмзә); фарингаль (йоткылык): [һ]);

• ясалу ысулы (йомык: [б], [п], [т], [д], [к], [г], [ц], [щ], [къ], [ء] (һәмзә); ярымйомык: [м], [н], [л], [ң]; өрелмәле (спирант, фрикатив): [в], [ф], [с], [з], [ч], [ж], [ш], [й], [җ], [w], [х], [h], [гъ]; калтыраулы: [р]);

• тавыш һәм шау катнашы (сонор: [р], [й], [м], [н], [л], [ң], [w]; шаулы тартыклар: барлык калганнары);

• калынлык һәм йомшаклык;

• саңгыраулык-яңгыраулык белән аерыла.

Югарыда аерып саналган 5 сыйфатның рифма ясауда роле төрлечә. Мәсәлән, алда әйткәнебезчә, саңгырау [п] яңгырау [б] белән бер яссылыкта гына кисешми, ә тел алды тартыгы булган [т]дан ясалу урыны (ирен-ирен) белән дә аерыла. Югарыда саналган сыйфатлар арасында беренче өчесе аеруча мөһим дип карала. Галимнәр әлеге билгеләрдәге аерымлыкны – ике, ә дүртенче һәм бишенчеләрендә

күзәтелгәнен – бер шартлы берәмлек белән үлчи. [п] белән [г] тартыклары, мәсәлән, яңгыраулык-саңгыраулыкта охшаш түгел, ясалу урыннары да төрле. Суммада аларның бер-берсенә охшамавы өч балл тәшкил итә. Үзара зуррак балларда охшашмаган тартыклар да бар. Бу аерма 3 шартлы үлчәм берәмлегенә тиң яисә аннан да артыграк икән, рифма бөтенләй юк дип санала.

Рифмада сузык авазларның аеруча мөһимлеген һичкем кире какмас. Алар никадәр тәңгәл булса, рифма да шулкадәр отышлырак: *сатылды – тартылды, ташлаган – башлаган...* Һәр рифмалашу очрагының тартыкларын җентекләп аерым карарга кирәк.

Хәзерге сөйләмебезне тудыруда 12 сузык катнаша. Шуларның тугызы – татар теленең үз сүзләрендә, өчесе – русча алынмаларда очрый. Сузыклар, сүзнең вертикаль юнәлештәге хәрәкәтенә бәйле, түбән ([а], [ә]), урта ([о], [ө], [ы], [э], [ō], [э̄]), югары ([у], [ү], [и], [ы̄]) күтәрелешле була. Сүзнең горизонталь юнәлештәге хәрәкәтенә мөнәсәбәтле, аларны алгы ([ә], [э], [ө], [ү], [и], [э̄]) һәм арткы ([а], [ы], [о], [у], [ы̄], [ō] рәт төркемнәренә бүләләр. Аваз ясауда иреннәрнең катнашу-катнашмауларына карап, сузыкларны иренләшкән ([у], [ү], [о], [ө], [ō] һәм иренләшмәгән ([а], [ә], [и], [э], [ы], [ы̄], [э̄]) дип йөртәләр.

Рифмалашуда сузыкларның оядашлыгы шулай ук мөһим. Күтәрелеш буенча мисаллар ярдәмендә карыйк: *арба – әрбә; орлык – өрлек; урды – үрде...* Югары күтәрелештәге сузыклардан [у], [ү] белән [и], алынма [ы] кергән сүзләр яңгыраштa бер-берсеннән ерагая *(куп – күп – кип...).* Дөрес, күп иҗекле сүзләрнең аермасы шул авазларга гына кайтып калса яисә составында алар булмаган иҗекләр үзара бик охшашса, яңгыраш шактый отышлы чыга: *күп төрде – киптерде – куб бирде...* Урта күтәрелешле [о], [ө] белән калган оядаш сузыклар уңышлы гына рифмалар төзи, әмма алар кергән сүзләрнең, тартыклары тәңгәл килгәндә дә, охшашлык дәрәҗәсе

бердәй түгел: *кытыгы – кытыры – отыры – өтере – о, тере…*. Рифмалашу камиллеге сүз төзегән сузыкларның кайсы рәткә каравына да бик бәйле, чөнки бу сыйфат лексемаларның калынлыгын-нечкәлеген билгели.

Рифмалашу процессын чагылдырганда, язылышка таянмаска, авазларны дөрес әйтергә һәм транскрипцияне дә яхшы белергә кирәк. Мәсәлән, оныт-ыргыт лексемаларының, парлаштырып әйткәндә, яңгыраште охшашлыклары көчле түгел, чөнки беренче сүзнең язуда «ы» хәрефе белән белдерелгән икенче сузыгы [о] булып ишетелә: «онот».

Сузыклар бер-берсенә никадәр якын булса, рифма да шулкадәр үк көчле яңгырар. Димәк, иҗек эзлеклелегендә бер үк сузыклардан торган сүзләр рифма өчен аеруча уңышлы: *бармак – кармак – тармак – сармак.* Хәзер бер аваз белән генә аерылган *бармак – ермак* (йырмак) парын карыйк һәм [ы] белән [а] ның бүленештәге урыннарын билгелик: [а] – түбән, арткы, иренләшмәгән; [ы] – урта, арткы, иренләшмәгән. Күрәбез ки, тәүге сузыкларның бер сыйфаты кисешми, ә төп тартыклар – бер үк. Менә ни өчен *кармак* һәм *ермак* сүзләре төгәл рифма төзи алмый.

Әйтелгән фикерләрне интернет сайтлардагы татарча шигырьләрдән мисаллар белән ныгытыйк. Түбәндә Лилия Сәләхетдинова исемле авторның бер рифмасы да булмаган әсәрен китерәбез:

***Үкенечсез булсын гомерләр***

*Чит булмаган таныш кешеләр бар.*
*Ерак булып якын кебекләр.*
*Бер күрергә теләп күрешмәгән,*
*Үкенечкә калган мизгелләр.*

*«Әгәр бераз алдан белгән булсам…!» –*
*Бу сүзләрне күпләр әйткәннәр…*
*Акыллылар вакыт таба алган,*
*Кыюсызлыкларын җиңгәннәр.*

*Җөмлә җитә, сүзләр мөһим кайчак.*
*Секунд җитә, аңлыйк, кешеләр!*
*Соңга калмыйк! Әйтик, күрик әле.*
*Яшендәй тиз уза гомерләр.*

Шигырьдә, күргәнебезчә, якынча рифмалар да юк, чөнки икенче һәм дүртенче юл азагында торган өч иҗекле сүзләрнең тамырлары охшаш яңгырамый (кебек – мизгел; әйткән – җиңгән, кеше – гомер), һичьюгы сузык авазлары бердәй түгел. Автор, мөгаен, әлеге лексемаларның һәр буыны охшашланырга тиеш дип санамый, шунлыктан соңгыларының гына якын яңгырашын кайгырта. Рифмалашмаган юлларның һәрвакыт «нәр-ләр»гә тәмамлануы шигырьне тагын да ямьсезләтеп, гадиләштереп җибәрә.

Хәер, шагыйрь таныклыгы йөрткәннәр дә рифманың ни икәнлеген, аңа татар шигърияте ирешкән биеклек куйган таләпләрне белеп бетермәскә мөмкин. Дөрес, рифма җитешсезлекләре кайвакыт автор һәм редакторның игътибарсызлыгы белән генә аңлатыла. Мисалга Рәсимә Гарифуллинаның «Ай нурында энҗе яна» (Казан утлары. – 2018. – № 4) шигъри шәкеленә кергән «Яшьлек белән сөйләшү» әсәрен китерергә мөмкин. Аннан алынган гади генә поэтик өзектә рифма бөтенләй юк:

*Үзгәрдеңме, йөрәк, әйтче миңа,*
*Нинди хисләр белән яшисең?*
*Кайтавазы булып гомеремнең,*
*Сорау бирә шулай яшьлегем.*

Кайчакта сүзләрнең рифмалашмавына басым сәбәпче. Югарыдагы өзектә ул чатаклык та күзәтелә. Рәсимә Гарифуллина тупланмасыннан бу төр җитешсезлеккә тагын мисаллар күрсәтик. «Яшисе иде бергә» әсәрендә *яна'лар* (фигыль) һәм *арала'р* (күплек формада килгән исем), *үзе'нчә* һәм *тү'змичә* сүзләре, басым төрле иҗекләргә төшкәнлектән, үзара охшашланып бетә алмый. Басым төрлелеге күзәтелгән

рифмаларны якынча рифма дип тану булса да, алар эффектлы яңгырамый. Кагыйдәләрдә басым арттан икенче иҗеккә төшә дип саналган кайбер сүзләрдә зур күпчелек аны, традицион рәвештә, соңгы урынга куя. Мисалга «аюдай», «кешедәй» тибындагы чагыштыруларны китерергә мөмкин. Әгәр бар халык бу сүзләрне кагыйдәгә туры китереп әйтсә, автор да шулай дөрес санаса, М. Җәлилнең «Бер үгет» әсәренең тәүге строфасында да ритм чатакланыр иде:

*Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:*
*Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.*
*Тик күрәсе иде эше белән*
*Кеше булган иң чын адәмне.*

Берничә сүздән оешкан (составлы) рифмалар – гаҗәп очраклар. Аларны уйлап тапканда, күп элементларны, шул ук басымнарның зур роль уйнавын да искә аласың. Мәсәлән: *Марҗаның да бар җаны – / Ташлап качты баржаны*. Татар шигъриятендә рифмадагы басымны санга сукмау шулай ук гадәти бер күренешкә әйләнә башлады. Дөрес, гомумән алганда, сүзләребездәге басым соңгы иҗеккә төшкәнлектән, текстны кычкырып сәнгатьле укучылар барлык басымнарны соңгы иҗеккә куялар да, рифма җитешсезлеге «юкка чыга». Руслар борынгы текстларда еш очраган бу төр «автор басымы»н яисә кайбер сүзләрдә басымның элекке позициясен яңа чыккан китапларда апостроф белән билгели.

Күпсоставлы рифмалар шигырьне үзенчәлеклерәк һәм тәэсирлерәк итә. Шул ук вакытта структурасы тәңгәл булмаган гайбарәләрне, җөмләләрне рифма ясарлык уйлап табу – зур талант чагылышы да. Рифманың гүзәллеге үтә охшаш яңгырауга гына кайтып калмый. Әйтик, *«Әле сабый чагыннан ук / Карадым бит мин аны – Инде шуны онытты дип / Каргадым бит мин аны* рәвешендәге рифма-җөмләләрнең тәэсире укучыга зур булмас. Алар болай да тел бизәкләреннән мәхрүм строфаны бизәп тормый, мәгънә эчтәлекләре

белән, хәтта ямьсезли. Ритм, рифма, эчтәлек, мәгънә үзара бик нык береккән, берсенең тәэсирлелеге, камиллеге икенчесенә дә йогынты ясый һәм киресенчә дә.

Сүзгә бер хәреф кенә өстәп рифмалаштыру бик актив кулланышта. Әгәр рифмалар бер үк лексеманың төрле грамматик формаларыннан корылса, авторның зур табышы булып тормый *(яшәгән – яшәлгән, ашаган – ашалган...),* әгәр төрле тамырлардан ясалса *(калган – талган, күргән – үргән)* яисә нигез сүзләр лексик мәгънәсе белән аерылса *(яшәлгән – яшәргән),* матур яңгыраш ала.

Кайвакыт, строфадагы соңгы ритмик буыннар бер-берсеннән чак кына аерылганда да яисә текстка бик үк актив кулланышта йөрмәгән лексемалар килеп кергәндә, көтелмәгән рифмалар килеп туа. Укучы мондый очракларда басымның төрле урынга төшүенә дә артык игътибар бирмәскә, рифманың хәтта якынча гына икәнлеген дә тотып алмаска мөмкин. Фикеребез дәлилле булсын өчен, рифманы матур әдәбиятта үтә пассив кулланылган, икенче иҗектәге басымга ия *божан* белән басым беренче иҗеккә төшкән *бу җан* сүзтезмәсеннән ясыйк. Ул, һичшиксез, оригиналь тоелачак:

*Син – шөпшәме, божанмы–*
*Ник чагасың бу җанны?*

Гомумән алганда, китерелгән мисаллар, төгәл рифма булсын өчен, аны төзүдә катнашкан барлык тартык һәм сузыкларның үзара якынлыгы, басым төшкән сузыкларның тәңгәллеге кирәклекне, сүзләр яңгырашындагы охшашлык дәрәҗәсен тартыкларның бер-берсеннән ничә сыйфатта аерылуы билгеләвен сөйли.

Шигырь юлларының охшаш яңгыравын тәэмин итүче шартлар безнең тарафтан күпмедер барланса да, рифмалашу күренешен катгый кагыйдәләр кысасына кертү гаять кыен, мөмкин дә түгел. Җитмәсә, кайсыдыр халык кабул иткән рифма нормалары икенчесенекенә туры килми. Әле

бит матур әдәбият бөрәмлеге булган һәр шигырьнең үз нюанслары бар. Рифма нигезләрен бик уйлап, кат-кат үлчәп табарга кирәк, шунлыктан татар поэзиясенә мөнәсәбәттә рифмалашу кагыйдәләренең төбенә төшеп язган кеше дә юк. Шагыйрьләребезгә килгәндә, алар да мондый анализлар белән шөгыльләнмидер, рифма камиллегенә бары тик ишетү сәләте – тоем белән генә ирешә торгандыр. Редакторга да әнә шундый сәләткә ия булу бик кирәк.

Рус әдәбият белемендә рифма мәсьәләсе күптән тиешле игътибарга алынган. Соңгы чорда да бу юнәлештә китаплар басылып тора[1]. Шулай да хәтта русларда да рифмага мөнәсәбәтле кайбер карашлар бәхәсле һәм поэзиянең рифмалашу күренешенә бәйле проблемалар ахыргача хәл ителмәгән. Әйткәнебезчә, рифманың гомуми теориясен эшләү аеруча авыр һәм катлаулы, милли телләрдәге авазлар үзара тәңгәл килми, фонетик төгәл яңгырашка ирешү чикләре дә бик төрле. Хәтта тугандаш халыкларның графикада бердәй күрсәтелгән авазлары да еш кына әйтелештә башкачарак яңгырый. Бер телдәге узуаль-төгәл фонетик бергәлеккә нигезләнгән рифма да шигырьне кычкырып укыганда таралып төшәргә, якынча гына булып калырга мөмкин.

Якынча рифма дигәндә, поэтик традицияләр кабул иткән рифма сайлаудагы нормадан тайпылышларны күздә тотабыз. Алар исә һәр халык, һәр чор, һәр поэтик төркем-юнәлеш өчен төрле дип карала. Боларга а) басымлы сузык төсмерләрендәге зур әһәмияткә ия булмаган аерымлыклар, ә) басымсыз сузыклардагы (вокализмдагы) тәңгәлсезлекләр, б) тартыклар системасындагы (консонантизмдагы) читкә китүләр керә.

Рифмага мөнәсәбәт чорга бәйле дигәннән, рус классицизмын искә төшерәсе килә. Бу чор шагыйрьләреннән идеаль рифмалар таләп ителгән. «Кыска и» өстәлү юлы белән генә

---

[1] *Богомолов Н.А.* Основы теории стиха. Краткое введение в стиховедение. М.: МГУ, 2004. – 59 с.; *Гаспаров М.Л.* Очерк истории русского стиха. – М.: Фортуна Лимитед, 2000. – 352 с.

ясалган рифмалар нормадан читкә чыгу дип каралган, якын һәм төгәл булмаганнары катгый тыелган. Татар шигъриятенең борынгы чорларында рифмаларга таләпләр шулай ук зур булган, шунлыктан элгәреләр калдырган поэтик мирас яңгыраш гүзәллеге белән һаман да игътибарга лаек.

Рифма хакында иң нигезле һәм кызыклы хезмәтләрнең берсе – В. Жирмунскийның 1923 елда Петроградта басылган һәм рус рифмасына хас сыйфатларны ачкан, шул ук вакытта рифма хакында гомуми күзаллауларны да үстергән «Рифма, ее история и теория»се. Ул, һичшиксез, шагыйрьләрнең һәм редакторларның өстәл китабы булырга тиеш.

Үкенечле ки, хезмәтебездә татар поэзиясендә рифма ясауның барлык үзенчәлекләренә тукталу мөмкин булмады. Рифма теориясен тудыру янәшәсендә, интернет сайтларында таралган «һәвәскәр» шигырьләр арасында ахыргача рифмалашып беткәннәре бик сирәк очраган заманда аларны сүтү-төзәтү – гаять кирәкле эш. Ул матур әдәбият сагында торучы тәнкыйтьнең генә түгел, поэзиябезнең киләчәк язмышын кайгырткан һәр каләм иясенең изге бурычы булырга тиеш.

Интернеттагы «Татарча шигырьләр»дә урын алган күпсанлы текстлар арасыннан нибары бер строфасы рифмалашкан (безнең тарафтан ассызыкланган) әсәргә мисал китерәбез:

*02.12.2013*
*Лилия Гиматдинова (Гыйматдинова!)*

*Сау бул үтеп киткән елым.*
*Сау бул үткән көннәрем.*
*Шул көннәрдә эз калдырып,*
*Йөргән минем юлларым.*

*Үтте бер ел, үтте гомер.*
*Дөньялар да үзгәрде,*
*Кемдер туды, кемдер үсте,*
*Кемдер азрак картайды.*

*Күпме бер ел, азмы бер ел,*
*Йомгак кебек сүтелде,*
*Тәгәрәде көннәр, төннәр.*
*Мизгел булып тоелды.*

*Үтте айлар, үтте көннәр,*
*Үзгәрешләр күп булды.*
*Күп кенә эшләр эшләнде.*
*Эшләнмәгәне калды.*

*Күп кенә уйлар уйланды,*
*Хыял утын<u>да яндык.</u>*
*Үткән елга шөкер итеп,*
*Яңа елга <u>куандык.</u>*

*Тагы бер ел өстәлде*
*Безнең гомер юлында.*
*Сүнмәде өмет утлары,*
*Йөрәгебез түрендә.*

Фаҗига шунда: матур әдәбият белән кызыксынучылар шушы төр әсәрләрне уңай бәяли, ә чын шигърияткә тәнкыйть сүзләре яудыра. Бүгенге көндә талантлы каләм ияләрен генә түгел, белемле һәм нәфис сүзгә тоемлы әдәбият сөючеләрне дә иң борчыганы – һәвәскәрлек дәрәҗәсендә язылган әсәрләрне авторларының, сайт хуҗаларының татар шигърияте үрнәкләре рәвешендә тәкъдим итүе, әлбәттә. Бу төр шигырьләр, бердән, милли сәнгатебезнең дәрәҗәсен башкалар каршысында һәм гомумән төшерә; икенчедән, зәвыклы укучының әдәбияттан күңелен кайтара, өченчедән… Нигә без балаларыбызны иң начар әйберләрдә генә тәрбиялибез, дигән җан өшеткеч сораулар уята. Дүртенчедән, әдәбиятка мөнәсәбәтле сайтларны ачучылар һәм аларның нинди эчтәлеккә ияләге өчен җаваплы кешеләр материалларны редакторлардан камилләштертү кирәклекне оныталар, дигән нәтиҗәгә китерә.

Рифманы якынча дип санау шулай ук шартлы. Кайбер охшашрак яңгырашлы сүзләрне хәтта фән төгәлләшмәгән

рифма дип таныганда да, шагыйрь буларак, бу мөнәсәбәт белән килешү кыен, андый очракларда рифма турында сүз йөртү дә мөмкин түгел кебек. Әйтик, кайбер рус галимнәре тартыкларының берише тәңгәл, ә басымлы сузыклары төрле диссонансларны шундыйларга кертәләр (солнце – сердце). Без, мәсәлән, басым төшкән авазлар һәрвакыт тәңгәл килергә тиеш дигән караштa торабыз. Һәрхәлдә, татар поэзиясе өчен бу бик мөһим. Барлык телләр дә үзенчәлекле булган кебек, һәр халыкның шигърияте, шул шигъриятнең рифмалары да төрлечәрәк калыплаша, шул сәбәпле аларны бәяләүдә, төркемләүдә аерымлыклар күзәтелә.

Рифмага иң игътибарлы халык гарәпләр булган, бу төр мөнәсәбәт оригинал һәм тәрҗемә шигърият аша безгә дә узган. Гарәп алынмалары әдәбиятта аеруча күп кулланылганлыктан, аларның рифма байлыгыннан да актив файдаланылган. Образларга, тел-сурәтләү чараларына поэтик әсәрләр дәрәҗәсендә бай Коръәннең рифмалашкан проза рәвешендә язылуын да онытмыйк. Хәтта Европа халыкларында да шигъри әсәрдә рифма мәҗбүрилеге гарәп әдәбияты тәэсирендә ныгыган.

Соңгы юлларның охшаш яңгырашына, рифма төгәллегенә килү гасырлар дәвамында барган. Борынгы римлылар ук рифма турында уйланган, Овидий, Вергилий, Гораций кебек танылган шагыйрьләр аның тәүге формасы булган гомеотелевтонны тел бизәге сыйфатында кулланган. Рифма ясауга бәйле төрле экспериментлар барган. Мәсәлән, өченче гасырда иҗат иткән латин шагыйре Коммодиан Газскийның «Instructiones» әсәре үтәли бер рифмага төзелгән.

Шигъриятнең рифма байлыгын һәм телнең аны формалаштыру потенциалын күрсәтүдә, аны популярлаштыруда, авторларның эшен җиңеләйтүдә сүзлекләр төзелү зур роль уйнаган, һәм ул төр хезмәтләр тора-бара мөхәррирләрнең дә өстәл китабына әверелгән. Дөрес, Европада андый белешмәлекләр XVI гасырдан ук таралыш ала башласа да,

басмачылык тарихы безнекеннән озынрак русларда да әле беренче сүзлек – И. Тодорскийның «Лексикон»ы – 1800 елда гына, анда да бик аз санда дөнья күргән.

Рус теленең рифма ясау мөмкинлекләре гаять зурлыгын күпсанлы гомуми һәм персональ рифма сүзлекләре күрсәтеп тора. Инкыйлабкача төзелгәннәре арасында Свечинның «Собрание рифм по алфавиту» (1834, 1836), М. Бродовскийның «Руководство к стихосложению». (1887), К.И. Ш-въның «Правила сочинения стихов и рифмовник» (1903), Н. Абрамовның «Полный словарь русских рифм» (Петербург, 1912) хезмәтләре популяр булган. Соңгы елларда да шактый сүзлек дөнья күрде, шулардан киң кулланышта йөргәне һәм гаять бае – галимнәр коллективы чыгарган «Словарь рифм русского языка».[1]

Мөмкинлекләре зур рус поэзиясендә рифмадагы бертөрлелектән качу артык авыр түгел, ә бездә, тапталып беткәнлектән, әсәрләрне зәвыксызлындыра башлаган охшашлыклардан гына котылу да шактый кыен. Баналь рифмалар бигрәк тә графоманнарның яраткан чаралары булып тора.

Рифмаларның төрләре шактый. Әйтик, юл азагында аваздаш сүзләр сузык авазга тәмамланса – ачык, ә тартык авазга тәмамланса, ябык рифма дип йөртәләр. Ачык кына, ябык кына рифмалы әсәрләрне табуы алай да кыен. Сүз басымы күпчелек очракта соңгы иҗеккә төшкәнлектән, татар шигъриятендә «ир» (мужская) рифмалар өстенлек итүен дә белгеләргә кирәк. Болардан тыш рифманың юл башы, эчке, үтәли (сквозная), гади, кушма, рәдиф дип аталган төрләре бар. Кушма рифманың бер төре – рәдиф. Бу очракта юл азагында ким дигәндә ике сүз рифмалашып килә, аларның икенчесе, гадәттә, бер үк сүзнең юл саен кабатланып килүеннән ясала.

[1] *Шалаева Г.П., Ситникова Е.В, Студеникина Л.Г., Лебедев П.В.* Словарь рифм русского языка. – М.: АСТ; М.: Слово, 2009. – 863 с.

Рифма ясауның күпсанлы алымнарын белү шагыйрьләр өчен бик кирәк, шулай да шигырьгә ритмик чатаклыклар, сайлаган үлчәмне саклый алмау кайвакыт рифма килеп бетмәүгә караганда да зуррак зыян сала.

Әдәбият теориясенә һәм тарихына караган китапларда ритм-үлчәм мәсьәләләре уңышлы хәл ителгән. Әлеге проблема Х. Госман («Татар шигыре», 1964), Х. Курбатов («Ритмика татарского стиха», 2005), М. Бакиров («Закономерности тюркского и татарского стихосложения в свете экспериментальных исследований», 1971) һәм башкалар тарафыннан тирән яктыртылган, шул сәбәпле бу хезмәтебездә әлеге темага артык кермәбез.

Галимнәр ритмны шигырьнең көче, энергиясе дип саный. «Аны тудыруда төрле тел-интонация компонентлары: иҗекләр, сүзләр һәм сүз аралыклары, синтагмалар, басымнар, сөйләм темпы, мелодика кебек күптөрле чаралар катнаша. /…/ Шул ук вакытта гомуми ритмга поэтик текстның мәгънә эчтәлеге дә теге яки бу дәрәҗәдә йогынты ясый»[1]. Моның шулай икәнлеген мисаллар ярдәмендә күрсәтербез, беррәттән, әсәрләрне очраган ритм-үлчәм җитешсезлекләреннән дә арындырырбыз.

Түбәндә Әминә Бикчәнтәеваның «Март аенда» әсәре иҗек саннары билгеләнгән рәвештә китерелгән:

*Кар дип җиргә / басасың, (7)*
*Суга кереп / батасың. (7)*
*Чыксын инде / умырза(я) (8)*
*Кар астында / ятмасын. (7)*
*Мартлар җитсә, / яз җитә, (7)*
*Бураннары / булса да, (7)*
*Песи чыккан / урамга (7)*
*Аяклары / туңса да. (7).*

---

[1] Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 159.

Күргәнегезчә, өченче юлда бер иҗек артык, шуңа күрә ул башкаларына караганда уңышсызрак яңгырый. Әсәрне укучы, иң азакта килгән иҗекне әйтер-әйтмәс узып, ритмик буыннарны саклый алганда, тамашачы үлчәмгә, шул сәбәпле ритмикага да хас җитешсезлекне тоймаска да мөмкин. Шулай эшләп булганга да, төзәтүгә зур көч сорамаган строфаны бу сыйфатта калдырырга ярамый. Хаталы юл идеалда шушы рәвешчәрәк язылырга тиеш: *Башын төртсен / чәчәкләр.* Әгәр умырзая сүзе эчтәлектә мөһим дип саныйбыз икән, буын арасының лексема уртасына туры килүен игътибарга алмыйча, автор юлын шушылай үзгәртәбез: *Баш төртсен у/мырзая.*

Инде Резеда Вәлиеваның «Көз» шигыренең тәүге строфасын иҗекләргә бүлеп урнаштырыйк һәм ритмны боза торган артыгын җәяләр эченә алыйк:

*Ни а-ра-да җәй үт-кән, (7)*
*Ал-тын көз ки-леп җит-кән. (7)*
*Җи-меш-ләр өл-гер(гәч), бакча (8)*
*Биг-рәк тә ма-тур и-кән!*

Төзәтәбез:

*Ни арада җәй үткән,*
*Алтын көз килеп җиткән.*
*Җимешләре өлгергәч,*
*Бакча бик матур икән!*

Редактор, ритм ясаучы башка факторларны белмәгәндә дә, һичьюгы иҗекләрнең артып китүен яисә җитмәвен генә тойса да, татар поэтик мирасындагы күпсанлы әсәрләр камилләшер иде.

**Сөйләмгә традициялелек һәм чит телләр тәэсире.** Татарча язма әдәбиятны алынмалардан тәмам арындыру борынгы заманда бөтенләй мөмкин булмаган, узган гасырда исә анда гарәп-фарсы сүзләре шактый кимегән. Бу вакытка көнчыгыш алынмаларының бер өлеше тәмам үзебезнекенә әйләнгән, күп кенә төшенчәләрнең төрки вариантлары

пассивлашкан яисә юкка чыккан. Яңа заманда татарча исеме табылмаган предметлар, күренешләр барлыкка килгән, алар инде көнбатыш телләрдәгечә, руслардагыча атала башлаган.

Элек рухани әдәбият һәм теологик китаплар гарәпчә-фарсыча сүзләр белән чуарланса, бүгенге көндә дингә мөнәсәбәтле гыйльми хезмәтләрдә дә көнбатыш терминнары шактый мул кулланыла, хәтта дини әсәрләрнең үзләрендә дә аларны очратырга мөмкин. Кыскасы, бер яктан, әдәбиятның лексик катламына традицияләр тәэсире һаман да көчле, икенче яктан, сүзлек байлыгыбыз, аның актив катламы чит телләр (инглиз, рус…) тәэсирендә сизелерлек үзгәрешләр кичерә.

Язма хезмәтләрдә нинди алынмаларның өстенлек итүе авторның белем дәрәҗәсенә, һөнәренә, тасвирлаган өлкәсенә, стиленә һәм кайбер башка сәбәпләргә карый. Белгәнебезчә, һәр фәннең үз терминологиясе бар, ә ул борынгы заманнарда теге яки бу гыйлемнәрнең кайсы территорияләрдә башлап формалашуына һәм алга киткәнлегенә нык бәйле. Әйтик, тыйб китапларында – латинча төшенчәләр, әдәбият белеменә мөнәсәбәтлеләрендә грек терминнары еш очрый. Бу бөтен дөньяда шулай. Ислам динен тоткан халыкларның рухани әдәбиятында – фарсы, бигрәк тә гарәп сүзләре гаять күп кулланыла. Кульязмаларны басмага хәзерләгәндә, әлеге фактны исәпкә алмыйча булмый.

Теләсә кайсы текстны ятрак яңгырашлы рус сүзләреннән генә ахыргача арындыру да, зур күпчелек актив кулланган чит лексемалар белән шыплап тутыру да – телебезгә мөнәсәбәтнең капма-каршы ике чигедер. Бар кешегә билгеле сүзләрне тар даирә генә аңларга мөмкин лексемаларга тулысынча алмаштыру исә текстларны күпчелекнең аңламавына китерә.

Җөмләдәге сүзләр тәртибе – күп гасырларга сузылган тарихи үсеш нәтиҗәсе. Телләр никадәр борынгырак булса, шуның кадәр үк үзгәреш кичергән һәм камилләшкән дип санала. Бер үк вакытта әлеге үзгәрешләр халыкның яшәү һәм

мәдәни бәйләнешләр мәйданы белән дә билгеләнә. Димәк, татар сөйләменең ниндилегендә бабаларыбызның яшәү урыннарын күп алмаштырганлыклары, халкыбызның континент буйлап чиктән тыш таралганлыгы, әллә ничә дәүләт кысаларында яшәве, ыругара, милләтара бәйләнешләре даирәсенең зурлыгы, диннәр алмаштыруы кебек күптөрле шартларның роле зур.

Бер сүзнең икенчесенә бәйләнү юллары, сөйләм берәмлекләрен төзү алымнары гасырлар дәвамында чарланып, тел структурасының иң тотрыклы элементларына әверелә. Язу барлыкка килгәннән соң, алар тагын да ныгый. Әкренләп нормаларга салынган милли тел формалаша. Традициялелек, күчемлелек күренеше шулай ук теге яки бу өлкәнең жанрларына, стильләргә, документ төрләренә дә хас, чөнки алар да аерым бер чорларда барлыкка килгән, үскән, калыплашкан.

Телгә тәэсир һәр чорда төрле дәрәҗәдә, төрле яссылыкларда бара. Иҗтимагый барышта уңай күренеш булуына карамастан, ислам һәм аның белән бергә тормышыбызга узган, актив кулланыла башлаган дини текстлар язма әдәбиятка, бер яктан, тискәре агрессив йогынты ясаган; икенче яктан, алга киткән Көнчыгыш мәдәнияте сүз сәнгатебезне яңа жанрларга, формаларга, калыпларга баеткан. Ул шулай ук сөйләмебезгә яңа төшенчәләр, гыйльми терминнар алып килгән.

Ислам дине тәэсирендә татарда кеше исемнәре чиктән тыш үзгәрешләр кичергән. Беренчедән, бу лексик катлам баеган, икенчедән, атамаларның саф төрки чыгышлылары сизелерлек кимегән, хәтта кушаматларның да алынмалары барлыкка килгән. Чит сүзләр, гасырлар дәвамында сөйләмебезгә татар теле кануннарына буйсындырып кертелсә дә, кызганыч ки, хәзерге вакытта бу катгый норма булудан туктады. Бигрәк тә көнбатыш телләреннән кергән төшенчәләрнең бөтенләй яисә артык зур үзгәрешләр кичермәве күзәтелә.

Явыз Иван Казан ханлыгын яулагач, кайбер татарча сөйләм төзелмәләренә рус синтаксисының тәэсире арта,

телгә моңарчы төркиләрдә очрамаган конструкцияләр үтеп керә, калькалаштыру күренеше киң тарала. Бүгенге көндә бигрәк тә калада яшәүчеләр сөйләменә гомумдәүләт теленең басымы гаять зур. Бер үк вакытта тискәре якка үзгәрешләр кичергән җанлы сөйләмнең дә әдәби телгә, язма телгә тәэсире артканнан-арта.

Хәзерге вакытта китап кулъязмалары белән эш иткән мөхәррирләр гасырлар дәвамында ныгыган тел нормаларын бозу очракларының ешайганнан ешаюы хакында чаң суга. Сөйләм җитешсезлекләре эфирда да, вакытлы матбугатта да филолог булмаган тыңлаучы, укучы тотып алырлык хәлгә килде, бермә-бер артты. Бу күренешләр, үз чиратында, яшь буын язучыларның, редакторларның сөйләменә, каләменә, тел нормалары бозылуга карата мөнәсәбәтенә дә тискәре йогынты ясый. Интернет челтәрендә барган кайнар бәхәсләр әнә шуны сөйли. Бүгенге мөхәррирләр бигрәк тә җанлы сөйләм, геройлар сөйләме кулланылган әдәбиятны камилләштергәндә зур кыенлыклар кичерә, төрле сораулар алдында кала. Бер яктан, әлеге сөйләмнең тормышчан булуы кирәк, икенче яктан, тормышчан итәм дип, аны татар теле закончалыкларына бөтенләй җавап бирми торган сыйфатта да калдырып булмый. Шулай да без, русчалы-татарчалы, тупас, бозык сүзләр белән тулган текстларны бер читкә куеп, «Безнең гәҗит» сайтына 2013 елның 23 гыйнварында каяндыр алып урнаштырылган, авторы күрсәтелмәгән бер язманы редактор күзе аша уздырыйк:

***Акыллы фикер***

*Һәр елны пенсия фондыннан килгән «сәлам хатлары» бу елдан килми башлаячак. Хөкүмәт, ниһаять, акчаны экономияләргә кирәк дигән фикергә килгән, чөнки шушы хатларның гомуми бәясе ел саен 3 млрд сумга төшә икән. Ә хәзер бу акчалар пенсионерларның тормыш көнкүрешен яхшыртуга сарыф ителәчәк, ягъни пенсиягә өстәләчәк. Кем дә булса үз*

*пенсиясе турында мәгълүматлы булырга теләсә, аны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, ягъни интернет аша кереп карарга мөмкин.*

Язманы стилистик хата саналырлык кабатлаулардан һәм башка җитешсезлекләрдән арындыру артык авыр булмас, ә менә алынмалардан бөтенләй чистарту мөмкин дә түгел. Бу текст – билгеле ки, тәрҗемә, шунлыктан ул, мөстәкыйльлектән һәм ана телләрен саклау шартларыннан мәхрүм ителгән татарларныкы янәшәсендә, дәүләтле халык сөйләменә дә чит йогынтылар көчәюне, шул сәбәпле татар теленә басымның икеләтә артуын, рус телендәге һәр үзгәрешнең анда да ниндидер күләмдә чагылыш табуын ачык күрсәтә. Мәкалә, теге яки бу күренеш ачылгач, предмет ясалгач, тиз арада үзенчә исемләмәсәң, аның, һичшиксез, аларны уйлап тапкан, ачкан халык телендә атала башлавын да сөйли. *Интернет, пенсия, портал, муниципаль* сүзләре – моның ачык мисаллары.

**Аһәң.** Уңышлы сайланган аһәң көндәлек аралашуыбызда ирекле урнашкан җөмлә кисәкләрен мәгънәви яктан бәйләргә, фикерне дөрес аңларга булыша. Ул сүз тәртибендәге иркенлекнең бик нык артып китүен чикли һәм сөйләмне теге яки бу формада оештыруга да күпмедер ярдәм итә. Кайвакыт, абзацның гына түгел, күләмле текстның нинди яңгыраш алуы да беренче җөмләнең аһәңенә бәйле була.

Алда саналган төрле факторлар һәрвакыт үзара тыгыз бәйләнештә тора һәм стильне, сөйләм формасын калыплаштыруда катнаша. Сүзнең җөмләдәге тәртибенә бәйле рәвештә, сөйләм ***әдәби*** һәм ***җанлы*** булырга мөмкин. Әдәби тел, үз чиратында, ***язма, сөйләмә*** төрләргә бүленә. Язма тел ***эмоциональ*** һәм ***эмоциональ булмаган*** сөйләмгә аерыла.

Эмоциональ сөйләмгә шигырь һәм нәсер, прозаның эмоциягә бай урыннары керә. Фәнни, рәсми телдә язылган хезмәтләр һәм тыныч хикәяләү тонындагы проза икенче ояга берләшә. Шул сыйфатка ия публицистика сөйләме исә эмоциональ булмаган төргә якын тора. Күпчелек әсәрләрне иҗат

иткәндә төрле стильләр бергә үрелә. Әйтик, нәфис текстларны сирәк очракларда гына бер стиль формалаштыра.

Әдәби телнең сөйләмә формасы – ***монологик*** (доклад, лекция, декламация) һәм ***диалогик*** (геройларның үзара аралашуы) характерда. Җанлы сөйләм дә монологик (әкиятләр, сөйләкләр, риваятьләр) һәм диалогик формада (көнкүреш теле) булырга мөмкин.

Гадәти тыныч сөйләмле чәчмә әдәбиятта сүзләрнең җөмләдәге урынын, иң беренче чиратта, аларның коммуникатив йөкләре һәм грамматик факторлар билгели, шул ук факторларны, яңалыкны ассызыклаган логик басым да билгеле бер әһәмияткә ия. Татар сөйләмендә традициялелек бигрәк тә хәбәрнең җөмләдә иң соңгы позиция алуында чагыла.

Хисси прозада сүзләрнең урыны шулай ук җөмлә кисәкләренең коммуникатив йөкләмәсе тарафыннан аныклана. Татар эмоциональ прозасы өчен җөмлә кисәкләренең кире тәртибе бик характерлы, әмма мәҗбүри түгел. Нәсер жанрында, моннан тыш, ритм барлыкка китергән хис көчен дә исәпкә алырга кирәк. Кайбер хис тудыру чараларын тыныш билгеләре безнең тарафтан шактый тәртипкә китерелгән нәсер үрнәгендә карап узыйк:

***Минем сиңа әйтер сүзем бар***

*Сәлам, дустым. Мин кайттым. Ә син, мине үлгән дип уйлап, һәйкәлгә чәчәкләр китерә идең... Мин бүген дә унсигездә, инде алтмыш дүрт ел үтсә дә, унсигездә.*

*Дөньяны кочасы, тормышны яратасы, якты хыялларны чынга ашырасы, каядыр очасы, биеккә-биеккә күтәреләсем килгән вакытта мин чит ил туфрагында ятып калдым. Мин тормышны өзелеп сөя идем. Хисләрем саф, яшьлегем чәчәк аткан иң гүзәл чорында Туган илдән еракта яу кырында ятып калдым. Мин яшәргә хаклы идем, мин яшәргә тиеш идем. Унсигездә үлеп буламы?! Минем бик-бик нык яшисем килде. Беләм, яшәү – кыйммәт бер нәрсә, яшәү шулай кыйммәт булганга, җиңү өчен бирдем мин аны.*

*Кичер мине, Илем! Синең газиз туфрагыңнан читтә калуым өчен. Су коенган күлләр, җиләк җыйган тугайлар, ялан тәпи йөгереп узган яшел чирәмлекләр, ат саклаганда яккан төнге учаклар – сезне, бик теләсәм дә, кабат кайтып күрә алмавым өчен кичерегез. Илебезне саклап, халкыбызны яклап, без ут эчендә тереләй яндык, үләсемне белә торып, күкрәгем белән дошман амбразурасын капладым. Утлы ядрәләр алдыбызда шартлап, пулялар яңгыры тәннәребезне теткәләп, яшь йөрәктән соңгы тамчы каныбыз тамганда да, без, Ватан, сиңа тугры калдык. Бик теләсәк тә, Җиңү көнендә горур атлап, Туган ил, сиңа кайта алмадык, кичер.*

*Кичер мине, Әнкәй! Вакытында туган нигезгә кайта алмавым өчен. Йокысыз төннәрең, борчулы көннәрең өчен. Синең моңлы күзләреңә карап, чал чәчләреңнән сыйпап юата алмавым, картаймыш көнеңдә терәгең була алмавым өчен кичер, әнием кадерлем...*

*Кичер мине, Сөеклем! Ялгызлыкта үткән яшьлегең өчен. Озак көттереп тә, яныңа кайта алмавым, хыялларыбызның тормышка ашмавы өчен кичер. Җирдә чын сөю барлыгына икеләнүчеләргә, дәлил итеп, мин Сине күрсәтер идем. Гомер буе мәхәббәткә тугры булып калган изге җан, озын чәчләреңнән иркәләүче назлы җил булып кайттым мин синең яныңа. Хыялыңда гына булса да башыңны кайнар күкрәгемә куй һәм үзеңне сагынып сыкраучы йөрәкнең тавышын тыңла. Син миңа алтмыш дүрт ел элек ничек якын булсаң, бүген дә шулай кадерле. Чөнки мин бүген дә – унсигездә.*

*Утлы еллар аша мин кайттым. Алтмыш дүрт елдан соң унсигездә килеш, сагышлы җыр булып, озын юллар аша, утлы еллар кайтавазы булып, мин кайттым.*

*Кешеләр, еллар аша без сезгә эндәшәбез. Без кайдадыр еракта калмадык, мин Туган илгә мәрмәр сыннар, моңлы җырлар аша кайттым. Кышларын акрын гына ап-ак карлар яуганда, шул кар бөртекләре арасында, язларын бер-берсен*

*куышып агучы гөрләвек тамчыларында, җәйләрен сызылып аткан таңда сайраучы сандугач тавышларында, көзләрен алтын яфраклар арасында безнең җаннар күбәләктәй очып йөрерләр. Фани дөньядан киткән якыннарыгыз өчен дога кылганда, безне дә искә алыгыз сез. Унсигез яшендә илен саклап чит илдә үлеп калучыларның моңа хакы бар. Онытмагыз безне, кешеләр, онытмагыз! Ватан өчен гомерен биргән унсигез яшьлекләрнең моңа хакы бар*[1].

«Минем сиңа әйтер сүзем бар» атамасын алмашлыктан һәм тартым кушымчаларыннан арындырып кыскартырга һәм чираттагы җөмлә белән охшашрак яңгыратырга мөмкин, әмма без алай эшләү ягында тормыйбыз, чөнки «Әйтер сүзем бар» – шактый шаблон сөйләм берәмлеге. Элеккерәк елларда ул рубрика исеме сыйфатында да күренгәләде. Димәк, «Сиңа әйтер сүзем бар» вариантын сайлау уңышлы булыр. Текстта мөрәҗәгать объектлары күплеккә бәйле рәвештә, аны «Сезгә әйтер сүзем бар» рәвешенә дә үзгәртергә мөмкин, әмма, тәүге абзацта сөйләм адресаты берлектә килгәнгә, ул атамага шулай ук өстенлек бирмәдек.

«Мин»нең атамада урын алуы, бер караганда, текст дәвамында кабатлануы һәм шул сәбәпле ассызыклануы аркасында аклана да. Исемнән кыскартсак та, әлеге алмашлыкны төп тексттан тәмам юкка чыгару кайбер җөмләара бәйләнешләргә һәм әсәр ритмикасына зыян салачак. Билгеле бер аралыкта кабатланып килүче «мин»нең төрле адресатлы абзацларны үзара бәйләүдә дә, текстка бөтенлек тойгысы бирүдә дә, аны ритмик буыннарга бүлүдә дә роле зур. Аталган алмашлык тәүге кече күләмле абзацта – якын, ә икенче зур абзацта ерак аралыкта кабатланганны да билгеләп узыйк.

Беренче абзац бер-берсеннән аерылырга тиешле ике мөһим яңалык алып килә. Аларны ирештерүче җөмләләр

---

[1] *Кадыйрова Лилия.* Минем сиңа әйтер сүзем бар // Матбугат.ру. – 2009. – 04.05.

төзелеш ноктасыннан шактый төрле. «Мин» якын аралыкта кулланылмаган һәм кулланылырга да мөмкин булмаган соңгы җөмләне кыскарту яңгырашны камилләштереп җибәрәчәк. Әгәр автор өчен мөһим икән, аны башка рәвештә язарга яисә икенче урынга күчерергә, аерым абзац рәвешендә калыплаштырырга да була. Калган өлешне дә бердәйрәк текст берәмлекләреннән оештырып, абзацның хиссилеген тагын да арттырырга мөмкин:

*Сәлам, дустым. Мин кайттым. Ә син мине үлгән дип уйлаган идең... Минем һәйкәлгә чәчәкләр китерә идең...*

«Мин»нең якынча тигез буыннар калыплаштыруын теләгәндә, әлеге алмашлыкны һәр өч яңа төшенчә артыннан куллану уңышлы:

*Сәлам, дустым. Мин кайттым. Ә син, мине үлгән дип уйлап, минем һәйкәлгә чәчәкләр китергәнсең... Мин үлмәдем, бүген дә миңа унсигез...*

Текстның тагын да шигъририрәк яңгырашына алгы җөмләләрне кыскартып, күләмдә яраштыру һәм поэтик әсәрдәге ритмик буыннарга тагын да якынайту, ә соңгыларын озынайта һәм лириграк итә бару, логик басымнар ярдәмендә ирешәбез:

*Сәлам, дустым. Мин кайттым. Мин исән. Миңа – унсигез. Син менә өлкәнәйгәнсең. Минннән алтмыш дүрт яшькә өлкәнәйгәнсең. Мине үлгән дип уйлап, һәйкәлемә чәчәкләр китергәнсең...*

Түбәндәге өзектә дә хис градациясе җөмләләрнең – озыная, фикернең киңәя баруына бәйле:

*Кичер мине, Сөеклем! Ялгызлыкта үткән яшьлегең өчен. Озак көттереп тә, яныңа кайта алмавым, хыялларыбызның тормышка ашмавы өчен кичер. Җирдә чын сөю барлыгына икеләнүчеләргә, дәлил итеп, мин Сине күрсәтер идем. Гомер буе мәхәббәткә тугры булып калган изге җан,*

*озын чәчләреңнән иркәләүче назлы җил булып кайттым мин синең яныңа.*

Тулы текстка хас хиселеккә автор зур югалтуларны яисә эндәшләрне бер-бер артлы тезү, үлгән кешенең үзенә генә түгел, башкаларга да иң кадерле булган затларга мөрәҗәгать итүе, туган илдән еракта торып калуы кебек эш-хәлләр турында сөйләү аша ирешкән. Аны һәр кеше үзенчә тоя, чөнки эндәш объектларының авторга, укучыга кадерлелек дәрәҗәсе төрле. Текстта адресатларның «мин»гә якынлыгы шушы эзлеклелектә арта бара: *Дус, Ил, Ана, Сөекле…* Кемдер текстны, *Әнкәй* эндәше ахырга калса, хислерәк санар. Эндәшләрне *Дус, Сөекле, Ана, Ил* эзлеклегендә бирү исә авторга югары гражданлык хисләре хаслыгын күрсәтүгә булышыр.

Инде нәсер авторына «мин»нең яшен күрсәтү мөһим дип санап, тәҗрибә рәвешендә, янәшә торган ике абзацны шушы рәвешчә үзгәртик:

*Сәлам, дустым. Мин кайттым. Алтмыш дүрт елдан соң кайттым. Үлгән дип уйлап, һәйкәлемә чәчәкләр китерә идең... Мин унсигездә килеш кайттым...*

Күргәнегезчә, бу очракта хис мәгънәви басымнарның яңа информациягә төшүе аркасында көчәйгәннән-көчәя бара. Прозаик әсәрдә тема-рема бәйләнешләрен кору гына да хис тудыруга ярдәм итә ала икән.

*Мин яшәргә хаклы идем, мин яшәргә тиеш идем. Унсигездә үлеп буламы?! Минем бик-бик нык яшисем килде.* Бу өзектә хис көчәйтүче, үзгәртүче чаралар сыйфатында яшәргә хаклылыкны ассызыклау, яшәү сүзен еш кабатлау, сорау-җавап алымы сайланган. Ә менә хәзер китерәсе җөмләдә ритмик яңгырашка бигрәк тә уртак фигыль формалары илтә: *Дөньяны кочасы, тормышны яратасы, якты хыялларны чынга ашырасы, каядыр очасы, биеккә-биеккә күтәреләсем килгән вакытта /…/.* Бер үк төслегә әйләндереп бетерик: *Дөньяны кочасы, тормышны яратасы, хыялларны*

*чынга ашырасы, каядыр очасы, биеккә күтәреләсе килгән вакытта /.../*

Сез укып узган нәсерне хисси итүче чаралар эчендә инверсия дә бар. Бер генә мисал китереп узыйк: *Фани дөньядан киткән якыннарыгыз өчен дога кылганда безне дә искә алыгыз сез.* Нәсердә инверсияләрнең очравы автор алдагы җөмләләрдә сайлаган ритм таләбенә дә бәйле булырга мөмкин. Шул ук вакытта инверсия үзе дә әсәр башыннан ук сөйләмне бер ритмик агышка көйләп җибәрә ала. Әйтик, без нәсерне «Дустым, сәлам!» рәвешендә башласак, укучы бөтенләй башка хисләр кичерер, яңгыраш гадәтиләшер, көндәлек сөйләмнекенә тартыр иде. Ул чагында автор әлеге язу манерасыннан тиз генә чыга алмаска да мөмкин.

Редакторның каләм иясенә текстны камилләштерәчәк, кызыклырак итәчәк киңәшләр бирә алырлык кеше булуы кирәк. Ул чагында язучы мөхәррир тәкъдимендәге вариантларны кәгазьдә башкарып карар һәм иң отышлысын сайлап алыр. Иҗатларын бигрәк тә интернеттагы шәхси сайтлар, блоглар аша укучыга ирештерүчеләрнең әлегә мондый мөмкинлекләре юк дип уйлыйк.

Тезмә текстларда, мәсәлән, шигырьдә ритм белән рифма алдагы сүзләрнең урнашу тәртибен билгеләүче төп сәбәпләрдән санала. Бу урында һәр шагыйрьгә хас үзенчәлекле поэтик синтаксис барлыгын билгеләргә кирәк. Әйтик, рифмаларны фигыль хәбәрләрдән төзүче һәм гадирәк алымнар белән эш итүче авторларда җөмләнең традицион тәртибе бик бозылмый. Инверсия күренеше – шигырь алымнарының иң оригинале, иң киң кулланылыштагысы, иң борынгыларыннан. Ул Дәрдмәнд кебек зур шагыйрьләрнең иҗат лабораториясендә стиль формалаштыручы төп алымнардан саналырга хаклы. Шагыйрьнең инверсия мул кулланылган «Кораб» шигыреннән бер өзек:

*Шаулый диңгез...*
*Җил өрәдер...*

*Җилкәнен киргән кораб!*
*Төн вә көндез*
*Ул йөзәдер:*
*Юл бара ят ил карап...*

Татар шигырендәге инверсия күренешләре дә телебезнең синтаксик нормаларыннан читтә тормый, чөнки тезмә тексттагы сүз тәртибе грамматик яктан ирекле булса да, стилистик яктан алай түгел. Ритм, рифма сайланышы белән, бөтен җөмлә кисәкләренең дә, хәтта иярүче сүзгә янәшә килү чарасы белән бәйләнгәннәренең дә, грамматик инверсиясе барлыкка китерелә. Инверсия гадәти сөйләмдә бик актив кулланыла, чөнки үзара аралашучыларга, мәгънә бирү максатына бәйле рәвештә, теге яки бу сүзне доминанта позициягә бастырырга, ә моның өчен аның җөмләдәге гадәти урынын алмаштырырга туры килә.

Теләсә кайсы прозаик текстны бары тик инверсия юлы белән генә дә поэтик яңгырашлы итәргә мөмкин. Шигырь техникасына өйрәтүдә чәчмә әсәрне үз эчендәге сүзләр белән рифмалаштыру, инверсия ярдәмендә тезмә рәвешенә китерү алымнары да файдаланыла.

Әлбәттә, грамматик фактор, нәфис текстларда гына түгел, көнкүреш сөйләмендә дә зур көчкә ия. Сүзләрнең җөмләдәге урыннарын билгеләүдә нәкъ менә аның роле зур. Шул ук вакытта җанлы сөйләмдәге сүз тәртибе әдәбинекеннән ирекләрәк. Димәк, матур әдәбиятны редакцияләгәндә, аларда урын алган геройларның монологларын, диалог-полилогларын камилләштергәндә, моны истә тотарга кирәк. Җанлы сөйләмнең сүз урынын сайлауда иреклелеген күп очракта анда кулланыла торган өстәлмә конструкцияләр билгели. Мондый төзелмәләр тууга кайвакыт сөйләм теленең алдан уйланылмаганлыгы яисә сорау-җавап рәвешендә оешуы да сәбәп була.

Гадәти сөйләмдә җөмләнең төрле калыплары очрый, алар кайвакыт нәфис текстларга да үтеп керә. Матур әдәбияттагы отышсыз кебек күренгән инверсия күренешләрен галимнәр,

бары тик рус теле тәэсире белән бәйләп карап, еш кына ялгышалар да.

**Лексик катлам белән эш.** Тел чараларыннан лексемаларны да стилистик ноктадан кулланырга мөмкин. Матур әдәбиятта омонимия, синонимия, антонимия, паронимия күренешләреннән мул файдаланалар. Шулардан антоним һәм синонимнарга тукталып узыйк.

***Синонимнар*** (грек. *synonуmos* – бер исемле) – мәгънәләре ягыннан тәңгәл килгән яки якын торган сүзләр. «Синонимнар «бер үк төшенчәне белдереп, мәгънә төсмерләре һәм стилистик бизәкләре белән аерылып торалар» дип аңлату да очрый. Чыннан да, синонимнар сүзнең төп вазифаларына нигезләнәләр: чынбарлык күренешләрен атыйлар һәм төшенчә белдерәләр»[1].

Мәсәлән, *куныч, балтыр* синонимик оясындагы сүзләр *итек, оек* кебек сүзләр янында яки шулар турында сүз барган контекстта бер үк мәгънә аңлатып, берсе урынына икенчесе килә ала: *итек балтыры, оек балтыры, кыска яки озын балтырлы* һ.б. телдә еш кулланыла, әдәби әсәрләрдә күп кенә язучыда очрый, ләкин төп мәгънәне куныч сүзе ачыграк бирә, аның мәгънәсе, кайсы контекстта яки нинди сүз янында килүенә карамастан, конкретрак һәм бер генә. Шуңа күрә ул синонимик ояда баш сүз – ***доминанта*** итеп китерелә[2].

Синонимнар турында сөйләгәндә, мәгънә төсмерләрен, ягъни сүзнең семантик үзенчәлекләрен, мәгънәне, төшенчәне барлыкка китерүче билгеләр бердәмлеге барлыгын истә тотарга кирәк. Әйтик, тугандаш халык төрекләрдә аралашу вакытында һәр нәрсәне «чок гүзәл» рәвешендә шаблонлашкан бәяләү, хуплау гадәте бар. Татар кешесе гүзәл дип –

---

[1] *Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле: югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. – 3 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б. 50.

[2] *Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С.* Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999. – Б. 3.

каршысыннан узып киткән кызны, ә чибәр сүзе белән аның йөзен бәяләр, кылган гамәлләрен исә яхшы дип атар.

Галимнәр сүз мәгънәсендә төп һәм өстәмә билгеләр була дип саный. Синоним лексемаларны бер-берсеннән аера торган мәгънә төсмерләре алар. Болардан тыш, сүзнең сөйләмдә теге яки бу стилистик максатка хезмәт итүенә, функциясенә генә карый торган төсмерләре дә бар[1]. Өстәмә төсмерләр лексемаларның тамыр мәгънәләрендә үк чагылыш таба (*калку, күтәрелү, өскә менү...; иелү, бөгелү...*). Синонимнарның тәңгәл булмаган мәгънәләре градация ясауга хезмәт итә (*елый, үкси, үкерә...; капкалау, тамак ялгау, ашау, убыру...*). Тәңгәл мәгънәгә нигезләнгән синонимия сөйләмебездәге төрле телләргә караган сүзләр арасында аеруча еш күзәтелә: *семья – гаилә – фамилия; моназара – диспут – бәхәс; төймә – сәдәф....* Синонимик рәттәге кайбер сүзләр аерым урынчылыкта гына аңлаешлы булырга мөмкин. Әйтик, киемдәге *молния*не (русча тагын бер варианты: *застёжка*) татарлар хәзер күбрәк *замок* дип йөртә, әмма элегрәк *шытыр* (Казан арты), *каптыргыч* (гомуми кулланышта) һәм башка исемнәр белән белдерүләр очрый иде. Хоккей уйнауда кулланылган *шайба*ны, *алка* вариантыннан тыш, *шәрә* яисә башка исемнәр белән, ә *кәшәкә*не (*хоккей таягы*н) *шәрә таягы* дип атау киң таралган иде.

Синонимнарның берише телдә – ***актив,*** икенчеләре ***пассив*** кулланылышта йөри. Мәсәлән, XX гасыр башында *сәгадәт, фамилия* сүзләренең мәгънәсе һәркем өчен ачык булган, алар, үзара берегеп, киң кулланыштагы гыйбарәләр дә ясаган һәм әдәби әсәр исемнәрендә дә чагылыш тапкан. Бу очракта мисалга Г. Исхакыйның «Фамилия сәгадәте»н («Гаилә бәхете») китерә алабыз.

Борынгы текстларны редакцияләгәндә, сүзне, активлыгын югалткан дип, синонимына алмаштыра алмыйбыз. Семья

[1] *Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С.* Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999. – Б. 4.

сүзен яшьләр күбрәк кулланганга карап, үзебезнеке булып киткән көнчыгыш алынмасы «гаилә»дән дә баш тартырга ярамый, чөнки бу татар теленең тагын да тизрәк ярлылануына, руслаша баруына китерәчәк.

Синонимлыкны сүзләрнең бер-берсен алмаштыра алулары билгели. Алынмаларга чагыштырмача бай ана телебездә тәңгәл яисә охшаш мәгънәдәге сүзләр шактый. Синонимнарны тикшергән галимнәр татар телендә алар барлыкка китергән ояларның 15 меңнән артып киткәнлеген әйтә. Язганда һәм редакцияләгәндә охшаш мәгънәдәге сүзләргә ихтыяҗ еш кына якынча синонимнарның, контекстка карап, бер-берсен алмаштырып килә алуына таянып канәгатьләндерелә.

Тәңгәл төшенчәләрнең, алдагы мисаллардан да күренгәнчә, вакытлар үтү белән, я берсе активлаша, я икенчесе. Теге яки бу сүз инде бөтенләй кулланылмый башларга да мөмкин. Шул ук вакытта кире процесслар да күзәтелә. Үзгәртеп кору елларына килеп кергәч, актив кулланыштан төшкән яисә онытылган бик күп сүзләр кире кайтарылды. Мәсәлән, әдәби җәмәгатьчелектә мөхәррир сүзе нык активлашты, әмма хәтта ул да редактор төшенчәсен тулысынча алмаштыра алмады. Алар элеккечә үк янәшә кулланылуларын дәвам итә. Сөйләмгә бер кереп яңадан чыккан сүзләр дә була. Бу урында үз вакытында хәтта халык җырларында да урын алган «митрапалитин» *(Их, митрапалитин, / Яратам, нихәл итим)* сүзен (метро) мисалга китерергә мөмкин.

Үзгәртеп кору еллары башында, сөйләмебезне алынма төшенчәләрдән арчу, сафландыру, дәреслекләргә, уку әсбапларына искергән терминнарны кире кайтару максатыннан, галимнәр, педагоглар, методистлар гади халыкка аңлашылмаган, гадәттән тыш ят тоелган сүзләрне яңадан куллана башлады. Алар *һәндәсә* (геометрия), *фәза* (пространство), *җәдвәл* (таблица, расписание) һәм башка бик күп сүзләр уку-укыту барышында көндәлек сөйләмдә дә активлашыр дип фаразлады һәм ялгышты. Журналистлар, әдипләр, мәсәлән,

тамыр мәгънәсеннән чыгып ясалган *санак* һәм оригиналдан үзгәртелгән *кәмпитер* сүзләреннән, башка шуныңише «заманча» лексемалардан вакытлы матбугатта еш файдаланды, әмма алар да киң катлам укучы арасында таралмады, күпләр өчен шул ук *санак* сүзенең дә мәгънәсе аңлаешсыз булып калды.

Әлбәттә, югары уку йортларында физиканы татарча китаплардан өйрәнүчеләр һәм фәннәрне үз телебездә укытучылар арасында әлеге дә баягы «фәза»ны һәм русчадан алынмаган башка терминнарны куллану бар, әмма гади халыкка аларның эчтәлеге элеккечә үк билгесез. XX гасыр башы матур әдәбиятында еш очраган *манзара* (күренеш), *моназара* (бәхәс) кебек сүзләрне ана телебездә сөйләшүчеләрнең күпчелеге, нигездә, контекстта гына аңлый, ә *казый* (судья), *сәркатип* (секретарь) төшенчәләрен аңласалар да, алардан файдаланырга ашкынып тормый. Шул ук вакытта, бигрәк тә газета материалларында, дәреслекләрдә активлаштырылулары сәбәпле, *инкыйлаб* (революция), *мөгаллим* (укытучы) лексемалары күпләрнең кулланылыштагы сүзлек байлыгына әйләнде.

Редактор, татар теленең үз лексемалары яисә үзенекенә әйләнгән гарәп алынмалары булганда, авторны рус сүзләрен куллануны киметергә чакырырга тиеш, әмма һәр очракта да әдиптән теге яки бу сүзне татарчалаштыруны таләп итү кирәкми. Бу хезмәттә дә *редактор* (мөхәррир), *профессия* (һөнәр) һәм башка алынмалар очрый, чөнки алар, темага бәйле рәвештә, бер үк төшенчәләрне кабатлаудан качарга булыша.

Тел һәрвакыт үзгәреш хәлендә, шул исәптән ул семантик үзгәрешләр дә кичерә. Аның үсеш тенденциясе тәгаенлекне таләп итә. Галимнәр, ул, бердән, теге яки бу төшенчәне анык һәм төгәл бирергә омтылуда чагылыш тапса, икенчедән, фикерне кыска әйтергә, кабатлаулардан, артык сүз һәм формалардан котылырга тырышуда күренә, ди.

Синонимнар халык тарафыннан тудырыла, синонимик рәтләр гасырлар дәвамында формалаша, һәм алар бүгенге көндә дә чит телләрдән кергән лексемалар хисабына арта.

Моның төп сәбәбе: бигрәк тә Европадан узган төшенчәләрне татарчалаштыру тукталу. Соңгы елларда алынмалар арасында инглизнекеләр зур урын ала башлады. Бу үзгәрешләр язма сөйләмдә дә чагылмый калмый. Төркия белән бәйләнешләр ныгыгач, телебезне ныграк төркиләштерү максатыннан, каләм ияләре *очак* (самолёт) кебек мәгънәсе һәркемгә ачык аңлаешлы сүзләрдән текстларда файдаланса да, аларны халык арасында даими кулланышка шулай ук кертә алмады.

Алынмаларны татарча төшенчәләргә яисә төрки сүзләргә алмаштырган редактор да телнең заманга хас торышын исәпкә алырга тиеш. Бүгенге вакытта, яшь буыннар тулы канлы милли сөйләмне аңламый дип, дәреслекләр өчен сайланган нәфис текстларны гадиләштерүне тәкъдим итүчеләр бар. Моның белән килешергә ярамый, алай эшләгәндә, татар теле үзенең гасырлар дәвамында тупланган сөйләм байлыгын тәмам югалтачак һәм әкренләп үсүдән генә түгел, яшәүдән дә туктаячак. Әлеге проблеманы чишү сүзлек белән эшне көчәйтү, дәреслекләрдә аларга элекке вакыттагыдан да зуррак урын бирү аша хәл ителергә тиеш.

Синонимнар телнең ни дәрәҗәдә бай икәнлеген бик ачык күрсәтә. Кешенең сөйләм һәм аралашу әдәбен үстерүдә аларның роле бихисап зур. Бердән, синонимнар мәгънә төсмерләрен җиткерергә булыша, сөйләмне матур яңгырашлы итә. Синонимик рәттән дөрес файдаланмау сөйләмне ярлыландыра, шаблонлаштыра, сүз куллануда ялгышларга да китерә. Түбәндә, фикеребезгә дәлил рәвешендә, Тукайның балалар өчен язган «Кызыклы шәкерт» шигыренең тәүге строфасын китерәбез:

*Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың берлә тор;*
*Аума, аума! Туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!*

Китерелгән өзектәге фигыльләр арасыннан *туп-туры тор – төз утыр* кебек тәңгәл синонимнарны күрсәтергә мөмкин. Алар янәшәсендә килгән башкалары исә кечкенә

Акбайга боерылган дөрес итеп арт аякта торуның ниндилеген (аумыйча, яхшы итеп) аңларга булыша.

Телнең гасырлар дәвамында тупланган байлыгын, сәнгатьлелеген билгели торган лексик синонимнар бервакытта да авторның һәм аның текстын камилләштерүгә алынган редакторның күз уңыннан читтә калырга тиеш түгел. Сүзне кулланудагы төгәлсезлекләрне яисә кабатлауларны тапканнан соң, мөхәррир аларны башкалары, контекстта дөрес мәгънә җиткергәннәре һәм матур яңгыраганнары белән алмаштыра.

Телдә синонимнар күп булса да, алар арасыннан иң төгәлен, теге яки бу стильне бозмаганнарын, текстка туры килгәннәрен сайлау шактый кыен. Татарча текстларны бигрәк тә *булу* сүзеннән коткару вакытны күп ала, чөнки ул текстларда гыйбарәләр составында кайчак чиктән тыш еш очрый. Шул ук вакытта синонимнар ярдәмендә *булу* кергән җөмләләрне берничә вариантка үзгәртергә мөмкин. Әйтик, автор: *Аннан биргән акчаңны кире алып булмый*, – дип яза. Ул әйткән җөмләне *Аннан биргән акчаңны кире алу <u>кыен</u> (читен, авыр, мөмкин түгел...)* – дип үзгәртү юлы бар. Күргәнегезчә, бу очракта синонимик рәттән файдаланып, төзәтү вариантларының санын арттырдык. Ә хәзер җөмләнең ике сүзен тулысынча алмаштырыйк: *Аннан биргән акчаңны кире кайтару кыен (читен, авыр, мөмкин түгел...)* Үзгәртелгән соңгы варианттан *кире* сүзен кыскартырга да була. Кабатланган төшенчәләргә мәгънәдә тәңгәл сүзләр тапмаганда, аларны әнә шулай контекстуаль синонимнарга алмаштырырга, сүзләрне яңадан үзара ураштырырга туры килә.

Татар теленең үсеш-үзгәреше, лексик катламнарының баюы шәхси һәм милли стильләрнең калыплашуына, әдәби сөйләмнең халыкныкына якынаюына китерә. XIX–XX гасырлар чигендә генә ныклап формалашып җиткән татар прозасында тора-бара чынбарлыктагы күренешләрне җанлы сөйләм аркылы бөтен нечкәлекләре белән тасвирлау зур урын били башлый. Алынмалар белән чуарланган шигърияттә татар

сүзләренең күбәюе, үз чиратында, анда синонимик рәтләр ешлыгын да арттыра. Кыскасы, нәфис стиль үсешендә лексик чаралар, шул исәптән синонимнар да гаять зур эш башкара.

Әдәби редакторлык хезмәтенә багышланган дәреслекләрдә, сүзлекләрдә ***антонимнар*** терминына анык билгеләмә бирелгән. Белгәнебезчә, капма-каршы мәгънәне белдерә торган сүзләрне антонимнар дип йөртәләр[1]. Ана телебездә дөнья күргән белешмәлекләрдә, шул исәптән «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә[2] дә, лексикологиягә кагылышлы фәнни хезмәтләрдә дә бу төшенчәгә шундый ук эчтәлек салынган.

«Антонимнар булып логик бәйләнешләре ягыннан берберсенә туры килгән сүзләр генә тора ала. Мәсәлән, ***Кайгылы*** *чагымда килмәде. / Авыр булды, түздем. /* ***Шатлыклы*** *чагымда килмәде. / ...Арабызны өздем* (Р. Фәйзуллин) җөмләсендә шатлыклы – кайгылы антонимнары арасында билге буенча логик бәйләнеш урнашкан.

Шулай ук семантик һәм грамматик мәгънәләр ягыннан да антоним сүзләр арасында уртаклык күзәтелергә тиеш. Шуңа күрә барлык сүзләрнең дә антонимик парлары булмаска мөмкин. Мәсәлән, конкрет мәгънәдәге исемнәр, саннар, кайбер алмашлыкларның антонимнары юк: өстәл, дивар, икешәр, уналты, ничә, үзе һ.б. Антонимик мөнәсәбәткә керә алу үзенчәлеге, иң беренче чиратта, ниндидер билгене белдергән сүзләргә хас*: озын – кыска, киң – тар, зур – кечкенә, яхшы – яман, күп – аз, туры – кыек, күмәк – ялгыз, куе – сыек, батыр – куркак* һ.б.»[3]

---

[1] Стилистика и литературное редактирование: учебник / под ред. проф. В.И. Максимова. – 3-е изд., перераб. и доп.– М.: Гардарики, 2007. – С. 183.

[2] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 1 т. / ред.: Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров, Ш.С. Ханбикова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – Б. 60.

[3] Татар лексикологиясе: өч томда. 1 т. / проект җит.: М.З. Зәкиев; ред.: Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – Б. 171.

Диалектика кануннарына нигезләнгән тормышта антонимнарның һәр өлкәгә караганнары бихисап. Ел фасыллары, кеше холкы, эш-гамәлләр, халәтләр, төсләр... – барысында да каршы позицияләрдә торган сыйфатларны, күренешләрне, үлчәмнәрне табарга мөмкин. Димәк, каләм иясе, ни хакында гына язса да, аларны игътибарга алачак һәм лексик чаралар ярдәмендә чагылдырачак.

Антонимнардан аеруча матур әдәбиятта мул файдаланалар. Мәсәлән, Тукайның күпсанлы капма-каршы иҗтимагый күренешләр, үзара каршылыклы көндәлек эшләр, төрле социаль катламнар (байлар – ярлылар; идарәчеләр – гади халык, ир-атлар һәм хатын-кызлар...) сурәтләнгән, контрастларга корылган шигъриятендә, үткен телле публицистикасында антонимик парлар шактый. Түбәндә Г. Тукай иҗатыннан тормышның каршылыклардан торганлыгын чагылдырган, төрле антонимнарга бай «Ит базарында» әсәрен китерәбез:

*Җиһанда «сез» сүзе бар «без»гә каршы,*
*Шикәр, бал бар керән һәм тозга каршы.*

*Мокабил барча әшья бер-беренә:*
*«Бәянел хак» чыга «Йолдыз»га каршы.*

*Әгәр тезсәм, тезәргә күп мисаллар:*
*Караңгы төн туа көндезгә каршы.*

*Вә «Ялт-йолт» та һәр унбиш көн саен бер*
*Чыга тәмсез «Чүкеч» һәм «Без»гә каршы.*

*Мөселман казлыгы чыккан базарга –*
*Шәригатьтә хәрәм дуңгызга каршы.*

Антонимнардан файдалану публицистика телен үткенәйтеп җибәрә. Әлеге тел-сурәтләү чаралары еш кына мәкалә исемнәрендә чагылыш таба, кайберләре, мәгънә яссылыгында гына түгел, яңгыраш ноктасыннан да үзенчәлекле һәм матур була: «Кала белән сала», «Алган белми, биргән белә», «Утка-суга кергән ул»... Антонимнар урын алган

халык мәкальләре арасында исем өчен уңышлылары күп. Әйтик, авыл тормышын мактаган, каланыкына каршы куйган язманы: «Шәһәрнең тавыгы булганчы, авылның әтәче бул» дип исемләргә мөмкин. Редактор антонимнарның һәркайда – төп тексттамы, атамадамы – отышлы һәм отышсыз кулланылган очракларын күрә һәм фикер җиткерүдәге, образ тудырудагы рольләрен бәяли алырга тиеш.

Антонимнар иҗатчыларга предметларның, җан ияләренең, процессларның, күренешләрнең сыйфат-билгеләрендәге, хәрәкәтләрендәге каршылыкны тасвирлаганда, озынлыкларын, күләмнәрен, урнашу рәвешләрен чагыштырганда, төрле аралыктагы вакыт төшенчәсен белдергәндә һәм башка очракларда ярдәмгә килә.

Антонимнар телнекенә һәм сөйләмнекенә аерыла. Беренчесенә тел системасына караган һәм галимнәр тарафыннан махсус сүзлекләрдә теркәлгән антонимнар керсә, икенчесенә аерым автор текстында гына капма-каршы мәгънәдә килгән, ә башка очракларда антонимик төшенчәгә ия булмаган сүзләр керә. Текстны, телнеке дип йөртелгәннәрдән бигрәк, каләм иясе тарафыннан тудырылган контекстуаль антонимнар аеруча үзенчәлекле итә. *Ул – йокымсырап утыручылардан, дәшми калучылардан түгел, һәрвакыт чәчрәп чыгарга, баскан җиреннән ут чыгарырга яратты* (*Зөһрә Мостафина.* Мин-гап-гади авыл малае // Шәһри Казан. – 2008. – 30 сент.) җөмләсендә журналист сөйләм антонимнары ярдәмендә героен бик уңышлы характерлый.

Сөйләмдә сүз белән сүз яисә фразеологизм, фразеологизм һәм фразеологизм һәм башкалар арасында антонимик мөнәсәбәтләр урнашырга мөмкин. Мәгънәләре капма-каршы булган фразеологик берәмлекләрнең күплеге татар теленең үзенчәлекле ягы санала. Антонимнар шулай ук тәгаен төшенчәләрдән дә, абстракт мәгънәле сүзләрдән дә ясала. Әдәби әсәрләрдә тәгаен төшенчәләр абстрактлашырга да мөмкин. Моңа мисалга Г. Тукайның «Күңел» шигырендә физик

халәтне, форманы чагылдыручы бөтен һәм сынган сүзләренең абстрактлашуын китерергә яраталар:

*Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!*
*Күп сөекледер бөтеннән – тәңрегә сынган күңел.*

Контрастлар шагыйре Г. Тукай иҗатын антонимнар яссылыгында өйрәнү гаять кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Аның бер үк әсәрендә я төрле, я охшаш антонимик мөнәсәбәттәге берничә сүз очрарга мөмкин. Түбәндә китерелгән «Картлар» шигырендә ике хәрәкәт антонимик парын күрсәтергә була:

*Шаулый-шаулый уйныйбыз без кайчагында картаны,*
*Без отабыз, оттырабыз – «тем»мы шунда, «банка»мы.*

*Кем көлә, кем кычкыра, һичбер өзексез шау да шау;*
*Бу хозурдан онтыла кайчак эчү берлән ашау.*

*Акчалар уйнарга дәртне кузгатадыр шалтырап,*
*Күзне кыздыргыч көмеш, алтын ятадыр ялтырап.*

Антонимнарны сүз төркемнәренә мөнәсәбәттә дә төркемлиләр. Әйтелгәннәрдән тыш кайберәүләр, мәсәлән, В.Н. Комиссаров аларны капма-каршы мәгънәдә торучы һәм, үзара каршы куелып, бер-берсен кире кагучы сүзләргә бүлә[1]. Күргәнебезчә, беренче типтагы капма-каршы полюста торучы сүзләр арасында өченче сүз юк, ә икенчесендә бар, чөнки төшенчәләрне «А» һәм «А түгел» формасына салырга мөмкин. Кояшлы, кояшлы түгел кебек каршылык мөнәсәбәтенә керү – шуның бер мисалы.

Капма-каршы мәгънәдә торучы сүзләр логика фәнендә бер-берсен сыйдыра алмаган һәм юкка чыгарган төшенчәләр дип санала. Мәсәлән, *ак – ак түгел, яхшы – яхшы түгел, биек – биек түгел.* Кайберәүләр карашынча, имеш, шунлык-

[1] *Комиссаров В.Н.* Проблема определения антонима // Вопросы языкознания. – 1957. – № 4. – С. 64.

тан аларга икенче төшенчәләр бирелгән *(кара, начар, тәбәнәк...)*. Бу – әлбәттә, сүзләр ясалышын гадиләштереп күзаллау. Әдәби әсәрләрдә кире кагучы сүзләрне капма-каршы мәгънәдәге сүзләргә алмаштыру кабатланулардан коткара, лексик кырны киңәйтеп һәм баетып җибәрә, шунлыктан редакторларның мөһим төзәтү чарасы булып тора.

В.И. Максимов редакциясендәге дәреслектә антонимнарның структур яссылыктагы бүленеше дә күрсәтелә:

• төрле тамырлы антонимнарга *(батыр – куркак, тиз – акрын);*

• бер тамырлы антонимнарга *(фаразлы – фаразсыз, сөтле – сөтсез)*[1].

Югарыдагы мисаллардан күргәнебезчә, мәгънә эчтәлеге кушымчалар ярдәмендә үзгәртелә. Алынма бердәй тамырлы антонимнар арасында башка конструкциядәгеләре дә очрый: *нахак – бинахак*. Галимнәр төрле тамырлы антонимнарны – ***лексик***, ә бердәй тамырлыларын ***грамматик*** антонимнар дип атый.

Редакцияләү барышында антонимнарның текстта башкарган вазифасы, мәгънә эчтәлеге, яңгырашы, кайсы телгә каравы, бер тамырлыларының сөйләмнең гомуми яңгырашына нинди тәэсир ясавы һәм башка яклары исәпкә алына.

Әдәби әсәрләрдәге лексемаларны алмаштыру, моның өчен антонимнар байлыгыннан файдалану пассивлаша башлаган сүзләребезне онытылудан сакларга булыша, фикерне эзлекле һәм тәэсирле итә, текстка укучы игътибарын да көчәйтеп җибәрә. Әйтик, автор болай язган булсын ди: *Нәгыймә түти базардан <u>мул сөтле</u> сыер кайтыр дип көткән иде, Габдрахман абзый капкадан <u>мөгезсез</u> җан иясен җитәкләп килеп керде.* Күрәбез ки, җөмләдә сыерның продукциялелеге тышкы кыяфәт билгесенә каршы куелган. Болай

---

[1] Стилистика и литературное редактирование: учебник / под ред. проф. В.И. Максимова.– 3-е изд., перераб. и доп. – М.: Гардарики, 2007. – С. 653.

эшләргә ярамый. Текстны шушы рәвешчә үзгәртергә мөмкин: *Нәгыймә түти базардан* <u>*чиләкләп*</u> *сөт бирәчәк сыер кайтыр дип көткән иде, Габдрахман абзый капкадан* <u>*чокырлап*</u> *эчерәчәген (яисә: эчерәчәк җан иясен) җитәкләп килеп керде.* Шушы ук текстны редакцияләгәндә, синонимнарга да мөрәҗәгать итәргә мөмкин: *Нәгыймә түти базардан* <u>*мүкләк*</u> *кайтыр дип һич көтмәгән иде, Габдрахман абзый* <u>*мөгезсез*</u> *сыер җитәкләп килеп керде.*

***Текст лексикасы белән эшнең*** дә үз тәртибе бар. Түбәндә аның бер схемасы бирелә:

- текстның сөйләм составын бәяләү;
- әсәрне сүз куллануддагы хаталардан арындыру;
- тар кулланылыштагы сүзләрне билгеләү һәм аларның текстка кертелүләрен үзең өчен нигезләп бару.

Канцелярия лексикасы, сөйләм штамплары, искергән сүзләр, неологизмнар, алынмалар, экзотизмнар, варваризмнар бик тар кулланышта йөри, шунлыктан мөхәррир хезмәт адресатын исәпкә алырга һәм теге яки бу төшенчәнең кайсы өлкәгә каравын белергә тиеш. Фәнни хезмәтләрдә специфик төшенчәләр күп очраса да, фәнни-популяр текстларда аларның санын мөмкин кадәр чикләргә кирәк. Текст белән эшләүченең терминнарның дөрес, гомумкабул ителгән язылышын, мәгънәсен белүе дә кирәк.

Кайсыдыр өлкәдән бик ерак торган мөхәрриргә әлеге өлкәгә караган хезмәттәге ялган фәннилек, уңышсыз теорияләштерү күренешләрен ачыклау, аларның әсәрнең сүзлек составында һәм фактик чагылышларын билгеләү кыен. Ул хәтта һәртөрле фәннәрдән күпмедер хәбәрдар кешегә дә авыр булырга мөмкин. Кыскасы, гыйльми язмалардагы җитешсезлекләр автор белән берлектә генә юкка чыгарыла.

Төшенчә һәм категорияләрнең мәгънәсен төгәл ачыклауда, аларны куллануның урынлы-урынсызлыгын билгеләүдә мөхәрриргә төрле белешмәлекләр ярдәмгә килә. Заманнар узган саен, кайбер төшенчәләрнең эчтәлеге үзгәргәнне дә

исәпкә алырга кирәк. Редактордан шулай ук гыйльми терминологиягә мөнәсәбәтле бәхәсләрне белү, аларның хәл ителешен күзәтеп бару, белешмәлекләрнең ышанычлылык дәрәҗәсеннән хәбәрдарлык сорала.

Нәфис тексттагы лексик катламны редакцияләүнең дә үзенчәлекләре бар. Бу вакытта бер әсәр эчендә төрле стильдәге сүзләр кулланылганмы-юкмы икәнлеккә игътибар итәләр. Моның өчен редактор сөйләм стандартларын яхшы белергә тиеш. Төрле стильгә хас лексика бер текст эчендә, хата рәвешендә генә түгел, әдәби алым буларак та очрый. Мәсәлән, ниндидер проза әсәрендә галим герой фәнни терминнар кулланып сөйләшергә мөмкин. Әгәр аның әйткәннәре күпчелеккә аңлаешсыз булса, әлеге төшенчәләрнең контекстта ачылуы яисә мәгънәләренең астөшермәләрдә бирелүе кирәк.

Соңгы вакытта, татар теленең актив кулланылыш җирлеге тараю аркасында, барлык халыкка аңлашылмаган сүзләрнең саны артканнан арта бара. Бу дәреслекләр төзегәндә зур кыенлык тудыра. Беләбез ки, балалар гына түгел, шәһәр ата-аналары да, хәтта бүгенге чор әдәбиятыннан хрестоматияләргә кергән әсәрләрдәге бик күп сүзләрне аңламый. Бер яктан, ул төр тупланмаларда астөшермәләргә каралган мәйдан чикләнгән, икенче яктан, баланың текстны яхшы аңлавы, яңа сүзләрне үзләштерүе кирәк. Мөхәррирләр моның икесен дә истә тота, әмма, беренче чиратта, искергән, татар сөйләмендә пассиврак файдаланыла торган сүзләрне аңлатып узарга тырыша. Аннан соң, мәйдан мөмкинлек биргәндә, телне начаррак белүчеләргә аңлаешсыз төшенчәләрнең дә эчтәлеген ача.

**Текст фонетикасын камилләштерү** дә билгеле бер схема буенча башкарыла**.** Мөхәррир иң башта сөйләмнең аваз ноктасыннан яңгырашына игътибар итә. Аңа куелган таләпләр исә басмага да, жанрга да бәйле. Шаблон җөмләләрдән корылучан күрсәтмәләрдә, инструкцияләрдә, эш кәгазьләрендә кабатлаулар еш очрарга, мөхәррир һәм укучылар тарафыннан җитешсезлек сыйфатында кабул ителмәскә дә мөмкин. Шулай да,

җаен тапканда, алардан котылырга кирәк. Бер үк сүзләрне янәшә куллану, әлбәттә, югарыда саналган хезмәт төрләрен дә бизәми. Дөрес, кайвакыт аларны һәм гыйльми текстларны кабатланмыйча гына язып та булмый.

Алынмалар сүзлек составында зур урын алып торган, шунлыктан синоним рәтләргә дә бай татар телендә язучыларның эше бераз җиңелрәк, кабатланган сүзләрне адекват мәгънәдәге синонимнарга алмаштыру мөмкинлекләре зур. Шул ук вакытта, әлеге текстларны башка телгә күчерденме, кабатлаулар саны арта. Дөрес, рус фәнни сөйләмендә терминнар кабатланышы, гомумән, бер үк төшенчәләрнең, шаблон җөмләләрнең күп очравы табигыйрәк санала.

Охшаш яисә бер үк авазлар ешлыгы кайвакыт тезмә текстларда да, чәчмә әсәрләрдә дә әдәби алым булып тора. Алардан бигрәк тә һәр аваз яңгырашында аерым мәгънә күргән символистлар уңышлы файдаланган. Димәк, теге яки бу әсәрне редакцияләгәндә, элек чыккан китапларны кабат басмага хәзерләгәндә, авторның иҗат юнәлеше дә истә тотылырга тиеш.

Шигъри текстта очраклы килеп туган, максатчан уйлап табылмаган аваз кабатлаулары – гадәти хәл. Еш кына алар, яңгырашны матурлатасы урынга, киресенчә, ямьсезләтеп җибәрә. Редакторның моңа игътибар итүе кирәк. Татар сөйләме өчен яңгырау авазлардан мул файдалану отышлырак. Шигырь өчен аеруча матурлардан тоелган [к] ның киң кулланышы татар теленең сүзлек составы белән үк билгеләнә. Ул аваз, әйтик, шигъри текстка табигый һәм очраклы рәвештә күпләп кергәндә дә, поэзия белгечләре әлеге күренешне авторның теге яки бу аһәңне тудыру өчен махсус сайлаган әдәби алымы дип билгеләп узарга мөмкин.

Бигрәк тә яшь авторлар, аерым хәрефләргә башланган сүзләрнең күплегенә таянып, шаян эчтәлектәге язмалар иҗат итәргә ярата. «Б»га, «т»га, «к»га, «с»га башланган сүзләрдән генә торган текстлар вакытлы матбугатта басылгалап тора,

чөнки аларны язу чагыштырмача җиңелрәк. Тел галимнәре хәзерге вакытка татар телендә «к» хәрефенә – 4894, «т»га – 3947, «с»га – 1930, «б» га – 1876 сүз теркәгән, ә менә «ы», «һ» авазларына башланган сүзләр бик аз булып чыккан.

Яңгырау авазлар текстның лириклыгын көчәйтеп җибәрә, колакка йомшак ишетелә, ә менә [ш], [т], [п], [х] авазлары күп килеп кергән текстлар татар кешесенә тупасрак тоела. Шул ук вакытта аларның да әдәби образ тудыруда әһәмияте зур. Алдарак та ишарә ясавыбызча, бигрәк тә «шартлаулы» саңгыраулар хәвеф тойгысын, табигать аномалияләрен, төрле фаҗигаләрне тасвирлауда мөһим роль уйный.

Ниндидер текст эчендә, бер үк сүзләрнең генә түгел, тамырдаш лексемаларның ешлык зурлыгы да кайсыдыр авазларның күбәюенә китерә. Татар сөйләме төрлелек белән матур, һәм ул шуңа омтыла да. Аларның төзәтүләре текстны гадиләштерә, язмада тел байлыгын күрсәтүне чикли, күптөрле кабатлауларга китерә. Бер үк вакытта сөйләмнең табигый матурлыгы да югала. Моны редакторларга аңлату шактый авыр.

Стилистик төзәтмәләр ярдәмендә, сүзләрне алмаштырып, сәнгать чараларын үзгәртеп, яңгыраштагы хаталардан котылу, әсәрнең тәэсирлелеген арттыру – редактор башкарган вазифаларның бик мөһимнәреннән, зур осталык сорый торганнарыннан.

Инде Суфия Мостафинаның «Бала чагым кире кайтыр кебек» шигыреннән алынган строфаны карап узыйк:

*Бала чакта йөргән сукмаклардан*
*Бер үтәсе килә яңадан.*
*Бер кабынып, күптән онытылган*
*Хисләрем дә кабат яңарган.*

Шигырьнең өч юлы да [б] авазына башлана. Бу махсус эшләнмәгән, билгеле. Текстта алардан тыш та «б»лар бар, һәм кабатлану максаты ачык булмаган әлеге аваз үзенә артык

игътибар иттерә. Җитмәсә, янәшә ике юлның тәүге сүзе уртак: «бер». Хәтта хәзер үзебез язган абзац кына да, «б»ның артык ешаюы аркасында, ямьсез яңгырый башлады. Аваз ноктасыннан уңышсыз мисалыбызда өченче юлның мәгънәсе һәм сүзләренең грамматик ярашуы турында да уйланасы бар. Җитешсезлекләр арту строфаның хисси тәэсирен шактый киметә. Текстны, бик кечкенә үзгәреш кертеп кенә дә, күпмедер яхшыртырга булыр иде:

*Сабый чакта йөргән сукмаклардан*
*Бер үтәсе килә яңадан.*
*Кабынган да сүнгән, онытылган*
*Хиснең барсы тагын яңарган.*

Яңгыраштa теге яки бу эффектка ирешү өчен махсус һәм уйлап кулланганда аллитерация поэтик техника алымы саналса да, охшаш тартыкларның очраклы рәвештә текст эчендә күпләп килүе һәрвакытта да әсәрне бизәми, кире эффект та тудырырга мөмкин. Түбәндә, аллитерациянең отышлы мисалы рәвешендә, Роб. Әхмәтҗановның «Богыллар» әсәре китерелә:

*Болында – богыллар,*
    *болында – бытбылдык.*
*Богыллар артында*
    *без икәү юк булдык.*

Шигырьдә «б» кабатлану болынны җанлы – хәрәкәттә күзаллата, бытбылдык авазларын имитацияли һәм шигырьнең образлылыгын көчәйтеп җибәрә.

**Фактлар белән эш тәртибе.** Мәгълүмати төгәллек, дәлилләрнең җитәрлек булуы бигрәк тә фәнни хезмәтләр өчен мөһим. Юриспруденциягә кагылышлы текстлар язганда да, теге яисә бу эш-хәлне раслаучы фактларга игътибарлылык сорала.

Әдәби редактор үз эшен башкару вакытында автор узган юлны тагын бер кат әйләнеп чыга. Әйтик, вакытлы

матбугатка мәкалә язарга тиеш журналист, ниндидер теманы ачу өчен, башта материал туплый, алар исә төрле өлкәләргә караган, тасвирлау объектын төрле яктан характерлаган булырга мөмкин. Шуннан соң каләм иясе мәкаләдә үзе тапкан информацияне, бигрәк тә фактларны кайсы урында һәм ничек кулланачагы турында уйлана, төрле вариантларын язып карый яисә алдан сайланганына туктала һәм башкарып чыга.

Кулына кульязма килеп кергән редактор да иң элек текстның мәгълүматилык дәрәҗәсен билгели, аннан соң кулланылган информация төрләрен ачыклый. Теманы ачу өчен, фактик материал җитәме, юкмы дигән мәсьәләгә дә җавап эзли. Әгәр мәкалә ошамаса, редактор теманы ачуның отышлырак вариантын тәкъдим итәргә мөмкин я автордан текстка өлешчә үзгәрешләр кертүне сораячак. Шулай да сөйләмне фактик яссылыкта редакцияләгәндә, мөхәррир, беренче чиратта, фактик төгәлсезлекләрне ачыкларга тиеш.

Еш кына ялгыш саннар автоматик рәвештә дә басыла, шул сәбәпле редактордан саннарга аеруча игътибарлы булу сорала. Ул, аларның төгәллегенә карата күңелендә шик туганда, иң башта автор белән элемтәгә керә, аннан кирәкле һәм ышандыргыч җавап ала алмаса, төрле белешмәлекләргә мөрәҗәгать итә, башкалар белән киңәшә, информацияне фәнни китаплар ярдәмендә ачыклый. Ул мәгълүмат җиткерү чарасы булган саннарны текст элементы сыйфатында дөрес куллануны да кайгырта. Мөхәррирнең даталар язылышына кергән соңгы үзгәрешләрне яхшы белүе зарур.

Редакторның үз эшендә, югарыда саналганнардан тыш, ышанычлы чыганаклардан гына файдалануы, статистиканы өйрәнүе, фактларны үзара чагыштыра белүе мөһим. Фактлар математик яисә башка төр тамгалар белән дә, билгеле бер төшенчәләр ярдәмендә дә җиткерелергә мөмкин. Әйтик, галимнәр яисә әдипләр Урта гасырлар дип тә язалар, бу тарихи этапны еллар аралыгында да күрсәтәләр. Әле бит

шушы ук чорны тар яисә киңәйтелгән тасвирлар ярдәмендә дә чагылдырырга була.

Һәрбер текстта очрамасалар да, эпиграфлар, башка төр цитаталар фактик материал буларак язма сөйләмдә актив кулланыла. Эпиграфлар, мәсәлән, төп өлешкә ачкыч бирә, авторның мөһим фикерен ассызыклый, текстның гомуми тональлеген, үзенчәлекле аһәңен билгели, тасвирланачак хәлләргә мөнәсәбәт белдерә. Редактор аларның нинди вазифа башкарганлыгын билгели алырга тиеш. Фикерне расламаган, ачмаган, ямьсез яңгыраган, мөһим булмаган «чит» текстларны әсәрдән сызып ташлау яхшырак.

Гыйльми хезмәтләрдә цитаталар автор идеясенең нигезлелеген ныгыту, статистик материал җиткерү, әсәрне кызыклырак, укылышлырак итү, теге яки бу карашның фәндә тотрыклылыгын күрсәтү кебек максатлардан кулланыла. Гыйльми хезмәтләрдә, гадәттә, өземтәләрне абруйлы шәхесләрнең язмаларыннан, ышанычлы чыганаклардан, белешмәлекләрдән, теоретик хезмәтләрдән китерәләр.

Цитаталарга бәйле хаталардан авторын дөрес атамау, чыганагын күрсәтмәү, текстка үзгәрешләр кертү, отышсыз кыскартулар кебек күренешләрне атап узарга мөмкин. Әле шунысы да бар: кайбер афоризмнар, канатлы сүзләр һәм башкалар язма әдәбиятта төрле авторларныкы буларак теркәлгән. Бу очракта башка вариантларны эзләвең, табуың хәерлерәк.

**Текст корректурасы (төзәтмәләре).** Тыныш билгеләрен төзәтү һәрбер редакциядә гадәткә кергән тәртиптә бара. Бу вакытта редакторлар да, корректорлар да нәшриятның гомумкабул ителгән нормаларыннан файдалана, корректурага куелган техник таләпләрне төгәл үти. Хаталарны төзәтүнең билгеле бер төрләре һәм тамгалары да бар. И.Б. Голубның мәгълүм хезмәтендә китап нәшриятларында кулланылган типик тамгалар мисалга китерелә[1].

---

[1] *Голуб И.Б.* Конспект лекций по литературному редактированию. – М.: Айрис-Пресс, 2004. – С. 104–111.

Кайбер шәхси нәшриятлар үз корректура тамгаларын эшләргә мөмкин, әмма алар редакторга һәм техник хезмәткәрләргә генә түгел, кулъязма авторына да ачык аңлашылырга тиеш. Моннан тыш, каләм иясенең шәхси корректура тамгалары булырга мөмкин. Таләпчән редакторлар автордан текст басылган битләрдәге хаталарны күрсәтүне һәм төзәтмә кертүне редакция яисә нәшрият эшчәнлегендә гомумкабул ителгән кагыйдәләр буенча башкаруын сораячак, чөнки аннан соң хезмәт корректорга биреләчәк. Дөрес, мөхәррирләр автор хезмәтенә күбрәк ташламалы якын килә, алар тарафыннан билгеләнгән урыннарны карап чыкканнан соң, төзәтмәләрне күпчелек очракта яңадан үзләренчә (бер кул белән) билгели.

Газета-журналлар корректурасы нәшриятларныкыннан бераз аерыла, алар гадирәк, һәм аеруча газета редакцияләрендә авторның шәхси формадагы төзәтмәләре дә, язма кырына чыгарылмаган тамгалар да кабул ителә. Соңгы вакытта мөхәррирләр текстларны электрон вариантларда гына камилләштерүне активлаштырды. Әлеге күренеш мәкаләне хәзерләү барышын кызулата, әмма, автор белән килештермичә, болай эшләү ярамый. Текстка рөхсәтсез җитди төзәтмәләр кертү төрле каршылыклар китереп чыгарырга, язма иясе белән үзара мөнәсәбәтләрне катлауландырып җибәрергә мөмкин. Мөхәррир эшкәртүендә дөнья күргән язмадан канәгатьсез автор, үз хокуклары бозылуны исбатлап, редакцияне хөкемгә дә тарта ала.

Электрон «тәрәзә»дә редакцияләү аның барышын күзәтү мөмкинлеген юкка чыгара. Мәсәлән, камилләшкән текстка кул куючы баш мөхәррир, язмадан риза булмаганда, хезмәттәшенең, теге яки бу төзәтмә керткәндә, дөрес эшләгәнмеюкмы икәнлеген ачыклый алмаячак. Мөхәррир яисә корректор язманы турыдан-туры төзәтсә, төп нөсхәне югалтмаска, үз вариантын аның белән кайтып-кайтып чагыштыру мөмкинлеген калдырырга тиеш. Оригиналны архивта саклау

төрле конфликтлы ситуацияләрдә редакторга үз дөреслеген дәлилләү өчен дә кирәк.

Һәр мөхәррир автордан да камилрәк яза дигән сүз түгел. Дөрес, үз эшенең остасы буларак танылган, кеше текстына бервакытта да зыян салмаган мөхәррирләр дә очрый. Гадәттә, алар әдип, шагыйрь, галимнәр арасыннан чыга. Редакторлар керткән үзгәрешләрнең әсәрләрен ямьсезләтеп кенә җибәрүен авторлар бик авыр кичерә. Газета-журнал редакцияләрендә, гадәттә, беренче этапта текстны коррекцияләүче керткән отышсыз төзәтмәләрне басма өчен җаваплы редактор яисә бүлек мөдире тотып ала һәм аны яңадан оригиналга якынайтуны кайгырта.

Кульязманың үзгәртелмәве урынлы килеш тә, аңа, үзара килештерелмичә, тиешсез төзәтмәләр кертелү хакында авторга очраклы рәвештә генә мәгълүм булганда, ул мөхәррир белән конфликтка да керергә мөмкин. Мондый чакта мөнәсәбәтләрне көйләүгә, хаталарны юкка чыгаруга нәшрият редакцияләрендә өченче кешеләрне тарту яхшырак. Андый очракларда, гадәттә, бүлек мөдире, баш мөхәррир казый ролен үти ала.

Соңгы елларда автор текстларына кирәгеннән тыш тыкшынулар татар басмаханәләренең, вакытлы матбугат редакцияләренең эшчәнлегендә бер нормага әйләнә башлады. Авторлар моңа берничек каршы тора алмый, чөнки теге яки бу басмалар шунда ук алардан материал кабул итүләрен туктата яисә, төрле сәбәпләр табып, актуаль яңгырашлы һәм кызыклы язылган мәкаләләрен дә чыгарудан баш тарта. Идеалда үз һөнәренең чын мәгънәсендә остасы булган мөхәррир, авторлар белән мөнәсәбәт корганда, эшлекле, нәтиҗәле хезмәттәшлек юлын сайлый.

## Дүртенче бүлек

## ХЕЗМӘТЛӘРНЕ БАСМАГА ХӘЗЕРЛӘҮНЕҢ ТӨРГӘ БӘЙЛЕ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Тәрҗемә әдәбиятка редактор күзлегеннән якын килү.** Тәрҗемәчелек – борынгы һөнәр. Тәрҗемәләр элек-электән халыкларны, кешеләрне үзара мөнәсәбәтләргә кертү кебек социаль функция үтәгән. Язу барлыкка килгәннән соң, моңа кадәр илара, кавемара арадашчылык хезмәтен телдән башкарган тылмачлар урынын дәүләт эшендәге рәсми тәрҗемәчеләр, дини әдәбият таратучы миссионер-руханилар, төрле халыклар культурасында каләмен чарлаган, чит телдәге әдәбият ярдәмендә үз халкын агартырга алынган мәгърифәтчеләр алган. Димәк, дөньякүләм диннәр тәгълиматы, әдәбият, фән, мәдәният казанышлары Җир шары буйлап нәкъ менә тәрҗемәчеләр хезмәте нәтиҗәсендә таралган.

Тәрҗемәләрне редакцияләүнең дә озын тарихы бар. Күптөрле кавемнәр, халыклар яшәгән Россиядә тылмачлыкның аралашу-аңлашу, рухи кыйммәтләр алмашу юлы икәнлегенә электән игътибар иткәннәр, әмма ул башта нормаларга салынмаган хезмәт булган. Әлеге һөнәр һәм язу, һәм әдәбият барлыкка килгән вакытта формалашкан, әдәби мирасны арттыру, сүз сәнгатенә тәэсир итү белән беррәттән, әкренләп һөнәри принципларын да барлыкка китергән.

Халкыбыз, милли үзаңга ирешкәнче, татар сыйфатында танылганчы, төрле тарихи этапларны кичкән, төрле хәреф системаларыннан файдаланган һәм шуларның һәрберсендә язма истәлекләр калдырган. Мәдәни кыйммәтләр тарихы татарларда язу, әдәбият, тәрҗемә эшенең янәшә диярлек

үсүе хакында сөйли. Шул ук вакытта чын мәгънәсендә киң колачлы тәрҗемәчелек бездә XIX гасырда гына җәелә, чөнки, башка телдәге хезмәтләрнең күпләп татарчалаштырылуы һәм халыкка таралуы өчен, тиражлаучы станоклар, басмаханәләр һәм, барыннан да бигрәк, хөкүмәтнең боларны булдырырга, китап басу эшен җәелдерергә бирелгән рөхсәте кирәк.

Россиядә беренче басмаханәләр ачылгач та, тәрҗемә китаплар саны тиз арада базар яуламый. Бердән, милли мөстәкыйльлеккә ия булмаган халыклар, аларны чыгару өчен, хөкүмәттән йөреп-йөреп тә рөхсәт ала алмый. Фәтва бирелгәннәрнең дә китап чыгару эшчәнлеге җиңел генә бармый: бердән, алар өстеннән ныклы күзәтчелек куела, икенчедән, авторларына төрле цензура киртәләрен узарга туры илә. Кызганыч ки, халык күңелен яуларлык, күзаллауларын үстерерлек иң яхшы хезмәтләр тыела, юк ителә яисә цензура архивларына «ябыла». Еш кына язучыларның һәм тәрҗемәчеләрнең цензорга илткән хезмәтләре махсус теркәү дә узмыйча юкка чыга.

«Атамалары», иҗат ителгәнлеге төрле истәлекләрдә чагылыш тапкан, әмма басылып чыкмаган бихисап кулъязмаларның язмышы бүген дә билгесез. Шунысы кызык: кайбер русча дөнья күргән, халыкка бик билгеле китаплар да татарча вариантта тыелган. Моны, гадәттә, цензорлар әсәр эчтәлегенең басып алынган милләтләрдә ирек хисе уятырга мөмкинлеге, теге яки бу рус персонажларының тискәре планда тасвирлануы, иҗтимагый стройга тәнкыйть тоемлану белән аңлата. Татар каләм ияләре басмага хәзерләгән чит әдәбиятның узган чорларда еш кына кыскартылуын, үзгәртелеп, бозылып дөнья күрүен дә билгеләргә кирәк. Хәтта күпсанлы тәрҗемә әдәбият тупланган иҗтимагый-тарихи этапларда да чит телдәге кайбер әсәрләрнең татарчалаштырылган вариантлары кулъязма хәлендә калганлык, тентүләр вакытында авторлардан тартып алынганлык басмачылык үсешенең көрәш тарихы рәвешендә баруын күрсәтеп тора.

Тәрҗемәчелек торышы кадрлар мәсьәләсе белән бик бәйле. Дөньяви уку йортларында белем алган, башка телләрне үзләштергән һәм үзе дә каләм маһирлыгына ия булган татарлар саны арткач кына, аның эчтәлеге киңәеп китә. Тәрҗемә әсәрләрнең сан һәм сыйфат ноктасыннан үсеше, кызганыч ки, бигрәк тә империяләрдә илнең эчке һәм тышкы сәясәте нәтиҗәсендә тоткарлана. Хәтта тирән белемгә ия һөнәр ияләренең барлыгы да, теге яки бу халыктагы тәрҗемәчелек эшен дәүләт хупламаса, үсешен тоткарласа, аңа матди нигез булдырмаса, милли үзаңлы кадрларның бу юнәлештәге хәрәкәтенә каршы киртәләр корса, тәрҗемәчелек эшен алга җибәрүгә юл ачмый. Глобальләштерү шартларында тәрҗемәчелек көчәйгән дә кебек, чынлыкта исә бу күренеш күпсанлы һәм сәяси мөстәкыйльлеккә ия милләтләргә генә карый.

Тәрҗемәчелектән башка халкыңны, мәдәниятеңне дөнья аренасында таныту мөмкин түгел. Шунысы бик үкенечле: әдәби әсәрләрнең, фәнни ачышларның милли телдә язылганнары чит халыкларга билгеле була алмый, мәртәбәле бәйгеләрдә урыннар яуламый, кайвакыт халыкара телдә башкарылмаган хезмәтләрдәге идеяләр урлана һәм башкаларныкына әйләнә. Бу проблемалар белән хәтта үз дәүләтчелегенә ия руслар да очраша.

Килеп чыгышлары күп кавемвнәрнекеннән борынгырак төркиләрдә тәрҗемәчелек тарихының озын булуы бәхәссез. Галимнәр теге яки бу халыкта язма тәрҗемәчелек барлыкка килү әдәбият белән бервакытта башлана һәм алар бер-берсенең үсешенә ярдәм итә дип саный. Дәүләт тоткан болгар бабаларыбыз ук чит хезмәтләрне күпләп тәрҗемә иткән дип уйларга кирәк. Төрле халыкларның, шул исәптән татарларның, мәдәни мирасында очраган, камил язылган бер үк сюжетлы әсәрләр шул хакта сөйли дә. Тарихның коточкыч зилзиләләрен исән-имин кичкән «Кыйссаи Йосыф» бүгенге әдәбиятка куелган таләпләр югарылыгында язылган икән, димәк, татар әдәбиятының да, әдәби тәрҗемәчелекнең

дә тарихы ул иҗат ителгән елдан алдагырак заманнарга барып тоташа.

Тәрҗемәчелек төрле кавемнәрнең чиктәшлеге, аларның аралашуы һәм якынаюы өчен, берничә телне яхшы белүчеләр кирәклек, үзара сугышлар һәм шулар вакытында коллыкка төшерелгән сугышчыларның, тыныч халыкның башка телләрне үзләштерүе шартларында барлыкка килә, үсә. Аның принциплары, кешеләр шәхси фикерләрен яисә башка берәүдән ишеткән сөйләмне икенче телдә дөрес яңгырату мөһим дип санаганга, табигый рәвештә формалаша. Борынгы заманнарда ук тылмачлар оригинал текст белән икенче телдәгесенең охшаш, эчтәлек-мәгънә ноктасыннан тәңгәл, һичьюгы үтә якын булырга тиешлекне, тәрҗемәчелектәге кечкенә генә җитешсезлекләрнең дә сәясәт мәйданында зур хаталарга китерергә мөмкинлеген истә тоткан.

Чичәнлек ярышлары, әдәби стилизацияләр, назирәләр – тәрҗемәчелекне фәнни нигезгә бастыруга әйдәүче күренешләр. Аны калыпларга салуда аеруча исламны дәүләт дине дәрәҗәсендә кабул итү һәм югары катламнарның, руханиларның мөселманнарның кануни китапларын, дини тәгълиматны һәр кешенең көндәлек тормышына уздыру юлындагы тырышлыклары аеруча зур роль уйный.

Борынгы бабаларыбыз Коръәнне, Изге китапка санап, ныклап өйрәнеп кенә калмый, дөнья буйлап таралган кардәш кавемнәргә ирештерү эшенә дә керешә. Аны башка телдә дә аңлата һәм ислам дине кануннарын өйрәтә алачак мөгаллимнәр, осталар хәзерләү кирәк була. Болгар, Казан ханлыгы дәүләтләренең турыдан-туры варислары булган татарлар да гасыр арты гасыр Хак сүзен кардәш халыкларга ирештерү хәрәкәтен мөмкин кадәр киңрәк җәелдерергә тырыша.

Тәрҗемә принципларына төп нигез Коръәнне татарчага күчерү, шәрехләү аша салына дип уйларга кирәк, чөнки әлеге эшкә куелган таләпләр бик катгый була. Бу бик борынгыдан ук югары мәдәнияткә, бай әдәбиятка ия гарәпләрнең

үзләреннән килә. Коръәнгә бихисап шәрехләр язылса да, аның актив кулланыштагы барлык сүрәләре татарчалаштырылса да, комментарийлар белән тәэмин ителсә дә, халык арасында киң таралса да, китапны тулы һәм сүзгә-сүз тәрҗемә итү озак гасырларга тоткарлана, әмма бу эшкә омтылучылар, әлбәттә, була.

Коръәнне башкалар өчен тәрҗемә итәргә алынудан мөселманнарны хаталанудан саклану тыеп тора дип уйларга кирәк. Урыны-урыны белән кирәгеннән тыш метафорик яңгыраган изге сүз, гарәп сөйләменең башка телләргә күчерү өчен шактый катлаулылыгы, еш кына асмәгънәлелеге – тәрҗемәчеләр өчен бу эштә зур киртә. Бер үк вакытта мөселман татар кешесенең Күктән иңгән сүздә кечкенә генә хата фикер аңлаудан да куркуын, һәм аның өчен төгәл тәрҗемәләрнең булуы бик мөһим икәнлекне дә әйтик.

Бүгенге көндә дә ислам динен тоту өчен кирәкле китапларның күбрәк гарәп телендә басылуы шулай ук Алла сүзенең мәгънәсен бозудан курку, аның һәм ул иңдергән Коръән алдында җаваплылык хисе белән дә аңлатыла. Без дини әдәбиятны тәрҗемә итәбез, шәрехлибез, әмма ритуаллар вакытында догаларны гарәпчә укыйбыз, чөнки бу аларга үзлегебездән хата мәгънә салудан коткара. Шунысы да бар: татарча эчтәлеге билгеле булып та гарәп телендә укылган дини өйрәтмәләр Коръән иңдерелгән телне дәрәҗәли. Мөселманнар гарәп телен генә түгел, хәтта аны язуда чагылдырган хәрефләрне дә изгеләштерә. Әле элеккерәк елларда өлкән яшьтәге кешеләр ул шрифт урын алган гадәти кәгазьләрне дә яндырудан, пычратудан, югалтудан курка, махсус урыннарда, савытларда саклый иде.

Гарәпчә укылган, ятланган сүрәләр гамәли кулланышка керсен, Изге китаплардагы карашлар һәм гомумән дини тәгълимат халык арасында таралсын өчен, әлбәттә, гади кеше бу төр әдәбиятның эчтәлеген һичьюгы якынча күзалларга тиеш. Шулай икән, Болгарда ислам динен кабул итү заманнарында

ук Коръәннең кульязма варианттагы шәрехләре, теге яки бу сүрә тәрҗемәләре башкарылган дип уйларга кирәк. Дөрес, зур фаҗигаләр, гарасатлар вакытында илнең мәдәни байлыклары тар-мар килгән, юкка чыгарылган, язма әдәбияты яндырылган.

Төрле сәбәпләр аркасында, узган заманнардан әдәби мирас аз калган, әмма сакланганының камиллек дәрәҗәсе аның күләме, тел-сәнгать ноктасыннан эшләнеше турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Әдәбиятыбызның чишмә башы хисапланган «Кыйссаи Йосыф» сюжетының әдәби-дини китаплардан алынганлыгы билгеле. Димәк, шул еллардан, кызганычка каршы, нибарысы үзе генә сакланып калган һәм бик сәнгати камил әлеге дастан язылганчы, гасырлар дәвамында бихисап тәрҗемәләр башкарылгандыр, үз әдәбиятыбызга нисбәтле әсәрләр дә иҗат ителгәндер, дип фаразлый алабыз.

Иҗтимагый яшәештә нинди генә эшчәнлек барлыкка килмәсен, ул шунда ук тәртипкә салына, кысаларга утыртыла башлый. Тарихтан шул билгеле: Урта гасырларда ук тәрҗемәчелекнең норматив таләпләрен башкарырга омтылганнар. Аңа дәлилләрне һәрбер халыкның тарихи ядкарьләреннән табарга мөмкин. Әйтик, болгарлар яшәгән җирләрдә табылган каберташ язуларының охшаш конструкциясе текстларга гарәп зиратларындагы үрнәкләрнең тәэсире турында сөйли. Шул ук вакытта, каберташ язуларында дини китаплардан тәрҗемә өзекләр кулланудан чыгып кына да, әлеге һөнәр культурасының инде формалашып килүе турында фикер йөртеп була. Кыскасы, матур әдәбият үрнәкләренә кадәрге истәлекләр язма әдәби телне генә характерлап калмый, башка халыклар иҗат иткән әсәрләрне файдалану алымнарын, әйтик, татар сөйләменә кертү һәм тәрҗемә итү ысулларын да ачык күрсәтә.

Болгарлар Әбүгалисина, Фараби, Газали, Бируни һәм башка күренекле галимнәрнең хезмәтләрен укыганнар, кайбер китапларны үз эшчәнлекләре һәм халык өчен тәрҗемә дә иткәннәр. Чит әдәбиятның фәннәребез үсешенә

йогынтысы гаять зур була. Мәсәлән, болгар галиме Йосыф Болгариның риторика, дарулар турындагы махсус рисаләләре иҗат ителүгә, әлбәттә, башка кавемнәрнең язма әдәбияты да йогынты ясаган. Төрле шагыйрьләрнең әсәрләренә шәрех-аңлатмалар шулай ук заманына күрә тәрҗемәнең бер төре санала ала. Йосыф Болгари, мәсәлән, Сәмәркандинең «Әдәб» исемле әсәрен укучы эчтәлеген ачык күзалларлык итеп шәрехләгән.

Болгарларның чит халыкларга тылмач сыйфатындагы хезмәтләре, тәүге сүзлекләр («Кодекс куманикус», 1303...) тылмачлыкны тагын да алга җибәргән. Тәрҗемә принципларын эшләү, әйткәнебезчә, әдәби редакцияләү нормаларын формалаштыру белән янәшә барган, аларның икесенә дә бер үк галимнәр көч куйган.

Тәрҗемәчелек эше кискен җанлану, аның сан һәм сыйфат ноктасыннан сикереш ясавы бары тик басмаханәләр барлыкка килгәч кенә күзәтелә ала. Бер халык теленнән икенчесенекенә күчерү таләпләрен фәнни һәм катгый дәрәҗәдә кую өчен, милли әдәби тел нормалары барлыкка килү кирәк. Телебезнең камилләшүе, матур әдәбиятның үсеше, тәрҗемәчелекнең алга китеше бер-берсенә бик тыгыз үрелеп бара.

Татарларда тәрҗемә эше һәр зур, һәм кече иҗтимагый-тарихи этапларда җанланып ала. XIX гасырның икенче яртысында – мәгърифәтчелек идеологиясе җәелүгә мөнәсәбәтле дә, XX гасыр башында – вакытлы матбугат ачылуга, чагыштырмача сүз ирегенә ирешүгә бәйле дә, 1917 елгы инкыйлабка хәрәкәт иткәндә дә, аннан соң да ул алга таба адым арты адым ясый. Иҗтимагый барыш дәвамында тәрҗемәчелекнең максаты, аның нәтиҗәсендә туган әдәбиятның эчтәлеге, аңа карата куелган таләпләр үзгәрә бара.

Советлар Союзында зур тиражлар белән татарчалаштырылган әдәбиятыбыз, кызганычка каршы, башка халыкларны коммунистик идеологиядә тәрбияләү кебек вазифаларын югалткач – Үзгәртеп кору елларына килеп кергәч, бөтенләй

диярлек тәрҗемә ителми башлады. Сүз сәнгатенең камил үрнәкләре хәзер инде чит телләрдә бары тик дәүләт югарылыгында хәл ителгән очракларда гына дөнья күрә.

Татарстан Язучылар берлеге, мәдәният министрлыгы, «Мәгариф – Вакыт» нәшрияты тәрҗемәчелекне яңадан җанландыру, дөнья халыклары иҗат иткән әдәбиятларны татарчалаштыру, милли сүз сәнгатебез үрнәкләрен русчага күчерү проблемасын чишү турында кайгырталар, юлларын эзлиләр. 2000 еллар башында Казан дәүләт университеты тәрҗемәче белгечлегенә хәзерләү эшенә керешкән иде, хәзерге көндә ул шуның варисы булган КФУда дәвам итә. Әлбәттә, махсус белемнәр бирү-алу гына тәрҗемә өлкәсенә караган барлык проблемаларны, шул исәптән хәтта телдән телгә дөрес күчерү мәсьәләсен генә дә хәл итә алмый, чөнки әлеге эшкә алынучыларның язучылык талантына иялеге дә кирәк. Ул төр әдәбиятны редакцияләү осталыгы шулай ук тылмачның әдәби әсәрне тою һәм камил яза алу сыйфатларына барып тоташа.

Гомумән алганда, фән-техника, мәдәният кебек өлкәләрнең тизләтелгән үсеше һәм глобальләшү заманында тәрҗемәчелекнең әһәмияте бик зур, һәм ***тәрҗемәләргә якын килүнең критерийлары, аларны редакцияләүнең*** мөһим ***принциплары*** бар.

Тәрҗемә әдәбият, автор хезмәтен үз теленә күчерүче дә, редактор да, бер үк сыйфатларга ия булганда гына, бөтен таләпләргә җавап бирә. Аларның тәрҗемә культурасын, бу өлкәдәге тәҗрибәсен билгеләүче сыйфатларга-гамәлләргә галимнәр түбәндәгеләрне кертә:

• телгә сиземлелек, аны ярату, оригиналны төгәл аңлау, тәрҗемә ителәчәк телне камил белү һәм анда җиңел язу;

• ике тел арасындагы аермалыкларны, бигрәк тә аларның стилистик үзенчәлекләрен, тәрҗемә башкарылган тел нормаларын исәпкә алу, шул ук вакытта автор вариантының тел-стиль сыйфатларын булдыра алганча чагылдыру, тәрҗемә өчен отышлы стильне сайлау;

• эчтәлекне, сүзләрнең төгәл мәгънәсен саклау, оригиналдагы лексемага адекват төшенчәләр булмаганда, гыйбарә аша, контекст эчендә кирәкле мәгънәне җиткерү;

• ике төр культураны, аларның кисешү чикләрен белү, тәрҗемә ителәчәк әсәрнең темасын яхшы аңлау, хезмәттә күтәрелгән проблемаларны дөрес күзаллау;

• язучылык сәләте.

Тәрҗемәче ике телне дә тәңгәл белмәскә мөмкин, әмма, оригинал әдәбиятны төгәл төшенсә һәм ана телендә камил язу күнекмәләренә ия булса, башкарган эше, һичшиксез, тиешле таләпләргә җавап бирәчәк. Әгәр шул ук тәрҗемәчедән ана телендәге китапны үзе аңлаган кайсыдыр халыкныкына күчерүен сорасаң, укучыга китапның якынча мәгънәсен җиткерә алса да, бөтен нечкәлекләрен ирештермәс. Ике телдә дә тигез аралашкан, һичьюгы аерым өлкәгә караган темаларда бердәй язган кешеләр сирәк. Шул ук вакытта кайбер кыска текстларны, бигрәк тә төгәл фәннәр буенча гыйльми хезмәтләрне тәрҗемә итү өчен, аны башкаручыдан икенче телнең бөтен функциональ стильләрен яхшы белү соралмый. Зур таләпләр бигрәк тә матур әдәбиятны тәрҗемә итүчеләргә куела.

Әдәби тәрҗемә техник, юридик һәм кайбер башка фәннәрдән хезмәтләрне икенче бер телгә күчерүдән яисә көндәлек тормышта, төрле мәҗлесләрдә арадашлык функциясе башкарудан нык аерыла. Ул ритмга, стильгә тоемчанлыкны, юмор нечкәлекләрен белүне, абстракт күзалаулар сәләтенә, югары сәнгати зәвыкка ия булуны, эрудициялелекне һәм башка сыйфатларны таләп итә. Язучының бер әсәрен отышлы татарчалаштыру өчен, берничә китабыннан, иң яхшысы, гомуми стиленнән хәбәрдарлык сорала.

Редактор, автордан яисә башка бер-бер ихтыяҗлы заттан үтенеч кабул иткәндә, бигрәк тә тәрҗемәне башкаруны кемгә дә булса тапшырганда, иң элек эш тибын билгели. ***Телдән телгә күчерү берничә төрле*** булырга мөмкин.

• ***Бер тел эчендәге тәрҗемәләргә*** ниндидер әсәргә язылган комментарийлар (әйтик, Коръәннең гарәп телендәге шәрехләре яисә тәрҗемәләренә шәрехләр), борынгы телдәге әдәбиятның бүгенге стильгә күчермәләре (диахроник тәрҗемәләр); киңәйтелгән аңлатмалы әдәби әсәрләр керә. Аларны башкарганда, сүзләрнең төгәл һәм күчерелмә мәгънәсен белү, төрле заманнарда кулланылган әдәби тел нормаларындагы аермаларны истә тоту, кайбер гыйльми өлкәләргә караган белемнәргә ия булу таләп ителә.

• ***Телара тәрҗемәләр*** дип, текстны бер төрле тамгалар системасыннан икенчесенә күчерүне дә, бинар тәрҗемәләрне дә саныйлар. Монда тел закончалыкларын бай сүзлек запасына ия булу яисә тиешле алфавит аша авазларны җиткерү нормаларын белү алгы планга чыга.

• ***Транспозицияләр*** – әсәрне бер жанр формасыннан яисә функциональ стильдән икенчесенә күчерү. Бу очракта язучылык талантына ия булу сорала. Стильләрне алмаштыру – шактый катлаулы эш. Бездә күбрәк проза әсәрләреннән сценарийлар язу яисә сәхнә әдәбияты ясау күзәтелә.

• ***Интерсемиотик тәрҗемәләргә*** табигый телләрдән ясалмага яисә киресенчәгә үзгәртүләрне кертәләр. Хәлбуки Фатих Әмирхан 1909 елда «Эсперанто теленең кагыйдәләре»н бастырып чыгарса да, бездә ясалма телләрдә иҗат итү киң таралыш алмаган. Бүгенге көндә эсперанто дөньяда бик актив кулланыла һәм әдәбиятны аңа күчерү барышы да көчле. Без моны интернет-сайтлардан күзәтә алабыз. Интерсемиотик тәрҗемәгә мисал рәвешендә, Луи де Бофрон нигезләгән лингвистик проект адьювантодагы, ягъни протоидо телендәге «Отче наш» догасын китерергә мөмкин.

• ***Трансмутация*** – бер ясалма телдә башкарылган хезмәтне халыкка икенче ясалма телдә ирештерү. Егермедән артык тел конструкцияләгән Р.Р. Толкин кайбер әсәрләрендә, мәсәлән, исемнәрне, кыска текстларны үзе уйлап тапкан төрле телләрдә чагылдырган.

Югарыда китерелгән бүленешне киңәйтеп тә, таркатып бирүчеләр дә бар. Редакторларның барысы да һәр төр тәрҗемәләрне эшкәртә алмый, билгеле. Татар мөхәррирлек хезмәтендә ясалма телдә иҗат ителгән әдәбиятны коррекцияләү тәҗрибәсе бөтенләй юк. Аз кулланылышлы телдә язылган ниндидер әсәрне камилләштерүгә ихтыяҗ туса, нәшриятлар махсус белгечләрне килешү нигезендә читтән таба.

Танылган язучы тәрҗемәчелек белән шөгыльләнми калмый. Кайвакыт ул әсәрләрен чит телләргә үзе күчерә. Редакторлар, билгеле шәхесләр белән эшлекле мөнәсәбәт корганда, еш кына кыенлыклар кичерә, төрле каршылыкларга очрый. Ул бервакытта да югалып калмаска, тылмачның кемлегенә карамастан, тапшырылган эшкә уртак таләпләр югарылыгыннан якын килергә тиеш. Оригинал һәм тәрҗемә әдәбиятның хуҗасы бер үк кеше икән, вариантлар арасында очраган аермалар яисә төзәтүләр вакытында күрелми калган башка төр җитешсезлекләр өчен җаваплылык, беренче чиратта, башкаручының үзенә йөкләнә. Шулай да була: автор кайбер очракларда икенчел вариантка махсус рәвештә оригиналныкында очрамаган сүзләр, хәтта өзекләр кертә яисә аерым өлешләрне төшереп калдыра. Бу цензурадан сагаю, инде башына яңа фикерләр килү, тәүге вариантта җитешсезлекләр күрү һәм башка сәбәпләр аркасында булырга мөмкин.

Традицион тәрҗемәчеләргә ул эшне мөстәкыйль башкаручылар кирә. Алар арасында тылмачлыкны һөнәр итеп сайлаганнары да, сайламаганнары да бар. Алар да, автор тәрҗемәсен камилләштерүче профессионаллар да тирән филологик белемгә ия булырга, телләрне бөтен нечкәлекләре белән аңларга тиеш.

Соңгы вакытта машина ярдәмендә башкарылган тәрҗемәләр дә күбәйде. Татарчага компьютер тылмачлыгы коточкыч нәтиҗәләр бирә. Рәсемгә төшереп алып, 2018 елның октябрендә инстаграмга урнаштырылган һәм зур тәнкыйтькә

очраган бер тәрҗемә үрнәге: *Туалет только для клиентов / Бәдрәф гына да клиентлар өчен.* Күренә ки, монда татарчалаштыру берәмлеккә-берәмлек рәвешендә бара, сүзләрнең сөйләмдәге урыны, үзара ярашу кагыйдәләре исәпкә алынмый. Димәк, текстка редактор кулы тимәгән. Дөресе: *Бәдрәф клиентлар өчен генә.*

Интернет челтәрендәге программаларның эш нәтиҗәләре машина тәрҗемәчелегенең әле башлангыч этапталыгын күрсәтә. «Переводчик» һәм башка ярдәмче чаралар хәтта дәүләти телләрне дә әлегә камил тәрҗемә итми. Бу төр программаларда күпсанлы телләр гомумән чагылыш тапмый. Электрон техника бигрәк тә әдәби әсәрләрне бер телдән икенчесенә хәтта якынча гына да дөрес күчерә алмый. Нәфис текстларны татарчадан – русчага, русчадан татарчага камил тәрҗемә итү турында сөйләп тә торасы юк.

Машина тәрҗемәсендәге кыенлыкларны ахыргача уйланып бетмәгән эш программаларына гына кайтарып калдырырга ярамый. Аның янәшәсендә кулланыштагы сүзлекләргә хас төгәлсезлекләр, күп кенә лексемаларга чит телләрдә эчтәлекне адекват түгел, хәтта якынча бирүче лексемалар да табылмау, электрон җайланманың сүзнең тиешсез мәгънәсен бирүе кебек сәбәпләр дә бар. Әлегә машина хезмәтен сүзләрне, кыска язылышлы, фикерне төгәл җиткерүче гади җөмләләрне татарчалаштырганда гына куллана алабыз. Сөйләмгә кисәкчәләр керү генә дә кайчак төрле мәгънәсезлекләргә китерә, редакторларның текстны яңадан эшләве кирәк була. Инстаграмнан алынган мисал шуны ачык күрсәтә. Кыскасы, машина ярдәмендә бер телдән икенчесенә күчерелгән текстны, һичшиксез, кабат эшкәртергә кирәк. Бу төр тәрҗемәчелек катнаш типка – өлешчә машина, өлешчә традицион башкарылган тәрҗемәләргә якыная.

Текстлар матур әдәбиятка карамаган очракта, аларны камилләштереп бетерү кайвакыт редакторның үзенә тапшырыла. Әгәр оригинал теле аңа таныш түгел икән, беренче

кат редакцияләү чит телнең махсус белгечләренә йөкләнә. Европа әдәбиятын һаман да русча вариантлар аша татарчалаштыру традициясе саклану – яңа заманга лаек күренеш түгел, әмма башка телләрне дә, татарчаны да яхшы белгән филологларга кытлык зур, шул сәбәпле әлеге проблеманың тиз арада чишелүе икеле. Вак-төяк материалларны, әйтик, аннотация-резюмеларны инглизчәгә күчерү өчен, күп очракта авторлар аны башта русчалаштыралар, аннан тәрҗемәне машинага тапшыралар. Редактор күзәтчелегендә чыкмаган әлеге материаллар кайвакыт шулай ук идеалдан ерак тора.

Гасырлар дәвамында чит, шул исәптән матур әдәбият татарлар арасына теге яки бу телнең (мәсәлән, төрек) арадашлыгы ярдәмендә дә, турыдан-туры да үтеп кергән. Соңгы елларда исә нәфис фильмнарны тәрҗемә итү киң җәелдерелде. Шулай да бу эшкә профессионаларча якын килү җитенкерәми. Рус матур әдәбиятын татарчалаштыруның озын тарихы, бай тәҗрибәсе, уңышлары бар югыйсә, әмма уңышсыз тәрҗемәләргә мисалларны шулай ук табарга мөмкин.

Татар вакытлы матбугатында Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» китабының Флёра Тарханова тарафыннан тәрҗемәсенә карата тәнкыйть сүзләре күп яңгырады. Ул, китап булып басылганчы, күпмедер дәрәҗәдә автор тарафыннан камилләштерелде дә, әмма аны эшлисе дә эшлисе иде әле. Тәнкыйтьчеләр туплаган һәм инде вакытлы матбугатта чагылыш тапкан шактый күлке һәм тупас мисалларны читләп узып, интернет сайтларда китерелгән кыска өзекләрдән күзгә шунда ук ташланган, махсус сайланмаган ике җөмләне генә карыйк. Беренчесе: *Зөләйха, – түбән тавыш белән эндәште Мортаза, хатынының ялангач тәнен күреп.* Монда «чыктым аркылы күпер» икәнлеге теләсә кемгә ачык. Оригиналны укымаган кеше дә җөмләнең «Мортаза, хатынының ялангач тәнен күреп…» дип башланырга тиешлеген аңлаячак. Аннан соң, ул «басынкы» яисә «тыныч» тавыш белән эндәшмәдеме

икән, монда сүз җырчы алган ноталар турында бармый бит, дип уйланачак. Әгәр тәрҗемәне Ф. Тарханова вариантында калдыру бик кирәк икән, текстның «…күргәч» рәвешендә тәмамлануы отышлырак.

Инде икенче мисалга тукталыйк: *Бүрәнәне чанага илтеп салгач, Зөләйха бүрәнә янәшәсенә хәлсезләнеп егылып ятты.* Бердән, татар сөйләмен монда очраган кабатлаулар ямьсезли. Икенчедән, көндәлек тормышыбызда: «Фәлән кеше фәлән җирдә егылып ята иде», – дип сөйләшсәк тә, бу җөмләдә «хәлсезләнеп егылып ятты» гыйбарәсен куллану дөрес булмас, чөнки монда мизгеллек хәрәкәт (хәлсезлектән егылып китү) хәбәр ителә, дәвамлы яту процессы турында сүз бармый. Шул ук вакытта: «Бүрәнәне чанага илтеп салган Зөләйха бүрәнә янәшәсендә хәлсезләнеп егылып ята иде» яисә «Бүрәнәне чанага илтеп салгач, Зөләйха, хәлсезләнеп, бүрәнә янәшәсендә егылып ятты», – дип сөйләргә мөмкин.

Бүрәнәне чанага, гадәттә, буйга саласың. Димәк, янынnan. Тагын сорау туа: кеше киселгәндәй, кинәт егылганда, ничек итеп җирдән биектәге чанага салынган бүрәнәгә янәшә һәм буе уңаена төшә алган? Әлбәттә, автор текстын күрсәк, үзебез куйган сорауларга җавап та таба алырбыз, әмма татарча китапны кулына төшергән укучы оригиналны эзләп китапханәгә барырга, аны тәрҗемә белән янәшә куеп укырга тиеш түгел. «Зөләйха күзләрен ача»ның сайтларга чагыштырмача уңышлырак дип сайланган өзекләре дә үз телендә яхшы сөйләшкән татар кешесендә әнә шундый бихисап сораулар уята. Әлеге күренеш тәрҗемәче исән вакытта китапны чыгаручыларның да, аннан өзекләрне үз газета-журналларында бирүчеләрнең дә хезмәтләренә җаваплы карамауларын сөйли.

Чит әдәбиятны татарчалаштыруда да чишеләсе проблемалар җитәрлек. Тылмачларның, нигездә, төп нөсхә белән түгел, ә аның русча варианты белән эш йөртүе оригиналлар һәм тәрҗемәләр арасындагы аерманың зураюына сәбәп

булып тора. Әгәр тәрҗемә икенче тел арадашлыгында башкарылган икән, редактор, оригинал әдәбият язылган телне белгән очракта, татарчада дөнья күрәчәк хезмәтне, сораулар туганда, төп вариант белән дә чагыштырырга тиеш.

Тәрҗемә әдәбият белән танышуның икенче этабында редактор аның жанр-стиль үзенчәлекләрен билгели. Алар:

- фәнни-техник әдәбият һәм документация;
- иҗтимагый-сәяси әдәбият;
- хәрби тематикага караган хезмәтләр;
- юридик характердагы кулъязмалар;
- сөйләм-көнкүреш текстлары;
- матур әдәбиятка караган әсәрләр булырга мөмкин.

Бездә бүгенге көндә фәнни-техник, сәяси, матур әдәбият кына түгел, дәреслекләр дә татарчалаштырыла фильмнар саны күбәеп китте. Бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү мөмкинлеге логик категорияләрнең төрле халыклар өчен уртаклыгы белән билгеләнә. Тылмачлык оядаш телләр арасында барганда тагын да камилрәк килеп чыга, чөнки бу очракта сөйләмнең гомуми кануннары гына ярдәмгә килми, ә ике телдәге фикерне төгәл, аңлаешлы белдерү, дөрес итеп кору чаралары да уртак була.

Тәрҗемә нинди генә формада башкарылса да, нинди генә төргә караса да, аның төп максаты һәм принцибы – текстны икенче телдә мөмкин кадәр тулы яңгырату, шуңа да карамастан кайбер принцип-критерийлар тәгаен хезмәткә бәйле рәвештә калкуландырыла ала.

Редактор тарафыннан иң башта, тәрҗемә әдәбиятны бастыру максатына, аның жанр формасына, бу вакытта файдаланылачак функциональ стильгә бәйле рәвештә, материалга якын килү юллары билгеләнә. Алар күп. Әйтик, нәшрият хезмәткәрләре оригиналның мәгънәсен төгәл җиткерүне (фәнни әдәбият), аерым сүз мәгънәсенә игътибарны (сүзлекләр), үзенчәлекле яңгырашлы тәрҗемәне (поэтик әсәр) алгы планга чыгарырга мөмкин. Башкарылган текстны,

оригиналга якынлык дәрәҗәсеннән чыгып, түбәндәгечә төркемлиләр:

• тәңгәл (адекват);
• төгәл (семантик релевант);
• ирекле;
• шәрехләү рәвешендәге;
• аутентик (оригинал белән бер үк юридик көчкә ия).

Редактор якын килүнең алда саналган төп принципларыннан һәм күздә тотылган башка таләпләрдән чыгып эш йөртә. Ул оригиналны аңларга, тәрҗемә башкарылган телдә язу һәм камилләштерү күнекмәләренә ия булырга тиеш. Мөхәррир, ике телдәге язмаларны үзара чагыштырып чыкканнан соң, кабул итү мөмкин түгел аермаларны билгели, сәбәпләрен ачыклый, кайбер төзәтмәләр кертә. Татарчалаштырылмыйча калган урыннарны тапса, бүлек һәм бүлекчәләрнең исемнәре туры килмәсә, китап атамасы матур яңгырамаса, абзац абзацка кушылса, текст үзенә ияртеп алып китмәсә..., кулъязманы, яңадан камилләштерү өчен, хуҗасына тапшыра. Ул аңа тәрҗемәнең тулы һәм адекват булырга, мәгънәне күздә тотылган адресатка дөрес җиткерергә тиешлеген, термин һәм төшенчәләр гомумкабул ителгән мәгънәдә кулланылырга һәм орфографик хаталар юкка чыгарылырга кирәклекне дә аңлата.

Редакторның төп хезмәте тәрҗемә текстны камилләштерүгә юнәлтелә. Үзе куйган таләпләр ярдәмендә инде хаталардан арындырылган хезмәт белән эшләү этабында ул ана телендә язылган текстларга якын килү принципларына, редакцияләүнең гомуми методикасына таяна.

Техник документациягә караган хезмәтләрне тәртипкә китергәндә, мөхәррир кул астында түбәндәге документ һәм күрсәтмәләр булырга тиеш:

• темага караган белешмәлекләр;
• дәүләти норматив эш кәгазьләре.

Техник әдәбиятны тәрҗемә иткәндә фикерне төгәл, тәгаен, туры мәгънәдәге сүзләр аша җиткерергә кирәк. Тел

яңгырашын матурлау өчен, җөмлә төзелешен, формасын билгеле бер дәрәҗәдә үзгәртергә ярый. Әйтик, артык катлаулы корылган җөмләләр берничә гадирәккә таркатыла ала, әмма, нәфис әдәбиятны тәрҗемә иткәндә, болай эшләү катгый тыела.

Тәрҗемәчеләрнең үз хезмәтләрендә синонимик рәтләрдән актив файдалануы, теге яки бу географик атамаларның, әгәр бар икән, икенче телдәге вариантын куллануы кирәк. Бездә исә кайвакыт җирле атаманы, барлык авазлары булганда да, русча вариантта үзгәртәләр, я шул телгә турыдан-туры көлке тәрҗемә итәләр, я гасырлар буе килгән мәгънәсен чагылдырмаган икенче сүз белән атыйлар. Арчада Эштерә елгасы ага һәм Штерә исемле авыл бар. Акыл белән уйлаганда, алар бер үк төсле әйтелергә һәм язылырга тиеш иде, әмма документларда төрлечә теркәлгәннәр. Инде русчага тәрҗемәләренә игътибар итик: елга Шира дип аталса, авыл исеме – Штырь. Әлбәттә, бу мисаллар географик атамаларны теркәүдә һәм тәрҗемә итүдә элек-электән килгән, инде төзәтелүе авыр, еш кына мөмкин дә булмаган хаталар турында сөйли. Мондый күренешләрнең күплегендә русларның татар авыллары һәм елга-тау исемнәрен үзләренчә ишетергә һәм язарга теләүләре зур роль уйный.

Матур әдәбият әсәрләрен тәрҗемә итүнең дә кыенлыклары бар. Каләм иясенә бу эш барышында авторга хас стильне саклау һәм шуның янәшәсендә ана теле үзенчәлекләренә дә хилафлык китермәү бик авыр. Бүгенге татар язучылары хезмәтләрен камил дәрәҗәдә русчалаштыра алырлык тәрҗемәчеләр таба алмыйча интегә. Руслар татарча аңламый, шунлыктан сүзгә-сүз тәрҗемә белән тәэмин итәргә кирәк, бу инде – тәрҗемәне үзең башкару белән бер. Русча да яза белгән татарлар исә чит телдә оригиналның бөтен матурлыгын, фикер тирәнлеген чагылдыра алмый, ана сөте белән сеңмәгән телнең барлык нечкәлекләренә ия түгел. Шушы шартларда кемгәдер хезмәтеңне тәрҗемәгә бирәсең икән,

ул яхшы нәтиҗәгә ирешсен өчен, хезмәттәшлек итмичә, үзара киңәшләшмичә булмый. Бары тик тылмачның русча язу талантын үзеңнекеннән югары бәяләгәндә генә, ничек тәрҗемә итү, стиль мәсьәләсен аның тулы ихтыярына куярга мөмкин.

Тәрҗемәчелек эшендә, алда сөйләнгәнчә, төрле искәрмә, чыгармаларны исәпкә алсак та, әлеге хезмәтнең төп һәм гомуми принципларын һәрвакыт истә тотарга кирәк. Аларны тагын бер кат ассызыклыйк:

• оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен, фикерләрен мөмкин кадәр тулы, төгәл бирү, боларның формадан әһәмиятлерәк икәнлеген истә тоту;

• автор стилен чагылдырырга тырышу;

• бер телдән икенчесенә хәрефкә хәреф күчермичә, тәрҗемәгә иҗади якын килү;

• ике тел закончалыкларын да исәпкә алу;

• тәрҗемә башкарылган телнең күптөрле чараларын белү һәм алардан уңышлы файдалану.

**Икенчел басмаларны әдәби эшкәртү**. Нәшриятта икенче, өченче һәм аннан күбрәк тә дөнья күргән китап-рисаләләр бар. Аларны бастыруга якын килү принциплары нәшрият коллективы, заказчы, автор тарафыннан яисә бергәләп хәл ителергә мөмкин. Бу эшне башкару шулай ук хезмәтне басу максатын, аның сыйфатламаларын һәм адресатын ачыклаудан, автор турында мәгълүмат барлаудан башлана.

Үзгәртеп кору елларыннан соң кайчандыр дөнья күргән басмалар яңадан китап базарына чыкты. Беренчедән, моңа кадәр уку тыелган хезмәтләр кайтты, икенчедән, гарәп графикасындагы әдәбият кириллицага күчерелде, өченчедән, моңа кадәр цензура тарафыннан кыскартылган, үзгәртелгән әдәбият тулы формада һәм эчтәлектә халыкка җиткерелде. Әлеге әсәрләргә якын килү бер төрле була алмый, әмма аларның кайсын гына редакцияләсәң дә, заман укучысына аңлаешсыз сүзләргә искәрмәләр; реминисценцияләргә, асмәгънә

белән теге яки бу шәхескә төрттерүләргә, фактларга төрлечә ишарәләүләргә, текстка кергән билгеле шәхесләр исемнәренә аңлатма язулары хәзерләргә кирәк. Элегрәк кулланыштагы графикада чыккан вариантлары булса, аларда җибәрелгән хаталарны бетерү лазем. Бу төр икенчел басмаларны эшкәрткәндә, редактор хезмәте, беренче чиратта, ике вариантны чагыштыруга кайтып кала. Димәк, ул гарәп һәм латин графикаларында җиңел, дөрес укырга, хәрефләр тәңгәллеген сакларга, гарәп-фарсы алынмаларының контексттагы мәгънәсен ачык аңларга, узган чорларга караган мәдәни хәтергә ия булырга тиеш.

Редактор, икенчел продукцияне чыгарганда да, махсус белгечләр киңәшенә колак сала ала. Бигрәк тә теге яки бу өлкәдә җитәрлек белеме булмаганда, ул, кульязма җитешсезлекләрен барлау һәм аның башкарылу дәрәҗәсен билгеләү өчен, эчке рецензия яздырып алырга мөмкин. Икенчедән, дәүләт яисә аерым бер оешма заказы белән басылучы икенчел продукция өчен җаваплылар еш кына аның белән махсус шөгыльләнүче предприятиеләрдән билгеләнә. Әйтик, әдипләрнең академик басмаларын, күптомлыкларын ТР ФАның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре башкара. Кайвакыт бу эш югары уку йортларының филологик факультетларында белем бирүче галимнәргә йөкләнә, аны Татарстан Язучылар берлеге дә үз җаваплылыгына алырга мөмкин. Хәтта шундый очракларда да нәшрият мөхәррир җаваплылыгыннан читкә тайпылмый. Чыгарылыш өчен махсус билгеләнгән редакторның арадашчылык, җитәкчелек вазифалары тагын да көчәйтелә, һәм ул, инде башка оешма хезмәткәрләре ахыргача камил эшләдем дип исәпләсәләр дә, кульязманы нәшриятта үтәргә тиешле барлык этаплардан уздыра.

Инкыйлабка кадәрге чорда пунктуация кагыйдәләре йомшак эшләнгән булган, аеруча өтер бик санга сугылмаган, татарлар, Көнчыгыш халыкларының басма продукциясенә

хас традицияләргә ияреп, нокта урынына чәчәк кебек бизәкләр дә куйганнар. Әкренләп уку йортларының программаларына кертелгән рус грамматикалары, тәрҗемәчелекнең алга китеше, чит телдәге китаплар тәэсирендә, татар теленең үз язылыш кагыйдәләре булдырылган, әмма аларның ныгуы бик озак вакытлар дәвам иткән.

Басмаханәләр эшчәнлеге алга китсә дә, дистә еллар дәвамында татар телендә тыныш билгеләре куюның кыен очраклары проблемасы хәл ителмәгән. Димәк, элекке заманнарда чыккан китапларны яңадан бастырганда, текстны пунктуация ноктасыннан тагын бер кат ныклап камилләштерергә кирәк. Шул ук вакытта кайбер сүзләр язылышына да хәзерге тел галимнәре эшләгән кагыйдәләр таләбеннән якын килү сорала. Кызганыч ки, орфографиягә һәм пунктуациягә кагылышлы кайнар бәхәсләр бүген дә бара, күп мисалларга бәйле рәвештә, танылган галимнәр бары тик үзләренең карашлары гына дөрес дип саный һәм уртак фикергә килергә ашыкмый.

Икенчел басмалар кайвакыт авторның фикере үзгәргәнгә, тулыланганга, киңәйгәнгә дөнья күрә. Мондый очракларда бер тапкыр апробацияләнгән һәм югары бәя алган китапның үзгәреш кермәгән урыннарына артык игътибар бирергә кирәкми. Редактор өстәлгән текстта стиль сакланышын, гомуми сөйләмгә аның матур ялгануын кайгыртырга тиеш.

Дәреслек, белешмәлекләр яисә башка төр әсбаплар бернинди өстәлмәләрсез яңадан бастырылса да, кабат фактик, орфографик, пунктуацион хаталарны барларга, табылганда – төзәтергә, шуннан соң әлеге хезмәтләрне тагын бер кат күздән кичерергә кирәк. Бу гамәлләр хатаның эзләгән саен табылуын, китап телен камилләштерүнең чикләре юклыгын күрсәтер.

Элекке китапларда авторлык сирәк очракларда наширгә, тәрҗемәчегә нисбәт ителгән булырга мөмкин. Вакытлы матбугатта авторы күрсәтелмәгән язмалар шактый очрый. Архивларда, төрле экспедицияләр вакытында титул бите

сакланмаган кулъязмалар, басма әдәбият табылып тора. Арабыздан күптән киткән каләм ияләренең стиленнән чыгып, башка дәлилләргә таянып, татар әдәбиятына караган кайбер материалларга мөнәсәбәтле атрибуция проблемаларын чишәсе бар.

Кайвакыт укучыларда язма истәлекләрдәге исем-фамилияләргә бәйле сораулар да туа. Әйтик, Гата Исхакый һәм Гаяз Исхакый кебек исемнәрнең бертөсле кыскартылмалары (Г. Исхакый) очраштыра. Гата Исхакыйны ишетеп белмәгән кеше, аңа кагылышлы материалларны, Гаяз Исхакыйныкы белән бутап, үзе төзегән җыентыккка кертеп җибәрергә, интернет сайтларга урнаштырырга, алар хакында хата фикерләр язарга мөмкин. Мөхәррир кайбер каләм ияләрен, бер-берсеннән аеру максатында, төрлечә язуның ныклы традициясе барлыгын белергә тиеш: Роб. Әхмәтҗанов (Роберт…), Р. Әхмәтҗанов (Рәшит…) һ.б.

Икенче кат басылган хезмәтләрне төзәтүне, әгәр үзгәрешләр зур һәм күп түгел икән, китапның бите өстендә генә башкарырга да ярый, ә инде табылган хаталар хисапсыз булса, текстлар компьютерда беренче мәртәбә җыелса, редакцияләү процессына шактый җитди якын килергә кирәк. Бу очракта корректорлардан аеруча игътибарлылык сорала.

Яңадан чыккан басмаларда моңа кадәр дөнья күрмәгән рәсемнәр, фотолар урын алырга мөмкин. Алар астындагы язуларны, Кереш һәм Соңгы сүзләрне редактор яңа китапны эшләүдәге барлык баскычлар аша уздыра. Ул рәсемнәрдәге шәхесләрнең кемлегенә, иң беренче чиратта, үзен ышандырырга тиеш. Рәсем асты язуларын төгәл башкару өчен, архивларга, тарихчыларга, рәсемдә сурәтләнүчеләр белән аралашкан кешеләргә яисә аларны якыннан белгән даирәгә мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

**Радио-телевидение хезмәткәрләренең сөйләме, эфир текстларын эшләү.** Радио-телевидениегә хас тел чараларын ачыклау аларның агитация-пропаганда ягыннан халыкка

тәэсир итү мөмкинлекләрен барлауны да күздә тота. Кызганыч ки, соңгы елларда бу проблемага кагылышлы хезмәтләр чыкса да, әлеге тармакларның жанр теориясе ахыргача эшләнмәгән; белгечләрдә аның хакында бердәй күзаллау барлыкка китерелмәгән. Моңа кадәр яшәп килгән тапшыру төрләренең эстетик һәм эффектлылык дәрәҗәсе дә төгәл билгеләнмәгән.

Радио-телетапшыруларның тел ноктасыннан камиллеге, эстетик зәвыклылыгы турында зур сөйләшүләр бигрәк тә татар сәнгать-мәдәният дөньясының алга барышы өчен кирәк. Безнең исә бу өлкәгә хезмәт итәрлек эрудицияле, эчке тоемлы белгечләребез юк. Җитмәсә, милли каналлар, матди мөмкинлекләре бик чикләнгәнлектән, кадрларны редакцияләргә күпләп чакыралар, ә гамәли эшчәнлек вакытында ныклап хәзерли алмыйлар.

Татар телевидениесе дә, радиосы да ана телдә аралашучы аудиториясез яши алмый. Халкыбызның иҗтимагый аңын үстерергә, зәвыгын тәрбияләргә тиешле әлеге институтлар шул аудиторияне булдыруны, беренче чиратта, үзләре кайгыртырга тиеш. Күпмиллионлы халыкка яңгыраган сөйләм милли телне үстерергә дә, аңа зур зыян салырга да мөмкин. Димәк, радио-телевидение хезмәткәрләре теленең үтә камил яңгырашлылыгы кирәк.

Әлегә халык алдында тирән эчтәлекле, төзек корылган чыгышларны күбрәк танылган каләм ияләре ясый. Татар каналларындагы спорт комментаторларының сөйләме, образлы экспрессив шәрехләре дә материалына күрә отышлыдыр дип уйлыйк. Шул ук вакытта, «саладан ерагайган» шәһәрлеләрнең генә түгел, «калалаша» барган авыл җитәкчеләренең әңгәмәләрдә русчалы-татарчалы җаваплары, шуларда тәрбияләнгән кыр һәм ферма хезмәтчәннәренең аларныкына авазлаш ярлы сөйләме, сәхнәгә очраклы менгән җырчы-сәнгатькярләрнең үзләренә кызыклы тоелган, чынлыкта тупас шаяртулы чыгышлары милли сөйләмебезгә тискәре йогынты ясый.

Радио-телетапшыруларда еллар дәвамында кимчелекле сөйләм өстенлек итүнең аянычлы нәтиҗәләре күренә дә башлады. Соңгы вакытта төрле милләтләр яшәгән Казан яисә башка шәһәрләрнең урамнарында алынган интервьюлар гына түгел, ана телдә белем биргән мәктәпләрдә яисә төрле мәдәният учакларында оештырылган әдәби-мәдәни чараларга бәйле эшләнгән я булмаса татар авылларындагы тормышны яктырткан репортажлар да күпчелек очракта саф татар сөйләменә корылмаган.

Шәһәр балалары катнашкан «Тамчы-шоу» һәм башка тапшырулар еш кына алмашка килүче буыннар сөйләмендә тел нормаларын ныгытуга хезмәт итми, ана телебезне түбәнсетә. Кайбер «шаян сәхнә» осталары, көлке тудыруның башка алымнарын таба алмаганлыктан, рус һәм татар сүзләрен буташтыруга өстенлек бирә. Аларның чыгышларыннан, ана телләрендә аралашкан татарлар, алынмаларны аңламыйча, көндәлек тормышта сәхнәдәгечә көлкегә кала, кебек фикер туа. Актуальлеген югалткан юмор-сатира алымнарының тагын да активлаша төшүе халыкка югары сәнгать үрнәкләре илтергә тиешле артистларыбызны бизәми. Редактор радио-телевидение чыгарылышларындагы тискәрерәк якларга мөнәсәбәтен тапшырулар эчтәлегенә үзгәрешләр кертеп, аларның сәнгати югарылыгын үстереп, катнашучылар алдына җитди таләпләр куеп белдерергә тиеш.

Юмор осталарының «җиңел теле» белән, сөйләмебезгә «әби-бабай» урынына «түшшә белән түш» кебек җанга ятышсыз сүзләр үтеп керде, тудыка-тудык һәм җиңги-җизни кебек әле генә киң кулланышта йөргән туганлык-якынлык атамалары онытылды, алар урынын апаның ире, абыйның хатыны, икетуган һәм башка төшенчәләр алды. Телевизорның халык аңына ясаган тәэсире биниһая зур, әнә шуңа күрә сурәт, тавыш, сүз белән берлектә яңгыраган сөйләмнең камиллегенә ирешергә кирәк тә. Моның өчен җаваплы кешеләр бик күп: тапшыруларны уйлап табучылар да, оештыручылар да,

алып баручылар да, сценаристлар да, язма сөйләмне тәртипкә китергән мөхәррирләр дә, төшерүчеләр дә, монтажлаучылар да, яктылыкны, бизәлешне кайгыртучылар да ...

Эфир материаллары автор модальлегенең чагылышы булып тора. Татар телевидениесендә штат сизелерлек кыскартылу сәбәпле дә, экраннардан күрсәтеләчәк чараларны алып баруны редакторларга йөкләү артты, шуның белән, татарча камил телне пропагандалау бурычларын ничек үтәүләренә игътибар бермә-бер көчәйде. Моннан тыш, аларның, визуаль элементның икенче планга калуына ирешү өчен дә, җөмләләрен дөрес, кызыклы, тирән мәгълүматка ия итеп төзүләре һәм аһәңне уңышлы сайлый белүләре зарур.

Телетапшыруларда чагылыш табачак текстлар алдан ук хәзерләнә. Редактор фикер җиткерү, эчтәлек планын логик-хисси мәгълүматка нигезләнеп төзи. Ул бу вакытта ук телевидение башкарган функцияләрдән үзара аралашу-аралаштыру бурычын җиренә җиткереп үтәргә тиешлеген онытмый. Укучы аңына тәэсир итү өчен, сөйләмне мөмкин кадәр гадирәк кору, мәгълүматны чамалап бирү, аудиториянең ниндилеген исәпкә алу мөһим. Балаларга, өлкәннәргә, белгечләргә адресланган тематикасы уртак тапшыруларның һәркайсы үзгә эчтәлеккә ия булып, яңгыраган сөйләм дә төрлерәк сүзлек составыннан оеша. Димәк, коммуникатив функцияне чишү үзеннән-үзе эстетик-стилистик бурычларны хәл итүгә алып чыга.

Телевидениедә һәм язма, һәм сөйләмә әдәби тел кулланыла, әмма икенчесенә өстенлек бирелә. Соңгы вакытта экраннарда текстлар бирү ешая бара, бу билгеле бер дәрәҗәдә реклама материалы күбәю белән бәйле. Алар өчен махсус игълан каналлары да бар. Популярлашканнан-популярлашучы тагын бер күренеш – модератор ярдәмендә «СМС»-аралашу. Ул тамашачыдан фикер туплау, статистик нәтиҗәләр чыгару, товар сатуны активлаштыру, кешеләрне бер-берсе белән таныштыру кебек максатлардан оештырыла.

Укучылардан килгән «СМС»лар камиллектән бигрәк тә ерак тора. Аның сәбәпләре берничә: халыкта үзара аралашу культурасының түбән төшүе, тел кагыйдәләрен яхшы белүчеләр мәйданы тараю, телефоннарның татарча шрифт белән тәэмин ителмәгәнлеге һ.б.

Язма сөйләмдәге кимчелекләр күзгә күбрәк ташланучан. Титрга урнаштырылган тамашачы текстындагы җитешсезлекләргә күз йомып булса да, аерым тапшырулар вакытында зур форматта экраннарга чыгарылган язулардагы хаталарны игътибарсыз калдыру, гомумән, мөмкин түгел. Бу төр ямьсез күренешләр редакторларның, башка махсус белгечләрнең үз эшләренә җавапсызлыгын күрсәтеп тора.

Хәзер радио-телевидениедә иркле сөйләмгә өстенлек бирелә, хәтта алдан хәзерләнгән текстлар да еш кына артист, диктор, редактор тарафыннан тамашачыга үзгәртелеп җиткерелә. Эфирда аралашу процессында оешкан сөйләмнең кайсын да – телеэкраннардан ишетелгәнен дә, радиотапшыруларда яңгыраганын да тулысынча контрольдә тоту кыен. Бигрәк тә чараны алып баручылар экспромт чыгыш ясаган радиодулкыннарда хаталы сөйләм күп яңгырый.

Төрле тип эфир текстларын редакцияләү тәңгәл була алмый. Бердән, радио-телевидение хезмәткәрләре басылып чыккан әдәби әсәрләр, документлар белән дә эш итә, һәм аларның һәрберсе кайчандыр редактор тикшерүен үткән. Шулай булгач, әлеге текстлар, алардан сайланган өзекләр оригиналдагыча кала. Мөхәррирләр башка төр язмаларның беришен алдан ук төгәл яңгырарга тиешле рәвешкә китерәләр, икенчеләренә – эфир чарасы барышында бик нык үзгәрергә мөмкиннәренә – игътибарны чагыштырмача азрак бирәләр. Чараның планлаштырылган барышына алдан фаразланган яисә бөтенләй көтелмәгән хәлләр, тапшыруга чакырылган кешеләрнең килмәве, карашларындагы төрлелек, кайберләренең әңгәмәгә катнашып китә алмавы, темадан хәбәрдарсызлыгы һәм башкалар сәбәп була. Дөрес, турыдан-туры

һәм ирекле аралашу рәвешендә барачак тамашалар өчен язылган текстлар да, традиция буенча, камилләштерелә, аны рөхсәт итүче җитәкче тарафыннан раслана.

Алдан яздырылган сөйләмне хаталардан арындыру монтажлау вакытында да дәвам итә. Бу максаттан, тапшыруны алып баручыларны яңадан төшерергә, кунаклар чыгышындагы хаталы җөмләләрне кыскартырга, тоныкландырырга мөмкин.

Радио-телевидениедә бигрәк тә илдә, дөньяда, кала һәм авылларда барган хәл-вакыйгалардан мәгълүмат бирүче чыгарылышлар, ашыгычрак хәзерләнә. Кайвакыт теге яки бу хәбәр дикторга тапшыру барышында ирешә, шулай да күпчелек материал алдан языла, кат-кат укыла, төзәтелә.

Кабатланучы эфир материаллары да була. Беренче чыгарылышта киткән тупас хаталарның икенчесендә бетерелмәве – ямьсез күренеш. Димәк, тапшыру, күрсәтелгәннән соң, ныклап тикшерелмәгән, бәяләнмәгән, кирәкле нәтиҗәләр ясалмаган. Җәмәгатьчелектә ризасызлык уяткан кайбер материаллар, сөйләм хаталары булмаса да, икенче чыгарылышка үзгәрешләр кичерергә мөмкин. Әйтик, 2018 елгы олимпиаданың фигуралы шуу трансляциясе вакытында һәм Гран-при этапларында Татьяна Тарасованың объектив булмаган һәм А. Заһитованы кимсетерлек сүзләре кабатлаулар вакытында кыскартылды.

Информация бирүче дикторларга аерым сүзләр, бәяләмәле гыйбарәләр ярдәмендә җиткерелгән фактка интонация аша мөнәсәбәт белдерү тыела, әмма алар аһәң аркылы халыкка җиткерелгән мәгълүматның мөһимлеген ассызыклый ала. Бу төр басым ясауга җөмлә төзелеше ярдәмендә дә ирешергә мөмкин. Соңгы вакытларда сәяси-иҗтимагый хәбәрләргә диктор акценты үзен шактый сиздерә башлады. Моның белән килешергә ярамый.

Телевидение сөйләме монолог һәм диалог, полилог рәвешендә оеша. Берничә кеше алып барган тапшыруларны

хәзерләгәндә, алар кулланачак сөйләмнең күпмедер аерылып торырга тиешлеген онытмаска кирәк. Аудитория белән диалог барлыкка килүне күздә тоткан яисә фикер-сораулардан торган текстлар да була. Бу очракта редактор сөйләмгә кушылучыларның җавапларын якынча чамалый һәм уйлап тапкан уңышлы сораулары аша тапшыруның эзлекле баруына ирешә.

Телевидение хезмәткәрләре риториканың, орфоэпиянең бары тик кабул ителгән нормаларына таянып кына сөйләшергә тиеш булсалар да, әйткәнебезчә, соңгы вакытта әлеге таләпләр белән исәпләшми башладылар. Кайберәүләрнең сөйләмендә диалекталь сүзләр очраштыра, авазларның дөрес әйтелмәве гадәти күренеш булып тора, бер үк структур җөмләләр, охшаш фразалар һәм сүзләр еш кабатлана. Шушы ук сөйләм хаталары тапшыруларга читтән чакырылучыларга да хас. Бигрәк тә производство җитәкчеләре арасында янәшә яисә якын аралыктагы җөмләләрне, «әлбәттә инде», «шулай итеп», «дөресен генә әйткәндә» һәм башка кереш сүзләр белән башлаучылар очрый. Мөхәррирләрнең эфирда катнашучыларга киңәшләре белән алдан ярдәм итүе, залда тыныч һәм эшлекле атмосфера тудыруы, кунакларны кайбер сораулар белән таныштырып куюы үзенең уңай нәтиҗәләрен бирә – алар сөйләмендәге хаталарның кимүенә китерә.

Радио теленең соң дәрәҗәдә камиллеге кирәк: ул эфир аша мәгълүмат җиткерүдә – төп, ә кайчак бердәнбер юл булып тора. Радиотапшыруларда монолог формасы өстенлек итә. Соңгы вакытта кайбер каналларда диалоглар да популярлашты. Тапшыруны ирекле стильдә алып баручылар бер-берсе белән сөйләшүне һәм халыкны әңгәмәгә тартуны хуп күрә. Бу бигрәк тә кыска дулкынлы каналлар өчен хас. Полилог, түгәрәк өстәл артында сөйләшүләр телевидениедә популярлашканнан-популярлаша барса да, радиода чагыштырмача сирәк кулланыла. Анда теге яки бу темага мөнәсәбәтле корреспондент монологы, төрле вакыйга-

күренеш барган урыннардан репортажлар,ниндидер эшхәлләргә комментарийлар элекке дәрәҗәдәге активлыгын саклый. Бүгенге көнгәчә радиоочерк, радиохикәя, радионовелла, радиохат, радиобүләкләрдә хикәяләү формасы рәвешендәге монолог өстенлек итә. Редакторлар почта аша килгән «тыңлаучы хатлары»н камилләштерергә, грамматик җитешсезлекләрдән арындырырга тиеш.

Радио-телетапшыруларга хас стильне әдәби тел эчендә яшәүче автоном стиль дип санаучылар да юк түгел, тик әлеге фикер бүгенге чынбарлыкны дөрес чагылдырмый. Эфирда яңгыраган сөйләм күп яктан көндәлек сөйләмебезнекенә якынайды һәм хәтта, әйтик, реалити-шоуларныкы күпчелек очракта тәңгәл килә. Радиодан яисә телевизордан күрсәтелгән нәфис әдәбиятка кагылышлы чыгарылышларда алып баручының сөйләме гади, гадәти булырга да, сәхнә теленә якын торырга да мөмкин.

Эфирда төрле функциональ стильләр чагылыш таба, индивидуаль стильләргә, сөйләм манерасына да зур урын бирелә. Кайберәүләр фикеренчә, дулкыннарда яңгыраган сөйләм төрләрен билгеләүдә материалларның, тапшыруда катнашучыларның җәмгыятьтә башкарган вазифалары нигез итеп алынырга тиеш, аларны рәсми, көнкүреш, әдәби һәм башка терминнар ярдәмендә атарга кирәк. Эфир телен теге яки бу сөйләмгә генә кайтарып калдыру дөрес булмас, чөнки бер үк тапшыруда һәм фәнни-популяр, һәм публицистик, һәм җанлы, һәм рәсми сөйләм урын алырга мөмкин.

Радио-телевидениедә хезмәт итүче әдәби мөхәррирнең текст белән эшләве үзенчәлекле, катлаулы һәм аннан төрле сәләтләр таләп итә. Ул махсус программаларга идеяләр бирә, кешеләрдән кергән тәкъдимнәргә төзәтмәләр һәм өстәмәләр кертә, режиссёр ролен дә башкара, монтажлауда да катнаша, сценарийлар яза, проза һәм шигъриятне сәхнәләштерә, төрле композицияләр эшли, теге яки бу авторның чәчмә һәм тезмә әсәрләрен үзе яисә башкалар ярдәмендә тамашачыга

җиткерә, студиядә һәм дулкын аша публика белән турыдан-туры аралаша.

Редактор-алып баручы функциональ стильләрдәге аерымлыкларны аңлап эш итәргә, төре анықланып җитмәгән сөйләмне теге яки бу стильгә җайлаштырырга, турыдан-туры тапшырулар барышында кайтарып сораулары, дөрес җөмләләре белән, әңгәмәдәшенең сөйләмен дә көйләргә, хаталардан арындырырга тиеш.

Хәзерге вакытта җанлы сөйләмгә корылган радио-телетапшырулар күбәйде, әмма кайберәүләрнең радио теле тулысынча шуннан гына тора диюләре белән килешеп булмый. Аның ниндилеге каналга, тапшыруга бәйле. Совет чорында эфир хезмәткәрләре бары тик камил әдәби сөйләмне кулланырга, ана телебезнең матурлыгын пропагандаларга тырышалар иде. Күпсанлы аудиторияне кулда тотып, бигрәк тә хата төзелешле җанлы сөйләмгә корылган татарча эфир чын мәгънәсендә камил әдәби телнең көндәлек аралашуыбызда кимүенә хезмәт итә

Хәзерге вакытта Татарстанда халыкка берничә радио хезмәт күрсәтә. 2011 елгы рембрендинг нәтиҗәсендә, исеме, логотибы, эчке сәясәте үзгәрешләр кичергән, 2012 елдан яңа исеме белән эшләп киткән «Болгар радиосы», Аналитик тикшеренү һәм тирәнтен өйрәнү үзәгенең 2015 елның февралендә үткәргән сораштыру нәтиҗәләре буенча, Татарстандагы 22 җирле һәм федераль радиостанцияләр исемлегендә беренчелекне яулый. Күп кенә тапшыруларның телен тагын да ныграк камилләштерергә кирәклеккә дә карамастан, чыннан да, «болгарлылар» эшчәнлеге башкаларныкыннан бермә-бер югарырак.

Радио һәм телевидение турында сөйләгәндә, халык фикеренә таянып кына, теге яки бу дулкын чыгарылышларының сәнгати югарылыгы, заманчалыгы турында катгый нәтиҗәләр ясау бик үк дөрес булмас. Аларның эчтәлеге, сыйфаты, җитәкчелек тарафыннан алып баручыларга куелган

таләпләр, тыңлаучылар һәм караучылар ихтыяҗы һәрдаим үзгәреп тора. Бу үзгәрешләрнең бер сәбәбе сөйләм сыйфатламаларына барып тоташа. Официальлектән шактый ерак торган сөйләмә стиль тиз үсә, һәрдаим үзгәрә һәм аралашуда катнашучыларның нәрсәне һәм ничек әйткәннәре турында уйламаулары шартларында формалаша. Җитмәсә, рус телендәге шул тип үзгәрешләргә бәйле рәвештә, хакимиятнең югары кәнәфиләрендә утырган кайбер билгеле шәхесләр, телебез өчен җаваплы кешеләр дә нормалар бозылуына табигый бер күренеш дип карарга кирәклеген белдерде.

Катнашучылары мәдәнисезлек-тәрбиясезлек, белемсезлек белән аерылып торган реалити-шоуларның киң таралуы – тел нормаларының бозылуына, заман сленгының, жаргон сүзләрнең массаларга күпләп үтеп керүенә сәбәпче. Мисалга яңа гасырның беренче унъеллыгында иң популяр булган, яшь тамашачыга «бозыклыкны пропагандалавы өчен» хәтта хөкемгә тартылган, төп эфир вакыты шул сәбәпле төнгә күчерелгән, әмма барыбер караучылары кимемәгән, статистикага таянганда, 40–60 млн арасында тирбәлгән «Дом-2»ны мисалга алыйк. Анда «яшәүчеләр» бер-берсен яхшы белә, узган вакыйгалардан хәбәрдар, аларга күп нәрсә хакында һәрвакыт җентекләп сөйләп торуның кирәге дә юк, әнә шул сәбәпле сөйләмнәрендә тулы булмаган җөмләләр активлаша. «Шоучы»лар еш кына, бушлыкны тутыру өчен, кул хәрәкәтен һәм мимиканы эшкә җигә; кискен конфликтларны исә, сөйләм ярдәмендә түгел, физик көч аша хәл итүне хуп күрә. «Дом-2»чылар үзара аралашуларында әшәке, тупас сүзләр куллана, алынмалардан мәгънәләрен белмичә файдаланып, көлкегә дә калгалыйлар.

Социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, әлеге тапшыруның бөтен дөнья буйлап таралган тамашачысының зур күпчелеге аны беренче көннән үк даими карый икән. Димәк, һәр нәрсәне комментатор тарафыннан шәрехләп бирүнең кирәге дә юк. Җитмәсә, әлеге тапшыру, «йорт хуҗалары» хакында

махсус журнал чыгарыла, вакытлы матбугатта күп языла, кассеталарда алар турында фильмнар сатыла һәм шоуда катнашучылар тормышы интернетта актив яктыртыла. «Дом-2»да тәрбиясезлеге, сөйләмнәренең ямьсезлеге белән аерылып торуларына карамастан, кайберәүләр, аннан киткәннән соң, төрле каналларга диктор, шоумен, корреспондент һәм редактор булып урнаша. Тапшыру белән көрәш тарихы җәмгыятьнең телгә зыян салучы күренешләргә, шартларга ахыргача каршы торырга сәләтсезлеген күрсәтте.

Сөйләмә стильнең сүзлек составы гына түгел, грамматик формалары да язма әдәби телнекеннән күпмедер аерыла. Тапшыруны хәзерләүче редактор, иң беренче чиратта, чакырылган кунаклардан, сайлаган темадан чыгып, өстенлек итәчәк сөйләм калыпларын чамаларга тиеш. Кызганыч ки, бүгенге редакторлар, эфирда чыгыш ясаучылар еш кына сүз басымнарын дөрес куймый, сүзләрне мәгънәсен аңлап бетермичә куллана, татар авазларын русча яңгыраталар. Мәсәлән, басымны боерык фигыльләрдә соңгы иҗеккә төшерәләр, ә кереш сүзләрдә беренче иҗеккә куйгалыйлар. Редакторларның тапшыруларны саф ана телендә сөйләүчеләрдән генә оештыру мөмкинлеге юк. Халыкның руслаша баруы, татар сөйләменең кулланылыш мәйданы кимү телнең гомуми сакланышына торган саен ныграк зыян сала.

Сөйләм этикетына гомуммәдәни дә, милли дә үзенчәлекләр хас. Редакторлар коммуникациянең сөйләм кагыйдәләренә генә түгел, тамашачы каршында чыгыш ясау культурасына да ия булырга тиеш. Алар тел-сурәт чараларын, лексик кырны чыгарылышның темасына, максатына, адресат үзенчәлекләренә, аралашу шартларына һәм даирәсенә карап сайлый. Ул үз сөйләмен коммуникатив бурычларга ирешү эффектлылыгыннан чыгып бәяли. Радиохезмәткәр, мәсәлән, каршы якны күрмәгән килеш тә, аның реакциясен күзаллый, тыңлаучылар белән турыдан-туры әңгәмә оештыра. Дулкынның төп чарасы – аваз-яңгыраш булганлыктан,

тапшыруны алып баручы дөрес, ачык, басынкырак, тигез һәм тыңлаучы күңеленә хуш килерлек сөйләргә тиеш. Радиоэфир текстының матур, лексик, грамматик, стилистик ноктадан камил корылуы, хата җибәрелсә, шунда ук төзәтелүе, каршы як биргән сорауларга җавапның аңлаешлы, тулы һәм ышандыргыч булуы мөһим.

Кыскасы, телевидение һәм радио идеалда халыкка әдәби сөйләм нормаларын пропагандалау эшен башкарырга тиеш.

**Фәнни хезмәтләрне басмага хәзерләү.** Әдәби редактор гыйльми язмаларга, галимнәрнең элекке тәҗрибәләренә, нәтиҗәләренә таянган, яңаны да хәбәр иткән, теге яки бу өлкәне алга таба үстергән акыл хезмәте булырга тиеш, дигән таләптән чыгып якын килә. Дөнья күргән һәр фәнни материал элгәреләр туплаган мираска кушылып китә һәм алга таба фәнни кулланылышка керә дип фаразлана.

Мөхәррир, алдан ук кулъязма хакында гомуми күзаллау булдыру өчен, аңа автор язган аннотацияне игътибар белән укый, ә инде хезмәт белән танышу барышында аның гомуми эчтәлекне дөрес чагылдырамы-юкмы икәнлеген исендә тота. Ул соңыннан аннотациягә яңадан әйләнеп кайта һәм, кирәк санаганда, үзгәрешләр дә кертә. Китап эчтәлегенә алып керүче әлеге текстта, Керештә галим үз хезмәтен фундаменталь дип атый икән, димәк, ул анда табигать һәм җәмгыятьнең яңа кануннарын, яңа принципларын ачкан, чынбарлыктагы күренешләр арасында яңа бәйләнешләрне тапкан булырга тиеш. Кулланмалар исә, гомумән алганда, гамәли ярдәмне күздә тота.

Әдәби редактор аңлатма язуындагы адресатка да игътибар итәргә тиеш. Фәнни китаплар, беренче чиратта, галимнәр, аспирантлар, магистрантлар, студентлар өчен хәзерләнә. Дөрес, гади халык арасында да гыйльми табышлар белән кызыксынучылар юк түгел, әмма алар күбрәк иҗтимагый фәннәргә караган китапларны укый. Андый хезмәтләрне киң катлам укучыга атап язганда, каләм иясенең фәнни-популяр

стильне сайлавы, шуны башыннан ахыргача саклый алуы кирәк. Теге яки бу өлкәдә эшләүче белгечләргә адресланган кулланмаларда гыйльми яңалыкларны артык гади тел белән җиткерү, фәннилектән качарга тырышу дөрес дип саналмый.

Гыйльми әдәбиятның гасырларга сузылган тарихы бар. Безнең эрагача VI гасырда ук Грециядә фәнне бүгенге кебек күзаллау, аңлау булган, әмма гыйльми ачышларны китап рәвешендә тарату Аристотель заманыннан гына активлашкан. Бу төр хезмәтләрнең тематикасы, эчтәлеге, гыйльмилек дәрәҗәсе һәр чорда аерыла. Фәнни әдәбиятка, теге яки бу өлкәләрнең алга китеше генә түгел, социаль-икътисади, сәясиичтимагый, идеологик шартлар да үз эзен сала, һәм автор, текст белән эшләүче редактор боларның һәрберсен аңларга тиеш.

Мөхәррир нәшриятка тапшырылган кульязманың тибын мәгълүмат бирү характерыннан чыгып билгели, автор язганнарны коррекцияли. Әйтик, монография дип, аерым авторның яисә коллективның бер теманы киңкырлы һәм тулы ачкан чагыштырмача күләмле әсәрен атыйлар. Күпсанлы фәнни эзләнү язмаларыннан торган хезмәт тибы җыентык дип билгеләнә. Аларны «Хезмәтләр», «Язмалар», «Материаллар» һәм башка төшенчәләр астында да бастыралар. Диссертация эчтәлеген кыскача ачкан эшләр автореферат буларак чыга. Фәнни конференция материаллары гына түгел, тезислары да тупланма сыйфатында дөнья күрергә мөмкин.

Гыйльми әдәбият белән эшләгәндә, редактор кульязма язылганнан алып басмага тапшырылганчы никадәр вакыт узганлыкка игътибар итәргә тиеш. Теге яки бу хезмәт, бик күптән хәзерләнгән булуына карамастан, яңа кебек нәшриятка тапшырылган очракта, моны сизеп алган мөхәррир кульязманы актуальлек ноктасыннан игътибар белән укырга, бәяләргә тиеш. Материалны яңартырга кирәк дип тапканда, ул аны авторга кайтара, искергән урыннарын төшереп калдырырга, үзгәртергә, кайбер фикерләренә төзәтмәләр кертергә, соңгы мәгълүматларны өстәргә киңәш итә. Дөрес,

аерым ачышлар еллар дәвамында укучыга яңа булып калырга яисә теге яки бу китапның гамәли әһәмияте озак вакытлар кимемәскә мөмкин.

Гыйльми хезмәтләр белән эш итүченең кулъязма чагылдырган өлкәдән теге яки бу дәрәҗәдәге хәбәрдарлыгы, шул юнәлештә белемнәрен даими арттыруы, фәнни тикшеренү институтлары, үзәкләре белән бәйләнештә торуы мөһим. Тапшырылган кулъязмалар арасыннан басарга яраклыларын, кирәклеләрен сайлаганда, баш мөхәррир яисә тематик план өчен җаваплы кешеләр маркетинг тикшеренүләренә таяна. Икенче яктан, аларның эчтәлеге, нинди максаттан хәзерләнгәнлеге, автор уйланмасы, бу төр әдәбиятка укучы ихтыяҗы исәпкә алына.

Фәнни әсәрне басмага хәзерләү вакытында аның предметына, башкарылу максатына, гыйльми тикшеренү бурычларына, характерына, метод һәм нәтиҗәләренә игътибар итәргә кирәк. Авторның язу стиле, күзаллаулары аркасында, текстта субъективлыкка да зур урын бирелергә мөмкин. Димәк, мөхәррир субъективлык-объективлык мөнәсәбәтләрендә чама хисен белергә тиеш. Каләм иясенең шәхесе, фәнни тирәлектәге дәрәҗәсе дә редакторның автор һәм текст белән эшләү рәвешенә эз сала, ул гыйльми авторитетлар белән исәпләшмичә булдыра алмый.

Аерым мәкаләләрне эшкәрткәндә, мөхәррир игътибарын теманың актуальлегенә, тулы яисә төгәл ачылганлыгына, терминнарның дөрес кулланылышына юнәлтә. Ул бу вакытта автордан билгеләмәләрне төгәлләштерүне, җитмәгән дәлили мәгълүмат өстәүне, астөшермәләрне бер кат күздән кичерүне, аңлашылмаган сүзләргә аңлатма бирүне һәм текстка башка кирәкле үзгәрешләр кертүне сорый. Фәнни тупланмаларда чыккан хезмәтләр исә галим тарафыннан «Кыскача нәтиҗә», «Аңлатма язу»ы, «Ачкыч сүзләр», инглизчә-русча «Аннотация», «Файдаланган әдәбият исемлеге», «Автор хакында белешмәлек» белән тәэмин ителә.

Фәнни хезмәтләрне басарга хәзерләү гомуми эш методикасына нигезләнсә дә, үзенчәлекләре дә бар. Боларга редакторның:

• хезмәтнең фәннилек, дәлиллек, теманы күзаллату һәм тулылык дәрәҗәсен, ышандыру көчен билгеләве һәм шул яклардан камиллеккә ирешүе;

• текст-китап структурасына, аларның логик бәйләнешләренә, уйланманы реальләштерү һәм тел-стиль сыйфатларына игътибар итүе;

• фән үзенчәлекләрен, ул бәйләнештә торган өлкәләрне яхшы күзаллап эш йөртүе кирә.

Ышандыргыч, дәлилле булсын өчен, гыйльми язмаларның фактик материалларга байлыгы, авторның аларга дөрес интерпретация бирүе кирәк. Редактор галимнең әлеге фактларны нинди шартларда һәм ничек туплавына, кая ничек теркәвенә, төркемләвенә, аларны аңлату рәвешенә, фәнни төшенчәләр, күренешләр белән ничек бәйләвенә, очраклы һәм закончалыклы фактларны аера белү-белмәвенә игътибар итәргә тиеш. Тулы барланган, дөрес аңлатылган, бәйләнешләре хаклы табылган фактлар гына гыйльми теорияләр тууга, аларның да фактка әйләнүенә китерә.

Хезмәт структурасының – укучы игътибары мөһим өлекләргә, өлешләргә төшәрлек төзелгәнлеге, ә эчтәлегенең һәм формасының бер-берсенә нык ярашканлыгы кирәк. Фәнни хезмәтләрнең структур кисәкләре, алдан ук план рәвешендә күрсәтелмәгәндә дә, укучы тотып алырлык булырга тиеш. Бары шул чакта гына хезмәтнең эчке логикасын аңларга мөмкин, ә аны җиткерү алымнары, үз чиратында, жанр спецификасын билгеләргә булышачак.

Фәнни журналларда еш кына структурага алдан ук төгәл таләпләр куела: автордан аны кереш, төп өлеш, йомгак рәвешендә башкару сорала. Әлеге өлешләрнең галимнәргә билгеле үзенчәлекләре бар. «Төп өлеш»тә тикшерү барышы, теманы ачу чагылыш таба, теге яки бу алым-юллар ярдәмендә

нинди дә булса нәтиҗәләргә килгәнлек күрсәтелә. «Йомгак»та дәвамлы тикшерүгә нокта куела, нәтиҗәләр туплана, алар төгәл рәвештә калыплаштырыла, бер эзлеклелеккә салына, теманы алга таба үстерүгә юнәлтелгән киңәшләр бирелә, мөмкин булган эзләнү аспектлары күрсәтелә.

«Эчтәлек», материалга карап (диссертация, мәкалә, китап, җыентык…), башта күрсәтелергә дә, ахырга калдырылырга да, гомумән, булмаска да мөмкин. «Файдаланган әдәбият»ны калыплаштыруның уртак кануннары бар. Болардан тыш, редакциянең әлеге исемлекне формалаштыруга, автор хезмәтенә яисә басма төренә караган (фәнни журнал, фәнни-популяр басма, массакүләм матбугат…) үз таләпләре була.

Мөхәррир, гыйльми текстны камилләштергәндә, һәр өлешнең әһәмиятле икәнлеген онытмаска тиеш. Шул ук вакытта максат-бурычларның, тема актуальлеген раслаган урыннарның, ясалган нәтиҗәләрнең аеруча төгәл калыплаштырылганлыгы кирәк. Яклауга чыгарылган диссертацияләрдә теманы уңышлы формалаштыру да мөһим, шул сәбәпле аны редакцияләү расланганчы һәм кабул ителгәнче үк башлана. Хезмәт язылып беткәч, төрле киңәшләр исәпкә алынып, тема тагын да камилләштерелә, шуңа да карамастан үтә стилистик матур калыплаштырылмаган, фәнни югарылыкта яңгырамаган, проблема рәвешен алмаган гыйльми эзләнү темаларын да очратырга туры килә.

Шәхси фикеребезчә, татар тел һәм әдәбият гыйлеменә караган хезмәтләрнең темалары еш кына артык гади, шаблон, русларныкын кабатлый. Аларның шундыйлыгында, авторныкыннан битәр, аны тәкъдим иткән коллектив һәм раслаган киңәшмә гаебе зуррак дип уйларга кирәк. Аспирантлар, билгеле ки, мәҗбүри йөкләнгән темалардан баш тарта алмый, зур галимнәр каршында югалып кала.

Мөһим һәм катлаулы темалар күтәрелүгә, проблема үткен куелуга карамастан, тикшеренүнең «Төп өлеш»е шуларга бәрабәр эчтәлеккә ия булмаска да мөмкин. Кайчак

авторефератлар хезмәт бик тирән язылган дигән фикер уята, ә менә диссертацияләрнең үзе белән танышу әлеге фикернең кире кагылуына китерә.

Гыйльми хезмәтнең аның икенчел дәрәҗәдәге яисә чит материал белән тутырылуы, теге яки бу карашларның дәлилсезлеге, отышсыз китерелгән цитаталар, нәтиҗә ясауга хезмәт итмәүче абзацлар күплеге, бөтеннең өлешләргә дөрес бүленмәве, өлешара бәйләнешләр юклыгы, бүлек һәм бүлекчә исемнәренең үзара ярашып бетмәве, аларның эчтәлекне дөрес чагылдырмавы, теманы ачуда логика кануннарының үтәлмәве, ачык план юклык тоелып тору һәм башка билгеләр аның сыйфатсыз башкарылуын сөйли.

Татарча фәнни хезмәтләрне редакцияләүчеләр терминология анализы белән шөгыльләнми диярлек, ә менә фәнни дәрәҗә алу өчен яклауга куелган диссертацияләрне тикшерүчеләр моңа тиешле игътибар белән якын килә. Бердән, аларның хата яисә аңламыйча кулланылышын күрсәтә, төрле фәнни дисциплиналарда очраган терминнарны бутау очракларын таба, терминнар урынына профессионализмнар файдалануны һәм төшенчә төрлечә аңлашылырга мөмкин урыннарны билгели. Идеалда бу эшне редакторлар да башкарырга тиеш, әмма еш кына моның өчен аларның белемнәре җитми.

Мөхәррир, саналган гамәлләр янәшәсендә, китерелгән цитаталарның чыганаклары күрсәтелүне, иллюстрацияләрнең, сызымнарның һәм башка төр сурәтләү чараларының текст ярдәмендә эчтәлеге ачылуны, формулаларның дөреслеген, таблицалар өчен отышлы калыплар сайлануны кайгырта. Тикшеренүче үз алдына куйган максат-бурычларны ачуда бу төр материалның кирәкме-юкмы икәнлеге, текстка органик ялгану-ялганмавы турында уйлана, әһәмияте булмаганнарын кыскарта.

Фәнни хезмәт мөхәррире аның стиле турында да фикер йөртә. Ул авторның язу манерасы гыйльми коммуникация стандартларына туры килергә, урыны белән экспрессив

җөмләләр очраса да, аларның итагать кысаларыннан чыкмаска һәм хезмәтне басып китмәскә тиешлеген онытмый.

Фәнни-популяр әдәбиятка таләпләр йомшаграк, әмма аз түгел. Алар гыйльми фикер таратуның фундаменталь чарасы булып тора, шунлыктан тематик яктан шактый киң. Бүгенге көндә фән-техника ачышларын, тарихка-мәдәнияткә караган табышларны популярлаштыручы текстлар интернет челтәрендә аеруча күп очрый. Төрле газета-журналлар үзләрендә чыккан бу тип материалларны шулай ук электрон вариантларыннан да төшереп калдырмаска, сайтларына да эләргә тырыша. Бу вакытта мөхәррирләр аларның халыкның үзаңын үстерү-үстермәвен, күзаллауларын киңәйтү-киңәйтмәвен, фәнни өлкә яисә кешенең көндәлек тормышы өчен мөһимлек сыйфатын, кызыклыгын, актуальлеген, җиңел яисә авыр укылышлылыгын, аны кабул итәчәк аудиториянең белем дәрәҗәсен, ихтыяҗларын исәпкә алырга тиеш.

Фәнни-популяр мәкаләләрне, китапларны халыкка тәкъдим итүчеләрнең, теге яки бу өлкәдәге яңалыкларны чагылдырган җыентык төзүчеләрнең эше ике юнәлештә бара. Беренчедән, алар әлеге хезмәтләрнең фәннилек дәрәҗәсен бәяли белергә, икенчедән, эчтәлекне чагылдыру чараларын, юлларын анализлый алырга тиеш. Ниндидер ачышны, фикерне халыкка аңлаешлы һәм кызыксындырырлык ирештерә алганда гына, фәннәр, эзләнү өлкәләре, яңа табышлар популярлашып китәчәк. Авторның тел-сурәтләү чараларының бай арсеналыннан уңышлы файдалануы укучыны текстка тартып торачак. Фәнни-популяр әдәбиятның иллюстрацияләр белән тәэмин ителүе исә продукциянең сыйфатында, таралышында роль уйнарга мөмкин. Гыйльми хезмәтләргә куелган бихисап таләпләр арасыннан аның актуальлеген махсус ассызыкларга кирәктер.

**Белешмә әдәбиятка, сүзлекләргә куелган таләпләр.** Һәркемгә билгеле: белешмәлекләрнең төп максаты – кулланучыны үзенә кирәкле информация белән тәэмин итү.

Моның өчен, теге яки бу өлкәгә караган белгечләр, нәшрият билгеләгән төзүчеләр, авторлар, хезмәтнең максатыннан чыгып, материал туплыйлар, аның арасыннан проблеманы-теманы-төшенчәне-күренешне ачарлык дәрәҗәдәгесен сайлыйлар, системага салалар һәм мәгълүмати тыгыз текст рәвешендә язалар.

ГОСТ таләпләрендә белешмәлекләргә фәнни-гамәли характердагы кыскача информацияне билгеле бер тәртиптә урнаштырган, шунлыктан алар җиңел табылган, өзлексез укылулары күздә тотылмаган хезмәтләр кергәнлеге язылган[1]. Мөхәррир төзүчедән аларның кулланучы ихтыяҗларын исәпкә алган һәм нинди бурычлар үтәгәнлекләрен чагылдырган ачык концепциясен эшләүне таләп итә. Шушы ук эшләрне үзләре башкарган редакторлар да була.

Белешмәлекләрнең **энциклопедия** төре укучыны бөтен өлкәләргә караган яисә махсуслашкан мәгълүмат белән тәэмин итә. Аларны алфавит тәртибендә яисә ниндидер системада бирәләр. Катнаш структуралы энциклопедияләр дә очрый. Татарларда бу төр басмаларны эшләү тәҗрибәсе бик кечкенә, аңа мисалга соңгы елларда дөнья күргән «Тукай энциклопедиясе»н китерергә мөмкин. Ул алфавит тәртибендә төзелгән.

Энциклопедияләрдәге мәкаләләр үзара тыгыз бәйләнгән, бер язмада чагылганны икенчесе яңадан кабатламый, күрсәтеп кенә уза торган һәм төшенчәне шактый тулы, әмма хезмәт биргән мөмкинлек кысаларында яктырткан булырга тиеш, чөнки һәр төшенчәне киң чагылдырам дип, басмага сайланган күләм, күзалланган матди як чикләреннән чыгып булмый.

Гадәттә, пландагы энциклопедиянең күләмен һәм акчалата чыгымнарын якынча чамалау, аны бер структурада күзаллау,

[1] ГОСТ 7.60-90. Издания. Основные виды. Термины и определения. Введен 01.01.91 // Стандарты по издательскому делу. – М., 1998. – С. 176.

өлкәне яисә теманы тиешле дәрәҗәдә иңләү, материал җиткерү юлларын ачыклау, төрле төркемгә караган язмаларга күләм билгеләү, күрсәткечләр һәм аңлатмалар системасын булдыру өчен, ***сүзлекчә*** (словник) төзиләр. Ул эш барышында тулыландырылырга мөмкин. Сүзлекчә авторларга темаларны бүлешү өчен дә бик җайлы. Иллюстрацияләр туплаганда, библиографик материал хәзерләгәндә дә, беренче чиратта, аңа таяналар.

Энциклопедияләрнең, материал сайлау һәм җиткерү максатыннан караганда, ***фәнни, популяр, фәнни-популяр*** төрләре була, һәм һәрберсе аерым катлам укучыга адреслана. Шул ук вакытта әлеге хезмәтләрнең теләсә кайсыннан галим дә, иҗатчы да, иҗаттан һәм фәннән читтә торган гади укучы да файдаланырга мөмкин. Редакторның төп максаты – гыйльми хилафлыкларны барлау, юкка чыгару. Энциклопедияләр, кемгә генә атап төзелмәсен, коллектив тикшерү узарга, озаклап һәм җентекле хәзерләнергә, төрле хаталардан азат булырга тиеш. Аның зур тиражлар белән чыгуын, халыкның грамоталылык, белемлелек дәрәҗәсенә йогынты ясавын онытырга ярамый.

Информация характерына нигезләнеп, энциклопедияләр ***универсаль, махсуслашкан, региональ*** төрләргә бүленә. Алар үз эчләрендә дә төркемләнә. Мәсәлән, махсуслашкан энциклопедияләрнең теге яки бу өлкәгә караганнары, шәхсиләре, тематиклары очрый. Алар бер томнан гына торырга да, күптомлык рәвешендә басылырга да мөмкин. Мөхәррир икенче очракта материалның китапларга тигез бүленешен һәм теге яки бу мәкаләнең тиешле томга керүен кайгырта. Редактор шулай ук, том саннарын арттыру өчен, энциклопедиягә чит материал кертеп тутыру кебек ямьсез күренешкә дә каршы тора.

Энциклопедияләрне, гадәттә, коллектив хәзерли, димәк, андагы һәр кеше хезмәтнең тиешле дәрәҗәдә чыгуы өчен үзендә җаваплылык хисе тоярга тиеш. Авторы танылган

галим дип, эчтәлеге йомшак, буш текстларны күләмле калдырырга, ә танылмаганының тирән фикерле мәкаләләрен урынсыз кыскартуларга юл куярга ярамый. Мондый гамәлләрне чикләү – тәүге нәүбәттә, хезмәт өчен бар кешедән дә җаваплырак баш мөхәррир бурычы. Энциклопедияләргә ниндидер темага караган берничә материал килсә, редактор араларыннан иң тулысын һәм дөрес формалаштырылганын сайлый. Бу вакытта ул, әлбәттә, хезмәткә материалы кермәгән авторларның ризасызлыгына очрарга мөмкин. Димәк, аңа ситуацияне аңлату бурычы да йөкләнә.

Алдан ук темаларны чагылдыру мәйданын ачыклау шактый кыен. Сүзлекчә төзелгәндә, ниндидер проблемага кагылышлы барлык материалны да күзаллап, белеп бетереп булмый. Кайвакыт хәзерлек белешмәлекләренә кергән темалар энциклопедиядән төшеп тә кала. Әйтик, әлеге сүзлекчәләр язучы әсәрләрен, аларда очраган төрле исемнәрне, атамаларны, әдәбиятта күпмедер эз калдырган каләм ияләрен, әдип яисә галимнең туганнарын, аралашкан даирәсен һ.б.ларны чагылдырды ди. Фәнни эзләнүләр барышында аларның кайберләренә кагылышлы бер генә мәгълүмат та табылмаска мөмкин, ә менә яңа темалар өстәлгәннән-өстәлә барачак. Тукай энциклопедиясен эшләү моны ачык күрсәтте.

Аерым хезмәтләрдә терминның мәгънәсен генә аңлатып узган дефиницияләр, кече күләмле белешмәләр янәшәсендә тема киң ачылган мәкаләләр дә очрый, хәтта катлаулы төзелешле монография рәвешен алганнары да юк түгел. Язмаларның саны, күләме, темаларның мөһимлегеннән һәм зурлыгыннан чыгып, шулай ук коллектив рәвештә билгеләнә. Тукай энциклопедиясен төзегәндә, мәсәлән, теге яки бу шәхеснең Тукай фәненә керткән өлеше, шагыйрьгә мөнәсәбәтле язмаларының саны, аларның тирәнлеге, Тукайга бәйле бүләкләре, Тукай белән бәйләнеш кысалары, туганлык җепләре, шәхесара дуслык дәрәҗәсе, автор белешмәлеккә

хәзерләгән мәкаләнең күләме, тирәнлеге һ.б. бик күп нәрсәләр исәпкә алынды.

Каләм ияләреннән килгән кулъязма белән белән танышканда, мөхәррир, аның шул рәвешчә язылуы үзен аклыймы, мәкалә куелган нормалар кысасыннан чыкмыймы, дигән сорауларга җавап эзли. Шулай ук аның тирән, тыгыз, кызыклы язылганлыгын кайгырта. Белешмәлекләр хәзерләүгә авторларны тарту, аларның фәнни исеменнән һәм фән мәйданындагы авторитетыннан бигрәк, теге яки бу өлкә, проблема буенча туплаган реаль белеменә бәйле булырга тиеш.

Энциклопедия язмалары бер-берсен кабатламасын, бер үк мәгълүмат төрле җирдә очрамасын өчен, текст эче ишарәләре, күрсәткечләре кулланыла. Мәйданны мөмкин кадәр күбрәк мәгълүматка файдалану да редакторның күз уңыннан чыкмый. Ул алдан ук кыскартылмалар исемлеген төзи, хезмәт өчен җаваплы редколлегияне аның белән таныштыра, төзәтмәләр кертелгәннән соң, яңадан бастырып, авторларга тарата. Әлеге исемлек энциклопедиядә аермачык бирелергә тиеш. Укучы, кыскартылмаларга мөрәҗәгать итмәгәндә дә, контексттан чыгып, мәгънәләрен аңлый алса, аңа күбесе элек язылган белешмәлекләрдән таныш яисә гомумән киң кулланышлы булса, бигрәк тә яхшы. Димәк, редакторның төшенчәләрне кыскарту вариантлары турында ныклап уйлануы, башка хезмәтләрдәге андый очраклардан, шартлы билгеләрдән, аббревиатуралардан танышлыгы кирәк.

Мәртәбәле энциклопедияләрдә еш кына ил башлыкларының, төрле рангтагы башка җитәкчеләрнең «Мөрәҗәгать»ләре, җаваплы редакторның хезмәткә алып кереп китүче «Сүз башы» урнаштырыла. Белешмәлекләрнең алгы өлешендә редакция коллективының, аны хәзерләүгә заказ биргән нәшрият директорының басманың максат-бурычлары, кулъязманы хәзерләү тарихы турында сөйләгән һәм башка эчтәлектәге мәкаләләре дә очрый. Берничә алсүз булганда, редактор шулай ук алардагы фикерләрнең

үзара кабатланмавын, текстларның кирәгеннән тыш киңәеп китмәвен кайгырта, сөйләмнәрне төрле тип хаталардан арындыра.

Мөхәррир мәкалә янына урнаштырылган рекомендация характерындагы әдәбият исемлегенең гомуми таләпләргә җавап бирерлек формалаштырылуын, дөрес мәгълүмат алып килүен тәэмин итә. Ул автордан аны киңәйтүне сорарга мөмкин. Кыскартулар шулай ук аның белән килешеп һәм библиографик материалга бирелгән күләмнән чыгып хәл ителә.

Энциклопедияләргә ГОСТ мәҗбүри куйган таләпләрнең үтәлеше өчен шулай ук редактор җаваплы. Боларга, беренче чиратта, хезмәтнең ярдәмче күрсәткечләр белән тәэмин ителеше керә, аларның исә предметлы, тематик, исемле һәм башка төрләре була.

**Сүзлекләрн**ең төп берәмлеге – ***мәкаләчек***. Ул эчтәлеге ачылырга тиешле төп сүздән башлана. Кечкенә күләмле әлеге мәкалә бербөтен булып оешырга яисә, аңлатма кебек, мөһим өлештән соңгы өстәмә мәгълүматны аерым абзацка чыгарырга мөмкин. Кайбер хезмәтләрдә зуррак материалны абзацларга бүлү дә очрый.

Сүзлекчәләр төшенчәләрне сайлау характерын аңларга булыша. Сүзләрне, хезмәткә алфавит тәртибендә генә түгел, тематик та, башка бер принципка нигезләнеп тә урнаштырырга мөмкин һәм аларны төркемләүнең отышлылыгы өчен, беренче чиратта, редактор җаваплы.

Редактор, сүзлекләрнең кайсы төре (терминологик, энциклопедик…) белән генә эшләмәсен, аңлатма-билгеләмәләрнең төгәллеген, сайланган тәртиптә бирелүен, техник яктан бердәй калыплаштырылуын кайгырта. Ул тел сүзлекләрендәге барлык мәкаләгә ***информатив, коммуникатив, норматив*** яссылыклардан якын килә, чөнки һәр берәмлек укучыга нинди дә булса мәгълүмат бирергә, сөйләм байлыгы рәвешендә күрсәтелергә, аның мәгънә киңлекләре, язылыш-укылыш нормалары ныгытылырга тиеш.

Терминологик белешмәлекләрне редакцияләгәндә, төшенчә эчтәлегенең дөрес һәм тулы ачылуы аеруча мөһим. Бу төр сүзлекләр дә лексеманың төгәл язылышын күздә тотып эшләнә. Мәкаләчекләрдә статистик мәгълүматлар китерелгән очракта, редактор автордан аларның чыганакларын күрсәтүен таләп итәргә, факт буларак дөреслегенә ышанырга тиеш.

С.Г. Антонова, В.И. Васильев, И.А. Жарков һәм башкалар авторлыгында чыккан «Редакторская подготовка изданий» (2004) хезмәтендә төрле тип басмаларны, шул исәптән сүзлекләрне, аның күпсанлы төрләрен хәзерләүгә якын килү бик җентекле тасвирланган.

**Белем бирү басмаларын редакцияләү.** Мөхәррир уку-укытуга караган китапларның теге яки бу өлкәгә мөнәсәбәтле мәгълүматларны җиткергән, предметның максат-бурычларын үтәүгә йөз тоткан чара икәнлеген исеннән чыгармый. Укучыларны белемгә һәм төрле күнекмәләргә ия итү янәшәсендә педагогик бурыч барлыгын да онытырга ярамый. Бу бигрәк тә төрле уку йортлары, тәрбия учаклары өчен чыгачак хезмәтләргә карый. Өлкәннәрне, урта яшьтәгеләрне укыту өчен төзелгән махсус басмалар да була, аларда мәгълүмат бирү, күнекмәләр формалаштыру алгы планга чыга. Димәк, автор һәм мөхәррир дәреслекләрнең яисә уку әсбапларының адресатын ачык күзалларга тиеш.

***Программа-методик*** (уку планы һәм программасы), ***укыту-методик*** (методик күрсәтмәләр, киңәшләр, гамәлият программалары, ***практик*** сәгатьләр өчен хәзерләнгән биремнәр һәм сораулыклар), ***гыйлем бирүче*** (дәреслекләр, уку әсбаплары, лекция конспектлары яисә курслары), ***ярдәмче*** (хрестоматияләр, уку китаплары, бирем-күнегү җыентыклары, практикумнар) белем бирү басмаларын хәзерләүчеләр һәрберсенә, предмет өлкәсен ачык күзаллап, төргә, төркемчәгә куелган таләпләр ноктасыннан якын килә.

Соңгы вакытта белем бирү басмалары тулы комплекс рәвешен алды. Аны махсус белгечләр бергәләп

планлаштырса, бер үк авторлар яисә авторлар коллективы язса, бер үк кешеләр тикшерсә, эшнең нәтиҗәсе уңышлырак чыга. Мөхәррирләр комплексны формалаштырган мөстәкыйль кисәкләрнең үзара ярашуын, бер-берсен тулыландыруын, эчтәлекләренең күпмедер кисешүен, әмма кабатланмавын, предметны укытуда төрле вазифалар башкаруын истә тота. Әлеге хезмәтләрнең янәшә яисә кыска вакыт аралыгында редакцияләнүе шулай ук отышлы, чөнки, аларны хәзерләгәндә, уку йортлары кабул иткән эш планнары, дәреслекләргә һәм белем бирү әсбапларына куелган таләпләр үзгәрергә, югары оешмалардан белем бирү барышына бәйле яңа күрсәтмәләр килергә мөмкин. Андый очракларда төрле яңалыкларны күздә тоткан төзәтмәләр дә китапларга берьюлы кертелә ала, хезмәтләр «искереп» дөнья күрми.

Югары уку йортларында хәзерләнгән укыту-методик комплекслары электрон формаларда да башкарыла, чөнки мөгаллимнәр, укыту планнарындагы үзгәрешләргә, бигрәк тә фәннәргә караган сәгатьләрнең артуына-кимүенә бәйле рәвештә, аларны һәр елны яңадан карап чыга һәм белем бирүнең гомуми барышы өчен җаваплы кешеләрдән раслата.

Белем бирү басмаларына һәм эчтәлеккә, һәм формага бәйле катгый таләпләр куела. Моны авторлар яхшы белә, мөхәррирләр дә әлеге таләпләр үтәлешенә җаваплы карарга тиеш. Интернет челтәрләрдә таралган белем бирү программаларының төрлечә калыплаштырылганлыгы югары уку йортларында хәзерләнгән инструкцияләрдә аермалыклар булуны күрсәтә. Әлеге төрлелек аларны башкарган авторларның укыту-методик комплексына куелган соңгы бердәм таләпләрне белмәве яисә алар белән исәпләшмәве турында да сөйләргә мөмкин.

Дәреслек программаларның предмет өлкәсен тулы тасвирларга тиеш булса да, лекцияләр курсы яисә конспекты, уку әсбаплары предметны өлешчә дә ача ала. Димәк, редактор аларга шуны белеп якын килә. Дәреслектәге

мәгълүматларның укыту әсбаплары, методик күрсәтмәләр һәм башка төр ярдәмче хезмәтләр өчен таяныч ноктасы икәнлеген дә онытырга ярамый.

Дәреслекләрне отышлы төзү – шактый катлаулы эш. Бердән, автор предметка караган белемнәрне системага сала, икенчедән, темаларны бер эзлеклелектә, җиңелдән катлаулыга таба ача, белем алучыларның моңа кадәр туплаган мәгълүматларын һәм аларны ни дәрәҗәдә кабатлау яисә ныгыту кирәклеген, теге яки бу материалның башка предметларда кайчан, нинди күләмдә ачылуын да исәпкә ала. Моны гамәлдә башкару бик авыр. Бигрәк тә ана теле һәм милли әдәбият дәреслекләре язу кыенлык тудыра. Әйтик, укыту программаларында күпчелекнең ана теле булган һәм сәгатьләр саны күп бирелгән рус теле бар. Предмет өлкәсе бер үк булса да, мәктәпләрдә ихтыяри гына һәм аз сәгатьләрдә укытылган татар теле дәреслеген аңа ничек яраштырырга? Бик нык чикләнгән вакытта өйрәтeләчәк милли әдәбият тарихын башка сүз сәнгатьләренеке дәрәҗәсендә ничек чагылдырырга? Бу сорауларны тагын да дәвам итәргә мөмкин.

Кулъязма белән танышучы мөхәррирнең аны кулланган укытучының гыйлем ирештерүгә, дидактикага, педагогикага караган мәсьәләләрне ничек хәл итәчәген ачык күзаллавы кирәк. Ул, басма эчтәлеген анализлаганда, кереш (булган очракта), төп өлеш (бүлек һәм бүлекчәләр, параграфлар), йомгак предметка нисбәтле гыйльми концепция белән ярашамы; хезмәт мөһим проблемаларны адресат аңларлык һәм тулы ачамы, дәлилләре, фактлары җитәрлекме; анда материал тәкъдим итү система рәвешен алганмы, кебек күпсанлы сорауларга җавап эзли. Мөхәррир шулай ук автор сайлаган стильнең уңышлымы-уңышсызмы икәнлеген тоярга, предмет үзенчәлекләренә туры киләме-юкмы икәнлеген күреп алырга тиеш. Ул бигрәк тә терминнарның һәм төшенчәләрнең дөрес кулланылышын күзәтә, аларга бирелгән аңлатма-билгеләмәләрнең камиллеген кайгырта. Дәреслекләрдә

уңышсыз формалаштырылган билгеләмәләр еш очрый, хаталар да бөтенләй үк юк түгел. Авторлар да, мөхәррир дә теге яки бу төшенчәне кайсы галимнең ничек аңлатканлыгын белергә һәм гыйлем бирү басмаларында моңа кадәр язылган хезмәтләрдәге иң отышлы билгеләмәләрдән генә файдаланырга тиеш.

Терминнар аерым предметның һөнәри нигезен чагылдыра, аларны үзеңчә, башкалар кабул итмәгәнчә аңлатырга ярамый. Кайбер төшенчәләргә дистәләрчә билгеләмә бирелгән. Югары уку йорты дәреслекләрендә галим яңача, үзенчә аңлатма-билгеләмәләр тәкъдим итә икән, студентларга аның башкаларныкыннан ни дәрәҗәдә аерылып торуын һәм сәбәбен аңлатып китәргә тиеш. Мөхәррирләр үз эшләрендә күп очракта дәүләткүләм һәм өлкә терминологик стандартларына таяна, аерым сүзләрнең, терминнарның төрле мәгънәгә ияләгән исәпкә ала.

Редакторның дәреслек белән эше аппаратны камилләштерү рәвешендә тәмамлана. Боларга, иң беренче чиратта, юнәлеш бирүче төргә караган «Кереш», астөшермәләр, исемлекләр, күрсәтмәләр, сүзлекчәләр, «Йомгак» һәм башкалар керә. Мөхәррир аларның тиешле күләмдәме икәнлеген, тулылыгын, хатасызлыгын тикшерә.

Оештыручы аппаратка сораулар, биремнәр, күнегүләр карый. Алар темага туры килергә, аудиториянең яшь үзенчәлекләрен исәпкә алырга тиеш. Укучыларның ничек җавап бирүе, күнегүләрне нинди тизлектә, төгәллектә башкаруы бирем һәм сорауларның дөрес формалаштырылуыннан, күнегүләрдә хаталар китмәвеннән дә тора. Бүгенге көндә оештыручы аппаратта төгәлсезлекләр еш очрый.

Кайбер язучылар һәм мөхәррирләр әдәби китапта аннотация булу-булмауга, эчтәлегенең тиешле таләпләргә җавап бирмәвенә игътибар да итми. Алар һәрвакыт булырга тиеш. Фәнни хезмәтләр һәм уку әсбаплары, дәреслекләр өчен бу таләп аеруча катгый куела. Аннотацияләр язманың яисә

китапның эчтәлеген чагылдыра, язылу максатын күрсәтә, адресатын тәгаенли. Кулланучы, тәүге битен ачуга ук, китапның кем өчен чыгарылганлыгын, нәрсә хакында икәнлеген белергә һәм сатып алыргамы-юкмы, укыргамы-юкмы, аңа кирәкме-юкмы, кебек сорауларга җавап табарга тиеш. Бу вакытта уңышлы сайланган атама, тулы һәм төгәл язылган «Эчтәлек», «Кушымта»лар да ярдәмгә киләчәк. Болардан тыш, хезмәтнең мәгълүматка, башкарылу максатына, төп эчтәлеккә бәйле тибы да дөрес билгеләнгән булуы мөһим.

**Матур әдәбият һәм мөхәррир хезмәте.** Сүз сәнгатенә караган проза, поэзия һәм драма әсәрләренең үз жанр сыйфатламалары бар. Нәфис текст эстетик-этик, коммуникатив, белем бирү бурычларын үти, кешедә чынбарлыкка җәмгыять көткән мөнәсәбәтләр формалаштыра. Эстетик функцияләрне дөрес юнәлештә башкарган матур әдәбият укучыда камиллеккә омтылыш уята, аның күңел дөньясын, хисләрен баета, зәвыгын тәрбияли, ә этик функцияләр аның рухи кыйммәтләрне, тормыш күренешләрен бәяләү ориентирларын барлыкка китерә.

Мөхәррир әдәби әсәрләр эчтәлегенең җәмгыять кабул иткән әхлакый нормаларны алга сөрүен кайгырта. Ул шулай ук нәфис текстларның тормышчанлыгы, иҗтимагый-тарихи вакыйгаларны дөрес сурәтләве һәм шәрехләве, кеше күзаллауларын булдырудагы роле, иҗтимагый барышка тәэсире, укучыда һәм тәнкыйтьтә китапка карата барлыкка киләчәк мөнәсәбәт кебек мәсьәләләрне дә күз уңыннан чыгармый.

Мөхәрирнең нәфис текст эчтәлеген дөрес аңлавы, төп идеясен ачыклый алуы мөһим. Ул камилләштерәчәк әсәргә аның аерым бер чорны һәм вакыйга-күренешләрне куелган проблемаларны чишү өчен кирәкле дәрәҗәдә яктырту-яктыртмавы; әдип кулланган фактларның дөреслеге-хаталыгы, мөһимлегекирәксезлеге, кимлеге-артыклыгы, тулылыгы; эчтәлекнең оригинальлеге, яңалыгы, заманчалыгы, тормышта барган конфликтларның әсәргә ничек күчүе һәм чишелүе;

персонажларның уңышлы-уңышсыз сайланышы, характер буларак ачылу-ачылмавы, үзара төркемләшүе, нинди идеалларга, максат-бурычларга хезмәт итүе кебек күпсанлы яссылыклардан якын килә. Мөхәррир автор язган әсәрнең, басылып чыкканнан соң, аныкы гына булудан туктавын, укучы, милләт, ил байлыгына әверелүен онытмаска тиеш. Әдәби сүз – кемнеңдер җан авазы, массаларга рухын ачуы гына түгел, җәмгыять кулындагы корал да, халыкның һәм аерым инсанның таяныч ноктасы да, тормыш дәреслеге дә.

Язучы иҗат вакытында тарихи хәтердән, үзен камап алган тирәлектәге күренешләрдән, җәмгыятьтә барган вакыйгалардан, дөнья хәлләреннән файдалана. Ул, озак вакытлар туплаган байлыгыннан чыгып, теге яки бу темага, сюжетка әсәр язу идеясенә килә; аннан әлеге уйланманы тормышка ашырыр дәрәҗәдә кирәкле материалны тагын бер кат барлый; җитмәсә, яңадан эзләнеп баета; моның өчен документларга, архивларга, башка кешеләргә мөрәҗәгать итә. Әдип тормышны чынбарлыктагыча, әмма сайланышлы тасвирлый, шул ук вакытта нинди итеп күрергә теләгәнлеген дә сөйли. Нәкъ менә шул сәбәпле әдәби әсәр укучыда яшәү идеалы формалаштыра да.

Язучы текст структурасын, тел-сурәтләү чараларын, әдәби алымнарны сәнгати уйланманы тормышка ашыру максатына ярашлы итә. Ул сөйләмнең һәр элементын, кечкенә берәмлекләрен яза башлаганда ук күзаллап бетерә алмый. Шул ук вакытта әдип башында, бигрәк тә күләмле текстлар иҗат иткәндә, аларның гомуми схемасы, сюжеты, шул сюжетта урын алачак төп персонажлар алдан ук яшәргә тиеш. Дөрес, әдәби уйланманы тормышка ашыру барышында ул тулыланырга, тараерга, хәтта бөтенләй үзгәреп китәргә мөмкин. Әйтик, прозаик хикәя язарга алына, әсәр материалы аны повестька алып чыга. Роман иҗат итәргә тотынган әдип кайчак повесть язу белән канәгатьләнә. Каләм иясе төп эшкә керешкәч, алдан күзалламаган бик күп нәрсәләр калка,

аңа теге яки бу дәрәҗәдәге проблемаларны чишәргә, әдәби уйланмасына төзәтмәләр кертергә туры килә.

Шигырь иҗат итү белән эш башкачарак тора. Күпчелек очракта ул ниндидер ситуация вакытында яисә аннан соң автомат рәвештә туган сыман тоела. Бу табигатьтән талантлы каләм ияләрендә шулай. Алар еш кына баш миендә мизгеллек уйлап табу барышын сизми дә кала, әнә шуңа күрә шигърият илаһияткә тиңләнә дә. Поэма, баллада, мәсәл кебек әсәрләрне язуга исә тиешле хәзерлек белән керешәләр.

Әдип тасвирлаган тормышның хәтта фантастик әсәрләрдә дә укучы аңларлык дәрәҗәдә булуы кирәк. Кызганыч ки, кайчак кечкенә генә шигъри текстта да авторның ни әйтергә теләгәнлеге ачык булмый. Мөхәррир, аңлаешлылыкны бәяләү янәшәсендә, язучы уйланмасының тормышка ашырылу дәрәҗәсен дә чамаларга тиеш. Автор «Эчтәлек»тә күрсәткән яисә әсәр жанрында чагылган уйланмалылык масштабы тормышка ашканмы-юкмы икәнллек тә – һичшиксез, мөхәррир җавап табарга тиешле сорау.

Нәфис текст – сәнгать әсәре. Димәк, ул редактор тарафыннан сәнгатилек һәм образлар яссылыгында бәяләнә. Мөхәррир, әдәби текст нигезендә образ, образлы фикерләү ятканлыгын белеп, образ сыйфатламаларын, ул башкарган функцияләрне ачыклый. Мәгълүм булганча, образларга ассоциативлык, күп мәгънәлелек, бөтенлек һәм башка сыйфатлар хас. Алар теге яки бу хисне тудыруга, идеяне уздыруга булыша. Әдәби әсәр белән танышучы үзен образлар дөньясында хис итсә, тасвирланган вакыйга-күренешләрне геройлар шикелле кичерсә, бәяләсә, үзендә әсәрнең көчле тәэсирен тоя. Укучы аерым каһарманнарны әдип белән тиңләштерергә, алар сүзендә аның фикерен ишетергә, вакыйга-хәлләр хикәяләүче исеменнән җиткерелгәндә, аны автор сыман кабул итәргә мөмкин. Бу күренештә дә әсәрнең тәэсирлелек сыйфаты, бигрәк тә эчтәлекнең һәм аны җиткергән сөйләмнең ышандыру көче күренә.

Автор белән хикәяләүче герой туры килмәгәндә дә, әсәр язучы хакында мәгълүмат бирми калмый. Теләсә кайсы күләмлерәк нәфис текст каләм иясенең белем дәрәҗәсе, күзаллау офыгы, зәвыгы, уй-хыяллары, нинди идеяләрне алга сөрүе, кайсы проблемаларны хәл итәргә теләве, иҗтимагый-сәяси карашлары һәм башка бик күп нәрсәләр турында сөйли. Ул, иң мөһиме, авторның нинди рухи кыйммәтләргә өстенлек бирүен күрсәтә. Болар язучының үзе иҗат иткән персонажларга мөнәсәбәтендә, конфликт үстерелешендә һәм чишелешендә, ул яратып тасвирлаган уңай геройларның уй-фикерләрендә, текст укучыга ирештергән мәгълүмат күләмендә, аның дөреслек дәрәҗәсендә чагылыш таба.

Образларның күпмәгънәлелеге, төрле ассоциацияләргә корылуы укучы аңын да эшкә җигә, басма продукциядән файдаланучының фикерләү дәрәҗәсен үстереп җибәрә. Әдип тасвирлаган материаллар кешенең күзаллау офыгын киңәйтә, аны гомумидән – тәгаенләштерүгә, тәгаеннән гомумигә килергә күнектерә. Нәфис текстта, образлар янәшәсендә, әдәби детальләр дә зур роль уйный. Алар, күләм ягыннан да мул булып, теге яки бу күренешне, персонажларны, ул куелган шартларны ачуга, аларны тулы канлы тудыруга хезмәт итә.

Язучының иҗат манерасын башкаларныкыннан детальләр оригинальлеге, аларның кайчан, ничек һәм ни сәбәпле кулланылышы, башка әдәби алымнар белән ярашу-ярашмавы, телгә осталыгы, файдаланган сүзлек составы, сөйләм төзелеше, әлеге сөйләмдә грамматик кагыйдәләрнең үтәлеш дәрәҗәсе, фикерләү осталыгы аерып куя. Шул ук вакытта нәфис текстның уңышлы табылган әдәби детальләргә, үзенчәлекле тел-сурәтләү чараларына муллыгы язучының тормышны ни дәрәҗәдә белүенә, аңлавына, күзәтү-чагыштырутотып алу кебек сәләтләренә, хәтта пассив сүзлек байлыгына да барып тоташа.

Редактор образны – сәнгати детальдән, ә анысын, үз чиратында, гади тәфсилләштерүдән аера белергә тиеш. Югары уку

йортларында белем бирүче филологларның да әдәби детальне образ белән бутавына, хәтта символ санавына да тап буласың. Төрле тип образлар (күренеш, предмет, герой һ.б.) күпсанлы хәрәкәтләрдән, эш-хәлләрдән, предметлардан, сыйфатлардан оеша. Бер генә күләмле әсәр дә алардан башка яши алмый.

Әдипнең күренешләргә, объектларга хас барлык үзенчәлекләрне, гамәлләрне атап чыгуы мәҗбүри түгел. Гадәттә, автор аларны текстка образларны күзаллатырга җитәрлек санда гына кертә. Хәтта кызыклы дип сайланган әдәби детальләр дә, күпкә китсә, әсәрне чуарлый, аның сәнгати сыйфатын йомшарта. Аларга кытлык та, артык тәфсиллек тә язучының талант һәм тоем дәрәҗәсен күрсәтеп тора. Моны редактор тотып алырга һәм язучыга каләмен чарлау юнәлешендә киңәшләр бирергә тиеш.

Каләм иясе кече күләмле әсәрендә фикерне уймак әйтүгә, образларны чагыштырмача тыгыз куллануга, хисси якның калкулыгына, сюжет оригинальлегенә, теге яки бу образның аерылып торуына, телнең үтә камиллегенә омтыла. Роман-повестьларны иҗат иткәндә, әдип аларның гомуми структурасы, сюжет сызыклары, сюжет сызыгына караган элементларның урыны-тәртибе, геройлар саны, персонажларның үзара мөнәсәбәте, төп геройлар һәм конфликт турында ныклап уйлана. Романнарның сюжет үстерелеше шактый катлаулы, аны язуга хәзерлексез, башында текстның якынча структурасы булмаган килеш тотына алмыйсың.

Күләмле эпик әсәрләр тормышның мөһим күренешләрен күрүне, шулар арасыннан кирәклесен сайлый белүне, вакыйгаларны масштаблы тасвирлау осталыгын, чорны һәм герой куелган шартларны төбенә төшеп аңлауны таләп итә. Романнар чынбарлыкны төрле яктан ача, күпсанлы проблемалар күтәрә. Эпопеялар тагын да зуррак вакыт аралыгын иңли, аларда үткәндәге, бүгенге, киләчәктәге хәлләр тоташырга, өч заман бер-берсенең урыннарын әледән-әле алмаштырырга мөмкин. Хронотоп тормыш күренешләренең,

зур иҗтимагый-сәяси вакыйгаларның элеккедән килгән сәбәпләрен, бүгенгедәге шартларын күрсәтергә, киләчәктә китереп чыгарырга мөмкин нәтиҗәләрен фаразларга мөмкинлек бирә.

Мөхәррир нәфис текстларда характерлар бөтенлеге, эш-гамәлләренең мотивлаштырылуы, логиклыгы, әсәр композициясен тотып торучы үзәк персонажның сюжет дәвамында алмашынмавы, саклануы һәм калку тудырылуы кебек мәсьәләләргә игътибар итә. Ул авторның төрле язмышлы геройларны бер җепкә бәйли алу-алмавы, язмышларын ничек һәм кай ноктада кисештерүе турында уйлана. Күләмле әсәрләрдә геройларның төрле позициядәге, ягъни беренче, икенче, өченче пландагы сурәтләнеше була, автор бу хакта әсәрнең башыннан ахырынача онытмаска тиеш. Әсәргә килеп кергән артык күренешләр дә, бернинди вазифа башкармаган геройлар да аның бөтенлеген юкка чыгара. Мөхәррир боларның һәрберсен игътибар үзәгендә тота.

Укучы үзен автор белән бергә иҗат итүче итеп тоярга, текстны кабул иткәндә, фантазиясенә тагын да киңрәк урын бирергә, кичергән вакыйгаларның тәэсирендә озак вакытлар яшәргә мөмкин. Редактор, алда санаганнарның барысына ирешкәндә генә, әдипнең матур әдәбият алдында торган өч, ягъни иҗтимагый, эстетик, тәрбияви бурычны ахырынача үти алганлыгын белә.

Мөхәррир, нәфис текстны бәяләүгә күптөрле критерийлардан якын килә. Аның сәнгатилек дәрәҗәсен (эчтәлек һәм форма берлеген, бөтенлеген, теле камиллеген һ.б.ны), эмоциональ тәэсирен бәяләгәч, автор стиленең оригинальлеген, ул кулланган материалның яңалыгын билгеләгәч, әсәр басарга яраклымы-юкмы, аны алга таба ни дәрәҗәдә камилләштерергә кирәк, әллә шушы хәлдә чыгарыргамы, ул укучысын табармы, аның социаль әһәмияте бармы, сорауларына җавап эзли.

Кыскасы, әдәби әсәрне анализлау барышында мөхәррир аның сәнгатилеген, хиссилеген, укучыга субъектив тәэсирен,

тел сыйфатларын исәпкә ала. Ул аның жанр спецификасын аңларга, әдәбият теориясе белән таныш булырга тиеш.

**Реклама һәм аңа куелган таләпләр.** Реклама сүзе латинчадан (*reclamo* – кычкырам, өндим) килеп чыккан. Төшенчәнең эчтәлеге тәүге таралыш ысулына бәйле. Борынгы заманнарда сөрән салучылык, шул рәвеш белән теге яки бу мәгълүматны тарату хәтта һөнәр дәрәҗәсендә йөргән. Кычкырып товар тәкъдим итү Көнчыгыш, шул исәптән безгә яхшы таныш Төркия базарларында һаман да саклана. Радио-телевидение хезмәте, басма сүз барлыкка килгәнче, кулланучылар товар сыйфатлары хакында сатучыдан, тирәяктагы кешеләрдән белешкән һәм гамәли куллану вакытында танышкан. Бүгенге көндә инде реклама газеталары да, телеканаллары да бар. Реклама, күп тиражлы басма продукциядән тыш, интернетта, телефонда сатуга чыгарылган товар капларында, товарларның үзләрендә дә дөнья күрергә мөмкин. Бигрәк тә 2000 еллар башында кычкырып рекламалау да киң таралган иде, хәзер ул кимеде, әмма реклама кәгазьләрен урамнарда тарату һаман да җанлы бара.

Әлегә кадәр тәрҗемә ителмәгән реклама төшенчәсе татар сүзлекләрендә «файдаланучыларны, кулланучыларны, сатып алучыларны, тамашачыларны һ.б.ларны тарту, аларның игътибарын җәлеп итү максатында үткәрелгән чара»; кемнең дә булса дикъкатен юнәлтү өчен, берәр кеше яки берәр нәрсә турында хәбәр, мәгълүмат бирә, игълан итә торган белдерү, плакат, афиша, вывеска һ.б.» дип аңлатыла[1]. И. Низамов аны татар сөйләменә хас вариантта – «реклам» рәвешендә куллана.

Реклама – товар файдасына башкарылучы түләүле хезмәт. Аны хәзерләүчеләр кулланучы игътибарын җәлеп итүне күздә тота. Кемнеңдер табыш алуын максат иткән реклама

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – Б. 58.

аерым бер кешегә генә юнәлтелми, ә массаларга ирештерелә. Теләсә кайсы игълан, хәтта сатып алучыны, куллanучыны күздә тотып хәзерләнсә дә, реклама саналмый. Товар яисә нинди дә булса хезмәт хакында белдерсә, аның иясен ачыкласа гына, җиткерелгән мәгълүмат реклама дип атала. Ул товар җитештерүче һәм кулланучы арасында тора, әнә шуңа күрә аларны бер-берсенә якынайтырга алынган реклама хезмәткәрләре, шул исәптән мөхәррирләр дә арадашчылык вазифасын башкара.

Замана шаукымына ияреп, башка күп кенә төшенчәләр белән бергә, реклама сүзе дә тормышыбызга көннән-көн ныграк үтә. Бу хәл, бер яктан, социалистик система җимерелгәч, милеккә карашның, базар мөнәсәбәтләренең үзгәрүе белән бәйле, икенче яктан, татар теленең дәүләт теле итеп рәсми белдерелүенә, рекламаның, кануннарыбыз таләп иткәнчә, татарча да таралырга тиешлегенә барып тоташа. Телебезнең хәтта Татарстанда үз позицияләрен югалтуы шунда ук реклама хезмәтенә дә үз эзен салды: татарча рекламалар бермә-бер кимеде, күп кенә төрләре юкка чыга башлады.

Рекламага бәйле аңлатмалар бихисап булса да, сатучылар һәм авторлар аны аңлату-аңлауда рәсми чыгарылган билгеләмәләргә таянырга тиеш. Дәүләт Думасы 2006 елны кабул иткән «Реклама турында»гы канунның (№ 38-ФЗ) 2018 елның соңгы редакциясендә:

«Реклама – теләсә нинди алым белән теләсә кайсы формада һәм һәртөрле чараларны кулланып таралган, тәгаенләштерелмәгән кешеләр төркеменә адресланган һәм рекламаланган объектка игътибар иттерүгә, аңа кызыксыну формалаштыруга яисә булган кызыксынуны күтәреп алуга, һәм аны базарда таратуга юнәлтелгән мәгълүмат», – диелгән[1].

[1] http://docs.cntd.ru; https://ipipip.ru/zakon-o-reklame/3/.

Безнеңчә, 1995 елның 18 июлендә 108 саны белән теркәлгән Федераль канун рекламаның эчтәлеген отышлырак ача иде кебек: «Реклама – төрле формаларда таралучы, төрле чаралар ярдәмендә физик, юридик затлар, товар, уй-фикер башлангычлары хакында мәгълүмат бирүче, юридик һәм физик затларның ихтыяҗларын канәгатьләндерүче, товар һәм уй башлангычын тормышка ашырырга ярдәм итүче массакүләм чара»[1].

Россиядә рекламачалык тарихы озын булса да, әлеге эшчәнлекнең теоретик өйрәнелүе һәм шул өлкә белгечләрен хәзерләү шактый соң башланды. Мөгаллим-галимнәребез, рекламага кагылышлы фәннәрнең нигезләрен эшләгәндә, дөньякүләм билгеле У. Уэллс, Дж. Бернет, С. Мориарти кебек галимнәрнең бу өлкәдәге казанышларына, үзебездәге шартлар кысасында формалашкан рекламаның эчке үсеш закончалыкларына таяна. Бу гасырга кергәч, әлеге өлкәдә бигрәк тә Петербург галимнәре активлашты[2].

Реклама товар байлыгы һәм аның турында мәгълүмат җиткерү материаллары, юллары үзгәрүгә бәйле рәвештә төрләнә бара. Соңгы елларда аның телен, структурасын, эшләнү принципларын чагылдырган, тәэсирлелеген, камиллеген җитештерүчеләр, шул исәптән редакторлар осталыгы белән бәйләгән хезмәтләр дә дөнья күрде[3].

Билгеле ки, филологларыбыз рекламага күбрәк тел ноктасыннан якын килә һәм, беренче чиратта, аның татарчаларын кимчелекләрдән арындыру турында кайгырта.

---

[1] vash-zakon.ru.

2 *Феофанов О.А.* Реклама: Новые технологии в России: учеб. пособие.– СПб.: Питер, 2000. – 377 с.; *Ученова В.В., Старых Н.В.* История рекламы. – СПб.: Питер, 2002. – 304 с.; *Сляднева О.В.* Очерки истории российской рекламы: учебное пособие: в 2 ч. Ч. 1. – СПб., 2001. – 138 с.

[3] *Шейнов В.П.* Эффективная реклама. Секреты успеха. – М.: Ось-89, 2003. – 448 с.; *Полукаров В.Л., Грановский Л.Г., Козин В.П., Лозовская В.Ю.* Телевизионная и радиовещательная реклама: учебное пособие. – М.: Дашков и К, 2004. – 388 с.

Студентларның фәнни тикшеренүләре милли рекламаның һәм төрки, һәм русча калыпларны куллануын ачты; кайбер рус рекламаларында да Төркиядә, Америкада һәм башка илләрдә таралган бу төр материалларның калькалары, тәрҗемәләре күплекне күрсәтте.

Татарча игъланнарның русчарак яңгырашында файдаланган өлгеләрнең роле чиксез зур. Казанда яисә башка шәһәрләрдә генә түгел, хәтта авыл җирләрендә дә эшмәкәрләребезнең хезмәт, бизнес биналарына куелган элмә такталарда, плакатларда телебезгә ят лексемалар очраштыра.

Узган гасырның соңгы чирегендә татар рекламасын тарихи үсеш-үзгәрештә, лингвистик һәм психологик һәм башка аспектларда өйрәнү ихтыяҗы туды, шул юнәлештә эш тә алып барыла башлады. Шунысы игътибарга лаек: КФУда редактор белгечлеген үзләштергән, журналист булырга хәзерләнгән студентлар билгеле бер күләмдә аны товар буларак та өйрәнә.

Татар реклама тарихына күзәтү өлешчә И.М. Низамов[1] хезмәтләрендә урын алган. Рекламаны беренчеләрдән булып өйрәнүче һәм аны редакцияләү тәртибе хакында да сүз алып баручы галим дә – И.М. Низамов. Алия Нигъмәтуллина Р.Ф. Харрасова ярдәмендә башкарылган чыгарылыш квалификациясе эшендә болай дип белдерә: «И.М. Низамов хезмәтләрендә татар реклама тарихын да, бүгенгесен дә ике тармакка бүлеп өйрәнүне кулай күрә: беренчесе – газета-журналга, радио-телевидениегә бәйләнмәгән реклама – товар ярлыклары, күргәзмә, афиша, игъланнар, проспект, каталог, альбомнар. Икенчесе – газета-журналга бәйле реклама»[2].

Хәзерге вакытта реклама күбрәк товарны популярлаштыру, аның хакында халыкта мәгълүмат булдыру

---

[1] *Низамов И.М.* Татар рекламы һәм матбугат. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1997.– 110 б.

[2] *Нигъмәтуллина А.* Татарча реклама теле // Диплом язучыга ярдәмгә: методик ярдәмлек.– Казань: РИЦ «Школа», 2007. – Б. 77.

вазифасын башкара. Советлар илендә сирәк очраган, товар әйләнешендә сизелерлек роль уйнамаган рекламаның, базар шартларына күчкәннән соң, эчтәлегендә, җиткерелү алымнарында, күләмендә, ешлыгында зур үзгәрешләр барлыкка килде. Аны иҗат итүче я булмаса шул типтагы материалны басмага хәзерләүче редактор боларның барысын да белеп торырга тиеш.

Реклама тормышыбызны уңайлатуны, ниндидер эшчәнлекне көчәйтеп җибәрүне күздә тоткан чара, шарт-сәбәп, мәгълүмат булса да, кулланучыга матди һәм әхлакый зыян да салырга мөмкин. Димәк, аны чыгаручы да, эчтәлеге өчен җаваплы редакция хезмәткәре дә үз өстенә теге яки бу дәрәҗәдә әхлакый җаваплылык ала.

Мөхәррир, рекламаның предметы товар (әйбер, хезмәт…) булганлыкны яхшы аңларга һәм текстында, бизәлешендә әлеге товарның сыйфатлары чагылганмы-юкмы икәнлекне күз уңыннан чыгарырга тиеш түгел. Аңа товар сәясәте дә үз таләпләрен куя. Әйтик, кибет киштәләре тәкъдим иткән әйберләр бер-берсеннән реализацияләнү-файдалану сроклары белән аерыла. Аларның киң – тар һәм даими – аз кулланыштагылары була. Товарларны сәнәгать яисә хуҗалык кирәк-яраклары кебек тә төркемлиләр, болары исә, үз чиратында, техника, инструмент, аш-су кирәк-яраклары, урын-җир предметлары... кебек төрләргә бүленә. Шулай ук товар саналган көнкүреш хезмәтенең җиһаз ремонтлау, химик чистарту, чәч ясау, аш-су хәзерләү һәм башка төрләре бар.

Тәгаен рекламаның тууы, таралуы, юкка чыгуы товар әйләнешендәге этапларга, пропагандаланган хезмәтнең, предметның билгелелек дәрәҗәсенә, аңа булган ихтыяҗ үзгәрешләренә барып тоташа. Тәүге тапкыр базарга чыгарылган товар хакында халыкка мөмкин кадәр тулырак мәгълүмат бирәләр. Товар киң таралыш алгач, аның үз ишләреннән нәрсә белән аерылып торганын, яңа маркаларындагы сыйфатларны – техник яссылыктагы һәм дизайнына

кертелгән үзгәрешләрне – сөйләргә тырышалар. Кайсыдыр әйбер, хезмәт сатылмый башлагач, белгечләр аның моңарчы кулланучыга билгеле булмаган мөмкинлекләрен ача, аңа үтә кирәклеген исбатлауны көчәйтә яисә, товарга бәя төшкәнне хәбәр итеп, сатып алуны кабат активлаштырырга омтыла.

Мөхәррир билгеле бер күләмдә акча – товар – реклама мөнәсәбәтләреннән хәбәрдар булырга тиеш. Әгәр ул игълан бирүченең табыш максатын күздән ычкындырса, киләчәктә ул эшләгән басманың кереме кимер, чөнки товар җитештерүче алга таба аның реклама тарату хезмәтен сатып алмас. Мөхәррир шуны да онытмый: кулланучыны җәлеп итү өчен кирәкле реклама башка төр язма, сөйләмә текстлардан эчтәлек, төзелеш, тел-стиль планында нык аерыла. Шунысы да бар: реклама хезмәте күрсәтүчеләрнең, үз эшләренә табыш чарасы сыйфатында якын килгәндә дә, продукцияләренең әхлакый кысалардан читкә чыкмавын кайгыртулары мөһим. Җәмгыять өчен зарарлы саналган күренешләрне пропагандалаган, кеше хокукларын бозган, милләтләргә карата тискәре мөнәсәбәт уяткан һәм башка төр «әхлаксыз» рекламалар өчен җинаять җаваплылыгы каралган. Димәк, әлеге җаваплылык редакторга да төшә.

Кызганыч ки, ана телебез дәүләти дип игълан ителгәннән соң да, «милли» рекламаның мәйданы үтә тар калды. Диварларда һәм транспортта очраган реклама, нигездә, русча, ә инде махсус «Игълан такталары»ндагылары күпчелек очракта Казанда узачак тамашалардан алхәбәр бирә. Рекламалардагы хаталар текстларның редактор күзеннән узмавын сөйли. Халыкның моңа битарафлыгы гомуми культурабызның түбәнлеген, телебезгә булган бүгенге мөнәсәбәтне күрсәтә.

Соңгы елларда рекламаның берьюлы инлизчә, татарча, русча таралганнары да очраштыра. Әйтик, «Бердәм Россия» Яшьләр гвардиясенең (МГЕР) «Иске Казан» проектына караган һәм, беренче чиратта, туристларга шәһәрдәге тарихи объектларны пропагандалауны, димәк, табыш алуны да күздә

тоткан плакатлары өч телдә эшләнгән. 2018 елда тукталышларга ябыштырылган «Мария кызлар гимназиясе» хакындагы игълан – шуның бер мисалы. Андагы татарча вариант белән танышыйк:

*Мариин хатын-кызлар гимназиясе*

*Мариин хатын-кызлар гимназиясе – Казанда кызлар өчен урта белем бирә торган беренче уку йорты. 1859 елда Мария Александровна императрицасы хөрмәтенә Мариин хатын-кызлар гимназиясе дип аталырга лаек була. Гимназия өчен бина Казан шәһәре управасы тарафыннан 1871 елда Александра II императорының Казанга килү йөзеннән алына. Гимназиядә мәҗбүри фәннәр укытыла: дини кагыйдәләр, рус теле, арифметика, география, тарих, кул эше. Моннан тыш теләк буенча рәсем ясау, җыр, бию, немец һәм француз телләрен өйрәнү булган.*

Күренә ки, тәрҗемәне күпсанлы кабатлаулар бик боза, аларны күпмедер киметергә кирәк. Бу эшне башкаргач, сүзләрне бер-берсенә яраштырырга, җөмлә кисәкләрен җөмләдә үзләре торырга тиешле урыннарга күчерергә, юкка чыккан гыйбарәләрне табарга тиешбез. Текстны аңламыйча тәрҗемә иткәнлек аркасында, императрицаның исеме Мариин рәвешендә калган, шунлыктан фамилиягә һәм ир кеше исеменә охшап тора. Александр Икенче исә патшабикәгә әверелгән. Дөресе шушылай булыр:

*Мария хатын-кызлар гимназиясе*

*Мария хатын-кызлар гимназиясе – Казанда кызларга урта белем биргән тәүге уку йорты. Ул 1859 елда патшабикә (императрица сүзен дә калдырырга мөмкин) Мария Александровна хөрмәтенә шулай аталган. Гимназия өчен бина Казан шәһәре управасы тарафыннан 1871 елда Россия патшасы Александр Икенче (вариант: император Александр II нең) Казанга килү йөзеннән (уңаеннан) алына. Гимназиядә дини кагыйдәләр, рус теле, арифметика, география, тарих, кул эшләре мәҗбүри*

*фән буларак укытылган. Алардан тыш, теләк буенча, рәсем, җыр, бию, немец һәм француз телләре өйрәтелгән.*

Мөхәррир грамматик яссылыктан караганда камил эшләнгән рекламадагы кайсы якларга игътибар итә соң? Беренчедән, ул андагы тойгылы җөмләләрнең, риторик сорау һәм мөрәҗәгатьләрнең укучыга нинди психологик тәэсир ясавын чамаларга тиеш. Татарча рекламаларда әлегә бозык, тупас яңгыраган сүзләр очрамау, гап-гади тормыш-көнкүреш кирәк-яракларын тәкъдим иткәндә кешенең интим тормышына кагылышлы күренешләрдән, предметлардан файдаланмау сөендерә. Дөрес, соңгы вакытта андый рекламалар русларда да кимүгә таба бара, алар бигрәк тә көндезге эфирлардан юкка чыгарылды, аракы һәм тәмәке ише товарларны пропагандалау да туктатылды.

Сыйфатсыз, тиешсез эчтәлектәге рекламалар күп ясала. Әйтик, ниндидер хушбуйны халыкка танытырга кирәк ди. Шуны сибенеп торучы шәрә хатын-кыз, сез, моны кулланмасагыз, сасып бетәчәксез, ди. Әлеге сүзләр тыңлаучыда ямьсез тойгы уята. Элеккерәк елларда хатын-кызларның гигиена әйберләрен шушы рәвешчә рекламалау бик киң таралган иде. Артистның шәрәлеге дә, әйткән сүзе дә товар турында мәгълүмат бирми югыйсә. Кулланучыга бигрәк тә товарның кайда сатылуыннан, бәясеннән, составыннан, функцияләреннән хәбәр кирәк.

Икенче гадәти күренеш – халыкны сертификатсыз продукцияне танылган шәхесләрдән мактатып алдау. Артистлар рекламалаган зыянлы, бернинди тикшерү узмаган дарулар аркасында, кешеләрнең хәтта үлү очраклары теркәлгән. Кайберәүләр, теге яки бу препаратларның ябыктыру һәм савыктыру мөмкинлекләренә ышанып, бурычка батканнар, матди кабалага төшкәннәр, әмма файдасын күрмәгәннәр. Шундый хәлләрдән соң кайбер танылган шәхесләр, вөҗдан намусы кичереп, үзләре дә хастаханәгә эләккән. Әлбәттә, товарны рекламалаучы аның сыйфатлары өчен җавап бирми,

әмма ул бигрәк тә медикаментларның сертификаты, бездә сатылуы рөхсәт ителгәнме, әллә тыелганмы икәнлеге белән кызыксынырга тиеш.

Халыктан акча җыючы пирамидалар тарихы бөтен илне шаулатты. Аларны пропагандалауга аеруча радио-телевидение, популяр артистлар зур өлеш кертте. Нәтиҗәдә, миллионлаган кулланучы алданды. Әлеге рекламалардан кабул итеп алучылар гына түгел, таратучылар да рухи зыян күрде. Яңа төр МММнар үрчүгә булышлык итмәс өчен, халыкка зыянлы эшләргә катнашудан, хокук нормалары белән тыелмаганда да, баш тартырга кирәк.

Хәзерге вакытта да пирамида рәвешендә акча туплаучы банклар яисә башка төр хезмәт оешмалары әле бер, әле икенче җирдә калкып чыга, әмма алар турында реклама инде Үзәк телевидение каналларыннан яңгырамый, рәсми газета битләрендә дә урын алмый диярлек. Җинаятьче төркемнәр, хокук органнары күзенә чалынмас өчен, үз эшләрен җирле пресса, аннан да бигрәк, интернет челтәре аша тәкъдим итүне хуп күрә. Кулланучыларны күпләп җәлеп итү максатыннан, «ялган реклама» компьютерларга үтеп кергән «вирус» ярдәмендә актив таратыла. Каләм ияләренең, редакторларның аңлы рәвештә аларны хәзерләүгә катнашуы бернинди этикет кысаларына сыймый.

Бүгенге радио-телевизион реклама гади халык сөйләме, көнкүреш лексикасы өстенлек иткән диалогларны киң куллану үзенчәлеге белән аерылып тора, чөнки бу алым кулланучыда ниндидер товарга яисә кайсыдыр оешмага ышаныч уятырга булыша. Икенче яктан, әлеге диалогларда еш күзәтелгән сөйләм хаталары халык теленә зыян сала, культуралы сөйләмне арткы плангарак күчерә.

Соңгы ике дистә елда татар рекламасының активлашып китүе аңа катгый таләпләр ноктасыннан якын килү ихтыяҗын тудыра. Кулланучы эфир һәм вакытлы матбугат хезмәткәрләреннән реклама текстларын татар теленең орфографик,

орфоэпик, лексик, грамматик һәм стилистик нормаларын исәпкә алып төзүләрен таләп итәргә тиеш. Россия Дәүләт советында, сессияләрдә рекламаны урнаштыруга, эчтәлегенә бәйле күп кенә кануннар тикшерелде, кабул ителде. Мисал рәвешендә, алда телгә алынган көндезге эфирда спиртлы эчемлекләрне, тәмәкене пропагандаламауны китерергә мөмкин. Төрле кануннар идеалда реклама әхлагының сагында тора дип саналса да, хәзергә бу төр продукциягә куелган таләпләр һәр очракта да үтәлми.

Татар рекламасының тормыштагы роле артканлыктан, аны төрле юнәлешләрдә фәнни нигездә тикшерүгә, башка яссылыкта анализлауга беренче адымнар ясалган инде. Редактор әлеге хезмәтләрдән таныш булырга, гомумән, татар матбугатындагы һәм эфирдагы рекламаларга үзе дә анализ ясый алырга тиеш.

Аерым бер җәмгыятьтә, аның институтларында, шул исәптән вакытлы матбугатта, реклама сәясәте башкаларныкыннан күпмедер аерылырга мөмкин. Ул кулланучыларның җитештерүчеләрнең психологик үзенчәлекләренә, илкүләм һәм илара сәясәткә, кабул ителгән канунияткә бәйле. Гавамны кулга төшерергә омтылган реклама халык аңына инде нык урнашты. Аның тиз арада базары да булдырылды, таралыш юллары да табылды. Төрле уку йортлары реклама белгечләрен җитәрлек санда тәрбияләде. Рекламаны гамәлгә куючы агентлыклар, фирмалар, бюролар, махсус нәшриятлар һәм матбугат чаралары оешты. Шул ук вакытта ул бүгенге көндә дә үсүен-үзгәрүен, үз кануннарын камилләштерүне дәвам итә. Дөрес, реклама белән шөгыльләнүчеләрнең – техник, әдәби, җаваплы редакторларның, предприятиеләрдәге коммерция директорларының; копирайторларның, маркетологларның, менеджерларның, агентларның һәм җәмгыять белән бәйләнеш өчен җаваплыларның – һөнәри осталыгы әле дә тиешле дәрәҗәдә түгел. Бигрәк тә очраклы кешеләр эшләгән татарча рекламаларга зәвыклылык, информативлык җитми.

Рекламаның ниндилеге, аны әзерләүчеләрнең гомуми һәм рухи культурасыннан тыш, аңа бирелгән акчага, зур хокукларга, идеяләргә ия булган продюсерларга, теле-радио хезмәткәрләренең бу төр продукциягә мөнәсәбәтенә, массакүләм мәгълүмат чараларының алга куйган мәсләкләренә дә бәйле.

Соңгы вакытта ныклы күзәтүгә таба ниндидер адымнар ясалса да, моңарчы интернет челтәрендә, башка чараларда чыккан реклама материаллары цензура аша уздырылмады. Бу дәрәҗәдәге ирекле лекнең уңай һәм тискәре яклары бар. Беренчедән, тыелган хезмәтләр, продукцияләр дә таратыла ала. Интернет аша наркотик тәкъдим иткән, саткан очраклар ачыклана килә. Порно-сайтлар эшләрен көннән-көн активлаштыра. Әлбәттә, нигезле тыелган күренешләрнең аудиториясе гаять киң булган интернет аша пропагандалануы җәмгыять иминлегенә куркыныч тудыра. Икенче яктан, реклама ярдәме белән, яшерелгән, дөрес мәгълүмат халыкка юл яра ала. Әйтик, ниндидер китапның эчтәлеге югары даирә кешеләренә ошамаска һәм хакимият башындагы фиркане өркетергә мөмкин. Аның хакындагы игълан масскакүләм чараларда дөнья күрсә, шуның нәтиҗәсендә күпләп сатылса, һичшиксез, халыкка якын идеяләр киң таралыш алачак.

Реклама аркылы җәмгыятебезгә, рухи яктан ныгымаган яшьләребезгә яисә үзаңы шактый түбән катламга янаган куркынычка бәйле рәвештә, шуны әйтик: аеруча шәхси сайтларда әхлаксыз тәкъдимнәр, инсанны түбәнәйткән рәсемнәр, теге яки бу күренешкә бәйле ялган мәгълүмат еш күренә. Махсус белеме булмаган реклама җитештерүчеләр исә үзләре эшләгән материалның сыйфатына игътибар итеп җиткерми. Димәк, киң катлам кулланучыларга товар хакында мәгълүмат бирүче реклама әхлагы – текст камиллеге, аның бигрәк тә яшь буынга рухи тәэсире, хакыйкатьне чагылдыруы турында бервакытта да онытмаска тиеш.

«Яман» рекламаның аеруча матди тормышы авыр катламнарга зыяны зур. Мәдәни учакларда ял итәргә акчасы

юклыктан, күп вакытын телевизор каршында уздырган халык, рекламадан ничек кенә сакланса да, 25 нче кадр эффекты, «яшерен реклама» барлыгын белсә дә, эфирдан ишетелгән сүз тәэсиренә бик еш бирешә: теге яки бу товарның юк сыйфатларына ышана, зур табыш вәгъдә иткән пирамидачылардан әлегәчә алдана. Бигрәк тә яңа заман «уеннары»ннан хәбәрсезләр, беркатлы һәм ялгыз яшәгән өлкәннәр үзләрендә психологик басым астында туган кыйммәтле яисә кирәксез товарны алу, нинди дә булса «отышлы башваткычлар»ны чишүгә катнашу теләгенә каршы тора алмый һәм матди кабалага төшә.

Рухи формалашып бетмәгән үсмерләр «әхлаксыз реклама»дан аеруча зыян күрә. Ул кирәксез, яман күренешләрнең чын асылын, яшерен максатын аңламый, тиешсез юлга баса. Кызлар һәм егетләр, илебездә үзен нәтиҗәле хезмәте, таланты, халык арасында һәм гаиләсендә тотышы белән таныткан кешеләрнең яшәү рәвешен өлге итәсе урынга, җәмгыять тарафыннан кире кагылган, тәнкыйтьләнгән һәм җәза бирү каралган эшләрне, «тискәре каһарманнар»ны үзенә үрнәк итә. Кайберәүләр, гаиләләренең авыр көн күрүенә дә карамастан, әти-әниләреннән беренчел ихтыяҗга карамаган кыйммәтле товарларны алдыра, шуңа ия булу өчен, караклык юлына баса, акча туплыйм дип, азартлы уеннарга керешә, кирәксез гамәлләргә тартыла.

Тискәре күренешләргә карап кына, базар икътисады шартларында реклама хезмәтеннән дә, рекламаның үзеннән дә баш тартып булмый. Юньле пропаганданың кешегә файда китерүен дә онытырга ярамый. Бу урында шуны ассызыкларга кирәк: иминлек хезмәткәрләре, кулланучыларны яклаучы җәмгыятьләр, педагоглар, ата-аналар, һәр аңлы инсан кешеләрне алдауга корылган, шәхесне түбәнәйткән рекламага каршы көрәшергә тиеш. Тормышыбызны җиңеләйтүне, тән-рухны сәламәтләндерүне, һәркемне афәт-хәсрәттән саклап калуны, ял иттерүне күздә тоткан игъланнар таратуны да бергәләп кайгыртырга кирәк. Реклама, аны җитеш-

теручеләр төрле өлкәләрдән тирән мәгълүматлы булганда, тәкъдим иткән товарларының сыйфатларын яхшы белгәндә, сөйләмнең ышандыру көченә таянганда, тамашачыны һәм укучыны әңгәмәдәш итеп тойганда гына, кеше аңына уза.

Кызык бер хәл: ачыктан-ачык рекламадан качкан кешеләр дә «яшерен рекламага»га капканын сизми калырга мөмкин, чөнки күпләр, игъланнар махсус рубрика эчендә бирелсә генә, материалның товарны яисә хезмәтне файдалануга чакыру максатыннан иҗат ителгәнлегенә төшенә. Вакытлы матбугат һәм реклама кагыйдәләре буенча, кемнеңдер табыш алуын күздә тоткан язмалар астында реклама икәнлек искәртелергә тиеш. Белгечләр моны үтиләр, әмма еш кына искәрмәләрне кеше укый алмаслык итеп язалар, астөшермәләр урынында гына бастыралар. Элегрәк товарда мәҗбүри торырга тиешле антирекламаларны да вак хәрефтән башкару гадәте бар иде, хәзер аңа каршы киң көрәш җәелдерелде. «Каршы» рекламага куелган стандартлардан чыгып һәм җитештерүчегә файдалы тәкъдимнәрнең кеше сәламәтлегенә зыянын белгәнгә, әйтик, тәмәке капларында аның зарарын сөйләүче текстны күзгә ташланырлык, укылырлык язу хакында карар кабул ителде.

Аеруча вакытлы матбугатта, әйтик, танылган шәхесләр белән әңгәмәләрдә, очеркларда, сәламәтлек хакындагы материалларда, реклама икәнлегенә искәрмә ясалмыйча, «сүз уңаеннан гына», товар, аны җитештерүче һәм таратучы, кемнеңдер хезмәте мактала. Рекламаның шул төре иң эффектлылардан санала. Шарлатан күрәзәчеләр, им-томчылар, сертификатсыз товар, файдасыз дарулар әлеге ысул белән үтә популярлаша.

Яшерен һәм зыянлы рекламага каршы көрәштә мөхәррир намусына бәйле хәрәкәт итә. Эшләгән редакциямә табыш китерәм һәм үз мәнфәгатьләремне кайгыртам дип, татар редакторы бигрәк тә милләтенең язмышы, мәдәни һәм икътисади хәле өчен җаваплыкны үз өстеннән төшерергә тиеш түгел.

Ил халкы көнкүрешендә реклама зур урын тота башлады. Бу җанланыш әлеге эшчәнлекнең катгый хокукый

нормаларын эшләүне таләп итә, һәм ул, товар кулланучылар өчен дә, аны җитештерүчеләр, таратучылар өчен дә кирәк. Рекламага кагылышлы мөһим карарларга, беренче чиратта, аны хокукыйкалаштырган халыкара актлар керә. Әлеге килешүләрдә кулланучы хокукларын алгы планга чыгарганнары[1], массакүләм мәгълүмат чараларындагы эшне җайга салганнары[2], журналист хокукларын кайгыртканнары[3] һ. б. төрләре бар. Реклама кануннары бездә «Россия Федерациясе Конституциясе», «Россия Федерациясенең мәгълүмати куркынычсызлыгы Доктринасы» кебек Гомумфедераль хокук актларындагы махсус матдәләргә нигезләнеп эшләнә.

Журналист хезмәтен корпорация эчендә көйләүне күздә тоткан халыкара документлар арасында «Журналист этикасының халыкара принциплары», Европа Советы Парламент ассамблеясы кабул иткән «Журналист әхлагы этикасы» резолюциясе һ.б. бар. Реклама эшчәнлегендә һәм үзебезнең[4],

---

[1] Акты ООН. Хартия прав человека: всеобщая декларация прав человека; Международный пакт о гражданских правах // Правовые и этические нормы в журналистике / сост. Е.П. Прохоров.– М.: Аспект Пресс, 2007. – С. 6–7.

[2] Акты Юнеско. Декларация об основных принципах, касающихся вклада средств массовой информации в укрепление мира и международного взаимопонимания, в развитие прав человека и борьбу против расизма и апартеида и подстрекательств к войне // Там же. – С. 7; Акты Совета Европы. Рекомендация Комитета Министров государств – членов Совета Европы № R (94)13 «О мерах обеспечения прозрачности средств массовой информации // Там же. – С. 11; Документы СНГ. Соглашение о сотрудничестве в области информации // Там же. – С. 24.

[3] Акты Совета Европы. Европейская конвенция о защите прав человека и основных свобод. Резолюция № 2 IV Европейской конференции министров по политике в области средств массовой коммуникации «Журналистские свободы и права человека» // Там же. – С. 8, 15.

[4] Кодекс профессиональной этики журналиста; Кодекс профессиональной этики российского журналиста; Хартия телерадиовещателей; Памятка журналиста телекомпании НТВ и т.д. // Там же. – С. 200–224.

һәм чит илләрнең[1] һөнәри-этик документлары нигез булып тора. Алар арасында Халыкара кодекс аеруча мөһим чыганак санала. Анда реклама эшчәнлеге кагыйдәләре, реклама культурасы һәм җаваплылыгы, реклама текстларындагы искәрмәләр, товар билгеләренә, исемнәренә карата нормалар чагылыш тапкан. Реклама хәзерләүгә тартылган мөхәррир аларның һәрберсеннән хәбәрдар булырга тиеш.

Мөхәррир үзе редакцияләгән текстның әйбер, хезмәт сыйфатламаларын төгәл, объектив, тулы чагылдыруын, ялган мәгълүмат бирмәвен, тәкъдим ителгән товарны башкасы белән бутатмавын, аның мөмкин булган чит яисә тискәре эффектлары хакында искәртүен кайгырта. Рекламада шәхесне яисә милләтне, аерым катламны, һөнәрне, динне мыскыллаган сүзләр, тәкъдим ителгән товарны кулланмаучыларны икенчел дәрәҗәдәге кешеләр итеп күрсәтү катгый тыела. Кызганычка каршы, бу норма бездә еш бозыла.

Башка халыклардагы кебек үк, татарларда да үз телләрендәге рекламага ихтыяҗ сәүдәгәрләр, эшмәкәрләр аерым социаль катлам булып формалашкач көчәя. Бездә бу XIX–XX гасырлар чигенә туры килә, ләкин XIX гасырның беренче яртысында ук ул сирәк булса да очраган һәм, нигездә, татар халкына, аның телен аңлаган башка азчылык милләтләргә, кан-кардәшләребезгә хезмәт иткән. Узган гасыр башы белдерүләренең калыплашуына, русча рекламалардан тыш, алманча, төрекчә һәм башка телләрдәге рекламалар шактый зур йогынты ясаган. Чит илдә эшләнгән товар игъланнары безнең мәдәни бәйләнешләребезне, икътисади-иҗтимагый үсеш дәрәҗәбезне ачык күрсәтеп тора.

Татар кешесенә товарны чит телдә тәкъдим итү, бер карагανда – әдәпсезлек. Башка халыклар кул астында яшәүче милләтләрдә, кызганыч ки, хаким кавем телендәге рекламалар

---

[1] Кодекс этики общества профессиональных журналистов США; Этический кодекс национальной ассоциации фоторепортеров США // Там же. – С. 175–184.

өстенлек итә, шунлыктан вакыт-вакыт татарча рекламаларның популярлашуы милли үзаң үсеше белән дә бәйле. Үзгәртеп кору елларында үз телебездәге рекламаның тагын бер кат активлашуы әлеге фикерне раслап тора.

Тәүге «милли» рекламалардан соң узган вакыт дәвамында текст яссылыгында камилләшә генә барырга тиешле игъланнар үзләренә куелган таләпләргә җавап бирми, базар алыш-бирешләренә хезмәт итү мөмкинлекләрен кулланып бетерми әле. Ана телебезнең яңадан гаилә эчендә генә яшәргә мәҗбүр ителүе шартларында, басма рекламага гына түгел, сөйләмә төрендәгесенә дә ихтыяҗ кими, бары тик сайлау алды кампанияләрендә генә ул милләтнең үзаңын югалтмаган өлешенә актив хезмәт итеп ала, дәүләт телен җиткерүче чара буларак, русча аралашучыларның да өенә мәҗбүри рәвештә китерелә. Бу да реклама кулланучыларның әхлакый сыйфатлары хакында сөйли.

Басмаханәләргә чит телдә китерелгән текстларны калькалаштырып тәрҗемә итү, хаталы текстлар сыйфатында халыкка ирештерү – бүгенге реклама хезмәте өчен табигый хәл. XX гасыр башында ук ана телендәге басма продукция ярдәмендә игълан тарату тәҗрибәсе шактый тупланугa карамастан, махсус белгечләр һаман да аннан тиешенчә файдаланмый, югыйсә милләтпәрвәр сәнәгатьчеләр барлыкка килгән, товар җитештерү һәм сатып алу көчәйгән заман камил, табыш китерүче татарча рекламаны бик популяр итәргә тиеш. Дөрес, кайбер мәгълүмат чараларыбыз, бигрәк тә рәсми характердагылары һәм күпләп таратылганнары, белдерүләргә тулы битләр бирә, әмма әлеге урынны сатып алучыларның шактые игъланнарының русча булуын таләп итә, ә табышны гына күздә тоткан редакция моның белән килешә. Кыскасы, хәтта реклама да милли журналистиканың түбәнгә тәгәрәве, телгә илтифатсызлык кебек күренешләр көзгесенә әверелде.

Массакүләм реклама совет чорында, нигездә, төрле урам игъланнары рәвешендә яши. Авыл, район җирләрендә

татарча дивар белдерүләре хәзер дә күпләп очрый, ике телдә язылган, әмма бер үк эчтәлектәге рекламалар да җитәрлек. Кайвакыт татарчалаштырылган игъланнар русча вариантларына адекват булмый. Аларның үзара тәңгәллек дәрәҗәсе реклама белгечләренең, текст өчен җаваплы кешеләрнең үз телләрен ни дәрәҗәдә белүенә бәйле һәм әлеге «осталар»ның нинди рухи кыйммәтләрне алга куюлары турында сөйли.

Рекламаның иҗтимагый төре сәяси, идеологик, дини һәм башка юнәлештә йогынты ясый, нәкъ менә шул сәбәпле аннан хакимият, сәяси партияләр бик оста файдалана. Бу төр рекламаларда әхлакый якка игътибар кими, «дошманнарга тап төшерерлек» сүзләр дә әйтелгәли. Мөхәррир реклама текстларында үзеңне башкаларны түбәнсетү бәрабәренә күтәрү күренешенә каршы торырга тиеш.

**Рекламаларны камилләштерү үзенчәлекләре.** Товар-хезмәт игъланнары мәгълүмат җиткерү юллары, урыннары, бизәлеш төре, мәйдан һәм таралыш вакыты, ешлыгы белән аерыла. Техник чаралар, технология, материал төрләре арта барган саен, реклама төрләре дә сан һәм сыйфат үзгәрешләре кичерә. Татарча рекламаларга, мәсәлән, телгә хөрмәт уяту максатыннан, милли мәдәният элементлары кертелә. Бүгенге көндә артистларыбыз катнашындагы реклама да – киң таралган күренеш. Төрле чараларны комплекслы кулланган заман рекламасы кыйммәтле хезмәт санала.

Бүгенге татар игъланнары барлык кабул ителгән нормаларны үтәүдән ерак тора. Мәсәлән, соңгы вакытта сөйләмә рекламага бәйле кайбер катгый таләпләр куелды. Шуның берсе тавышка карый: аның көче башка сөйләмнекеннән аерылып торырга, кискен күтәрелергә тиеш түгел. Бу таләп русча тапшыруларда да даими рәвештә бозыла.

Мөхәррирләр сөйләүчесе күренмәгән, бары тик аның тавышына гына нигезләнгән теле-радиорекламада җирлек итеп кенә сайланган көйнең әлеге тавышны басып китмәвен контрольгә ала. Ул махсус корымаларга беркетелгән,

диварларга урнаштырылган баннер, плакат рәвешендәге, панно эчендәге һәм башка төрле рекламаларның аз сүзле булырга, тексты җирлек өстендә ярылып ятарга тиешлеген онытмый.

Рекламаның бурычы – хәбәр ителә торган мәгълүматның кулланучыга тиз, тоткарлыксыз барып җитүенә ирешү, хисләренә һәм аңына тиешле дәрәҗәдә тәэсир итеп, сатып алу һәм куллану теләге уяту. Ачык мәгънәле сүзләр, яңгыравык гыйбарәләр, ышандыргыч дәлилләр; җөмлә конструкциясенә, гомум текстка хас логик-стилистик алымнар; кискен каршы куюлы, исбатлаулы, гомумиләштерүле, көтелмәгән нәтиҗә ясаулы, киң таралган яисә реклама кулланган фикерләрне раслаулы һәм кире кагулы җөмләләр кулланып, аларны отышлы сайланган рәсемнәр, сызымнар, бизәкләр белән баетып, теге яки бу фикерләрен ассызыклап, үзенчәлекле рекламалар иҗат итәргә мөмкин.

Искергән лексемаларны (архаизмнарны), яңа әйләнешкә кергән сүз-терминнарны, автор табышлары саналган неологизмнарны, күчерелмә мәгънәгә нигезләнеп ясалган эпитет, метафора, метонимия, чагыштыру кебек сурәт чараларын, аллитерация һәм башка аһәңлелек алымнарын кулланганда, мәкальәйтемнәрдән, канатлы гыйбарәләрдән файдаланганда, рекламаның аңлаешлы булырга тиешлеген, төп максаты, шаккатыру булмыйча, мәгълүмат бирү икәнлеген онытырга ярамый.

Татарча рекламаларны тәрҗемә аша эшләгәндә, теге яки бу предприятие исемен русча варианттагыча калдырыргамыюкмы, дигән сорау туа. Әгәр оешма үз исемен ике төрле рәсмиләштергән икән («Камилдә кунакта» – «В гостях у Камиля»), һичшиксез – кирәк, юк икән, татарчалаштыру («Пятёрочка», «Ашан», «Колорит», «Эдельвейс») – мәҗбүри түгел, кайвакыт хәтта ярамый да. Мәсәлән, Казанда «Кич» һәм «Вечер», «Дулкын» һәм «Волна» кафелары бар. Әгәр без аларның исемен тәрҗемә итәбез икән, хезмәтләрен кулланучы югалып калачак, рәсми документларда исә бөтенләй

буталчыклык китәчәк. Мөхәррир моны башка төр текстларны тикшергәндә дә онытмаска тиеш.

Аерым атамаларның тәрҗемә вариантлары табылмаска да мөмкин. Татар сүзләренең синонимик рәтендә ныгыган сүзләрне исә оригиналда калдыру дөресрәк дип санала. Җитәкчелекнең предприятие атамасын рекламада бер генә телдә куллануны таләп итүе дә мөмкин. Моңа, әйтик, сыйфатлы продукция чыгаручы фирманың аның күпсанлы кулланучыга билгеле исем астында гына таралуын теләве бар.

Татарча гына аталган товарлар да юк түгел. Аларның күбесе урынчылык исемнәре булып тора һәм теге яки бу төбәкне, шәһәр-авылны танытуга хезмәт итә. Кукмара бренды булган табаларның район исемен йөртүе әнә шуңа күрә табигый. Шул ук вакытта Татарстан телеканалларының Кукмара атамасындагы басымны соңгы иҗектән алдагысына күчерүләре гаҗәпкә калдыра. Ул ни татарча, ни русча яңгырамый булып чыга. Үзгәртеп кору елларында Россиядә инглизчә атамалар күбәеп киткән иде, соңгы вакытта бу күренешкә каршы көрәш үзен сиздерә башлады, әмма Татарстанда исем сайлау тәмам эшмәкәрләр ихтыярында кала сыман.

Текстта, теге яки бу төшенчәне ана телебездә биргәндә, укучы аңласын өчен, искәрмә ясарга, русча атамаларны янәшә, җәя эчләрендә кулланырга, аныклагычлардан файдаланырга туры килә. Бер телгә дә күчереп булмый торган исемнәр барлыгын яздык, ә бит төрле сүзләрдән кыскартылып ясалган, сүзтезмәләрнең баш хәрефләреннән оешкан атамаларны да һәрвакытта татарча бирү җиңел түгел. Җитмәсә, укучы да аларның русча вариантларын гына белергә мөмкин.

Аббревиатураның, оригиналда нинди принципка нигезләнсә, тәрҗемәсендә дә шулай ук юл белән ясалуына омтылырга кирәк. Бердәй атамаларның төрле телләрдәге кыскартылмалары бер үк төсле булырга тиеш. Әйтик, Институт языка, литературы и искусства – Тел, әдәбият һәм сәнгать

институтының аббревиатурада ИЯЛИ – ТӘһСИ дип бирелүе – зур кимчелек. Шунысын да әйтик: башка күп кенә халыкларның да аналогик институтларының атамалары русчадагы кебек кыскартылган. Википедиядә, башка күпсанлы сүзлекләрдә институт атамасы ТӘСИ рәвешендә бирелсә дә, кайбер галимнәр һәм мөхәррирләр, исемдә «һәм»нең дә барлыгын исәпкә алып, басма продукциядә аның ТӘһСИ формасында язылуын таләп итә, шул сәбәпле татарча басылган китапларда төрлелек күзәтелә. Атамада теркәгеч бернинди роль уйнамый, шунлыктан мәсьәләне аны русчататарча вариантларның икесеннән дә кыскарту юлы белән бик җиңел хәл итәргә мөмкин.

Реклама текстларында урынчылыкның татарча атамасын белмәү аркасында җибәрелгән хаталар очраштыра. Мәгълүмат тарату хезмәте белән шөгыльләнүчеләр, теге яки бу географик пунктның исемен язу өчен, бары тик белешмәлекләргә мөрәҗәгать итәргә тиеш, югыйсә Кукмара районындагы Күкшел (русчасы: Кошкино) авылында эшләнүче тәрәзә өлгеләрен, өслекләрен рекламалаганда, сатып алучыларны Песигә чакыруыгыз мөмкин. Татарча исемнәрне русчалаштырып, көлкегә калучылар да юк түгел. Мәсәлән, Бакалы районы Сасы күл авылында яшәгән үсмер шагыйрь Ләис Зөлкарнәйгә килгән бер хатның адресы Лягушкинский район деревня Вонючее озеро дип куелган була. Бу урында русча хәрефләр белән генә язылган тарихи географик атамаларның да үзгәртелүе, хәтта башка сүзгә алмаштырылуы турында үкенеч тойгылары белән әйтеп китәргә туры килә.

Тәрҗемәләрнең хаталы башкарылуы башкалабызны да бизәми, көндәлек тормышыбызда кыенлыклар тудыра. Кайчак теге яки бу белдерүдә Казан урамнарының татарча исемнәрен атыйлар, ә аңа ориентлашучы эзләгән сәүдә оешмасын таба алмыйча интегергә мөмкин. Мәсәлән, Киров районындагы йортларга «Ул. Борьбы – Көрәш ур.» дип язылган.

Белгәнебезчә, русча атама «Көрәш ур.» рәвешендә татарчалаштырылырга тиеш иде.

Белдерүләрдә «бик кирәкле», «искиткеч яхшы», «башкаларныкыннан сыйфатлырак», «теләсә кемгә файдалы», «очсыз бәһадән», «бәясе төшерелеп», «узган елгы бәядән» һәм башка шушы тип гыйбарәләр, сыйфатны аныклаучы сүзләр күп очрый. Мөхәррирнең аларны аныклагычлар янында дөрес куллану турында онытмавы кирәк.

Вакытлы матбугат битләре аша тәкъдим ителгән һәм, иясеннән тыш, редактор тарафыннан да камилләштерелгән сәүдә рекламаларында татар теленең орфографик, пунктуацион, стилистик хаталары чагыштырмача сирәк очрый. Район күләмендә яисә рус төбәкләрендә таратылучы газеталарда сәүдә рекламалары исә шактый хаталы, аларда рус алынмалары да ешрак кулланыла.

Рекламаны татарчалаштыру юлында күп эшлисебез бар. Бизәнү кирәк-яракларын рекламаучылар духи (хушбуй), одеколон (ислемай), помада (иннек), тень (сөрмә), тушь (керфек сөрмәсе), пудра (кершән), (крем – сыек кершән) һәм башка бик күп сүзләрнең татарчасын белмиләр, шунлыктан ялгыш татарчалаштыралар, язучыларның, мөхәррирләрнең кисәтүләренә игътибар итмиләр. Казанның Профсоюз урамында, мәсәлән, вакытлы матбугат аша белдерүгә, җитәкчелеккә ирештерүгә дә карамастан, хаталы баннерны еллар дәвамында көн саен урамга чыгардылар. Борынгы картиналарны җыюларын хәбәр иткән игъланда: «Искергән рәссамнарны сатып алалар», – дип язылган иде.

Югарыда саналган җитешсезлекләр кайвакыт сүзлекләребез камил башкарылмаудан да, сөйләмебездә төшенчәләрнең бик үк туры килмәгән мәгънәләр белән ныгуы аркасында да килеп чыга. Мәсәлән, больница – хастаханә, поликлиника – шифаханә яисә башкача булырга тиеш иде кебек. Аларның икесе дә бердәй – шифаханә дип тәрҗемә ителә. Татарлар, гадәттә, ятып авырган кешене – хаста, бик каты

чирләп киткәнне урын хастасы гыйбарәсе белән атыйлар. Димәк, больницаны хастаханә дип тәкъдим итүебез урынлы. Тирәннән уйлаганда, шифаханә, эчтәлеге белән, санаторийга ныграк та туры килә, ә поликлиниканы дәваханә дип атарга була. Курортларны шифаханә дип тәрҗемә итү очраштыра, аларны исә ялханә дип ачыклау отышлы.

Типик реклама үрнәкләрен карап узыйк һәм аларны камилләштерү юлларын да күрсәтеп барыйк. Бездә «Алгы приводлы б/у «Лада» машинасы сатып алам», – кебек белдерүләр еш очрый. Ассызыкланган гыйбарәне алгы тарту көчле, тотылган дип татарчалаштырырга мөмкин.

Кайбер тәрҗемәләр тузга язмаган төгәлсезлекләр белән шаккатыра. Әйтик, газеталар «предметы сложных конструкций»ны яисә «тончайшие изделия»не – «катмарлы төзелмәле предметлар» һәм «нечкә ясалган әйберләр» рәвешендә һәм башка хаталы вариантларда язалар. Казанның Киров районына караган Фрунзе урамындагы киемнәр кибетендә «панталон»ны – балаклы трусик; «брюки»ны – озын балаклы ыштан дип татарчалаштырганнар иде. Дөресе: катлаулы төзелешле, нәфис эшләнгән; ыштан, чалбар.

Көлке тәрҗемәләр белән көн дә очрашып торабыз. Шуларның бер урыны – кибет-киоск язулары. Аларда кайвакыт артык сүзләр куллану күзәтелә. Мәсәлән, камыр ризыгын «губадия с рисом» дигәннәрен күргән булды, ә бит гөбәдия дөгесез булмый. Балсыз, ит кушып пешерелгән гөбәдияләрне генә «итле гөбәдия» дип махсус ассызыкларга кирәк.

Игълан бирүче, чыгымнарны киметү максатыннан, мөмкин кадәр аз сүз куллануны үтенә, шунлыктан телетапшыру вакытында барган рекламаларда кайвакыт аңлашылмаучылык барлыкка килә. Мәсәлән: «Буяучылар, төзүчеләр бригадасы. Тел.: /…/». Китерелгән рекламадан хезмәт күрсәтү тәкъдим ителәме, әллә аталган һөнәр ияләрен эзлиләрме – аңлашылмый.

Кайбер газеталар күпсанлы сәүдә рекламаларын берләштергән махсус рубрикаларга урын бирә. Мөхәррир аларда мәгълүматны мөмкин кадәр аз, әмма аңлау өчен кирәкле күләмдәге сүз аша бирүне кайгыртырга тиеш. Бер мисал: *Түбән Кама каласында яшәп торырга бүлмә яки фатир эзлим. Спиртлы эчемлекләр, тәмәке бөтенләй кулланмыйм. Тел. /.../* Текстны түбәндәгечә кыскартсак, мәгънә эчтәлегенә һич кенә дә зыян килмәс: *Түбән Камада бүлмә яки фатир эзлим. Эчмим, тартмыйм. Тел.: /.../* Кыскартуларны тагын да дәвам итәргә мөмкин. Бүлмә һәм фатир сүзләрен бер сүз ярдәмендә торак дип атарга була. Фатир иясен кызыксындыру өчен китерелгән икенче җөмләдәге мәгълүмат шулай ук артык. Хуҗалар, гадәттә, андый информациягә ышанмый, йортка төшүченең яман гадәтләрдән азат булуын теләсә, үзара килешү вакытында аңа катгый таләпләр куя.

Соңгы вакытта товар рекламаларынннан чирәп (черепица), күмәртәләп (күпләп, опт), борыс (брус) кебек һәркемгә аңлаешлы сүзләр бөтенләй төшеп калды, алар урынына рус сүзләре языла башлады яисә актив кулланышта булмаган лексемалар «яңача» татарчалаштырылды. Бигрәк тә шәхси газеталар сүз уйлап табу белән артык мавыгып киттеләр.

Хезмәт күрсәтү рекламаларында иң еш очрый торган хата кеше исемнәренең язылышына карый. Әйтик, танылган җырчыбызның исеме Хания Фәрхи булырга тиеш, чөнки әлеге исем хан сүзеннән ясалган. Рамил, Фаил һәм башка сүзләрдән соң нечкәлек билгесе куелмый, чөнки, татарча укыганда, аларның соңгы иҗеге болай да нечкә әйтелә. Шушы төр тәнкыйть сүзләрен Миңнегулов (Миңнеголдан ясалган), Тәлгат (дөресе: Тәлгать) һәм башка исем-фамилияләргә карата да әйтергә мөмкин.

Рекламаның заман төрләрендә, бигрәк тә интерактив формаларда хаталар тагын да ешрак очрый. Соңгысы – кәрәзле телефон яки электрон почта, интернет челтәре аша кирәкле товар яисә хезмәткә заказ алуны күздә тота. Аларның татарча

вариантлары чагыштырмача сирәк күзәтелә, һәм бу төр белдерүләрне юллау, кабул итүләр аерым катлаулар арасында гына бара. Әйтик, мөселманнар, милли яшьләр, төркиләр һәм башка тар даирә эчендә күзәтелә. Товарны ана телебездә тәкъдим итүче интерактив игъланнар әлегә авыл җирендә актив кулланылышта.

Гомумән алганда, рекламаны камилләштерүче редактор үз эшендә аның хәбәр итү, мәгълүмат бирү, тәэсир итү, йогынты ясау кебек вазифаларын һәм сайланган стиль үзенчәлеген (поэтик, публицистик, фәнни, функциональ...) истә тотарга тиеш. Ул язган яисә төзәткән текстлар, һичшиксез, башка төр сөйләмнән эчтәлеге, төзелеше, тел берәмлекләрен куллану ягыннан аерылып тора. Мөхәррир шул ук вакытта рекламаны редакцияләүгә сөйләм төзәтүнең күпсанлы яссылыкларыннан якын килә: аны орфографик, орфоэпик, лексик, грамматик һәм стилистик нормаларга сала. Рекламаны тәртипкә китергәндә, ул шулай ук тәкъдим ителгән хезмәтнең яисә товарның төгәл билгеләнгәнлегенә игътибар итә, текстларның кыска, ачык аңлаешлы булуына омтыла.

Редактор кайвакыт бер биттә әллә ничә рекламаны эшкәртә. Ул бу вакытта аларны грамматик яктан охшашрак калыпларга сала, кайсыдыр тәкъдимнамәгә эмоциональ планда үзгәрешләр кертә, тематик төркемли. Әгәр бер рекламада әллә ничә товар турында мәгълүмат бирелсә, алар өчен отышлы эзлеклелек таба. Әйтик, анда мәктәп кирәк-яраклары саналган канцелярия товарлары, дәреслекләр, кием-салым турында сүз бара ди. Бу очракта сүзне зуррак һәм мөһимрәк товар булган укучы формасыннан, дәреслекләрдән башласак яхшырак. Алга таба без мәктәп букчасы, төрле фәннәр буенча китаплар, язу әсбаплары тәкъдим итә алабыз. Ниндидер әйберне һәм аның детальләрен рекламалаганда да, предмет исеме алдан аталырга тиешле. Әлеге эзлеклелек кайвакыт график формада да күрсәтелә.

**Хөрмәтле укучыларым!**

Күләм ягыннан чикләнгән уку әсбабында редакцияләүнең барлык яклары, нечкәлекләре хакында тәфсилле сөйләү мөмкин түгел. Без аны максат та итмәдек. Хезмәт, сезнең барлык сорауларыгызга җавап бирмәсә дә, текстларны камилләштерү юлында беренче адымнар ясаганда, ниндидер таяныч була алыр.

Мөхәррирлек маһирлыгына каләм осталарының иҗаты белән танышу, үз язу күнекмәләреңне дә камилләштерү, даими рәвештә төрле тип текстлар белән эшләү, чит кешеләр язган хезмәтләрне һәрьяклы анализлау, уңышлы һәм уңышсыз якларын билгеләү, аларда очраган хаталарны барлау, сәбәпләрен ачыклау, төзәтүнең уңышлы юлларын табу ярдәмендә генә ирешеп була. Редакторлар башкалар язган текстларны камилләштергәндә үз стильләренә хас кытыршылыклардан да арына бара. Әдәби редакцияләү хезмәте мөхәрриргә гасырлар дәвамында чарланган ана телебезнең нәфисләгән, камиллеген аңларга һәм башка кешеләргә дә аңлатып бирергә булыша.

# ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

## Дисциплина таләп иткән мәҗбүри әдәбият

*Рус телендә*


*Голуб И.Б.* Конспект лекций по литературному редактированию. 2-е изд., испр. и доп. – М., 2017.

*Накорякова К.М.* Литературное редактирование. Общая методика работы над текстом. – М.: Изд-во МГУ, 2011.

Редакторская подготовка изданий / под общей редакцией доктора филол. наук, проф. С.Г. Антоновой. – М.: Логос, 2004.

Стилистика и литературное редактирование: в 2 т. Т. 1: учебник для академического бакалавриата / под ред. Л. Р. Дускаевой. – М., 2016.

*Зуева Т.А., Иванова Е.Н.* Практикум по литературному редактированию: учебное пособие. – Екатеринбург: ФГБОУ ВПО «УрГПУ», 2015.


*Татар телендә*


*Вәлиев М.Х.* Милли нәшрият һәм китап редакторы: югары уку йортлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2006.

*Низамов И.М.* Татарча әдәби редакцияләү: югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Казан (Идел буе) федераль университеты нәшрияты, 2012.

*Харрасова Р.Ф.* Әдәби редакцияләү: махсус дисциплина программасы. – Казан., 2007.


## Өстәмә әдәбият

*Рус телендә*


*Алисов Г.* Мусульманский вопрос в Росии // Русская мысль. – 1909. – № 7.

*Базанова А.Е.* Литературное редактирование: учеб. пособие. – Ч. 1. – М.: Изд-во РУДН, 2006. – 105 с.

*Бакиров М.Х.* Закономерности тюркского и татарского стихосложения в свете экспериментальных исследований: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1971.

*Богомолов Н.А.* Основы теории стиха. Краткое введение в стиховедение. М.: МГУ, 2004.

*Былинский К.И.* Литературное редактирование газеты. – М., 1953.

*Валгина Н.С.* Теория текста. – М.: Логос, 2003.

*Виноградов В.В.* О языке художественной литературы. – М., 1959.

*Виноградов В.В.* Проблема авторства и теория стилей. – М., 1961.

*Виноградов В.В.* Стилистика. Теория поэтической речи. Поэтика. – М., 1963.

*Виноградов В.В.* О теории художественной речи. – М., 1971.

*Виноградов В.В.* Проблемы русской стилистики. – М., 1981.

*Воскобойников Я.С., Юрьев В.К.* Журналист и информация: Профессиональный опыт западной прессы. – М., 1993.

*Вьюкова Н.Б.* 85 радостей и огорчений: Размышления редактора. – М., 1986.

*Галахов А.Д., Буслаев Ф.И.* Конспект русского языка и словестности для руковдства в военно-учебных заведениях, составленный А. Галаховым и Ф. Буслаевым на основании наставления для образования воспитанников военно-учебных заведений, высочайше утвержденного 24 декабря 1848 года. – СПб., 1852.

*Гаспаров М.Л.* Очерк истории русского стиха. – М.: Фортуна Лимитед, 2000.

*Горбачевский М.В., Караулов Ю.Н., Шаклеин В.М.* Не говори шершавым языком: О нарушениях норм литературной речи в электронных и печатных СМИ / под ред. Ю.А. Бельчикова. 2-е изд., испр. и доп. – М., 2000.

*Гессе Г.* Магия книги. – М.: Книга, 1990.

*Добросклонская Т.Г.* Вопросы изучения медиатекстов. – М., 2000.

*Дунаевская О.В.* Современная деловая речь. – М., 1987.

*Жирмункий В.* Рифма, ее история и теория. – Петроград: Академия, 1923.

*Замалиев А.М.* Татарское стихосложение: типологические и национальные особенности: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2011.

*Западов А.В.* От рукописи к печатной странице. – М., 1979.

*Зарва М.В.* Некоторые особенности языка радио как вида массовой коммуникации // Язык и стиль средств массовой информации и пропаганды. Печать, радио, телевидение, документальное кино / под ред. Д.Э. Розенталя. – М., 1980.

*Инджиев А.А.* Универсальный справочник начинающего журналиста. – Ростов н/Д.: Феникс, 2007.

*Каримуллин А.* Татарская книга пореформенной России. Исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983.

*Кожевникова К.* Формирование содержания и синтаксис художественного текста // Синтаксис и стилистика. – М., 1976.

*Кожина М.Н.* О речевой системности научного стиля сравнительно с некоторыми другими. – Пермь, 1972.

*Кожина М.Н.* О специфике художественной и научной речи в аспекте функциональной стилистики. – Пермь, 1966.

*Кожина М.Н.* Стилистика русского языка. 3-е изд. – М., 1993.

*Комиссаров В.Н.* Проблема определения антонима // Вопросы языкознания. – 1957. – № 4.

*Костомаров В.Г.* Русский язык на газетной полосе. Некоторые особенности языка современной газетной публицистики. – М., 1971.

*Костомаров В.Г.* Языковой вкус эпохи. Из наблюдений над речевой практикой массмедиа. – СПб., 1999.

*Кохтев Н.Н.* Стилистика рекламы. – М., 1981.

*Курбатов Х.Р.* Ритмика татарского стиха. – Казань: Алма-Лит, 2005.

*Ларин М.В., Сокова А.Н.* Оформление служебных документов: Рекомендации на основе ГОСТ Р 6.30.-2003. – 2-е изд. – М.: МЦФЭР, 2006.

*Лариохина Н.М.* Вопросы синтаксиса научного стиля речи (Анализ некоторых структур простого предложения). – М., 1979.

Лексические минимумы русского языка. – М., 1972.

*Леонтьев А.А., Базылев В.Н., Бельчиков Ю.А., Сорокин Ю.А.* Понятия чести и достоинства, оскорбления и ненормативности в текстах права и средств массовой информации. – М., 1997. Гл. 4.

Литературное редактирование: курс лекций / Н.С. Валгина, А.В. Барандеев, И.Б. Голуб и др.; под ред. Н. С. Валгиной. – М.: Изд-во МПИ, 1989.

*Лихачёв Д.С.* Первые семьсот лет русской литературы // Изборник: Сборник произведений литературы Древней Руси. – М., 1969.

*Лотман Ю.М.* Структура художественного текста. – М., 1970.

*Лотман Ю.М.* Анализ поэтического текста. – М., 1972.

*Матвеева Т.В.* Лексическая экспрессивность в языке. – Свердловск, 1986.

*Мильчин А.Э.* Издательский словарь-справочник. – М., 1998.

*Мильчин А.Э.* Методика редактирования текста. – М., 1980.

*Мильчин А.Э.* Памятная книга редактора. – М., 1988.

*Митрофанова О.Д.* Язык научно-технической литературы. – М., 1973.

*Михальская А.К.* Основы риторики: Мысль и слово. – М., 1996.

*Михальская А.К.* Русский Сократ: Лекции по сравнительно-исторической риторике. – М., 1996.

*Морозова И.* Слагая слоганы. – М., 1998.

*Мучник Б.С.* Человек и текст. – М., 1985.

*Накорякова К.М.* Редактирование материалов массовой информации. – М., 1994.

*Накорякова К.М.* Редакторское мастерство в России XVI–XIX вв. – М., 1973.

*Накорякова К.М.* Очерки истории редактирования в России XVI–XIX вв. – М.: Изд-во «ВК», 2004.

*Нечаева О.А.* Типы речи и работа над ними в школе. – Красноярск, 1989.

*Никитина Е.И.* Русская речь. – М., 1996.

*Одинцов В.В.* Стилистика текста. – М.: Наука, 1980.

Основные стандарты по издательскому делу / сост.: А.А. Джиго, С.Ю. Калинин. – М.: Университетская книга, 2009.

Основные стандарты по издательскому делу: дополнено двумя новыми стандартами / сост.: А.А. Джиго, С.Ю. Калинин. – М.: Университетская книга, 2010.

Правовые и этические нормы в журналистике / составитель: Е.П. Прохоров. – М.: Аспект Пресс, 2007.

Практическая стилистика русского языка. Функциональные стили / под ред. Б.А. Алексеева, К.А. Роговой. – М., 1982.

*Рамеев З.З.* Текстология татарской литературы начала XX века. – Казань: Алма-Лит, 2008.

*Рахманин Л.В.* Стилистика деловой речи и редактирование служебных документов. М., 1973.

*Рейман Е.А.* О значении слов в текстах разных функциональных стилей // Стиль научной речи. – М., 1978.

Редактирование отдельных видов литературы / под ред. Н.М. Сикорского. – М., 1987.

Редакторская подготовка издания: учебник / под ред. С.Г. Антоновой. – М., 2004.

*Рисе О.В.* Беседы о мастерстве корректора. – М., 1959.

*Рисе О.В.* Семь раз проверь: опыт путеводителя по опечаткам и ошибкам в тексте. – М.. 1977.

*Рождественская К.В.* За круглым столом: записки редактора. – М., 1962.

Русско-татарский словарь / Э.М. Ахунзянов, Р.С. Газизов, Ф.А. Ганиев и др.; под ред. Ганиева. – М.: Рус. яз., 1986.

*Сафиуллина Ф.С.* Порядок слов в современном татарском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. – Казань, 1966.

*Сафиуллина Ф.С.* Синтаксис татарской разговорной речи. – Казань, 1978.

*Светана С.В.* Телевизионная речь // Язык и стиль средств массовой информации и пропаганды / под ред. Д.Э. Розенталя. – М., 1980.

*Свинцов В.И.* Логика. – М., J987.

*Свинцов В.И.* Смысловой анализ и обработка текста. – М., 1979.

*Сенкевич М.П.* Культура радио- и телевизионной речи. – М., 1997.

*Сенкевич М.П.* Стилистика научной речи и редактирование научных произведений. – М., 1984.

Система обучения сочинениям на уроках русского языка (IV – VIII классы): пособие для учителей / под ред. Т.А. Ладыжской. – М., 1978.

*Солганик Г.Я.* Лексика газеты. – М., 1981.

*Солганик Г.Я.* Стилистика текста. – М., 1997.

Справочная книга редактора и корректора. – М., 1985.

Основные стандарты по издательскому делу: сборник / сост. А.А. Джиго, С. Ю. Калинин. – М.: Университетская книга, 2009.

Стандарты по издательскому делу. – М.: Юристъ, 1998.

Стилистика и литературное редактирование / под ред. проф. В.И. Максимова. – М.: Гардарики, 2004.

Стилистика и литературное редактирование: учебник / под ред. проф В.И. Максимова. –3-е изд., перераб и доп. – М.: Гардарики, 2007.

*Феллер М.Д.* Эффективность сообщения и литературный аспект редактирования. – Львов, 1978.

*Феллер М.Д.* Структура произведения. – М., 1981.

*Формановская Н.И.* Речевой этикет и культура общения. – М., 1989.

*Челпанов Г.И.* Учебник логики. Построение определения подчиняется правилам . – М.: 2000.

*Чуковская Л.К.* В лаборатории редактора. – М., 1960.

*Шалаева Г.П., Ситникова Е.В, Студеникина Л.Г., Лебедев П.В.* Словарь рифм русского языка. – М.: АСТ, 2009.

*Юсупов М.Х.* Галимджан Баруди. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2003.

Язык и стиль средств массовой информации и пропаганды. Печать, радио, телевидение, документальное кино / под ред. Д.Э. Розенталя. – М., 1980.

*Татар телендә*

Әдәби суд // Идел. – 2018. – № 4.

Әдәбият белеме сүзлеге / төз.-ред. А.Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

*Бәширов Г.* Бүген дә, иртәгә дә. – Казан, 1974.

*Госман Х.* Татар шигыре. Казан: Татар. кит. ншр., 1964.

*Зәбиров Г.* Максуд баба һәм Максудилар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.

*Ибраһимов С.М., Сафиуллина Ф.С.* Практик стилистика: укучыларга ярдәмлек. – Казан, 1978.

*Курбатов Х.* Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре. – Казан, 1956.

*Курбатов Х.* Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. – Казан: 1971.

*Низамов И.М.* Ярдәмең берлән синең…– Казан: Мәгариф, 2008.

*Низамов И.М.* Татар социолингвистикасы. – Казан ун-ты нәшр., 2006.

*Поварисов С.* Тел – күңелнең көзгесе. – Казан, 1982.

*Рамазанов Ш.* Татар теле буенча очерклар. – Казан, 1952.

*Сафиуллина Ф.С.* Текст төзелеше. – Казан, 1991.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар телендә сүз тәртибе. – Казан, 1974.

*Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З.* Хәзерге татар әдәби теле: югары һәм урта уку йортлары өчен дәреслек. – 3 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2006.

*Сәгыйров Г.* Үзе турында һәм барысы да аның турында. – Самара: Медиа-Книга, 2015.

Татар лексикологиясе: өч томда. 1 т. / проект җит.: М.З. Зәкиев; ред.: Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2015.

Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. 1 т. / редкол.: Ш.Ш. Абилов, Н.Ш. Хисамов, Х.Ю. Миңнегулов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда. 1 т. / ред.: Л.Т. Мәхмүтова, М.Г. Мөхәммәдиев, К.С. Сабиров, Ш.С. Ханбикова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

*Хаков В.Х.* Татар теле стилистикасына кереш. – Казан, 1963.

*Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С.* Синонимнар сүзлеге. – Казан: Хәтер, 1999.

*Хөсни Ф.* Ни әйтергә, ничек әйтергә? – Казан, 1965.

*Юсупов Р.* Тәрҗемә һәм тел культурасы. – Казан, 1978.

**Электрон чыганаклар һәм алардан алынган материаллар**

БСЭ. Третье издание. – М.: Советская энциклопедия. – 1969–1978 // http://www.rubricon.com.

БСЭ. М.: Большая Советская Энциклопедия, 1997. OCR Палек // twirpx.com.

Тренд // Википедия // ru.wikipedia.org.

Законы пионеров Советского Союза // stydopedia.

Подари мне чудо // https: // litnet.com.

ЭЧТӘЛЕК

**КЕРЕШ** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Беренче бүлек. **ӘДӘБИ РЕДАКЦИЯЛӘҮ ПРЕДМЕТЫ** . . . . . 6
Фәнни дисциплина идеясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 6
«Әдәби редакцияләү» фәненең дөньяга килүе һәм үсеше . . . 13
Русча текстларны әдәби редакцияләү тарихыннан . . . . . . . 17
Татар текстларын әдәби редакцияләү тарихыннан . . . . . . . 25
Әдәби редакцияләү предметы, максаты һәм бурычлары . . . . 34
Әдәби редакцияләү терминына карата . . . . . . . . . . . . . 36
Икенче бүлек. **ӘДӘБИ РЕДАКЦИЯЛӘҮ – НӘШРИЯТ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ БЕР АСПЕКТЫ** . . . . . . 40
Мөхәррирлекнең коммуникатив эшчәнлек буларак проблемалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Мөхәррир һәм кульязма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Кульязманың төп сыйфатларын ачыклау . . . . . . . . . . . . . 46
Басманың тибын билгеләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Редакторлык эшендә дәүләт стандартлары . . . . . . . . . . . 52
Редактор һәм автор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Редактор һәм укучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Редактор һәм корректор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Редактор хезмәтендә яңа технологияләр . . . . . . . . . . . . 71
Өченче бүлек. **ӘДӘБИ РЕДАКЦИЯЛӘҮНЕҢ ГОМУМИ ТӘРТИБЕ** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Текстны анализлау һәм төзәтү схемасы, методикасы . . . . . . 78
Әсәр композициясенә бәйле эш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Атама сайлау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Сөйләмнең функциональ-мәгънәви типлары, аларны текстта камилләштерү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118

Логика кануннарын үтәү . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Текстка стилистик якын килү . . . . . . . . . . . . . . . 182
Сөйләмгә традициялелек һәм чит телләр тәэсире . . . . . . 198
Аһәң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Лексик катлам белән эш . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Текст фонетикасын камилләштерү . . . . . . . . . . . . 222
Фактлар белән эш тәртибе . . . . . . . . . . . . . . . . 225
Текст корректурасы (төзәтмәләре) . . . . . . . . . . . . 227

Дүртенче бүлек. **ХЕЗМӘТЛӘРНЕ БАСМАГА ХӘЗЕРЛӘҮНЕҢ ТӨРГӘ БӘЙЛЕ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 230

Тәрҗемә әдәбиятка редактор күзлегеннән якын килү . . . . . 230
Икенчел басмаларны әдәби эшкәртү . . . . . . . . . . . . 247
Радио-телевидение хезмәткәрләренең сөйләме, эфир текстларын эшләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Фәнни хезмәтләрне басмага хәзерләү . . . . . . . . . . . 261
Белешмә әдәбиятка, сүзлекләргә куелган таләпләр . . . . . . 267
Белем бирү басмаларын редакцияләү . . . . . . . . . . . 273
Матур әдәбият һәм мөхәррир хезмәте . . . . . . . . . . . 277
Реклама һәм аңа куелган таләпләр . . . . . . . . . . . . 283
Рекламаларны камилләштерү үзенчәлекләре . . . . . . . . . 299

**ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ** . . . . . . . . . . . . . . . . . . 308

Учебное пособие

**Харрасова Рифа Фатхрахмановна**

**ЛИТЕРАТУРНОЕ РЕДАКТИРОВАНИЕ**

(на татарском языке)

Редактор *Л.Г. Шарифуллина*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 18,4. Уч.-изд. л. 13,4. Тираж 200 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12